ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2007



# Дөнья инди сабантуйлар



Германия



Чехия



Әзербайҗан



Латвия



Литва



Татарстан

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

7

(1017)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча
Татарстан Республикасы агентлыгы
һәм Татарстан Республикасының
Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөсният**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
: **Факс**—(843) 541-38-77.
: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рашат НИЗАМИ. Кыяк ярган үлән генә—өр яңа. *Шигырьләр.* ........ 5
Камил КӘРИМОВ. Уен. *Роман.* ........ 11
Әнәс ХӘСӘНОВ. Әхлакый нур калдырсаң. *Шигырьләр.* ........ 64
Нәҗибә САФИНА. Сабый җаның—тагын бишегендә. *Шигырьләр.* ........ 83
Шәукәт ГАДЕЛША. Туган ягым—Себер уе. *Шигырьләр.* ........ 98
Ләйсән КӘШФИ. Ак хисләрем—җырлар канатында. *Шигырьләр.* ........ 101

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Рәдиф СӘГЪДИ. Бакчасарай гөлләре. *Ике пәрдәле мелодрама.* ........ 67

**ХИКӘЯЛӘР КОНКУРСЫНА**

Фәрит ЯХИН. Чишелмәс төен. *Хикәя.* ........ 87

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Яңа юллар бәхете. ........ 103

**ФӘН**

Гөлзада ӘХТӘМОВА. Борынгы Алабуга. ........ 118
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 171
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 174

**ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Татарга нигә кагыйдә? ........ 132

**ХӘТЕР**

Альберт Фәтхи турында истәлекләр. ........ 146

**ГАЛИМҖАН НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ**

Әдип. Галим. Мөхәррир. ........ 163

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Шахматтагы ике ат һәм һәйкәл Салават. Җиде юл чатында. . 165

**АК ҖИЛКӘН**

Алия ГАБДЕЛХАКОВА. Тарту көче. *Хикәя.* ........ 178
Безнең календарь. ........ 185
«Казан утлары» архивыннан. ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман К. КАРИМОВА «Игра» (окончание), рассказ Ф. ЯХИНА «Не развязанный узел»; стихи Р. НИЗАМИ, А. ХАСАНОВА, Н. САФИНОЙ, Ш. ГАДЕЛЬШЫ, Л. КАШФИЕВОЙ.
«Драматургия»: мелодрама Р. САГДИ «Цветы Бакчисарая».
«Литературная критика»: статья Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ о творчестве Ф. Сафина.
«Наука»: Г. АХТЯМОВА. «Древняя Елабуга»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень (продолжение); статья А. ТИМЕРГАЛИНА «Что нам делать с орфографией?».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: воспоминания о А. Фатхи.
Статья к 110 летию Г. Нигъмати.
«Рассказы из жизни»: З. ЗАЙНУЛЛИН. «Скульптор Сослан бек», «На перепутье».
«Белый парус»: рассказ А. АБДУЛХАКОВОЙ «Сила притяжения» (окончание).
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Летний пейзаж»; писатель Анас ХАСАНОВ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

Prose and poetry: novel by K. KARIMOV "Games" (termination), story by F. YAHIN "Tied knot; verses by R. NIZAMI, A. HASANOV, N. SAFINA, SH. GADELSHY, L. KASHFIEVA.
Dramatic art: melodrama by R. SAGDI "Bakhchisaray flowers".
Literary critics: article by D. ZAGIDULLINA about creativity of F. Safin.
Science: G. AHTYAMOVA. Ancient Elabuga; F. GARIPOVA. History of our villages (continuation); article by A. TIMERGALIN "What to do with spelling?"
Pages from Tatar encyclopedia.
Memory: memoirs about A. Fathi.
To 110th anniversary of G. Nigmati.
Stories from life: Z. ZAYNULLIN. Sculptor Soslan bek, At the crossroads.
White sail: story by A. ABDULHAKOVA "Attraction force" (termination).
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Summer landscape; writer Anas HASANOV.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.06.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–760 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.



Рашат
Низами

# КЫЯК ЯРГАН ҮЛӘН ГЕНӘ—ӨР-ЯҢА...

РОБАГЫЙЛАР

**Күк йөзендә—бер йомарлам ак болыт,**
**Кала алсаң иде шулай пакь булып.**
**Жирдә ничек? Әнә Галәм багында**
**Болытлар да яши чәчеп яктылык.**

* * *

**Балкый агач—гүя яшел чатырлар,**
**Бал кортлары чәчәк тәмен татырлар.**
**Үлән үсә, яфрак сыза... Ләкин, күр:**
**Күзләр карый инде фасыл чатыннан.**

* * *

**Дөбер-дөбер поезд чаба жилкенеп,**
**Узган гомер—гүя искән жил кебек.**
**Бу дөньяның тагын кайсы оҗмахы**
**Бар микән соң туып үскән ил кебек?**

* * *

**Галәмдәге кара бушлык, калтырап,**
**Үзенә тарта безне һаман «жан сорап».**
**Ярый әле кочагына сеңдергән**
**Мәрхәмәтле Кояшыбыз—шәм-чыраг.**

* * *

**Көз хәбәре килә кайсы, кыйтгадан?**
**Җәйнең соңгы жиле исә кыйбладан.**
**Биектәрәк калмак тели бер яфрак—**
**Өзелмәскә дип тартыша ул һаман.**

Рашат НИЗАМИ (1950)—*шагыйрь, прозаик, публицист; «Кызыл җәй», «Яшьлеккә хат», Фәрит Яруллин турындагы «Ут һәм җыр» исемле роман-хроника һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Чү... Карлыгач! Узып чыпчык-йолкышны,
Оча уктай—күрсәгезче бу кошны.
Оеп-изрәп яткан ялкау адәмгә
Бирсәң иде, димен, шушы очышны!

***

Чибәр кызлар, дус-иш булса янында,
Сүз шәрабен уйнатабыз табында.
Шагыйрь хаклы: Хәйямнең үзе белән
Чәкәшерлек фикер бармы җамында[1]?

***

Бәп-бәләкәй чакларымда—зур идем,
Әткәм-әнкәм өчен сүнмәс нур идем.
Күп нәрсәләр кичерәйде... И Ходам,
Сабый чакны кайтарып бер бир идең.

***

Читләр моны тоя алмас, күрәсең,
Кояш шакып керә күңелем хөҗрәсен.
Күрми адәм йөзъяшәрлек агачның
Үзәгендә сызып яткан боҗрасын.

***

Күңелнең сусап көткәне—син идең,
Исәрдәй шашып сөюче мин идем.
Галәмне урап кайтырлык гыйшкыбыз
Мизгел түгел, бер гасырга тиң иде.

***

Бу болытлар бәйсез дәүләт сымандыр,
Яңгырларың белән, әйдә, куандыр.
Берәү өчен күкләр—йолдыз бакчасы,
Чи наданга—тоташ соры томандыр.

***

Өскә күтәр яхшылыкның әләмен,
Игелек кылуның тап син әмәлен.
Уй-хыялга батып кына, кардәшем,
Мөмкин түгел бизәү тормыш галәмен.

***

Җырлый белмәгән нишләсен—сызгырыр,
Теле белән кемдер тузан туздырыр.
Дәрвиш димә! Булган кеше, кирәксә,
Уч өстендә хәтта тәбә кыздырыр.

***

Беркөн шулай барган идем ломбардка,
Хуҗалары елмаеп теш агарта:
Акча белән уйнаш иткән заманда
Әл-Әхлакның кадере арта, хак арта.

---

[1] Зиннур Мансуровның шигъри юлларына ишарә.

***

Таулар да бит тузан-таштан яралган,
Энҗе-мәрҗән—тутыкмас дип дан алган,
Бишектәге бу сабыйдан кем чыкмас:
Пакь өметләр белән йөзе камалган...

***

Бугазларга баса заман ачысы,
Уйнаклыйдыр күктә язмыш кайчысы.
Житәкләшеп килә шатлык-хәсрәтләр,
Минем өлешкә шуларның кайсысы?

***

Затлы кеше матурлыкка табынган,
Карун исә туймас дөнья малыннан.
Чикерткәнең әллә юкмы уенда
Авыз итеп карау чәчәк балыннан?

***

Сәгатьләрнең дә бит була төрлесе:
Кыңгыраулы, күкелесе, герлесе.
Дөнья тулы асыл-чибәр кызлардан
Йөрәгеңне аңлый алсын тик берсе.

***

Болгар җире. Әрнеш белән карыйсың
Таш-туфраклы җирнең һәрбер карышын.
Армадыңмы тотып, айлы кабerташ,
Урысларның кан-чиркәүле тарихын?!

***

Кулда тота кемнәр галәм тезгенен,
Кем үлчәгән яктылыкның тизлеген?
Төзи алырмы кешелек берзаман,
Көче житеп, шаһ-йолдызлар сүзлеген?..

***

Табигатьнең бозлык чоры булгандыр,
Табигатьнең кызлык чоры булгандыр.
Күр, заманны: шартлый, ава, кыйшая,
Дулый туфан—тагын дөнья болганыр.

***

Күмдек илтеп эткәемнең гәүдәсен,
Арыды ул эзләп яшәү мәгънәсен.
Гүяки, миләш куагын җирләдек:
Каберендә—бары яфрак шәүләсе.

***

Көтмәгәндә чәчәк сабын җил кисә,
Чәчәк гомере—тик бер мизгел югыйсә.
Ә син, кешем, ни кылырсың—бер мәлне
Әҗәл бавы синең бугаздан буса?

***

Сүз кушамын инештәге талларга,
Күзләреңнең серен телим аңларга.
Калтырана күк йөзендә Ай табы,
Төнге сулар ни пышылдый ярларга?

***

Әллә кайчан үз «мәзһәбен» тудырган,
Ул какшамас кәнәфигә утырган.
Бар белгәне  ашау-эчү, нәфсе тик,
Ни көтәсең «яңа татар углын»нан?

***

Офыкларда өр-яңа көн кабынган,
Кул болгыйм сиңа мәхәббәт тавыннан.
Күңелне уятыр, егълатыр өчен
Төштең микән әллә күкләр багыннан?

***

Күк астында үземә урын юнәттем,
Офыкларның түгәрәген киңәйттем.
Хет бер тамчы сөю калсын безләрдән,
Егетлекнең асылы шулдыр—мин әйттем!

***

Кемдер елмая балкытып тешләрен,
Бәхетсез-фәкыйрь мескенем нишләсен,—
Дөньяга ник туганына үкенеп,
Ихтыярсыз терсәгенме тешләсен?

***

Йокымсырый кышкы урман эргәсе,
Кар өстендә—чыршы-нарат энәсе.
Агачлар, дим, койган ылыс-яфрагын,
Чәчне коя тормыш, әттәгенәсе!

***

Бәндәләрнең кылган эше хатадыр,
Тамырлары бик тирәндә ятадыр.
Хаталана түрә-улак, патшалар,
Кояш кына ялгышмыйча батадыр.

***

Яхшы эшнең була яхшы мәгънәсе:
Ташлар вата, юллар сала кәйләче.
Барыр юллар туфрагында ятадыр
Үлемнең аклы-каралы шәүләсе.

***

Сыгылмасын аякларың, иңбашың—
Яхшыларны син үзеңә юлдаш ит.
Тустаганга агу түгел, кәүсәрсу
Сала белгән адәмнәрне кулдаш ит.

***

Күктә йолдыз сүзсез генә ялтырар,
«Мәрткә китәр», тавышланмас мал-туар.
Ялгызакның мендәрендә төнката
Ай шәүләсе генә өнсез калтырар.

***

Күңелемнән сине сызып ташладым,
Янәсе, мин яңа тормыш башладым.
Әй син, язмыш: шулмы миңа биргәнең—
Күңелем тулы хәзер ачуташларың.

***

Күкләр белән җан-күңелен бәйләр ул,
Аңлар өчен ай-йолдызлар сәйләнен.
...Җиргә иелеп бер уч туфрак алырга
Диден исә, вакыты юк бәндәнең.

***

Сусаганда эчкән суым—бер йотым,
Күк астында куышым бар—үз йортым.
Келтер-келтер дөнья куган булабыз,
Дөнья үзе безне куа ыжгыртып!

***

Әй, кызларның ялтыр-шома тез башы,
Бар дөньямны әсир итә күз-кашы!
Ярдәм итче, и Аллаһым, кәгазьгә
Төшерергә мәдхиянең сүз башын...

***

Син кайларда йөрисеңдер, и язмыш,
Кайсы кылда нинди яңа көй язмыш?
Нәрсәдән бу: кайчакларны кинәттән
Бозлы сулар чоңгылында уянмыш.

***

Әйтә алам нык күтәреп тавышны:
Безнең хәят дөреслеккә авышты.
Күрегезче, күк йөзендә Ай белән
Яңа мәчет манарасы кавышты!

***

Кайчан туган ВАКЫТ—без бит белемсез...
Уйлый китсәң, менә шунсы күңелсез:
Тугарылып чапкан дөнья каршында
Әлмисактан вакыт кына—үлемсез.

***

Кануннары—үзгәрешсез, һаман нык,
Табигатьтә була алмый яманлык.
Тезен чүгеп сәҗдә кыла яңа КӨН,
Яшел чирәм—әйтерсең лә намазлык.

***

Үткәннәрен сүтеп-барлап карый да,
Уйлый кеше: дөнья бакый, фани да.
Көрәшле һәм катмарлы бу заманда
Уйлап баксаң, безнең тормыш—КОРРИДА.

***

Бал кортлары балын кояр кәрәзгә,
Шагыйрьләрнең сүзе тамар кәгазьгә.
Әй, Низами, уйдырып сал уеңны,
Батмаенча, бәгъзеләрдәй, вәгазьгә.

***

«Бәгырь катты!..—диләр. Димәк бар сәбәп,
Күңелләрнең йомшаклыгы—нәрсәдән?
Таң чыкларын кошлар сусап көткәндәй,
Яхшылыкка сусап яши һәр адәм.

***

Тургайның да үзе белгән күге бар,
Офыкларда диңгезнең дә чиге бар.
Туктап-туктап, нурлар тама галәмнән,—
Галәмнең дә, мәйтәм, әллә биге бар?

***

Аңлар өчен адәмнәрнең хикмәтен,
Бизмәннәргә салып үлчә һиммәтен.
Бар дөньялар зыр әйләнеп торганда,
Бу дөньяда бар микән соң кыйммәтем?

***

Бушбугазның гамәлен кем тыялган,
Әллә ничә төскә тормыш буялган.
«Ялган заман...»—дия-дия ялгышма,
Ун дөрестән чынрак—кайчак бер ялган.

***

Учак яна... Инде сүнә ахрысы.
Пакъ җаннарның кая төшә яктысы?
Чакма бәреп бәхәсләшә уйларым—
Күңелемдә Ак һәм Кара тартышы.

***

Ком-ташларның базар хакы бик арзан,
Алтын гына кыйммәт йөри, фаразан.
Күлтәгиннән калган моң чәчелерме—
Таш балбалны әгәр ярып карасаң?

***

Салмак кына яңа кояш уяна,
Күзен сирпеп ала фани дөньяга.
Борынгыдан килгән күп шәй таушалган,
Кыяк ярган үлән генә—өр-яңа!

Камил
Кәримов

# УЕН

РОМАН

## Малайлар чуагы

Телефонда тәүлек буена җыелган язмалар бихисап булып чыкты. «автоответчик»тагы хәбәрнең беренчесендә тимер тавышлы хатын-кызның катгый кисәтүе: «Шәһәр телефон станциясенә ундүрт сум бурычыгыз бар. Атна эчендә түләмәсәгез телефоныгызны өзәбез!»—диелгән. Менә шулай, коры сөйләшәләр хәзер налог түләүчеләр белән. Газовиклар—сүндерәбез ди, электриклар—кисәбез ди, элемтәчеләр—өзәбез ди, водоканал бетерәбез дип кенә янап тора. Мондый янаулардан котылыр өчен гади халык бу тормышта нәрсә кисәргә тиештер—монысын белгән юк. Әлегә безнекеләр коммунизмны сагынып-сүгеп базар мөнәсәбәтләренә «йомшак» кына кереп, катыга лып итеп утырды.

Сөмбеләнең ул ундүрт тәңкәлек квитанцияне күргәне юк, бушлай килә торган калын-калын реклама гәҗитләре белән ташланганмы ул, әллә төшеп югалганмы—анысын шылтыратып белешәсе булыр.

Сөмбеләләрнең почта әрҗәсе беренче катның лифт ишеге каршында. Элеккеге елларда сабыр гына лифт көтәргә түземлеге җитмәгән үсмерләр әрҗәләрне каерып, килгән почтаны ботарлап баралар иде. Хат-хәбәрләр дә күпләп югала торган иде... Инде хулиган малайларга да уй керде, почта әрҗәсен ачкан саен аннан кочак-кочак квитанция, счет, боерык кәгазе, йә хәрби повесткалар коеласын беләләр, тимиләр. Атналап гастрольдә йөрсәң дә төя-төя тутырылган кәгазьләр шул килеш тора. Укулар башлангач Зәйтүнә гел өйдә, күрше Мөнирә әби белән ике фатирны бер итеп дигәндәй яшәп калалар. Хат ташучылар килгәнче әрҗәне вакытында бушатып өлгерәләр.

Телефон чыбыгын өздерергә ярамый Сөмбеләгә, һич ярамый. Заманында җидешәр мең түләп тә күп еллар буе чират көтәсе бар иде өенә телефон кертер өчен. Ярый ла ул чактагы элемтә министры Сөмбеләнең якташы булып чыкты, чиратны алгарак күчерергә ярдәм итте.

Кесә телефоны уенчык кына бит ул, ашыгыч ярдәм өчен генә. Гипермаркетларда адашканда, урам бәйрәмнәрендә югалышканда бер-береңне эзләргә җайлы. «Син кайда йөрисең? Кайчан кайтасың?»—дигән ике сорау аркасында гаиләдә кеше саен кесә телефоны.

Ә чыбыклы телефон гел өеңдә уяу тора, фатирыңны, малыңны саклый, килгән хәбәрләрне язып бара, төшеп югалмый, маршрутлы таксиларда урланмый, аккумуляторы утырмый, элемтәсе нык. Чыбыклы телефон—тугры

*Ахыры. Башы узган санда.*

дус, аның адресы бар. Утыз ел элек кемгәдер язып биргәнсең икән—номерың гел шул. Алты урынлы, хәтта җиде урынлы саннарга күчкәндә дә телефон номерларының искесен саклап алдагы санны гына үзгәртергә тырышалар. Теләгән кешеңне эзләп табуы кыен түгел.

Сөмбеләне дә кемдер эзли... Шуңа күрәдерме, бу арада аның уйлары күбәйде, берсен-берсе ашыктырып, өсте-өстенә өелеп тора. Ул «автоответчик»тан икенче хәбәрне ачты. Ләкин икенче «хәбәр» хәбәрсез югалган: ярты минут буе эндәшмичә торган. Сөмбеләнең өйдәме, юкмы икәнен белергә теләгәнме, әллә кара-каршы сөйләшер сүзе бармы? Сулыш алганы да ишетелә хәтта—ир кеше булса куркак, хатын-кыз икән—мәкерледер ул.

Әйе, кайсыбер көннәрне, гастрольгә дигәндә төркемдә унышар кеше җыела. Яшенә-картына карамый һәммәсенең өендә көткән кешесе бар. Җырчының телефоны бүгенге кебек сораулар, үпкәләүләр, үртәү-шелтәләүләр белән тулган чаклар еш була. Зәйтүнә аларны әнисе кайтканчы сыздырып ташлый торган иде, бүген өлгермәде шул:

«Кичә үк кайткансыз, минеке бүген дә юк әле...»

«Ник аны банкетларда бераз тыймыйсың, эчеп үлгәнен көтәсеңме?!.»

«Петербурга чаклы барып әҗәткә җырлап йөрмиләр инде. Башка артистларга шундук түлиләр...»

«Өенә жыеп күңел ачтырып ятма, балалары көтә!»

Бу хәбәрләр телефон хәтереннән сызылып, яңалары белән алышынгач та алар, Сөмбелә хәтеренә күчеп, атналар буе тынгы бирми, күңелнең иң тирән төпкелендә дегет булып нахакка җәелеп кала, онытылды бугай дигәндә дә искә төшеп горурлыгын борчый иде. Мәгәр бүген кызның халәте бүтән, аның фикер сөрешендә вәзгыять үзгәрде. Салкын сулышы сизелеп торган ярты минутлык язма хакына ул бүген барлык мескеннәрне дә гафу итте. Сары розалар бүләк итәрдәй кеше җырчының уйларын куып too, ул барыбер көрешү чарасын эзләячәк. Чөнки Сөмбелә шулай тели, аның өчен сөенечле көрешүләрнең, серле өметләрнең, мәхәббәт гөлләренең тансык чагы.

Телефондагы барлык хәбәрләргә кул селтәп, рәттән сыздырып ташламакчы иде Сөмбелә, күңеле сизенгәндәй, иң соңгысын тыңлап карарга булды. Анда Хәмзә тавышы.

Хәмзә бик универсаль артист, кулыннан килмәгәне юк. Ул кирәксә җырчы, композитор, язучы, алып баручы, гармунчы, режиссер, сценарист, укытучы да үзе. Бөтенесен дә әз-мәз булдыра. Эстрадага хилафлык китермичә генә «Яшел эшләпә» дигән гәҗит тә чыгарып караган иде. Ел ярым дигәндә күнеле булды, гәҗитен япты, яшел эшләпәсен чөйгә элде. Ул диңгез сәяхәтчесе кебек, архипелаглар, утраулар, яңа илләр ачарга ярата, ләкин үзе анда озаклап яшәргә теләми. Житди кичәләрдә парик кия, юмор сөйләгәндә пеләш баштан чыга. Аның бу гадәтен Президент та сизеп алган, сабантуйда көрешкәндә бөтен кеше алдында ул аңа «Ике башлы Хәмзә» дип эндәшкән.

Хәмзә Сөмбеләнең репертуарын яттан белә, «солянка» дип аталган күмәк концертларда бик еш кына бергә туры киләләр.

Сәхнә дөньясының кәмит яклары күп кырлы. Артистлар арасында киң таралган атамаларның тамырдаш мәгънәләрен эзләр өчен тел белгече булу гына җитми, пешекче, балта остасы, тәржемәче, хәтта экономист та булырга кирәк. Әйтик, музыкант күзлеге аша караганда «солянка» сүзенең тамырында «соло», ягъни ялгыз җырчы—солистның үз концерты дигән мәгънә ятарга тиеш. Юк, бу очракта ул берничә яшелчәдән пешерелгән солянка ашына кайтып кала, димәк концертта бик күп солистлар чыгыш ясаячак... Әгәр башкарыласы көй алдан ук тасмага язып куелса һәм сәхнәдә музыкантлар уен коралларын күтәреп юри генә басып торсалар—бу вакытта инде

фонограмма «фанера» дигән төзелеш материалына әверелә. Электр көчәнешендәге полюслар да «унай» яисә «тискәре» дигән мәгънәсен бөтенләй югалта. Әгәр жырчы фанерага үз тавышы белән кушылып жырлый икән монысын «минус»овка диярләр. Ә инде анда башкарыласы жыр да язылган булса, ни өчендер «плюс»овка дип унайга әверелә. Баянга кушылып «тере» килеш жырлау исә—«живьём» көчәнү дип атала. Артистлар телендәге «Отвертка»—ул исерткеч белән пепси-кола кушылмасы, анын шөреп бора торган эш коралына бөтенләй катышы юк. Техниканын исән-имин хезмәт итү елын вәгъдә иткән «гарантия» сүзе артистлар телендә: «Кеше килмәсә дә, концерт булмаса да түләнәчәк» дигәнне анлата. Мәжлесләрдә артистлар утырган өстәл шар тәгәрәтерлек булып бушап кала икән—монысы «банкет на шару». «Даром-шаром»га сыйлануны башкача ничек атыйсын ди инде тагын?!

Хәмзәдән килгән хәбәр артистлар телендә язылган иде:

«Сөмбелә, жомга көнне гарантиягә бер солянка бар. Минусовой фанераларынны алып тор, ну күбрәк «живьём» жырлыйсы булыр. Баянчынны калдырма, безнеке отвёртка белән күбенгән. Артистлар өчен «на шару» швед өстәле әзерлиләр. Катнашам дисән срочно шалтырат... Хәмзә бу.»

Авызы бер пешкән кеше шикәрне дә өреп кабар, Сөмбелә чакырган һәр жиргә йөгереп бара торганнардан түгел. Ашыгып килгән яналыкнын ялганы күп була. Хәмзәгә шылтыратып вакыйганы төгәлрәк белешмичә ярамас.

—Алё, Хәмзә?

—Сөмбелә, нихәл? Жомга көнне бушмы син?

—Бушлыкка буш. Кайда була сон ул концерт?

—Барыбер түгелмени.

—Мин кайда нилэр жырлаганымны язып барам. Кабатланмас өчен. Син чакырган жирдә булганым бармы-юкмы, көндәлектән тикшерәсем килә.

—Кая икәнен үзем дә белмим. Кичке дүрткә Хантимер ресторины янына жыелырга диделәр. Зурдан кубып банкет үткәрәләр ди.

—Банкет?! Ә кемнен бәйрәме?

—Ниндидер мальчишник булса кирәк.

—Ә мин нәрсәгә алайса?

—Әмир үзе киләчәк. Ә ул халык жырларын бик ярата. Жора Хәйбушов урынына чакырам мин сине. Жора Мәскәүдә йөри, кайтып житмәскә мөмкин. Кайтып өлгерсә дә борчылма. Бәлки әле сина жырларга да туры килмәс, ну түләү гарантияле. Бер жыр жырлап, сыйланып кайтасын килмиме? Сораган ставканны бирәләр.

—Банкетларны женем сөйми.

—Баедын мәллә, Сөмбелә?!

—Хәерченен ин зур кимчелеге—анын горурлыгы, Хәмзә. Әле унбиш ел элек кенә көтүче булып йөргән Яна байлар алдында шамакайланып, мескенләнәсем килми.

—Сәнгать шунын өчен инде ул, теләмәсән ихтыярын... Карале, Сөмбелә, сине бенефис үткәрергә жыена диләр. Нинди унайдан ул? Яшен түгәрәкләнергә иртәрәк бугай әле...

—Ижатыма егерме, кызыма унсигез яшь тулу унаеннан.

—Оригинально! Шәп идея! Ә беләсенме, ул банкетта спонсорлар күп булачак, мактаулы исемгә кул куярдай кеше дә килә. Яшерен-батырын түгел инде, артистларга званиеләр, орден-медальләр өләшү ин элек банкетларда хәл ителә.

—Синен банкетлардан кайтып кергәнен юк. Ә наградной листынны ничә тапкыр кистеләр инде.

—Ни бит, Сөмбелә, мин кыек-мыек сүзләр сөйләп кенә күнелләрен

күтәрермен дип тырышам да, ялгыш турысын әйтеп атам. Турысын әйткән түрәсенә ярамаган ди... Хәмзә дигән исемем житә миңа.

—Миңа да шулай. Жырчы сәхнәгә фамилия белән чыга, ә исем дигәнең соңрак үзе килә ул.

—Ярар алайса. Әле уйланырлык вакытың бар. Акылыңа килсәң шалтыратырсың. Хәерле төн сиңа, яме... Зәйтүнәнә сәлам әйт. Мин аңа багышлап бер жыр язам әле. Бенефисына чакырырсың... Зәй-зәй-зәй Зәйтүнә асыл кошым, зифа буйлы житез канатым, Зәй-зәй-зәй...

Сөйләшү кинәт өзелде. Хәмзә яңа жыр язарга утырды бугай.

***

Әүвәл электр кыңгыравы шау-шу куптарды. Гадәттә, иртәнге якны мазасызлап, йә хәер соранучылар, йә махмырлы музыкантлар, йә яшелчә сатучылар килә торган иде. Алар өйдән-өйгә йөреп, бикле ишекләреннә ачтырырлар, «Кишер, кәбестә, бәрәңге—кирәкмиме?»—дигән мәжбүри гозерләренә жавап ишетмичә торып тынгы бирмәсләр. Сөмбеләнең, шуңа күрәдерме, кыңгырауның өзгәләнүенә исе китмәде. Иртәнге хәбәрләргә битараф ул. Әти-әниләреннән хәвефле телеграммалар көтми, әле атна башында гына Балантауга кайтып хәлләрен белеп килде, шөкер, сау-таза, калдылар—абзардагы мал-туарның көенә төшеп, бакча-кураны тернәкләндереп, биш почмаклы өй эчен көр мөгамәлә белән тотырып яшәп калдылар. Үзләренең Сөмбеләгә кунакка килеп китәргә исәпләре юк. Яңа фатирга күчкәч тә төпчек кызларын хат жибәреп кенә котладылар. «Пенсиягә чыккач айкап кайтырбыз әле Казаныгызны да бик сагынабыз» дигәннәр иде, ләкин, хикмәти Ходә, Гөлчәчәк белән Харисның пенсиягә чыкканнарына биш былтыр инде, тик Сөмбеләнең бусагасын атлап кергәннәре юк әле.

Кыңгырау тагын тавыш куптарды. Ул да булмады, мазага ишек шакулары өстәлде—ике фатирны аерып торган тоташ тимер ишеккә ачкыч түтәсе белән төяләр иде.

—Әни, бар ач инде, безгә бит,—диде күрше бүлмәдәге Зәйтүнә һәм үзе, көтелмәгән кунаклар өйгә керә калса дип, тиз генә торып, спорт костюмын киеп куйды.

Сөмбелә, өй ишеген бераз ачып, тимер ишек артындагы тавышлар белән аңлашты.

—Кем анда?

—Судебный пристав.

—Чакырганым юк. Адресны бутагансыздыр.

—Сезгә түгел, күршегез Галиевләргә килдек. Ул ишеген ачмый. Без аны ике тапкыр кисәткән идек инде.

—Әгәр ачмасам?!

—Тимер ишегегезне ватып керәбез. Галиевне мәжбүри рәвештә фатирыннан күчерергә дигән суд карары бар...

Закон белән тимер ишек аша әрләшеп утырудан ни файда?! Ачып кертте. Алар жәмгысы алты кеше иде: икесе—пристав, икесе—милиционер һәм ике эшче.

Хөкемдарлар илчесенең Галиевләр дип күплек санда сөйләшүе бераз сәер тоелды, Мөнирә апаның ире үлгәнгә инде өч айлап бар, ул хәзер бер бүлмәле фатирда үзе генә яши. Сөмбелә монда күчеп килгәндә Зәйтүнәгә әле ун гына яшь иде. Себер якларына икешәр атналык гастрольләргә чыгып киткәндә өченче сыйныф укучысы тулаем күршеләр кулында кала иде. Телефонга керешү, суыткычка ит-май куеп тору, бер-беренә ачкычлар ышанып калдыру ише йомышлар урам-подъезд ыгы-зыгысыннан тимер ишек белән бүленгән ике фатир арасындагы дуслыкны туганлык дәрәжәсенә житкергән иде. Әнисе

гастрольләрдән кайткан чакта да Зәйтүнә йомшак уенчыкларын күтәреп, бер бүлмәле күршеләренә кереп уйнарга ярата иде.

Мөнирә апа ире белән икәүләшеп шәһәрнең Ленин исемендәге фәнни житештерү берләшмәсендә эшләде. Яшьли килеп урнашкан эш урынын алыштырмыйча, сау-таза гомерләрен шунда үткәрделәр. Иртән икәүләшеп ашыга-ашыга чыгып киттеләр, кичен бергәләшеп кайтып керделәр. Яшь аермаларын киләчәк өчен алдан ук күз алдында тотып кавышканнар диярсең, пенсиягә дә икесе бер елны чыктылар. Халык телендә «Дары заводы» дип йөртелә торган берләшмәгә Ленин исемен ник кушканнардыр, ул кадәресен эшчеләргә аңлатучы булмады. Анысы хак, бик серле завод иде ул. Бер серләрен Сөмбелә дә сизеп алды. Мөнирә апаларның сулышыннан эфир исе килә, якын торып кара-каршы сөйләшкәндә бу ис үзен аеруча нык сиздерә иде. Операциягә-мазар эләгә калсаң, Алла сакласын, безнекеләрне наркоз алмый, дип бик еш зарлана торган иде күршеләр. Башка заводныкыларга караганда пенсиягә ун елга алданырак чыксалар да тигезлек белән картаерга язмаган, Мөнирә апаның ире Ленин яшенә житкәч жан тәслим кылды. Утыз биш ел тигез гомер итеп тә истәлеккә калырдай бала таба алмагач, Мөнирә апа берүзе яшәде һәм ялгызлыкны бик авыр кичерде. Өендәге ялгызлыктан качып йөргәндәй, йә мәчеткә ашыкты, йә митингларга кушылды. Ленин исемен саклап тоткан Мәдәният сараендагы чараларны калдырмады, өметсезләргә ияреп «Орион» пирамидасына килеп эләкте. Дөресрәге, һәр атна кич үткәрелә торган лекцияләренең берсенә туры килде.

Чибәрләр бәйгесендә жиңеп чыккан кызларга алыштыргысыз бер ханым сәхнә уртасына чыгып баскан да залдагыларны күз уңыннан ычкындырмаска тырышып кына сөйләпме сөйли: жөмләләре шигырь кеби, фикерләре тылсымлы әкият гүя, тавышы көйгә салынган. Илле сум түләп кергән лекциядән шунысы аңлашылды: бер мең доллар акчаңны кызганмасаң, ел эчендә йөз мең булып әйләнеп кайта ди! Үзең ише тагын ике кеше алып килсәң беренче взносыңның яртысын шундук кире кайтаралар, таба алмасаң мең килеш «Орион» кассасында калып тора. Кыскасы, тиз арада һәркем меңәр долларлы ике кешене тотып китерергә тиеш. Кем алдан языла—йөз меңне дә алданырак ала... Шул көнне үк язылып кайтты Мөнирә апа. Акчасын китереп бирергә ашыкмаган иде, ике көннән теге төзек ханым өенә килеп житкән, өстәмә лекция укып күндерде. Йөз мең сумлы матур киләчәк сихерләде, тәки...

Сөмбеләнең юлда чагы иде. Ул инде язмыштан шактый өтелгән—залдагы халыкның психикасына йогынты ясарга өйрәнгән, кешелекле күз карашын гипноздан аерырлык кына тәжрибәсе бар. Тик, гөнаһ шомлыгына күрәдер, гастрольдән кайтып житкәнче Мөнирә апасы ире белән гомер буе жир астындагы заводта эшләп жыйган барлы-юклы акчасын, «Орион» тирәсендә бөтерелгән дилерлардан алынган әжәт белән түгәрәкләп, ике битлек килешү кәгазенә алыштырып өлгергән иде. Сүз дә юк, килешү кәгазе үзенең матурлыгы белән Пермь шәһәренең «Гознак» типографиясендә эшләнгән кыйммәтле документлардан һич ким түгел. Гомер бакый яшәп һәм эшләп үзен газета-журнал битләрендә күрмәгән Мөнирә апагызның тулы исем фамилиясе шома йөзле каты кәгазьгә алтын хәрефләр белән басылган, аллы-гөлле тәсләр белән бизәлгән, тугралы тышлыкка кыстырылган. Мөнирә апагыз ул килешүне, йөз мең сум акчаны хөрмәтләгән кебек итеп, кием шкафындагы шүрлеккә пөхтәләп яшереп куйды.

Бурыч түләүне бик тиз ашыктырдылар. Атна-ун көн эчендә дилерларның элеккеге тенор тавышы гонорга әверелде. Алакардагы йөз меңгә зыян китерәсең килмәсә, Мөнирә апагызга әлеге әжәтне кайтарыр өчен сулышыннан эфир исе килә торган бик күп танышларын барлап чыгарга

туры килде. Шулай итеп, бурычны әҗәт белән, әҗәтне—үтеч, үтечне янә бурычка кереп очын-очка ялгап барганда, Мөнирә апаның фатир өчен түләве җыела башлады. Инде «Итого к оплате» дигән шакмак турысына өелгән саннардан котылыр өчен, бер еллык пенсияңне тиененә кадәр чәчми-түкми илтеп бирсәң дә котылырлык түгел иде.

Эшләр судка барып җитте. Тимер ишек артындагы приставның «ике мәртәбә кисәттек» дигәне рас икән. Ике атна эчендә әвәл энергетиклар килеп утны өзгәннәр, икенчесендә газовиклар газдан мәхрүм иткән. Пунәтәй рәвешендә, приставларга ияреп кергәч кенә, Мөнирә апаның керосинка өстендә корымланып беткән яшел чәйниген күреп «ah!» итте Сөмбелә. Әйтәм аны соңгы көннәрдә, ялгыз күрше кич утырырга кергәч, бик ашыкмый торган иде: киноларны ахырынача карап бетерер, татар концертларының башланганын көтеп алыр, табынга чакырсаң баш тартмас, урын җәяргә тотынгач кына капылт саубуллашып чыгып китәр. Ялгыз башы газсыз, утсыз яшәп ятадыр дип кем уйлаган аны?! Чакырылмаган алты кунак җыйнаулашып килеп кергәч, бер бүлмәле фатир эче ипсезләнеп калды. Чакырылган кунаклар булса—ишек төбендә үк туфлиләрен салырлар иде, ә болар урамнан керә керешли үк туп-туры түргә үттеләр. Мөнирә апа, стенадагы кадагыннан ипсез егылып төшкән иске портрет кебек, диванның арка терәвенә сөялеп тәрәзә өлгесенә төбәлгән. Сөмбелә аның күз карашына эләгер өчен тәрәзә каршына килеп басты, тик барыбер игътибарын җәлеп итә алмады.

Ул арада пристав хөкем карарын кычкырып укып чыкты, Мөнирәападан бигрәк чакырылмаган кунаклар кыланышын, ишек ярыгыннан күзәтеп торган күрше-күлән колагына гыйбрәт өчен кирәк иде бу.

—...Кисәтүләргә карамастан, фатир өчен түләнмәгән бурычның уналты мең җиде йөз утыз сумга житүен исәпкә алып, хөкем карары нигезендә, Челюскин урамындагы өлешчә шартлары булган ике катлы йортка мәҗбүри рәвештә күчерергә...

—Кадышев зираты тирәсеннәнрәк юк иде микән бирәр бүлмә, иремнең каберенә якынырак итеп?

Мөнирә апа хәвефне алдан ук сизеп үзенең иң кадерле киемнәрен: көмеш туена ире бүләк иткән мамык шәлен, ялгыз калгач барып йөри алмам дип сатып җибәргән өйле бакча хакына алган кара тунын һәм беренче пенсия акчасыннан адарынган көрән күнле итеген киеп өлгерсә дә ясалма теш казнасын кимичә, кулъяулыкка төреп тунның эчке кесәсенә салган иде. Кечерәеп калган ияге, болай да тар маңгайлы, нәни күзле, шома битле әби-апаның йөзенә самимилек өсти. Шуңа күрәдерме, аның соңгы гозере фаҗига рәвешендә түгел, ә сабый бала авызыннан чыккан көйсезлек булып ишетелде. Сөмбелә әлеге хөкем карары өчен үзен гаепле сизде. Шөһрәт, дан, мал, дөнья нужасы куып сәхнә тирәсендә буталып йөргән арада «базар мөнәсәбәтләре» дигән вәхшәт тимер ишек аша үтеп, инде газиз кызының сөекле дәү әнисенә әверелгән Мөнирә апаның бусагасын атлап кергән. Һәм бу вәхшәт Сөмбеләнең фатирына килеп терәлгән. Ике арада нибарысы унике сантиметрлы бетон стена гына. Стеналарның һай тотрыксыз чагы...

—Туктагыз әле,—диде Сөмбелә, кинәт кенә хәсрәт əзәрлекләвеннән айнышкандай булып,—бүтән бернинди дә чара юкмыни соң?

—Бар, ник булмасын,—диде теге пристав,—куып чыгару эшен егерме дүрт сәгатькә чигереп торып була, әгәр шул вакыт эчендә соңгы счет-фактура буенча бурычын түләп өлгерсә.

—Үзем түлим! Кызның укуына дип җыйган запасым бар. Банктан алам да сберкассага кертеп бирәм. Ярты сәгать эчендә өлгерәм. Акча саный торган урыннарда таныйлар мине.

Шунда гына эшчеләрнең берсе чын күңелдән куанып куйды:

—Баядан бирле карап торам, сез жырчы бит, әйеме?!

—Әйе. Таныгач рәхмәт инде.

—Иптәшләр-әфәнделәр! Бу бит Татарстанның халык артисты,—дип мактаулы исем дә биреп өлгерде бу кеше.—Сөмбелә үзе!.. Сезне халаттан бер дә күргән булмагач, тиз генә танымадым. Гафу итегез! Миндә сезнең кассеталар бик күп.

Эшче шундук кесә телефонын чыгарып өенә шылтыратты.

—Алло, улым, тиз генә Сөмбеләнең яңа компашкасын алып кил әле. Көттермә. Автограф алам. Без Колахметов урамындагы адреста. Ике әйттермә, яме!

—Бер дә автограф өләшерлек кәефем юк шул, кем, энем. Хәер, мин дә шылтыратып алсам була—президентка!—диде Сөмбелә ниһаять батыраеп.—Гади халыкның ни хәлдә яшәгәнен ишетеп белсен.

Сүзгә тагын теге пристав кушылды.

—Без бит сезне чыгарырга дип килмәдек. Закон язылган икән, ул кемнең кем булуына карамастан үтәлергә тиеш.

—Закон язучылар өчен фатир хакын дәүләт түли шул. Телевизордан күреп торабыз, гел гади халыкны елатасыз.

—Алайга китсә, артистлар да начар яшәми. Әнә, Мәскәү артистлары килде—билет бәяләрен биш йөз доллар итеп куйганнар. Хатын белән икебезгә өч мең сум түләдек.

—Ә сез татар концертларына йөрегез, өч мең сумга егерме билет алырсыз.

Сөмбелә пристав белән кискен бәхәскә керүдән тыелып калды, эшне бозудан курыкты. Хәер, жырчы күршенең тәкъдименә сөенделәр генә. Иске-москы җиһазларны исемлеккә теркәп, машинага төяп-бушатып, гаепле хуҗаны милиция белән алып чыгып, елатып, күршеләрнең каргышын җыеп китү хөкемдарларның үзләренә дә бик ошамый иде бугай. Сөмбеләнең кассадан әйләнеп кайтканын урамда гына көтеп тордылар.

Автографлар өләшеп аерылышкач, Сөмбелә минутын да әрәм итмичә, тизрәк Мөнирә апасы янына ашыкты. Зәйтүнә анын туннарын салдырып кабаттан үз урынына элгән иде инде, зур кызларча дәү әнисе итеп кочаклаган да башын башка терәгән. Берсе еларга тотынгач икенчесе дә түзмәгәндер инде—парлашып үксиләр. Сөмбелә кызы белән бергә Мөнирә апаны кочаклап алгач, өчәүләшеп күңел бушаттылар.

Ут белән газны яңадан тоташтырыр өчен гаризалар биреп оешмаларына ялынасы бар иде әле. Бу кичне Сөмбелә, Мөнирә апасын караңгыда утыртмас өчен, озын чыбык белән ишек өсләтеп кенә үз фатирыннан ут сузды. Күчмә розетканың өч оясына да эш табылды: телевизор кабынды, өстәл лампасы янды, өченчесе буш калмасын өчен «Тефаль» чәйнеге күтәреп керде. Әлбәттә, Сөмбелә күрше апаны алып чыгып кунак итәргә бик теләгән иде дә, ләкин Мөнирәттәй кузгалмады, диваныннан төшмәде, үз куышын шулкадәр дә нык сагынган иде ул бүген...

Сөмбелә кухняга чыккан арада кесә телефоныннан Хәмзә белән сөйләшеп алды.

—Мин риза. Барам,—диде ул гафу үтенергә теләгәндәй, пышылдап кына.—Банкет булмагае, хет әллә шунда туй булсын. Жиһкчеләрне сагындым.

—Вәт молодчиха! Димәк, жомга кич, сәгать дүрткә! Шунда Зәйтүнә дигән яңа җырымны да ишетерсен.

Әлбәттә, Хәмзә артык сораулар биреп төпченеп тормады, жырчының барыбер ризалашасына алдан ук ышанган иде бугай ул. «Түрәләрнең күзенә карап әйтер сүзем бар»,—дигәнен ишетсә исемлектән сызып ташлар иде ул Сөмбеләне...

«Барам!» дигән ныклы карардан соң Сөмбеләнең үзалдына, кинәт, кәефе

күтәрелеп китте. Банкетларда берәүләр ял итсә, икенчеләр эшли. Аның әлеге халәтен ай буе эш эзләп интеккән кешенең, ниһаять, вакытлыча яңа эшкә урнашып кайтуы белән чагыштырып булыр иде. Вакытлыча эшләп, олы сөенечне ваклап-ваклап, фани дөньяда вакытлыча гына җырлап яшәү кебегрәк.

Килгән бер артистны «Хантимер» ресторанының урам ягындагы ишеге төбендә үк каршы алып тордылар.

Сыйлау бизнесының сәер яклары бар… Гадәттә, ашлы-сулы ханәләрне олы юл өстенә, халык күбрәк бутала торган тыкрыкларга, үзәк урамнарга, базар тирәләренә, һич югында билгелерәк тукталыштан күренердәй урыннарда ача торганнар иде. Карурман эчендә супермаркет ачып куйсаң—адашкан аучылардан, качкын-зимагурлардан гайре кем килсен?! «Макдональдс», «Эдельвейс», «Бәхетле», «Кызыл шәрекъ» сарайлары, төнге клублар, элеккеге союздаш республикалардан бүленеп калган «кухня»лар, кафе-бистролар, йөремсәк халык ташкынына аркылы төшеп, салават күпереннән ялтыраган нурлы рекламалары белән юмалыйлар, алгысыталар.

«Хантимер» ресторанының аталышы ике олы агайның исемен бергә кушканнан килеп чыккан. Аның өч кенә каты җир өстендә. Берьюлы житмеш машина килеп туктарлык ишегалды бар. Шәһәрнең төньяк көнчыгыш өлешендә «Хантимер»дән соң бүтән төзелеш юк. Сыйлану ысулы белән күңел ачарга теләгән урта хәлләләр тиз генә эзләп таба алмасын дигәндәй, бу ресторанны хәрби завод белән тимер юл арасындагы ташландык далага илтеп салганнар.

Җырлаганы бар монда Сөмбеләнең, хәтта бер генә тапкыр да түгел. Кануннары кырыс… Соңгы клиент кайтып киткәнчегә кадәр, артистларны җибәрми тоталар. Татарда: вакыт житте, мәҗлес тәмам, барыгыз, таралышыгыз, димиләр—чәй генә бирәләр. Башка рестораннарда төнге уникe житте исә, кыстый-кыстый чәй өләшергә тотыналар. Ә «Хантимер»дә кунак чәйне үзе сорап ала, төн уртасында эчәме ул аны, әллә иртәнге якта телиме—официантлар зарланмый, кисәтми, көйләп тик йөри. Килгән саен Сөмбелә: «Бүтән бармыйм!»—дип тәүбәләп кайта. Ләкин вакыт дигән табиб белән кытлык дигән нужа, уртак телгә килеп, тәки тәүбәдән яздыра тора.

Шөкер, бүгенге банкет »Хантимер» ресторанының үзендә түгел иде. Сәгать нәкъ дүрт тулганда баскыч төбендәге «Тойота» микроавтобусы ян ишеген шудырып ачты, җыелган артистларны төяп алып киттеләр.

Билгесезлек башланды.

«Кая алып барырлар икән?»—дигән шик һәммәсен борчыса да сораулар биреп төпченеп йөдәтүчеләр табылмады. Ләкин, адашудан курыккандай, тәрәзәгә чыраен терәп, һәркем юлны карап барды. Әгәр автобус шәһәр үзәгенә юнәлсә—димәк, банкет Кремль ашханәсендә булачак… Юк, кирегә киттеләр. Автобус, сонга калырга ярамаганны белепме, тукталган урыннардан йолкынып-йолкынып ыргыла. «Божра» дип халык теленә кергән әйләнгеч юлга чыккач, Сөмбелә күңеленнән генә юрарга кереште: «Әгәр хәзер Мәскәү ягына борылсак… Зөя утравындагы резиденциягә, әгәр унга китсәк—Идел буендагысына илтәләр булыр…» Ләкин артистлар, божра юлны кисеп, туптуры урман эченә керделәр. «Димәк, ял базасына дип соңгы нәтиҗәсен уйлап өлгерде. Капкага җитәргә ярты чакрымнардагы борылышта зәңгәр билле ак «Жигули» кырында үрә катып милиция капитаны честь биреп калды.

Менә монысы инде базага килергә лаек булган кунаклар өчен генә салынган махсус юл—ике урман арасына тарттырылган чем-кара күн тасма кебек шома һәм елкылдап ята, машинадан төшеп сыйпап карыйсы килә үзен. Ул шундый туры—шофер кесә телефоныннан капка каравылчыларына алдан ук хәбәр җибәргәндә тизлекне киметмичә генә ике кулын да рульдән алып, рәхәтләнеп сөйләште. Өч тарантас янәшә сыярлык капканың тимер читән канатлары

ачылгач, ГАИ инспекторлары кулындагы аклы-каралы кәрлә кусәккә охшатып ясалган шлагбаум күтәрелде.

Калибрланган юан-юан бүрәнәләре кояш баегач та алтын төсен югалтмаган, капус түбәсе зәңгәр черепицалар белән ябылган, чорма тәрәзәләре бизәкле, унжиде эргәле, Әмир сараедай матурлык янына килеп туктагач үзенне мең ел элек тасвирланган борынгы тарихка әсир төшкәндәй хис итәсен...

...Әмирнең сый-хөрмәт бүлмәсе ни өчендер тәрәзәсез, кирәк чакта тәүлек буе янып, өсталләр өстенә көн яктысына тин нур чәчеп торган бәллүр шәмдәлләрнең ике бәйләме эленгән. Унжиде эргәнең бишесе әнә шул шәмдәлләр кунак башына тимәсен өченгә күтәрелгән булса кирәк.

Киемнәрне алыштырыр өчен уенчыларны аерым бурага озаттылар. Шунда ук аларга швед өстәле әзерләнгән иде. Хәтта артист халкының үз ирегенә куеп каты эчемлекләр дә тезгәннәр, Әмир алдына салмыш баштан чыгып басарга җөрьәт итүчеләр табылырмы, янәсе. Үзләренчә сынаудыр инде бу.

Бүгенге ялханәдә берданбер хатын-кыз заты буларак Сөмбеләне мансард дип аталган чормага яшерергә телә̀деләр. Өскә алып менә торган әйләнмәле текә баскычка тиз генә өстәл читеннән үтеп китешле иде. Ләкин ул бик тиз үтеп китә алмады, табынга карауга күзе буылып туктап калды. Әле дә ярый Әмир үзенең яраннары белән бильярд залында шар тәгәрәтә иде, юкса егерме дүрт өлешкә бүленгән табынны фотога төшергәндәй текәлеп торган Сөмбеләне гафу итмәс иде.

Озын сәке сыман тоташ өстәлне Мари Иле осталары куллан ясап биргәнгә охшый. Һәр тактасы бүрәнәдән яңа гына телеп алынганмы—сап-сары килеш. Аның сәдәлеген капламас өчендер, постау, йә эскәтер япмаганнар, хәзинәдә бары ялангач такта өстенә шул килеш кенә тезелгән. Кая килеп эләккәненне белмәсән—аучылар йортындагыча диярсен. Әгәр кибет өстәле булсамы, шушы кадәр нигъмәтне күтәрә алмас, билләһи сыгылып төшәр иде.

Сөмбеләне этә-төртә өскә ашыктырдылар. Текә баскычтан менеп җиткәнче, чормага кереп киткәнче астан карап калдылар. Әле дә ярый ул ирләр күзен кыздырыр өчен күзәнәкле кара колготки белән кыска итәген кимәгән иде... Ә джинсы чалбарның балак очыннан ак ноские да күренерлек түгел, тар кунычлы күн итеге җыеп тора.

Чорма түшәменә почмак саен сүрән ут эленгән. Шушы яктылыкка күз ияләнгәч кенә шәйләп алды Сөмбелә—бу җылытыла торган мансард бихисап бүлмәләргә бүленгән, тар коридор стенасы гел ишекләрдән генә корылган кебек. Коридорның буеннан-буена ни диван, ни утыргыч, ни өстәл юк. Аптырагач ул берәм-берәм ишекләрне ачып карады—бөтенесе дә бер төрле—поездлардагы купе чаклы гына чолан. Һәммәсендә агач караватъ, суыткыч, урындыксыз өстәл, төнге лампа. Суыткычлары эчемлекләр, кабымлыклар белән дыңгычлап тутырылган. Ковролин идәнгә җиңелчә баскалап ишекләрне санап чыкты—егерме дүрт—нәкъ мәҗлес залындагы өлешләр чаклы.

Чакыра калсалар, озак көттермәс өчен, Сөмбелә борылмалы баскычка якынрак бүлмәне сайлады. Ишекне япмады. Урындыклар булмагач, теләсә-теләмәсә дә караватка утырырга туры килде. Чәчәкле бүз белән пөхтәләп җәелгән урын-җир җылыга кинәнгән гәүдәне үзенә тартып тора. Өстәл лампасын яндыргач, ул суыткыч өстендә «Мен дә бер кичә» дигән әкиятләр китабын күреп алды. Сәхнә туфлиләрен салмыйча гына ятып торырга ниятләде. Аңа бер уй тынгы бирми иде: «Кем бүлмәсе бу, кем мендәре? Кемне көтеп ятам соң мин?..» Һәр кунакны да исеннән таныгандай, мендәрне иснәп карады. Шөкер, тырышып үтүкләнгән шома тукымадан җиләк сабыны исе килә иде. Сөмбеләнең көмеш читлектә бәргәләнгән кенәри хәтлек кенә йөрәге азрак тынычлангандай итте һәм ул, калын китапны түшенә куеп, өн белән төшне бутарлык заманча әкият эзли башлады...

...Борын-борын заман түгел, борын төбендә генә, далалар-чүлләрдә түгел, Казан түрендә генә: әллә Дәрвишләр бистәсендә, әллә Байлар саласында; әллә Югары, әллә Түбән; әллә Олы, әллә Кече; әллә Яңа, әллә Иске бер аланда яшәгән ди Гали атлы гап-гади бер умартачы. Гали яшәгән тарафларда карурманнар нурлы, имәннәре җырлы, каеннар шикәрле, усаклары серле, наратлары өйле, юкәләре чәйле, умарталыклары мәйле булган ди. Әлеге алан Тимер патша биләмәләренә кергән икән. Тимер патша бик озак идарә иткән: калалар төзегән, җир асты юллары салган, күперләр корган, пайтәхетне баеткан, күрше мәмләкәтләр белән тату яшәгән. Тимер патша илләр-җирләрне күп гизгән, дөньяның җиде могҗизасын күргән, әмма чолыкчы Гали аланыннан да гүзәлрәк урын тапмаган. Шуңа күрә дә җәен-кышын, Гали аланына сәфәр кылып, ауга йөрергә, мунча керергә, яңа аерткан балдан авыз итәргә яраткан ул. Әлеге дуслыктан патшага сихәт, умартачыга шөһрәт килгән.

Галинең берсеннән-берсе тере җиде улы булган. Оланнар, умарта ояларын арбага төяп, болыннарга, тугайларга, кырларга илтәләр икән. Кем юкәдән, кем чәчәктән, йә карабодайдан бал җыя ди... Урман үскән, еллар үткән. Патша кунакка килгәндә Галинең бал җыеп, самавыр куеп, күбәләк куып йөргән малайлары инде буйга ныгыган, ил гамен иңнәренә алырлык ирләр булып җиткән ди.

Умартачы үлем түшәгенә яткач Тимер патша аның белән бәхилләшергә дип килгән һәм Галигә әманәтен әйткән:

—Кылган игелегенә рәхмәт йөзеннән, мин синең җиде улыңны да урынга куям,—дигән.

Тимер патша сүзендә торган, кече улны әтисе аланында нигез хуҗасы итеп калдырган. Уртанчысына ил-юл аманлыгын тапшырган. Олысын—Әмир атлысын патшалыкка үз янына алган.

Мәрхәмәтле патша Әмиргә бөтен казнаны ышанып тапшырган, уттан-судан, җирдән-һавадан акча эшләргә өйрәткән. Патшаны тәхетеннән төшерсәләр—Әмир дә илтәбир буларак үзенең диванын югалтасын белгән, шуңа күрә дә яшәп калыйм дип яшәгән ул: төрле утрауларга, урманнарга зиннәтле сарайлар корган, карачыларына атсыз арбалар, тимер кошлар бүләк иткән, яраннарына вилаятьләр, җирләр өләшкән, башкала уртасына туган авылын күчереп зиннәткә төргән... Әмирнең мәмләкәт тарафларында ханәләре шул тиклем бихисап булган ди, аның кайда төн үткәрәсен, кем кулыннан хөрмәт күрәсен, кайсы канизәктә тукланасын газиз бануы да белмәгән ди хәтта. Тора-бара Әмир тәмам борнайланган: юлда йөрсәң салым салган, урманга керүчеләрнең исәбен алган, һава сулаган өчен ясак җыйган, чишмәләрне сатуга куйган. Сыйланганда, колач җитмәслек кыздырылган мәрсин балыгы эченә керкә уылдыгы тутырып китерергә куша икән дә, кире борып, кабыклы бәрәңге сорап ала ди. Атсыз арбалар җимереп күңел ачкан, җырчыларны, шамакайларны җыеп төрле сынаулар үткәргән ди ул.

—Нинди җыр өйрәнеп килергә кушкан идем әле мин сиңа?

—«Җанкай җанаш»ны.

—Өйгә бирелгән эшенне эшләдеңме?

—Юк шул. Мәскәү кенәзлегеннән яңа гына кайтып төштем. Җыр өйрәнергә вакыт булмады. Телисезме, «Кәвәл авылы көен» җырлыйм?

—Следующий кем анда?

Җырчыны алып кереп киттеләр. Келәмгә түгәрәк гәүдәле шамакай чыгып басты. Микрофонны чүкеч сабы тоткандай кыскан. Буш кулы белән кесәләрен капшап тарак эзләгән ише кыланды. Ул таракның түш кесәсендә икәнен бөтен татар иле белә, юкса... Ә түгәрәк шамакай шул рәвешле уйнап вакытны суза. Тел ачкычы булырдай беренче мәзәген сайлаган арада каш чолымына тарак элеп куя.

Әмирнең кәефе шәп күренә иде. Жәйге ялга әнисе янына кайтып, тау итәгендәге чирәмлеккә сузылып яткан кунак егет кебек, ике кулын баш астына салган да кәнәфидә ял итә. Келәмгә кем арты кем чыгасын алдан ук белә идеме, шаян сүз ишетергә әзерлеге шушы идеме—ул хәтта шамакайга күтәрелеп тә карамады.

—Сүгенеп сөйли торган мәзәкләрне синнән күбрәк беләбез. Сәяси ялганнарың бармы? Халык авыз ижаты үзенең хужалары турында ниләр сөйли?

—Сүгенү дигәннән, сүгенү буенча ярыш үткәргәннәр. Өченче урынны сәүдәгәрләр яулаган... Көтүчеләр икенче урынга чыккан. Ә хакимият башлыклары сүгенү буенча беренче урында ди...

—Бала чагымда минем дә көтү көткәнем бар... Сүгенү буенча главалар түгел, көтүчеләр беренче урында булырга тиеш.

—Юк, галиҗәнабым, көтүченең сүгендерерлек хайваны йөзләп кенә...

—Ә минеке?!.—Үз соравының җавабын үзе үк белгәнгә күрә Әмир мужикларча кычкырып көлеп җибәрде. Бу инде башкаларга да көлергә ярый дигән фал иде. Ниһаять, урыннарына кадакланган балбаллар кебек утырган яраннары да хихылдашты. Әмир көлгән арада берәр чәркәне түнтәреп, кабымлык чәпелдәтеп өлгерәселәре дә бар иде әле аларның...

Әмир, көлүеннән кинәт туктап, шундук боерык фигылькә күчте.

—Сөйлә!

—Кайсысын икән? Сезнең хакта да яңа әкиятләр күбәйде. Халык бит ул шундый—дөреслекне әйтергә курыкса әкиятләр чыгара башлый.

—Ә син курыкма! Падишаһ турындагыларны сөйлә!

—Сүләгән өчен берни дә булмасмы соң?

—Булмас. Шелтә дә булмас, янау да булмас... фатирың да булмас, мактаулы исемең дә булмас. Пайтәхеттән куылап, кәмитче сукбай булып тик йөрерсең шунда!..

Яраннарга тагын бер чәркә күтәрерлек җае килде.

—Алайса, куркырлык нием дә калмады инде. Сүлим...

—Сүлим дисең, син мишәрме әллә?

—Тегел.

—Татар мыни?

—Да... Сүлим. Менә тыңлагыз...

«Син бер онгайдан күрше мәмләкәт белән дә идарә итә аласыңмы?»—дип сораганнар Падишаһтан.

«Әйе!»—дигән Падишаһ.

«Ә барлык шәрык илләре белән?»

«Барлык шәрык илләре белән дә житәкчелек итә алам...»

«Әгәр бөтен Жир шарын ышанып тапшырсалар?»

«Пожалуй, бөтен Жир шары белән идарә итә алмам, туганнарым житмәс...»—дип көрсенгән Падишаһ...

Әмир шамакайны шундук туктатты:

—Сине ошбу келәмдә чыгыш ясаудан өч елга мәхрүм итәм.

—Өч кенә елгамы?.. Ә мин әле сезне диваныгыздан тагын биш елсыз төшмәссез дигән идем...

—Следующий!.. Берәрегез «Жанкай жанаш»ны җырлап бирәме инде бүген, юкмы?!

Җыр башланыр алдыннан гына туа торган тынлык урнашты. Ләкин бу тынлык күпме генә сузылмасын—җыр башланмады. Кайдадыр көнгерә тибенгәндәй итте. Сикергәк адымнар якынаеп чормага күтәрелде...

Сөмбеләне тумышыннан бирле шушылай куркытып, әкиятле төшләрен бүлдереп, мыскыллап уятканнары юк иде әле.

—Карале, гырлап йоклап ята! Йоклап акча эшлисең килсә «Досуг»ка ялланырлар! Без анда көйсез кубызга биибез. Төш тизрәк!

Тавыш җепселләрен карлыктырыр өчен «сандугач йокысы» да җитә. Һәр тамаша алдыннан кыллы музыка коралларын ничек көйлисе булса—йокыдан уяну белән моңны көйгә салу өчен дә «распевка» ясап чыныктырып алырга кирәк. Сөмбеләнең моңа вакыты юк инде, ул чорма баскычыннан төшкәндә чарасыздан тамагын кыргалады, юл уңае гына чәчен төзәткәләде, күлмәген сыпыргалады.

Гармунчы келәм янында иде инде. Сөмбелә: «...месез?!» дип кенә күрешкән булып, кунакларны күздән кичерде, дөресрәге күңел түрендәге хәтер альбомына салынган рәсемнәр белән чагыштырып алды. Күргәне бар инде бу рәсемнәрне, бөтенесе дә таныш. Банкетларда гел бер үк кешеләр. Бүгенге егерме дүрт балбал мәҗлеспәрвар җитәкчеләребезнең меңнән бере генә...

—Максат,—дип эндәште Сөмбелә киң авызлы, җәенке иякле, калын соры кашлы, керпе чәчле гармунчы егеткә,—«до-мажор»дан, яме...

Чалкан яткан Әмир кырын борылды. Яраткан җырын ниһаять тыңлау сөенеченнән түгел, ә бүгенге малайлар чуагында хатын-кыз тавышы ишетүдән сәерсенгән сораулы карашын яраннарына күчерде. «Син чакырдыңмы моны?» дигәндәй, ым кагып кайберләреннән аеруча җавап көтте. Әмма яраннар акланып баш какты.

Максат гармун уйнаганда җырчыларның кирәге юк.

Кечкенәдән гармунсыз, җырсыз-уенсыз үскән Әмир аны туктатырга җөрьәт итмәде. Сөмбеләне тыңларга мәҗбүр булды.

...Утырдым да атның, һай билене,
Биш әйләндем Казан каласын...

Кемнең авызы буш—шулар кул чапты. Әмир, сул кулына таянган килеш, һаман да әле кырын ята иде, яраткан җыры хакына ашаудан-эчүдән тыелып торды. Озакка сузылган соңгы аккордны да бүлдермәде. Гармунчы бөтен күрәгенә киерелеп моңайган баянны кочагына кысып тынып калгач кына Сөмбеләгә сүз катты.

—Каян килдең әле?

—Чормадан төштем.

—Чормада йөрергә син ана мәче түгелсеңдер ич?..—Әмир бераз кунакларга көлеп алырга ирек бирде.—Кайсы авылдан, дим?

—Балантаудан.

—Балантаудан?!! Анда гел караклар гына яши диләр...

—Ә кем урламый инде хәзер...

«Менә без, мәсәлән!»—дип әйтергә теләгәндәй, Әмир кырын яткан жиреннән тора башлады.

Җыр бетүгә баш иеп, артистлар янына кереп китәсе генә калган иде кана, ә Сөмбелә, җүләр, килгән-килгән, инде тагын берәрне җырлатырлар дипме, саубуллашырга ашыкмады. Инде һич кирәкмәгән җирдән, Әмир белән икәүдән-икәү сөйләшүгә күчте. Хуҗа кеше кунакларның кәефен күтәрердәй мәзәк хәл чыгармакчы иде. Ләкин халыктан бөртекләп җыелган казна хисабына көрәйгән түрәләр каршында салымын түли алмаган ялчы хәлендә басып торудан хурландымы, әллә фатирына приставлар килеп төшкән күршесе Мөнирә карчык өчен үчектеме, бүгенге эстрада сәхнәсендә хөкем сөргән хаос өчен әлеге «балбаллар»ны гаепле санадымы—рәнҗүле сүзләре күперде Сөмбеләнең, кара-каршы сөйләшүе Әмиргә каршы дәшүгә күчте. Һәм татлы әкият булып башланган төш әкренләп кырыс чынбарлыкка әверелә барды...

—Кемнең күпме урлаганын эшеннән алынгач кына саныйлар.

—Менә бу әфәнделәрне беләсезме?—дип, Әмир кунаклар тарафына кулын изәде.

—Белмичә. Һәммәсенең диярлек визит ярлыклары бар миндә, шушылай төрле банкетларда күрешкәләп торабыз. Мәҗлес азагында әфәнделәр юмартлана, иганә таулары вәгъдә итеп телефон номерларын өләшә башлый. Иртәгесен исләренә төшереп шалтыратып карыйсың... ә анда һаман да шул секретарьша тавышы: «Ул юк, киңәшмәдә... юлда... чит илдә... сарайда...» Бүген иртән генә берсенә шалтыраткан идем әле: «Федераль округ председателе чакыртып алды, бер атнасыз кайтмас!»—диделәр.—Һәм Сөмбелә җаваплылыгы бик үк чикләнмәгән «Ташлы» фирмасы гендиректорына шундый киная белән карап алды ки—тегесе урындык аркасына сенеп, юка гәүдәсен Холдинг президенты күләгәсенә яшерде.

—Ә ул әфәндене вертолёт белән кызлар куып йөри димәделәрме?

Кунаклар дәррәү күтәрелеп көлешкәч, Сөмбелә җинел сулап куйды. Ходайның рәхмәте белән аңа: «Кызый, җитәр, тукта, хуҗаларның кушканын кыл, кылганын кылма!»—дигән гакыл килде.

«Вәт гөнаһ шомлыгы—җырчы дигән кодрәтеңә масаеп, Әмир белән әйтештең түгелме? Әрләшкәндә Ходай бәндәсе үзеннән өстен көчләрдән вакытлыча гына булса да азатлык яулап ала, уйлаганын әйтеп, яшергәнен күрсәтеп өлгерә. Әле дә ярый, әйткәләшүләр озакка сузылмый. Көчсезләрне исән-имин саклар өчен Тәңрең күп әрләшерлек куәт бирми.»

—Чакыруыгыз өчен рәхмәт. Кәефегезне күтәрә алмаган булсам—гафу итәрсез.

—Артист җырласын гына ул. Сөйләүчеләр җитәрлек!—диде Әмир һәм кабат диванына чалкан ятты. Бу аның җырчы белән саубуллашуы иде.

Сөмбеләдән соң келәмгә Хәмзәне чыгардылар. Башка шамакайлардан аермалы буларак ул сөйли-сөйли җырлый, җырлый-җырлый көлдерә белә иде. Аның хәерчеләр өчен язылган «Колбаса» дигән җыры кунакларга бигрәк тә ошады, чөнки табынга бер генә телем колбаса да куелмаган иде.

—Синең җүнлерәк җырларың бармы?—Әмир инде торып өстәл читенәрәк якынайган да кабыклы бәрәңгене ярып, тоз урынына кызыл уылдык ягып маташа иде.

—Ник булмасын!?—диде Хәмзә бер күзен японнарча хәйләкәр кысып, икенче күзен яһүдләрчә акайтып.—Әйтик, Зөлфиянең «Миләшкәем» җыры, Әлфис мәрхүм җырлап калдырган «Кил син, кил син, үзең кил», Равил башкара торган «Тымытыгым»... Күп инде алар.

—Да ну! Азаматка да берәр яңа җыр язып бирәсеңме? Болары туйдырды инде.

—Толк ни какой. Язганнарына да түләгәннәре юк әле.

—Сиңа күпме тиеш алар?

—Кем санаган инде аны кинәт кенә. «Шаян-шоу»ны авылдан авылга йөртер өчен бер микроавтобус ярап куяр иде...

Әмир Хәмзәгә кул бирде:

—Иртәгә минем управляющий янына килерсең.

Шул мизгелдә, егерме дүрт яран арасыннан, Азамат килеп чыкты. Ул һәрвакыт иң кирәкле чакта, кирәкле җирдә, кирәкле кешеләр янында була белә.

—Котлыйм, Хәмзә! Мондый зур презент—һәркемгә дә тәтеми. Безнең Әмир сүзендә тора белә! Ягымлы сүз—җан азыгы. Безнең Әмир яхшылыкны бәяли белә!

Сәхнәдәш егетнең бу сүзләре бил бөгәргә яратмаганнар өчен җәза рәвешендә яңгырады, чөнки ул Әмир авызыннан тартып алгандай әйтелде.

Дөрес сүз—туры сүз. Турысын әйткән—дусларын югалткан.

Туры сүз—утлы корал.

Утлы коралны теләсә кем йөртә алмый.

Җитәкче кеше никадәр биектәрәк утырса—туры сүздән шулкадәр тизрәк яралана.

Ялынычлы кеше генә туры сүзгә түзә ала. Сөмбелә ялынычлы кеше. Бүген дә аңа түзгән өчен гонорар түләделәр.

«Мальчишник» ике пәрдәле, җиде күренешле спектакль кебек төгәл ике сәгать барды. Артистлар өйгә киеп кайта торган киемнәрен эзләгән арада кунаклар утырган урыннарыннан юкка чыккан иде инде.

—Мунчага киттеләр...—дип пышылдады кемдер.

Сөмбелә егерме дүрт кеше сыярлык ләүкәне күз алдына китереп карады: театр сәхнәсе чаклы бардыр ул...

Артистларга капкадагы шлагбаум янына чыгып басарга куштылар. Автобус шунда килеп аласы иде. Мәҗлестә буыны йомшарган тәнне суык куырып алды. Ярты сәгатьләп көткәч туры сүзен пышылдап кына әйтә торган теге тавыш тагын юатты.

—Олег булса бик төгәл йөри иде. Юраның сменасыдыр бүген—он цехында аның бер кызы бар, шуны утыртып килгәли, урман юлында камыр изәләрдер...

—Ну, җегетләр, иртәгә килгән булсагыз өр-яңа «Газель» белән генә алып кайта идем үзегезне.

Суыкта авыз үзеннән-үзе ыржаеп торса да Хәмзәнең бу сүзеннән беркем көлмәде, аның машина отуы бөтенесенең дә кәефен кырган иде.

Ап-ак урманны телеп, яңа каештай тартылган чем-кара асфальт өстенә фара нурлары килеп кергәч тә сөенүләре заяга булды—туксан тугызлы «Жигули»га дүрт кыз төялгән иде. Аларны ерактан ук күреп шлагбаум үзеннән үзе күтәрелде. Интим мөнәсәбәтнең төрле юнәлешләре турында артык хәбәрдар булгангамы, Сөмбелә «мальчишник» дигән күңел ачулардан шикләнә дә, өнәми дә. Шөкер, дүрт кыз килде, араларында дүрт егет бар икән бит, дип, бик сөенде әле ул.

Алай да, теге пышылдау остасы караңгылыктан файдаланып төрттереп куйды.

—Сөмбелә, әллә син дә боларга ияләсеңме?

Тизрәк җавап кайтарырга кирәк иде.Әгәр «ияләсеңме» дигән сорауны фәлсәфи фигыльләргә таратып карасан—тузынып китеп гауга чыгарырлык нигез бар. «Әллә яратмаганнар дисеңме? Мин гомер буе бер генә кешенеке булдым. Фатир алыр өчен дә җәелеп ятмадым. Филармониягә дә гинекологлар аркылы урнашмадым. Күпме кеше ялынып йөрде минем арттан, ышанмасагыз, әнә, визит карточкаларын килеп санарсыз—туфли тартмасы шыгрым тулы. Микрофонны сүндереп җырлый торган бүгенге йолдызларыгыз кебек имтиханнарны карават өстендә тапшырмадым...» Әйтмәде, шөкер, уйлап кына өлгерде. Әйтә калса зурга китәсе, әшәке сүзләргә батасы, ирләр гайбәтенә быкырдап бетәсе иде. Уйлар арасында туган паузаны телсез корал итте Сөмбелә. Ашыгыбрак ирештергәнен аңлапмы, пышылдаучының тыны чыкмады.

—Машиналарында бүтән урын юк ич!—Менә шушы тапкыр җавап Сөмбеләне саклап калды.

Кышкы төннең кыл бер уртасында галибанә тынлык хөкем сөрә. Шау-шулары, ыгы-зыгылары, мәшәкатьләре белән теңкәгә тигән иске көн ниһаять үтеп киткән. Хәл итеп өлгермәгән эшләр өчен, борчылдың ни, борчылмадың ни, барыбер шул килеш калган инде. Яңа тәүлек туып кына килә, бар хәрәкәт тирән йокыда, хәерсезлек яктыга чыкмаган әле. Ишегалдында өшеткеч бушлык, подъезд ишекләре ял итә, урамнар хәл ала.

Сөмбелә, артык төнгә калганчы дип, кайтышлый ук күршесе янына кереп чыкты. Мөнирә әби «Гаилә» каналыннан иске заман киноларын карап утыра.

Кыстыбый пешергән—тешкә йомшаклыктан түгел, кәефе шәп булганда гына өеп куя ул аны.

Әнисе ауга чыккан песи кебек кенә йөрергә өйрәнде, ишек ачып кергәнен Зәйтүнәсе сизмәде. Күчтәнәчкә тигән кыстыбыен ашап бетермәс килеш урын өстенә ауган, көне буе имтиханга әзерләнеп нык алҗыгандыр, күрәсең. Кызның сулыш алганы әни кеше сизәрлек кенә.

Урамда да, күршедә дә, өйдә дә тыныч. Сөмбеләнең генә күңеле тыныч түгел. «Юлбарыс» холдингының чираттагы бәйрәменә ник чакырдылар соң аны? Бактың исә ирләр мәҗлескә кунак булып ялгыз гына килгән, артистлар да гел ирләр генә, пешекчеләр, хәтта сыйлаучылар да ачык-күрән алъяпкыч япкан кысык күзле егетләр иде. Бер җыр өчен кечкенә корабка хатын-кыз алалар диме?! «Җанкай җанаш»ны җырларга Жора юк икән, Азамат үзе шунда иде ич!.. Ике тәрәзәле өйдә үткән яшь гомер мажара көтә дә тора. Берәр хәсисен рәнҗеттеме, әллә киресенчә өмет бирдеме? Байлар уенымы бу, әллә мылтык көпшәсе аша күзәтүләреме? Берәр эзләүчене ялласаң—эшләгәнең түләргә җитмәс...

Сөмбелә кием шкафы өстендәге шүрлектән рәсемле катыргыдан ясалган тартма алып килде. Утыз җиденче размерлы туфлидән бушаган кап визит карточкалары белән шыгрым тулы—егерменче гасыр азагында башланган базар ислахының соңгы унбиш елы сыйган. Актара башлагач, колак төбендә авазлар янара: мәйдан ораторлары, сайлау көрәшчеләре, банкет сандугачлары, түрәләр вәгазе—берсен-берсе бүлдереп оран сала кебек. Җәмгыять үсешенең нигезендә—бу урында кичә син идең, бүген мин; кичә сезнекеләр безне, бүген—безнекеләр сезне, дигән сүгенү эпитетлары ята икән. Трамвай-троллейбус тукталышларындагы киоскларның директорлары, кунакханә номерын офис иткән генераль директорлар, хәер-хәйрия акчасына төзелгән фондлар, һавалы компанияләрнең президентлары күбәйгәннән күбәя бара. Тузга язмаган оешма исемнәрен ташка бастырып визит карточкалары чыгарулар—эшләүне түгел, фәкать акча эшләүне максат итеп куйган текә җитәкчеләрнең мең-меңлек ярышына, дөньяны яулау хөрриятенә әверелде.

Эстрада ялтыравык утрау булып кыл уртада калды. Үзгәртеп «кыруның» бөтен юллары шушы утрау аша үтте. Океан артыннан килеп кергән бер генә яңалык, бер генә термин да сәхнә базарын әйләнеп узмады. Сайлаучыларны артистлар тирәсенә җыйдылар, олылау чараларына җырчы чакырдылар, Яңа байларның варислары өйләнешкәндә туйлар концертка әверелде, һәр яңа вакыйганың рекламасын күренекле, талантлы шәхесләрдән әйттерделәр, сәүдә мәйданнарына җыелма сәхнәләр кордылар, күп кенә холдингларда, «АО»ларда, министрлыкларда тамаша оештыручы методистлар, баянчылар штаты булдырылды. Мәдәният министрлыгы, филармония диктатыннан бәйсезлек яулаган артист үзе дә сизмәстән яклаучысыз калды, ул хәзер чакырган җиргә баручы, түләүчегә күңел ачучы уен коралына әверелде. Нәтиҗәдә җыр белән бию бергә буталды, кендекләр ачылды, нәфис сүзне очсыз мәзәк алыштырды, түләүле фабрикалар йолдыз чүки башлады, сәнгать тәненә сусаган Яңа байлар өчен төнге клублар үрчеде.

Җыр яңгырасын өчен чикләр кинәйде. Җырчы кызлар чит ил байларына кияүгә чыгып хәзер Казан сәхнәсенә кунакка кайта ала. Алмания, Австралия, хәтта Англиягә барып сабан туйлары үткәреп кайту берни тормый. Татар артистлары Пенза, Төмән, Самара, Башкортстанга барып мәмләкәт башлыкларын сайлауда катнаша алдылар. Әвәл алар альтернатив кандидат өчен көрәштеләр, ул үтмәгәч икенче турга чыгып, тамашачыларны элеккеге хуҗага тавыш бирергә үгетләделәр...

Сөмбелә катыргы тартманы бушатып берәмтекләп яңадан тутыра башлады. Теге егерме дүрт әфәнденең визиткасын каршысына тезеп күңеленнән генә

сорау алырга иде исәбе. Берничә исемгә килеп төртелгәч ниятеннән язды, искә төшереп алырдай шәхесләр болай да шактый иде әле монда. Бәлки сары табышмакның җавабы табылыр дип җентекләбрәк тукталды. Газ плитәсенә чәй куеп җибәрде. Йокы качкан иде инде... Чәй кайнаган арада кухнядагы биек суыткыч түбәсеннән амбар кенәгәсен үрелеп алды. Сөмбелә бу калын дәфтәрне үзенчә шаяртып «вахта журналы» дип атый. Ерак гастрольләрдән алҗып кайткач, беркавым хәл җыя да: «Кызым, китер әле теге вахта журналын, тәэсирләре суынганчы язып куйыйм»—дип соратып ала. Кайда ниләр җырлаган, кемнәр катнашкан, халык яратып кул чапканмы, нинди маҗаралар булган, кемнәр, нинди спонсорлар белән танышкан—соңгы егерме еллык сәхнә тормышы кәгазьгә теркәлеп бара. Хан мәҗлесен дә ул 2004 елның 24 гыйнвары дип бөртекләп язып куйды. Аннан чәй эчә-эчә, кайбер визиткалар бүләк ителгән көннәрне вахта журналыннан эзләде. Мине тап, мине, дигәндәй исем өстенә исем өелде, журнал битләре бөгәрләнде, көннәр-еллар әле алга, әле артка күчте. Язылганын «эһ!» дигәнче укып чыгарлык язмаларга көннәр буена сузылган, гомер буе онытылмаган вакыйгалар сыйган иде.

1993 елның 2 сентябре...

Казан елга портының беренче причалына өч палубалы «Леонид Соболев» теплоходы килеп туктады. Пассажирларның кемлеге алдан ук мәгълүм булса да кая барасыны беркем белми иде әле. Шәһәр башкарма комитетының мәдәният идарәсе тутырган исемлеккә Марат Гомәрнең исемен үгетләп диярлек яздырды Сөмбелә. Хәниянең баянчысы бар, Зөһрәнең ире баян алып килә, сиңа махсус гармунчы чакыруның бөтенләй кирәге юк, «Уйна гармун» фестивале түгел—җитәкчеләрнең культуралы ялын оештыру, артистлар саны чикләнгән, дип бик нык каршы төшкәннәр иде. Сөмбелә һаман үҗәтләнде: «Кеше музыкантлары белән теплоходта репетиция ясап йөрергә мин үзешчән түгел. Марат Гомәр бөтен репертуарымны белә, кайсы кунак нинди җыр сораса да курыкмыйм.»

Барыбер ризалашмадылар.

—Алайса мине дә исемлектән сызыгыз!—диде Сөмбелә, кул селтәмичә генә.

—Тукта, тукта, кызма әле син, Сөмбелә! Ярар соң, алып кил гармунчыны!—дип, шул минутта ук кире чигенде идарә башлыгы.

Сәер, ул бит хәзер: «Син үзеңне Җир шарының кендеге дип белдеңме әллә?!»—дияргә тиеш иде. Табеевлар заманыннан калган әлеге канатлы шелтәнең телдән-телгә күчеп киң таралган чагы иде әле бу. Бүлмәсеннән куып чыгарса да бер сүз әйтә алмыйсың. Горисполком шәһәрдә фатир өләшүче берданбер мәккә. Чакырсалармы—исән чакта престижный фатирга чиратта калган идем дип, билләһи, теге дөньядагы җырчыларың әйләнеп кайтыр... Шәһәр башлыгы имзасыннан башка бер генә кешегә, бер генә оешмага да фатир ордеры бирелми. Юк, идарә башлыгы җикеренмәде, тавышын күтәрү түгел, чыраен да җыермады хәтта, киресенчә, елмаеп озатып калды. Чакыру кагыйдәләренең нинди юк... Сөмбеләнең теплоходка керүе мәҗбүри булгач, кем сораткан сабыр гына көтәсе кала.

«Кем?» дигәне причалга килүгә үк беленде. «Мөмкинме?»—дип Сөмбелә кулындагы сәфәр сумкасын күтәрешергә алынучы кеше Казанга иң ерак районның хакимият башлыгы иде! Мәктәп баласы булса—ул да сыйныфташ кызыйның букчасын тиктомалдан күтәреп йөрмәс... Ә монда күкрәгенә депутат билгесе таккан, никахка килгән кияү егетедәй чем-кара костюм-чалбар кигән, жете аклыгыннан күз камашырлык күлмәк якасына ут янып торган кызыл галстук элгән алпамшадай әфәнде нииндидер бер Балантау авылында туып-үскән колхозчы кызына йөк ташучы сыман иярсен әле!..

Сөмбеләнең җырларына гашыйк микәнни? Алай дисәң, инде сер түгел, җырларына гашыйк дип башланган уенның азагы—әлеге дә баягы шул—җырчының үзенә гыйшык аңлату белән бетә. Сөмбелә бик күптән мәктәп баласы түгел инде, өйләнергә йөргән егет белән күңел ачарга килгән ирләр холкын гына бутамас.

Басма кичкәндә бер түрәнең шоферга җиткергән әмере колакка чалынды:

—Кичке алтыга, как штык, килеп баскан бул!

Ун сәгатькә сузылачак сәфәрнең юл озынлыгын күз алдына китереп карады Сөмбелә... Ялыктырасын алдан белә—туйлар да уңышар сәгать бармый хәзер.

Төгәл әйтелгән вакытта трапны җыеп алдылар, теплоходның тышавын ычкындырдылар. Мәҗлес Идел уртасына җиткәнче ярдагы «Волга»лар таралышмыйча торды. Каяндыр капитан фуражкасы табып алган шәһәр башлыгы соңлап булса да команда бирде:

—Отдать швартовы!

Су өстендәге иртәнге җилдә озак бөкшәергә туры килмәде, артистларны чамасыз ашыктырып каюталарга урнаштырдылар. Урнашу дип—кеше саен берәр аерым бүлмә, ачкычлары ишектә. Теге Кем, Сөмбеләнең кайсы каютага урнашканын белергә теләп, озатып куймакчы да иде, кают-компаниядән шәһәр башлыгының карлыккан тембрлы баритон тавышы ишетелде:

—Житәкче составны срочно биш минутлык киңәшмәгә!

Теге Кемнең кают-компаниягә кереп югалуы булды, Сөмбелә, эз югалтыр өчен, иң түрдәге бүлмәгә шылды. Марат Гомәрне янәшәгә урнаштырып нигез күршесе итте. Сигез йөз кешегә исәпләнгән ак корабта качышлы уйнавы кыен түгел... Юка пластик стеналар калын тукыма белән тышланган, күрше-тирәнең сөйләшкәне ишетелмәсә дә кирәк чакта шакып гармунчыны чакырырга була. Монысы әлеге шартларда бик мөһим.

Шәһәр башлыгы фуражкасын салмаган, артистлар ягына рупор аша гына кычкырды:

—Бөтенегез дә кают-компаниягә!

Артистлар «тревога» белән уятылган матрослар кебек кабаландылар, коридорга чыккач кына чәчләр төзәтелде, төймәләр-путалар каптырылды, туфли йөзләре сөртелде.

Сөмбелә Марат Гомәр белән янәшә утырмакчы иде, өлгермәде, теге Кем килеп, аны кулыннан тотып, үз өстәленә алып китте.

Алдан игълан ителгән биш минутлык киңәшмәдә өчәр йөз-дүртәр йөз чакрымнан иртәнге сигезгә килеп өлгергән район хакимияте башлыклары хөрмәтенә берәр бокал ром бушатылган иде инде. Шуна күрәдер, шәһәр башлыгы оештырган уен кагыйдәсенә тиз күнделәр.

—«Леонид Соболев» Җир тирәли сәяхәткә чыкты. Корабльнең штурвалы минем кулда. Мин кем булам инде?

—Адмирал!—дип кычкырды кырык дүрт район берьюлы.

Шәһәр башлыгы балдаклы бармагы белән өстәлгә өч кат төртеп алды, шымчы юкмы дигәндәй як-ягына каранды.

—Авызыгыздан җил алсын. Үзе ишетмәсен. Мин капитан гына. Ә сез...

—Без юнгалар!

—Юк, сез мичманнар. Ә менә тегеләр?—диде ул бер иллюминатор төбендәге ике өстәлгә сыенган артистларга таба имән бармагын төбәп.

—Пиратлар!

—Юк. Алар чегәннәр!—Артистлар ягыннан ризасызлык урынына алкышлар яңгырагач, капитан дәвам итте.—Мин кубрикка кереп ял иткән араларда капитан мостигында үз урыныма өлкән мичманны калдырам,—диде ул Сөмбелә кырындагы теге Кемнең иңбашына учын куеп. Капитанның уч төбе адмирал погоны чаклы иде...

Сөмбелә вәзгыятькә төшенә башлады кебек. Өлкән мичман капитанның ышанычлы кешесе, таянычларының берсе икән ләбаса... Димәк, теплоходка кемне һәм ни өчен чакырасын алдан ук хәл итә алган.

Өлкән мичман җөмһүрият чигенә терәлеп торган районнарның берсендә мактаулы хуҗа. Коммунизм төзегән чорларда ул КПСС райкомының I секретаре иде, «суллар» «уңга» борылып баскач, шул ук районда хакимият башлыгы булып калды. Бүгенге татар түрәсенә хас бөтен сыйфатлар да бар үзендә, ул физик яктан көчле, тик көйсез; авторитар җитәкче, үзе ярдәмчел; рекордлар куярга ярата, әмма кызлар алдында каушый; Алыптай гәүдәле, мәгәр йомшак күңелле; законны әйбәт белә, шулай да кирелегә белән дуамал... Сүз ирегенә ышанып, район халкы аның өстеннән бик күп шикаять язып өлгерә. Инде, калага күчереп үстерәләр икән, дигән хәбәр йөри, һәрхәлдә Сөмбелә шулаерак дип ишетте. Кадрлар миграциясе, сайлауларда җиңәсе кандидатлар, җитәкчеләр шәҗәрәсе кебек четерекле юрамышларның төгәлрәк җавабын артист халкы алданрак белә. Чөнки һәр сәяси яңалык банкетларда туа...

Күчмә утраулар, якорьле рестораннар, йөзә торган мунчалар, оча торган кинәшмә заллары чоры бу. Бүгенге сәяхәт тә гади бер күңел ачу гына булып калмас.

Капитан кечкенәдән диңгезләр гизәргә хыялланган иде. Хәрби лайнерларда радист булып хезмәт итү теләге белән ул элемтә техникумын да тәмамлады. Ләкин билгеле бер сәбәпләр аркасында Армиягә алмадылар. Аның хыялы ун елдан барыбер гамәлгә ашачак, шәһәрнең мэрлыгына әзерләнгәндә: «Казна—диңгез, без—пароход!» дигән тәвәккәллеге өчен бу капитанны Япон диңгезе ярларына контрадмирал итеп җибәрәчәкләр... Хәер, бу турыда әлегә беркем дә, хәтта адмиралыбыз үзе дә белми.

—Господа офицеры! Август ае коры килде. Урып-җыю гөрләп бара. Мин сезне бүген махсус җыйдым. Кырларга чыгып, игенчеләргә комачаулап йөрмәсеннәр дидем. Колхозчылар бер генә көн булса да тынычлап эшләсеннәр дидем... Сез дә тынычлап ял итегез, хатыннарыгыз да, кредиторларыгыз да эзләп табалмасын дидем.

Капитан үзенең яңа вазифасын уен кагыйдәсенә туры китереп дәвам итте.

—Лоцман! Лоцман!.. Колак бае...

Штурвал күперчегеннән җавап килде.

—Тыңлыйм!

—Курс Nord-ost, скорость пять узлов в час. Малый вперёд.

—Есть, малый вперёд![1]

Идел өстендә штиль хөкем сөрә. Төньяк офыкта күпергән болытлар, вак-вак күбекләргә таркалып, җил чыгармыйча гына теплоход өстеннән үтеп китә. Көнчыгыш иллюминаторлардан кергән кояш баганасы тигез янмаган лампа кебек, янып-сүрелеп, янып-сүрелеп ала.

Кок өстәлдән өстәлгә күчеп кемгә нинди шулпа кирәклеген белеште.

Бу кок ризыкларны бүлеп өләшүче генәдер, дип уйлап куйды Сөмбелә. Кухняны термослар белән китергәннәрдер. Шушында ук пешкән ризык булса симез калҗа, шулпалы өчпочмак, итле бәлеш исе борыннарны кытыклап, нәфесне котыртып торыр иде. Ә кают-компаниядә кипшегән яңа буяу исе эленеп тора. Юкса өстәлләр дәүләт белән тулы, берсе-бер буш түгел.

Тостлар әйтүне, мөгаен, беренче булып амазонкалар уйлап чыгаргандыр. Сугышчы хатын-кызлар гел яуда, гел походта. Ирләре белән бик-бик сирәк, бары тик балага узу өчен генә күрешкәннәр. Малай туса—әтиләренә калдырып киткәннәр, кыз баланы үзләре белән алып сугыш кырында тәрбияләгәннәр.

[1] Бу сөйләшүләрне тәрҗемә итүнең әллә ни әһәмияте юк (К. К.)

Жину яулаган көннәрдә, кырда учаклар ягып, күнел ачулар оештырганнар. Бузалы касәләр күтәргәндә амазонкалар бер-берсен мактап купшы сүзләр әйткәннәр... Дәверләр алышынып, яуга чыгу хатын-кыз иненнән төшкәч, купшы сүзләрне ир сугышчылар әйтергә тиеш булган... Озын-озак, күп сүзле, тапкыр, әмма мактауга корылган комплиментар тостлар хатын-кыз табигатеннән килә түгелме?!.

Беренче тостны капитан әйтергә тиеш иде...

—Дошманның су асты көймәсен эзләп табар өчен дингезне йөз градуска җиткәнче кайнатырга кирәк, ул һичшиксез өскә калкып чыгачак, дигән бер яһүд. Дингез тиклем дингезне ничек кайнатып була соң, дип сораганнар моннан... Мин кинәшемне бирдем, ә тормышка ашыра аласызмы, юкмы—анысы сезнең эш, дигән яһүд... Мин бокалларны мөлдерәмә тутырырга кинәш итәм... Ә эчәбезме, юкмы—анысы безнең эш!

—Яһүдә хатыннарыбыз өчен күтәрик!

—Ике башлы бөркет Ак барсны чукымасын!

—Господа офицеры! Сәясәткә кагылмагыз!

—Боцман! Чегәннәр өстәлендә ром бетте!

Марат Гомәрне тыеп торучы юк, тагын исерер инде. Гармунын караватка егылган килеш тә уйный ала ул, анысы өчен борчылмый Сөмбелә. Каюта стенасын шакылдатуга йөгереп керердәй аек булуы кирәк иде...

Ниһаять, капитан «Смирно!» командасы ишеткәндәй үрә катты.

—Господа мичманнар, хәзер Венера җырлый! Венера, әйдә тегене...

Кают-компания тып-тын калды. Талгын музыкага теплоход тирәли нидер эзләнеп йөргән акчарлакларның зарланулы чиелдаулары кушылды.

...Очмыйча син түзеп кара,
Иннәрендә канат барда!..
Кый-гак! Кый-гак! Кый-гак!

Җыр беткәнне дә көтмичә башланган көчле алкышлар җиде баллга җиткән шторм дулавын хәтерләтте.

Алкышларны капитан да бик ярата. Мәртәбәсенә күрә аны яна сәүдә үзәкләре ачканда дисеңме, яна өйләр салынган буш нигезгә таш ыргытканда, уныш бәйрәмнәре булып килгән ярминкәләрне каршылаганда, тәбрикләү чараларында, Мәскәү юлыннан кунаклар каршылаганда, башкарма комитет утырышларында чыгыш ясаганда дисеңме... Кыскасы, аны гел кул чабып каршы алалар, алкышлар белән озаталар. Ул микрофонга гашыйк, чөнки һәр вакыйганың халык җыела торган өлешендә аны йә стационар, йә күчмә сәхнә корып каршы алалар, тавышын меңәр ваттлы динамиклар белән көчәйтеп тараталар. Ә инде һәр кичне «Эфир» каналының соңгы хәбәрләреннән күренгәндә анын каршысына җидешәр микрофон куялар иде.

Капитан Венерага багышланган алкышларның тынганын да көтмичә, микрофонны йолкып алды, урынбасарын чакырган ише генә җинеллек белән, имән бармагын изәп гармунчыны үзенә дәште һәм җырлап та җибәрде. Ни җырлыйсы алдан әйтелмәгәч Марат Гомәр гармун киеренкелеген тыеп торып беренче иҗекнең яңгыраганын көтте.

Әйтмә син, авыр сүз, әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы...

Капитанның, чынлап та, мәҗлесләрдә җырларлык кына тавышы бар иде. Банкет саен диярлек җырлый торгач, ул вокал буенча ярыйсы шомарды. Мелизмнар белән бизәмичә, борылышларын турыдан гына кистереп җырласа

да, бер үк куплетларны өчәр тапкыр кабатласа да, аңа барыбер артистлар көнләшерлек итеп кул чабалар, әле «Афәрин!» дип тә үсендерәләр иде.

Рәттән алты җыр башкарганнан соң, җиденчесенә ул «Әйтмә син авыр сүз»не тагын тулаем кабатлады. Бер балалы хатыны белән тулай торакта яшәп яткан тавыш операторы капитанның репертуарын бүлдереп бию көе кушарга курыкты, ә мичманнарның погоннары «бәләкәйрәк».

—Могҗиза җидәү генә була!—диде капитан үз вакыты җиткәч. Тыңлагыз, бер тост әйтәм... Кичә орбиталь станциянең аэронавтлары ачык космоска өч тапкыр чыктылар... сәбәбе шул—туалетлары эшләмәгән ди... Әйдәгез, берәрне күтәрик тә ачык космоска чыгып керик. Ярты сәгатьлек тәнәфес игълан итәм!

Җиде җырдан соң җор сүзгә сусаган команданың рәхәтләнеп көлүе капитанның күңелен күтәрде.

Аһ, бу озын тәнәфесләр! Аһ, хатыннарын ияртергә ятматмаган агайларның малайларча тугарылуы...

Алданрак торып киткәннәр туалет ишегенә чиратка баскач, соңрак килгәннәрнең көтәрлек чыдамы калмаган иде. Беренче ярусның чыбык читәне аркылы Идел өстенә чәпердәтү ярышы башланды. Һәм һәр мичман, башкалары алдында үзенең егәре, әүхәте, ирлеге белән мактанырга теләгәндәй, ярышып чәптерергә тырышты: кем ераккарак җиткерә—шул сәламәтрәк, аның простатасы да юк, гайрәте дә ташып тора. Әгәр ярышка катнашырлыгың юк икән—димәк, син тумас борын картайган мескен бер җан иясе.

Өлкән мичманның да ярышка катнашырга исәбе бар иде, чыбык читәнгә килеп сөялгәч як-ягына каранып тыелып торды, ник дигәндә, уен белән мавыгырсың да, әгәр шулвакыт Сөмбелә килеп чыкса?!. Бүгенге ситуацияне оста файдаланыр өчен җырчы алдында горур, җитди һәм дә ихтирамлырак булып күренергә теләде ул.

—Нәрсә, иптәш Өлкән Мичман, давлениең юкмы?—дип үртәштерделәр аны.

—Юан торбадан су әкрен ага!—дип, теленә килгән беренче җавапны аклану итеп, бу тирәдән тизрәк китеп барды ул.

Палуба әйләнәсе буйлап оештырылган малайлар бәйгесе шултиклем озак дәвам итте ки, хәтта ватерлиния Идел өслегеннән бер сөям өскәрәк күтәрелгәндәй булды.

Сөмбелә, чынлап та, түгәрәк тәрәзәгә маңгаен терәп, палубадагы тамашаны күзәтте. Мичманнарның аңа җилкә белән басып торуы бу күренешкә әллә ни оятсызлык китермәде. Өлкән мичманның уенга бирелмичә кирәк чакта әдәпле булып кала белүе ошады әле аңа. Якындагы кәмиттән бик тиз ялыгып, Сөмбелә мавыктыргыч манзараны ерактанрак эзләргә теләде. Һәм ни күрсен—Елга порты әле һаман да якында гына.

—Ике сәгатьтән бирле ник бер урында таптанабыз соң әле без?—дип сагая калды Сөмбелә.

Җавап эзләп һавага чыгарга ашыкканда аның юлына аркылы төшкән беренче кеше Өлкән мичман булды.

—Сөмбелә, синең белән сөйләшәсе бар иде!

—Ике сәгать буе бергә утырып, сүз башларга җаен тапмадыгызмы?

—Үзен тыңламыйча, өстәл артында юк-бар сөйләшеп утырганнарны капитан бик өнәми.

Өлкән мичман, сул канатын җәеп, ишеге ярымачык бер каютага таба кулы белән юл күрсәткән иде, Сөмбелә шундук кире какты.

—Юк-бар сөйләшеп утырыр өчен өске палуба шәп. Аннан соң минем бу трюмда күңелем болгана.

—Дингез авыруымы әллә синдә?

—Дингез авыруы дингез буена еш йөргән житәкчеләрдә генә була торгандыр ул. Болай диагнозлар куярлык чирләрем юк. Таң тишегеннән башланган шау-шулы мәжлес кенә башыма капты.

—Профессиональ артист өчен иртә ни дә, кич ни? Барыбер концерт инде.

—Кызыл туй белән Сабантуйлар да иртәнге уннан башлана. Ә без бүген сигездән үк… Карагыз әле, сез маршрутны беләсезме? Ник һаман Казаннан чыгып китә алмыйбыз? Комга терәлдекме? Фарватер буш түгелме?

—Тес-с!

Өлкән мичман ике бармагы белән Сөмбеләнең авызын капламакчы иде. Ләкин кызый чиркануп читкә борылып өлгерде. Тәмәке төтене, ысланган балык, суган кыягы исе сеңгән әлеге кулдан жирәнүдән йөзенә чыккан жыерчыкларны яшерер өчен, елмайган булып, тимер басмаларны жиз дагалы үкчәсе белән төя-төя, иң өске палубага йөгерде.

—Йә, кая алып баралар безне?—диде Сөмбелә аулакта сабырсызланып.

—Әнә, ярдагы теге вак урманны күрәсеңме?

—Бишбалта причалы.

—Ярга якын килмибез. Якорь салып шлюпкалар төшерәбез дә халыкны ярга ташыйбыз. Анда безне шашлык учагы, балык шулпасы, көлгә күмгән бәрәңге көтә. «Иделкәем» ансамбле каршылый. Кичке сигездә кабат Елга портына кайтып төшәбез.

—Биш чакрым араны унике сәгать буе йөзәбезме?

—Кая ашыгасың, Сөмбелә?! Ял ит рәхәтләнеп.

—Сезгә ялдыр да, безгә эш инде ул. Унике сәгатьлек эш көне.

—Эш дигәннән, Сөмбелә, сиңа гына сер итеп әйтәм… Шушы көннәрдә мине Казанга күчерәләр. Республика районнары буенча кураторлык эшен миңа йөкләячәкләр… Әгәр үз бригадаң белән районнарны йөреп чыксаң, ә?!. Кырык дүрт концерт! Гарантияле! Чыгымнарның бер өлеше бюджет хисабыннан булыр, районнарга хат жибәрербез, шәпләп оештырырлар! Син ризамы шуңа?

«Эрләмәгән сукмаган, Шаһи сиңа ыштанлык!», «Тумаган тайга атланма, билен сындырырсың!», «Алдан кычкырган күкенең башы авырткан…» ише әйтемнәр кинәт исенә төшеп, Сөмбелә үрталгәндер күрәсең. Өлкән мичманга аның елмаюы бик ошамады.

—Ихтыярың. Теләмәсәң, бүтәннәр килер… Тик халкыбызга мин күбрәк сине тыңлатыр идем. Сөмбелә дигәндә тамашачы сырпалана бит…

—Рәхмәт инде. Килермен мин. Тик бу сөйләшү чакыруга охшамаган әле.

—Әйе, әйе, искә төшерү, ягъни мәсәлән, алданрак килешеп кую!

Ул Сөмбеләнең кулын кыскан булып аны үзенә якынрак тартып китерде. Махсус шулай эшләде, чөнки бер төркем мичманның баскычтан менеп килгәнен күреп алды. Ул аларга: «Бу жырчы бүген минеке!» дип шапырынырга теләде, күрәсең.

Сөмбеләгә бу хәл бер дә ошамады. Житмәсә, ике ара шул тиклем якынайган иде ки, хәтта Өлкән мичманның сулышындагы аракы түгелгән салат исе тынын кыса иде. Кызый мәктәп баласы кебек елгырлык белән, абзагызның «ике колачлы» тозагыннан шуып кына чыкты. Чыкты да палубаның икенче ягындагы баскычтан аска ыргылды. Өстә мичманнарның көлешкәне, кемнеңдер: «Кок! Безгә ром китер!» дигәне генә ишетелеп калды.

Сөмбелә бер ялгызы каютага кереп бикләнде. Кием шкафының бигe чаклы гына йозак аны шау-шудан аерып куйды. Колакта тынлык чынлап тора. Шуны гына көткәндәй, инде кайчаннан бирле эзәрлекләп йөргән уй бөтен фикерне биләп алды… Үз биләмәсендә патшага әверелгән, хакимлек итүнең бөтен тантанасын күргән, базарча яшәүнең тәмен белеп өлгергән типик Яңа житәкче бу… Алар сәнгатькә соклана белми. Жырчы кызларны яулау малайлар чуагының бер уены гына.

Ул: «Шлюпки на воду!»—дигән тавышка уянып китте. Димәк, мәжлеснең тәнәфестән соң гөрләгән өлешенә йоклап калган. Бәлки әле капитанның бу әмерен дә ишетмәгән булыр иде—теплоходның двигатель тавышы тынган, шуңа һәр аваз, һәр үкчә тыкылдавы каюта аша үтәли йөри.

Төшәргә исәбе юк Сөмбеләнең. Ул инде ярда шашлык көткәнен белә. Алай да хатын-кызларга хас «күрәсе килүен» тыя алмады, иллюминаторга бик якын килмичә генә су өстен күзәтте. Капитан биргән команда шаяру гына икән—берниндн көймәне дә суга төшермәгәннәр. Бишбалтаның «Леонид Соболев» теплоходын китереп бәйләрлек причалы юк. Шуңа күрә халыкны ярга якын килә алырдай «ОМ»икка күчереп төяделәр.

Кунаклар тиз күченде, кают-компаниянең кысанлыгыннан, рәсми табынның протоколларга теркәлердәй тостларыннан ялыккан кунаклар шашлыклы вак урманга су өсләтеп йөгерергә әзер иде инде.

Калды Сөмбелә. Өч палубалы олагаем теплоходта берүзе калды. Учак тирәсендә баян белән эчемлек булса—шул җитә. Өстәвенә әле ярда «Иделкәем» ансамбле көтә. Анда яшь җырчылар гаскәре—Зәлия, Әлфия, Рәмзия, Резидәләр...

Шашлыкчылар десантына ияргән өлкән мичман, учак тирәсендәге ыгы-зыгы тынган арада, Сөмбеләнең юклыгын абайлап алды. Җитәкченең мин-минлегенә көч килде. Һәркайсы чибәрләр конкурсында бәйге тотарлык «Иделкәем» кызлары да күренмәде аның күзенә, күбрәк эчкән саен ныграк айный баргандай тоелды аңа, капкан ит кисәген йоталмыйча интекте, вак урманның һәр куләгәсен тентеп чыкты, аның юклыгына ышанган саен ачуы кабара торды. Ниндидер бер колхоз хәерчесе, үзенең популярлыгына масаеп, бүген-иртәгә расланасы җитәкчене санламаган булып йөз чөереп маташа... Хәерченең иң зур кимчелеге—намуслы горурлык. Ләкин акчасыз горурлык—ул мескенлегенне танымаска тырышып масаю гына. Масаюны яшәү рәвеше итәр өчен акча, акча кирәк, кызый. Ә күп акча эшлим дисәң, намусыңны онытырга, горурлыгыңны кырыкка чатнатып сындырырга туры килә... Безнең җәмгыятьнең иң зур хакимияте хәзер—акча.

Өлкән мичман, «ОМ»ик белән берүзе килеп, теплоходның каюталарын актарып чыгарга бик тели. Сөмбеләне барыбер эзләп табар, ай-ваена карамыйча акыртып көчләр иде... Концерт күлмәген кигән килеш! Назлыйсы килмәсә—җырлап ятсын, җырлыйсы килмәсә—җыласын!..

Ләкин капитан алдында дуамаллану килешеп бетмәс. Субординациянең кануннары кырыс. Үсешкә дучар ителгәнсең икән, карьера баскычында үзеннән өстәрәк торганнарның сүзе-имзасы, мөнәсәбәтенә тешеңне кысып булса да түзәргә, хөрмәт итәргә мәҗбүрсең. Идарә итүнең диалектикасы гадел түгел, әмма бик гади: бүген—син мине, иртәгә—мин сине!..

Ниһаять, шашлык учагы сүрелде, вак урман эче тынды...

Яңы белән килеп сыенган «ОМ»иктан «Леонид Соболев« бортына сикереп төшкән иң беренче кунак өлкән мичман иде. Тар, озын коридор буенча тезелгән ишекләрне рәттән ача барып ул, ниһаять, эчтән биклесенә килеп төртелде. Ныклап тартса сувенир йозак шартлап ачыласы, тик ул эчтән бикләнү мөмкинлегенең аңарга әле һичшиксез кирәк булачагын исеннән чыгармады.

Теплоход ирләр белән хатын-кызлар арасындагы интригаларны тавышланып хәл итә торган урын түгел. Каюта ишеге йодрык игына таба ачылды, төбенә чаклы ачылганын көтмәде өлкән мичман, гүя ярыктан шәүләдәй шуып керде дә эчтән бикләп куйды. Ятып торган чагы булса ул бәреп кергән хутка аның өстенә авасы иде. Шөкер, Сөмбелә аягында нык тора, ул аучыны һөҗүмгә әзерләнгән боксчы рәвешендә көтте.

Өзәргә дип үрелгән кулга чәчәк каршы тора аламы? Комарлы ир колачы,

келәшчә сыман кысылып, Сөмбеләнен кулларын бөкләде, әмма йодрыклары ике гәүдә арасында йомарланып калган иде.

—Йә, нишлибез, Сөмбелә, бил сызганып эшкә тотынабызмы? Әллә тагын качышлы уйнап алабызмы?

—Шушындый бәйрәм көнегездә дә гел эш турында сөйләшмик инде.

—Алайса, «әбәк-әбәк» уйныйбыз?

—Юк, сездән качар өчен бу теплоход кына түгел, мәркәзебез бәләкәй.

—Күптән шулай дип әйтәләр аны! «Риза» дигән сүзенне дә кешечә әйтә белмисен бит син. Бәлки шуна күрә кызыгамдыр да әле мин сина. Сөмбелә—ул минем өчен чибәрлек, горурлык, нәфислек һәм жырлый торган йолдыз символы.

—Ялганлап мактау—түрәләр белән, үзеннән көчлеләр белән сөйләшкәндә бик файдалы. Ә мин сон... гади бер жырчы... сезненчә әйтсәк—иске йолдыз.

—Түрәләр, көчлеләр, имеш! Хатын-кыз белән мактаусыз сүз башлап буламы? Ләкин сина башынны жүләргә салсаң ныграк килешер иде. Акыллы булып әллә кыланасың, әллә үзен шундый...

—Үзгәрә алмыйм инде мин. Сезнен күнелне күрер өчен генә шамакайланасым килми.

—Акыллы-акыллы! Әйт әле, кыйммәтле артисткам, үз гомерендә ничә ир белән йокладын син?

—Санап торучысы юк инде анын. Су белән газ торбасына счетчик куялар куюын, ә ирләр белән хатыннар арасына уйлап тапмаганнар ди әле.

—Димәк, коммерческая тайна!.. Әһә, ниһаять ачуынны чыгардым, күзеннен кешесе зурайды! Юкса салкын канлы булып кылануын кайнар тәненә күрә түгел иде.

—Ачуланып торырга, мин әллә юмагайлар студиясенә контракт төзергә килгән яшь жырчымы?

—Гөнаһларың күп инде синен, ә?!

—Унсигез яшьлек кыз үстергәч, сезнен каршыда гөнаһсызга сабышып торыр хәлем юк. Беләм, ирләрнен кайсын гына алма—бөтенесенен дә беренче буласылары килә... Унсигез ел элек кайда йөргәнсездер? Бүген гөнаһларым өчен каршыгызда гафу үтенергә генә кала.

—Кыз баланың гөнаһлары рухландыра мине. Ят, әйдә! Юкса көчлим!

—Нинди көчләү ди ул?! Үземнен дә күптән сөеләсем килә. Бүген гел кызлар тирәсендә бөтерелден, шуна көнләшүемә чыдый алмыйча әрләшәм.

—Алайса сузма.

—Хәзер. Син чишенеп ята тор. Мин бер минуттан әйләнеп керәм.

—Нәрсә-ә?!!

—Ярамаган ризык эләкте. Эчем китә минем. Теплоходта берүзем ник бикләнеп калды дисен. Тиз генә эшне бетереп тәһарәт алып килəм.

Азгыннар кулыннан качып котылу дигәндә, әлеге авыруны телгә алу кыз бала өчен һич түбәнсенүгә саналмый. Киресенчә, ирләрнен әүхәтен сүндерә торган, сыналган алым бу. Өлкән мичман да ниятеннән кире чигенә язды. Язды, әмма чигенмәде, Сөмбелә чыгып киткәч, чишенеп, ишекне бикләмичә генә, караватка менеп ятты. Башы мендәргә тию белән гәүдәсе авырайды, бөтен эчкәне, ашаганы ике потлы гер булып, күкрәк читлегенә басты. Һәм ул, яклаусызларны сөендереп, гырлап йокыга китте.

Озак йокламады, күп дигәндә ун-унбиш минут черем иткәндер, сәфәренә сонга калган юлчыдай сискәнеп уянды.

Сөялгәнсен чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрен;
..............................

..................................
Күрәм, ике ирнең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

Унбиш минутлык йокыдан тәүлек буена җитәрлек көч туплап, тынычланып һәм айнып уянган чын совет җитәкчесе: «Кайда син?! Ник ялангач? Булдымыюкмы? Коридорның теге башында нинди туй?»—дигән сорауларга җавапны Сөмбеләнең җырлавыннан тапты. Җавап белән бергә тагын ярсуы әйләнеп кайтты. Кызыйның тавышына түгел, Тукайның шигыренә үртәлде ул—ишетәсеңме, мөнәҗәт җырлар хәлгә төшкән мескен җырчы хәерче шагыйрьдән яклау эзли?!.

Теплоход, кырлардагы хәлне искә төшергәндәй, буш элеваторлар тирәсендә борылыш ясап, пристаньга кайтып бәйләнде. Кунаклар командасы, төрле илләрдән җыйналган туристлар кебек бер-берсенә артык илтифат күрсәтмичә генә трапка ашыкты. Һәм җиргә төшкән бере янадан үзенең элеккеге халәтенә кайтты: капитан инде шәһәр башлыгы булган, ике урынбасарын ияртеп иң алдан бара; мичманнар хакимият башлыкларына әверелде; чегәннәр ин азактан чыгып, шәһәр коймаларына ябыштырылган плакатларына охшарга тырышып, тыелгысыз елмайдылар. Ярдагы бөтен машина берьюлы кабынды. Күрсәтмә буенча алар автовокзал янындагы тимер юл күперенә чаклы эскорт ясап тезелешеп киләчәкләр, аннан инде һәр хакимиятне каладан чыгып кача торган үз юлы көтә.

Елга порты кырындагы троллейбус тукталышына килеп баскач, Сөмбелә никтер яр буена әйләнеп карыйсы итте. Чөнки аның инде теплоходтан ерагайганына, ниһаять ирекка чыкканына чын-чынлап ышанасы килде бугай... Вәт, гөнаһ шомлыгы... Элеккеге мичман эскорттан бүленеп калган—машинасы кабынмый!

Стартерның кушылырга теләмичә бушка әйләнүеннән туйдымы, әллә хурлануы чиктән ашкан идеме, ул машинадан кинәт чыгып, шоферны селтәп ыргытты да руль артына үзе утырды. Хакимнең холкыннан чыныккан шофер, егылган җиреннән тиз генә торып, авырайган кара «Волга»ны этә башлады. Машина кабынган унайга аны калдырып китеп баргач та, вакыт әрәм итмичә, тез башларын ашык-пошык сыпырып, әче тотен артыннан йөгерде...

* * *

Сөмбелә кухня тәрәзәсенең авыр өлгесен ачты. Амбар кенәгәсенең 1993 елыннан йокы тәмам качты. Чәйнек кайнарлыгы бөтен бүлмәгә таралды. Чикләвек оны белән куертылган сөт тәрелгән как рулетыннан бер телем кисеп алды. Әлем кагының ачысы чәйдә эреп бөтен тәненә ут булып таралды. Вакыйгалардан тизрәк ерагаерга теләп ул үзенең «вахта журналы»н тоташлап актарырга кереште. Бер-ике елны җәһәт кенә үтеп китсә дә ул әле барыбер теплоходтан котыла алмады. Өч палубалы мажара күз алдыннан китми, офыкта эленеп калган ак мираж булып еллар арасында очып йөри, күптән таралышкан йөгәнсез малайларның шаукымы әле һаман колак төбендә... Теге абзый калага килгәч тә озак тоткарланмады, «башка эшкә күчү сәбәпле» тагын районга җибәрелде. Ул кардәшләр җөмһүриятенең төньягында яна тормыш күтәрү белән мәшгуль... Юк, дистә елдан артык вакыт үткәч тә Сөмбеләгә сары розалар сибә торган шаһзадә түгел ул...

## Коры сихер

Сары табышмакның җавабын коммунизм кырларыннан эзләмәде Сөмбелә. Дөрес, элек тә һәр җитәкченең күнеленә ятышлы «үз җырчысы» була торган

иде. Әдәбият һәм сәнгать көннәре, мәдәният декадалары, классикларыбызның юбилей кичәләренә әзерлек башланса, делегация житәкчесенең кем булуыннан чамалап, бәйрәмгә кайсы жырчыларның барасын алдан ук белеп торалар иде. Мәскәүдәме, Уфада—Чабаксардамы, Каракалпакта—Ижаудамы—кемнең кайда йөргәнен мактаулы исемнәренә, почет грамоталарына карап чамаларга була.

Малайлар чуагы чын-чынлап туксанынчы елларда башланды. Пролетариат диктатурасының житмеш ел буе туплаган бөтен байлыгы, жәмгыяте белән шәхси мөлкәткә әверелеп, житәкчеләр кулына күчте. Базар юлына чыкканчы кем кайда утырган—шул үзенең кабинеты тирәсендәге малга, жиргә, житештерү тармакларына һәм хәтта эшче көчләренә дә хужа булды. Ә кабинетсызлар ваучер тотып калды.

Берара акчаның нольләре калькуляторларга сыешмады, кулдан-кулга «пачкалап» кына йөри башлады, билен буган штамплы кәгазе исән торса, кибетләрдә дә санамыйлар иде хәтта. Эмиссия, дивидент, дисконт, девальвация, деноминация, валюта, дефолт, дотация, банкрот ише әйтеп бетергесез терминнар арасында кыйналган тинтәк акча артистлар язмышын мөлкәтлеләр хәйриясенә калдырды.

Филармониянең эстрада бүлеге ябылгач, жырчылар «Ура!» кычкырган иде. Өч ай эчендә кырык биш тапкыр жырларга мәжбүр итә торган концерт оешмасы юк хәзер! Шуның белән бергә: план үтәмәгән өчен шелтә бирүчеләре дә; һәр жырыңны тикшереп, көе-эчтәлеге, башкарылышына бәя куеп утыручы худсоветлары да; кассага күбрәк акча жыя алган артистларга гына мактаулы исемнәр, фатирлар бирүне берүзе хәл итә торган директоры да юк...

Жырчы халкы тамашачы белән бергә-бер калды. Медиа-магнатлар экраннарда кемне әйләндерсә, тамашачы шуларны көтте. Кемгә кул чапсалар—шул эшләде. «Йолдызлар фабрикасы» шомарткан чибәр, гәүдәле, сөйкемле кызлардан, ыспай малайлардан унсигез яшьлек эстрада йолдызлары кабынды. Нәфислек сәхнә алдына чыкса, классик тавыш хәзер арткы планда. Афишаларны ертып йөрүчеләр, концерт булмый дип шылтыратучылар күбәйде. Һәр тамашачы өчен «йолдызлар сугышы» башланды. Филармониянең эстрада бүлеге мәдәният сарайларында айга бер генә концерт куярга жөрьәт итә иде. Ә хәзер көн дә бәйрәм: афиша өстендә плакат, игълан астында белдерү. Хәләл акчасын түләп керердәй апаларның гайрәте чикте, азмы-күпме халык йөрердәй заллар бармак белән санарлык кына калды.

Филармониядән киткәннән бирле Сөмбеләнең хезмәт кенәгәсендә бүтән мөһер юк. Каян килсен ди инде ул?!. Календарьдагы бәйрәмнәр, сабантуйлар, юбилейларда жырлатыр өчен кем штатка алсын сине?

1994 елның март азагында урам бәйрәмнәре, жыеннар, ерак гастрольләр оештыру буенча шактый тәжрибә туплаган Манс шылтыратты. Ул атказанган баянчы, күп кенә матур жырлар авторы. Базар синдромы башлангач, эш коралын читкә куеп, менеджмент кәсебенә тотынды. Үзен кызыксындырган шәхесләр белән итагатьле сөйләшә белә. Сорауларын рәттән тезсән—хәл белешүдән һәм яңа эш тәкъдим итүдән гыйбарәт иде.

—Исәнмесез, Сөмбелә?.. Кызыгыз әйбәт кенә укыймы? Бер проект тәкъдим итсәм ничегрәк уйларсыз икән? Экстрасенс Фаил абый публичный сеанслар үткәрергә жыена, аңа ассисент кирәк иде. Сәхнәгә чыкмыйча гына, авырулардан килгән сорауларны тәртипкә салып, пәрдә артыннан укып торырга... Фаил абый аларга жавап бирәчәк. 1 апрельдән башлап өч көнгә икешәр сәгатьлек унике сеанс. Билетлар күптән сатылып беткән. Көн саен дүртәр аншлаг, «Уникс» залында!.. Түләүне алдан әйтмим—ну гонорары Мәскәүләрчә... Әйбәт кенә узса алга таба эшләргә дә өмет бар. Уйлагыз, ризалашыгыз, ун минуттан тагын шылтыратам.

«Уникс» залында унике аншлаг—ул унике мең тамашачы дигән сүз. Авыру,

гарип, саулыкка сусаган бичараларны—концерт залына җыелгач алар барыбер тамашачы инде. Тулы залның шаулавы язгы ташкын белән тулган елга яры кебек, пәрдә аркылы да ишетелә. Риза, әлбәттә риза Сөмбелә, ләкин Манс ун минут күтәргә куша, ул башка берәүләрне дә үгетләп, үзенчә кастинг үткәреп маташамы? Һәм ни өчен сеанслар 1 апрельдә—алдалау көнендә башлана?

Ун минуттан дигән тынлык биш минуттан арыга сузылмады. Иң беренче җавап итеп Сөмбелә ризалыгын белдерде. Тик сораулар бирмичә түзә алмады.

—1 апрель шуткысы түгелме?

—«Биш татар» районга чыгып киткән. Залның ул көннәре буш.

—Мине кем урынына чакырасыз? Берәрсе кире уйладымы?

—Сездән башкага әйткән юк әле. Җырчылар арасында медицинаны азмыкүпме белгән бер Сөмбелә диделәр.

—Мин бит ике ел гына укыдым.

—Белештек. Сез анатомияне өч семестр укыгансыз, Фаил абыйның ассистенты булыр өчен әлегә шул җиткән.

Колхоз базарыннан ерак түгел бер ишегалдында ике бүлмәле янкорманы арендага алып Фаил абый экстрасенсорик дәвалау эшенә ныклап керешкән иде. Ул ишегалдында һәрчак урам бәйрәменә килгәндәй халык булыр. Фаил абыйга эләгер өчен авыллардан килеп көннәр буе чират торалар. Фаил абыйның хатыны, малае, хәтта күршеләре аша танышлык кылып чиратсыз үтүчеләр дә күбәйде. Сырхау тәнгә кул белән кагылмыйча энергетик массаж ясап сихәтләндерүе хакында бик күп газеталар язды, Казан телевидениесе көн аралаш диярлек әңгәмәләр үткәрде. Журналистлар, артистлар аның фатир телефонын үз кулыннан алып, әкренләп дус-ишләргә, таныш-белешләргә тарата торды. Өйгә шылтыратучылар, урамда очрап сихәт сораучылар шултиклем күбәйделәр ки—ачык сеанслар үткәрү котылгысыз ихтыяҗга әверелде.

Ниһаять... Менә ул 1994 елның 1 апреле. Иртәнге унда башланасы сеанска әзерләнер өчен Сөмбелә алтыда ук уянды. Концерт күлмәкләренә күз йөгертеп чыкты да рәсми очрашуларга дип сакланган киң озын итәкле, ябык изүле көрән бәрхет костюмын киде. Зәйтүнәне мәктәпкә илтер өчен күрше Мөнирә апа кереп калды.

Дулкынлануын җиңәр өчен ул тайгак тротуардан вак-вак атлаган килеш борын тишекләрен киңәйтеп, кояшлы иртәнең язгы һавасына ябырылды. Университет үрен менгәч ни күрсен—башланырга ике сәгать барын белә торып, мәйдан халык белән тулган. Әйтерсең лә, колхоз базары «Уникс» янына күченеп, кырмыска оясына әверелгән. Җентекләбрәк күзәтсәң, шәһәрнең арбалы, култык таяклы, зары йөзенә чыккан меңнәре хәвефтән котылып, каядыр эвакуациягә әзерләнгән кебек. Ни елмаерга, ни еларга белмәгән сау-сәламәт артистның бикле ишеккә килеп шакылдатуы бик күпләрнең чыраен сытты. Бу минутта алар Сөмбелә дигән җырчыны, популярлыгы белән сырхауларны санламыйча, татар Кашпировскийе янына чиратсыз үтәргә маташучы сәхнә кыланчыгы дип кенә уйлыйлар иде.

Шөкер, озак шакып мескенләнергә туры килмәде, эчке якта кизү торучы апакай, аны танып, тиз генә ишекне ачып-ябып алды.

Микрофонлы киң өстәлне каплап торсын өчен пәрдәне махсус ачып бетермәгәннәр иде. Манс моны Фаил абый белән киңәшеп алдан ук әзерләп куйган. Шунысы әйбәт, Сөмбеләнең эш урыны күз алдында тормаячак икән.

Башланды...

Ул исеме алдан ук игълан ителгән сөекле артист кебек башын югары тотып, күкрәген киереп, ышанычлы, тигез ритмнар белән җәһәт атлап сәхнә алдына чыгып басты. Янпәрдәләр арасыннан шәүләсе күренү белән башланган

овация биш минутлап дәвам итте. Дегет төсендәге кәчтүм чалбары, өске төймәсе кара канатлы күбәләк белән капланган жете ак күлмәге, күтәренке үкчәле ялтыравык туфлиләре, ин мөһиме—меннәрне әсир итәрлек серле күзләрне каплап торган эңгер пыялалы, алтын кысалы тар күзлеге... болар барысы да, базар мөнәсәбәтләре башлангач, Фаил абыйга котмәгәндә генә Ходайдан ингән әулиялык кодрәте өстәп торалар иде сыман. Ул терсәген турайтмыйча гына ике кулын күтәреп, алкышларны туктатты. Күпләр инде анын тирәсендә салават күпере, төньяк балкышы, таң нурлары күреп сабыйларча дәгъва белән еларга тотынды, йөткерүләр, тамак кырулар көчәйде.

Иң әвәл ышандыра алырлык сүз кирәк иде...

Фаил абый, газеталардан өземтәләр укып, үзенең уңышлары белән сихәтләнгән, чирләреннән котылган кешеләрнең исемнәре-адреслары белән сөендерде...

Зал тынычланды, Сөмбелә тәмәке уты белән өтелгән тишектән пәрдәнең теге ягына күз салды: тирән эчле, комач түшәкле утыргычларда мен төрле хаста—башлары иелгән, кыйшайган, чөелгән, сәхнәгә баккан... Кызгану катыш куркуданмы, Сөмбеләнең иртән эчкән сөтле чәе мангаена тир булып бәреп чыкты.

—Минем кулларымнан нур таралганын күрәсезме?

—Әйе! Күрәбез!

—Мәгез! Ходай миңа сезне савыктырырга кушты.

—Безнең якка да... Безгә дә жибәр нурларыңны.

—Һәммәгезгә дә барып житә! Ышанган кеше савыгыр...

Беренче сәгатьтә Фаил абый залга учлап-учлап нур өләште. Ягымлы сүзләр белән туктаусыз юатты. Карлыккан тембрлы, тигез моңлы тавышны микрофон йотып ала, көчәйткечләр аша күпертеп, сандык чаклы колонкалар залга коя.

Сөмбеләне йокы баскан иде инде.

—Сорауларыгыз булса язып жибәрегез. Залдан кычкырмагыз!—дигән тавышка ул сискәнеп китте.

Килде сорау... Килде сорау...

Колак авыртуым басылмый... Күзләрем сызлый... Йокым юк... Бот төбеннән аягым туктаусыз сызлый... Үпкә... Бавыр... Бәвел куыгы... Бөер... Сөмбелә, гүя анатомичкадагы практикант кебек, авыру «әгъзаларны» өстәлгә тезеп салды. Ул сорауларны укый башлады, Фаил абый жавап биреп торды.

—Авыртуың басыла. Сызлаудан туктый. Бүгеннән башлап йокларсың. Бүсерең юкка чыга. Бөереңдәге ташлар уалып чыгачак...

Сораулар ялыктыра башлагач, Фаил абый үзгәреш кертергә теләде. «Атналап башым авырта», «Ирем кыйнаганнан кул сөягем калтырый торган булып калды...» дигән сорауларның кешесен сәхнәгә чакырды. Вакыт бетеп килә, икенче сеанс өчен залны жилләтеп өлгерәсе һәм кодрәтне күрсәтеп, үзенә күрә реклама ясап аласы бар иде.

Фаил абый янына ике хатын чыгып басты. Аларга карап залдагыларның көнчелектән күзләре елтырады. Урамда жәйгә охшаш көн иде инде, көндезләрен залны жылытмыйлар, шуна күрә авыру халыкка өс киемнәрен салмаска рөхсәт ителгән. Чандыр гәүдәле, очлы иякле, илле яшьләрдәге ханымның кулы туктаусыз калтырап баллонья курткасы кыштыр-кыштыр килеп тора иде. Фаил абый аны сыпырды гына—кыштырдау шундук туктады. Залда кул чабулар көчәйде...

Какао төсендәге пәлтәсен киң пута белән билләп буып куйган, кара толымлы, киң маңгайлы егерме яшьләр чамасындагы кызның башын кушучлап тоткач зал тагын тынып калды. Фаил абый бер учын баш чүмече ягыннан, икенчесен маңгайдан ерагайта барып читкәрәк китеп басты.

—Йә, ничек?!—дип сорады ул тыныч кына, җавапның нинди буласына алдан ук ышанган кешедәй.

—Абау, сызламый! Туктады!—Кызның сытык чырае язылды, йөзенә елмаю кунды.—Билләһи, бетте! И, абый, Ходайның рәхмәте яусын сиңа!—диде дә сөенеченнән тыела алмыйча елап, сәхнә читендәге баскычка таба китте. Ул залга төшеп өлгерә алмады, сабырлыгы төкәнгән сырхаулар дәррәү кубып сәхнәгә ыргылган иде инде. Кыз читкә тайпылып чак егылмый калды.

—Мине дә сыпырып кара! Бер генә булса да сыйпа!—дигән ташкын Фаил абый өстенә ябырылды. Таянган таякларын кылыч итеп янаучылар да күренде.

Фаил абый микрофонны авызына кабардай булып кычкыра башлады.

—Җәмәгать, дәвалау өчен тынычлык кирәк! Мин болай эшли алмыйм! Вакытыгыз бетте! Тагын килерсез! Урамда яңа авырулар көтә!

Ишектәге кыңгырауның өзгәләнүенә исе дә китмәгән халыктан чак котылып, сәхнәдән югалып торды Фаил абый. Ул арада Сөмбелә дә аның янына гримм бүлмәсенә кереп бикләнде.

—Фаил абый, гафу ит, мин кайтып китәм. Ике сәгать үткәнче көчкә түзеп утырдым. Бик авыр...

—Әллә миңа җиңел булды дисеңме? Берьюлы мең сырхау белән эшләп караган кешеме мин?!.

—Бу сезнең сольный концерт. Гафу итегез, сезнең проект дип әйтәсем килә. Мине алыштыруы берни түгел.

—Ун минутлык тәнәфестә шушындый катлаулы эштә ассисент эзләп табып буламы! Әллә син аларны ишек төбенә тезелеп басканнар дип уйлыйсыңмы? Синең белән дә ике атна алдан сөйләшеп куйган идек, онытма шуны! Алга таба сорауларга җавап бирүне туктатырга, и берәүне дә сәхнәгә чакырмаска кирәк... Монысы минем ялгыш. Ярты чокыр гына чәй эчеп алыйк та—эшкә тотынабыз. Син ничегрәк җырлыйсың әле:

Яратмагач башламыйлар,
Башлагач ташламыйлар!—дипме?

—Мәхәббәт турындагы җыр ул, Фаил абый, темасы туры килми.

—Бик туры килә. Тамашачының авыруларын да, көлә торган сәламәтләрен дә яратырга кирәк.

—Нинди тамашачы?!! Болар бит концерт залына ялгыш җыелган мең сырхау!

—Әйе, бик дөрес әйтәсең, миңа сырхау, ә синең өчен тамашачы. Билет алып кергәннәр. Урыннары Азамат концертыннан да кыйммәтрәк тора. Унике сеансны да эшләп чыгыйк. Инша Алла, соңыннан тагын сөйләшербез.

Гипнозы бардыр инде Фаил абыйның—кайтырга дип җыена башлаган Сөмбелә янадан ризалашты, бөтен борчылуларын онытып, зур-зур йотымнар белән чәй эчәргә тотынды.

Бик күп кеше икешәр-өчәр сеанска рәттән билет алган булып чыкты. Алар инде Фаил абыегызның: «Сораулар бирегез!»—дигәнен көтеп тормадылар, тигезсез ертылган һәм төрле төстәге кәгазь кисәкләрен дәвалаучының аяк астына өя башладылар. «Икенче коймак»та төерләнмәсен өчен шактый көчәнделәр: сорауларга гомумирәк җавап кайтардылар, чакырмаган килеш сәхнәгә ыргылучыларны үгетләп кире урыннарына утырттылар. Көн азагына таба Сөмбелә үзен меңәрләгән җан иясеннән чир йоктырган сырхау кебек хис итте. Башы, муены, умыртка баганасы, кул-аяк буыннары бөтенесе сызлый һәм эчке әгъзалары дәррәү кубып сулкылдый сыман иде. Сорауларга ияреп килгән ялварулар, пәрдәнең теге ягындагы гозерләр, нәүмиз өметләр барысы да кызның җаны аша үтә торды бугай...

Икенче көн дә «скорый»лар чакыртмыйча тыныч үтеп китте.

Залдагыларның киемнәре, йөзләре-тавышлары үзгәрде, тик елаулары, ыңгырашулары, зарлары үзгәрмәде.

Өченче көнне исә... Ниһаять соңгы сеанска тотындык, җиңәбез, дигәндә генә Сөмбелә бер сорауны укыгач кинәт тотлыгып калды:

«Зинһар өчен дип әйтәм, кычкырып укыгыз. Миндә аю табаны. Бүген сезне дүртенче тапкыр тыңлыйм. Тагын ничә көн килергә кирәк миңа? Идрис.»

...Аю табаны... Идрис!..

Шушы өч сүзнең кайтавазы көчәйткечләр аша үтеп, бөтен залны айкап, сәхнәгә килеп, Сөмбеләнең үз тавышы белән үзенә әйләнеп кайтты... Балантауныкы... Классташы... Күрше егете...

Ул арада исен-акылын җыеп, Фаил абый белән киңәшмичә генә, Идрисне сәхнәгә чакырды, дөресрәге кемлеген тизрәк беләсе килде.

Идрис сәхнәгә менәрмен дип көтмәгән иде бугай, эре буразналы вельвет курткасының төймәләрен боргычлады. Аның житен чәче коңгырт киеменә бик килешеп тора иде. Гәүдә җыйнаклыгы, йөзенең кызларныкыдай аклыгы һәм шомалыгы белән ул әле гел мәктәп баласыдай... Идрис үзе!

Фаил абый Сөмбелә капризына буйсынырга мәжбүр булды. Егеткә сәхнә буйлап арлы-бирле йөрергә кушты. Аннан, көтмәгәндә: «Тукта!»—дип кычкырды.

—Идрис!—дип өстәде Сөмбелә дә. Һәм тавыш җепселләре коргаксыса йотып куярга диелгән стаканлы суны тотып егеткә таба атлады. Кыз кулындагы су ике арада эленеп калды.

Идриснең кызны танып өнсез калуын, өч йотым белән стаканны бушатуын, тирән сулап озак көрсенүен, һәм Сөмбеләнең аны җитәкләп сәхнә артына алып чыгып китүен залдагылар йөрәк өянәге дип аңладылар. Шуңа күрәдер, Фаил абыйга сыйпатыр өчен сәхнәгә ашкынучылар күренмәде...

—Нихәл, Идрис, нихәл?!

Сөмбелә аны ике иңбашыннан тотып күкрәгенә кысты, аркасыннан сөйде, җитен чәчләрен тузгытып башыннан сыйпады, үзенең күз яшьләрен сеңдергән зәңгәр бизәкле кульяулыгы белән егетнең томаулы борынын сөртте...

—И, балакаем, авылда нишләп яталар анда?

—Белмим,—диде Идрис кырыс кына. Ул һаман тораташтай катып калган. Зарыгып сагынуын йөзенә чыгармый.

—Ничек белмисең?—дип өзгәләнде Сөмбелә, аның саен.

—Күптән кайтканым юк.

—Монда каян килеп эләктең?

—Аякны төзәтәм.

—Сау-таза егет бит син!

—«Аю табаны»н бетерәм. Аннан армиягә китәм.

—Ник?

—Егет булыр өчен.

—Менә дигән егет бит инде син, болай да.

—Армиядән кайтам да сиңа өйләнәм.

—Идрис, минем инде мәктәптә укый торган кызым бар, Зәйтүнә исемле.

—Беләм. Балаң белән бергә алам. Балантаулылар аны минем кыз дип беләләр. Ачулансаң ачуланырсың, гайбәтен үзем чыгардым.

—Зәйтүнәм сиңа тамчы да охшамаган. Ул бит чем-кара чәчле, калын кара кашлы, кара тутлы...

—Аттан ала да туа, кола да туа...

—Кияүгә чыгарга җыенмыйм инде мин. Җырчы кирәк дисәң, мин сине яшь-яшь кызлар белән таныштырам.

Залда урындыклар дөбердәве, аяк тавышлары, кычкырып сөйләшүләр

ишәйде. Фаил абый, гүя өч көнгә сузылган бәрелештә җиңү яулаган батыр солдат кебек, сугыш кырыннан елмаеп чыкты. «Рәхмәт. Бирешмәден. Бөтенләй шомардың» дигән гади сүзләрне тантаналы мактауга корып, Сөмбеләне күрше бүлмәгә алып китте. Идрисне бәйләнчек бер сырхау дип уйлап, аннан тизрәк коткарырга теләде ахрысы.

Сөмбеләнен:

—Хәзер киләм, китмичә тор, йәме,—дигәнен чынга алмагандыр, биш минуттан әйләнеп килгәндә Идрис анда юк иде инде.

Фаил абый үзенә ассиссент итеп бер журналист егетне ияртте. Сөмбеләгә үпкәләмәде, дебютта түккән көчен гадел бәяләп: «кирәгем чыкса тел яшереп торма, синең исемнән килгән кешеләрне чиратсыз-нисез кабул итәрмен»—дип тә өстәде хәтта.

## Март айлары

Сәхнә артистны эзләмичәрәк торса, артист сәхнәне үзе эзләп китә.

Март айлары сискәндерә Сөмбеләне...

Көн белән төннең тигезләнгән мәле. Саба җиле кояшны болытлар белән томалап куйса да җиһанда күнел сөенердәй язгы яктылык. Борынгылар Яңа Ел дип атаган вакыт исәбе белән астрономик яз башланды.

Мәдәният сарайлары тирәсендәге коймалар «Нәүрүз» бәйрәменә чакыручы афишалар белән тулды.

Сөмбелә бүген Академия театрына «Нәүрүз» бәйрәменә китте—тыңлаучы булып. Бәйрәм дигәч тә, шул ук концерт инде ул. Онытылып калган йолаларны сагынган моңлы халык «Нәүрүз», «Җыен», «Сөмбел», «Каз өмәсе» кебек тамашаларга күбрәк җыела. Елның фасылына күрә үз бәйрәмен алдан ук көтеп тә тора хәтта...

Ул иртәрәк чыкты. Зәйтүнәнең мәш килеп өй җыештырганын карап утырмас өчен ашыгыбрак кузгалды. Фатирны икәүләшеп бизәмиләр, үзенчә матур булсын дисәң, анда бер генә кеше кулы кирәргә тиеш. Өй җыештырганда хатын-кыз рәссамга әверелә.

Зәйтүнәнең язгы каникулы башланды. Соңгы каникулы. Алга таба укырга керә алса, яз көне бүтән каникуллар тәтемәячәк инде аңа. Керә алса... Сыйныфташларының күбесе, инде югары уку йортларын сайлап, әзерлек курсларына йөри башлады. Ә Зәйтүнә исә: «Укырга кая барырга?»—дигән сорауга соңгы каникулга чыккач кына җавап бирә алды. Авиация институтына керәсем килә, диде... Бала әгәр төсе-бите белән эти-әнисенә охшамаса, һичьюгы холкы белән, инде холкы килмәсә хыяллары, уй-шөгыльләре белән булса да охшарга тиеш. Беренче сыйныфта укыганда ук Зәйтүнәне музыка мәктәбенә йөртте Сөмбелә. Үзе гастрольләргә киткән чакта күрше Мөнирә апасы иренмәде, ике мәктәп арасында йөгерде. Сигез ел укып кызыл катыргы алып чыкты Зәйтүнә. Ә бит кызның киләчәге турында уйлап сарыф ителгән иде ул вакыт. Урта мәктәпне тәмамлау белән алга таба да музыка буенча укырга китәр, җырчы Сөмбеләнең бердәнбер кызын консерваториянең ишек төбеннән үк елмаеп каршы алучылар табылыр, шуның белән югары белем турындагы матавыклы проблема җиңел генә хәл ителер дип торганда Зәйтүнә кырын басты: «Минем авиация институтына керәсем килә»—диде. Һәм, музыка мәсьәләсендә бөтенләй икеләнерлек урын калдырмаслык итеп, «Кулдан кулга» дигән базар газетасына әнисе белән киңәшми-нитми генә пианино сату турында игълан биреп кайткач, кызны бүтән үгетләмәс булды. Әмма пианиноны сатмады. Әйе, Сөмбелә гомер буе хыялланып та үзе җыр яза алмады; әйе, панель йорттагы күршеләрнең тынычлыгын бозмас өчен ул өйдә тавышка күнегүләр дә ясамый; әйе, пианинода уйнап җырлашып

утырырдай дусларның да күптән жыелганы юк инде. Тик, барыбер, өйдән музыка чыгып китәргә тиеш түгел, бу—өлкәннәр сүзе! Пианиноның һәр телендә Марат Гомәрнең бармак эзләре саклана... Соңгы жырын ул нәкъ менә шушы пианинода язды.

Уйлары бәргәләнгән чакта, кызы белән гармунчы исеме янәшә туры килсә, Сөмбеләнең күзләреннән яшь бөртеге тибеп чыга. Әле дә ярый, күз төпләрен сөртеп алу урамда узган-барганнарның игътибарын җәлеп итми, болытлар сыегайган чактагы күз ачкысыз яктылык бик күпләрнең күзлеген салдырта, кулларына кульяулык тоттыра.

«Бәхетле» супермаркетының икенче катында затлы киемнәр бүлеге ачканнар. Кесәдә акча юклыкны бик сиздермичә генә, карап чыгарга кирәк, дигән уй күптән тынгы бирми иде инде. «Сим-сим, ач ишекне!»—дип әйткәнне дә көтмәде, Сөмбеләне күреп алу белән пыяла дивар, уртага аерылгандай, ачылып китте. Әчке ыгы-зыгысы белән базар күренешен хәтерләтсә дә бу кибеттә байлар тынлыгы—кычкырып сөйләшүче юк, бәхәсләшмиләр, зарланмыйлар, адашкан иптәшләрен тавышланып эзләмиләр.

Икенче катка күтәрелү өчен, Сөмбелә үз кадерен белеп кенә, пыяла лифтны көтеп алырга булды. Күреп иялəнгән нәрсә булмагач, кызыксыну дигән үҗәтлек күзне гел лифтка ияртә. Әкәмәт җайланма инде, билләһи—үтә күренмәле олагаем торба эчендә дүрт кеше сыярдай пыяла банка, гигант пешкәк сыман, аска-өскә йөреп тора. Кем төшкәне-менгәне, кулына ни тотканы—барысы күз алдында, хәтта сатып алган малларын да үтә күренмәле сумкага салганнар.

Идән белән тигезләшә дигәндә генә Сөмбелә пыяла лифт эчендә Венераны күреп алды һәм аның белән күзгә-күз очрашмас өчен, янәшәдәге кара гранит баскычтан өскә йөгерде... Житешмәгән жире юк примадоннаның... Әллә кай арада яңалыкны эзләп таба, һәр ачышка башкалардан алдан барып өлгерә, кем әйтмешли, соңгы жөйне төенләп бетергәнен дә көтмичә, модельерларның кулыннан тартып алып өр-яңа үрнәкләргә төренеп сәхнәгә дә чыгып өлгерә. Көрәш девизын яшермәс: «Һәрбер «ноу-хау» минеке булырга тиеш: эксклюзив күлмәк, радио-телеаппаратура, яңа җыр, машина, затлы фатир, мактаулы исем!»—дияр ул... Менә хәзер дә, кара-каршы очрашсалармы?!. Венера, үзенең каядыр ашыгуына да карамыйча, Сөмбеләгә ияреп тагын пыяла лифтка керер, Алман коллекциясе бүлегеннән күлмәк сайларга булышыр, һәм шуларның берсен яучылап, мактый-мактый барыбер сатып алырга мәжбүр итәр, акчасы житмәсә әжәткә биреп торыр, артык кыйммәткә төшсә кредитка кәгазьләр тутырырга булышыр.

Казан базарының борынгы бабасы—Печән базары, атасы—«колхоз», урта буыны—«толчок», бүгенгесе—«Вьетнам базары»... Сатучылары куштан, үлчәүләре ялгыш, ярлыклары ялганчы, эксклюзивлары—игезәкле... Сөмбелә артык сайланып, Венераның үтә күренмәле сумкасындагы кебек үк күлмәк сорап алырга мөмкин. Ә пардан киенеп, икең дә бер төрле күлмәк белән чыгу эстрада җырчысының йолдызын кечерәйтә, сәхнәне «Вьетнам базары»на әйләндерә...

Сөмбелә кием-салымнар бүлегенә керүнең кызыгын тапмады, әле яңа гына Венера сайланып йөргән күлмәкләргә гыйшыгы сүнгәндәй булды. Чыгып китәргә ашыкмады. Кафетерийдан, бер чокыр сөтле каһвә белән пица кисәге алып, мансард тәрәзәсенә терәп куелган өстәл артына килеп утырды. Үзенчә, тагын танышлар очрамагае дипме, кибет эчендәге баягы сатып алучыларның яңалары белән алышынып беткәнен көтте...

Галәттә, август тамашачысын ярата торган Азамат, ни хикмәттер, «Нәүрүз» көннәренә туры китереп, ике концерт куярга теләгән. «Ник? Ни өчен? Нәрсә булган? Әллә, Ходаем, быел жәйге концертлары булмый микән?!»—дигән

сорауларга җавап таба алмаган халык Камал театрына агыла. Азаматның ни уйлаганын, ниләр майтарганын Азамат үзе дә белми диләр... Мажараларны уйлап чыгара тора егет: Йә ул үз исемен язып Казан күгенә дирижабль күтәрә, йә Татарстан урамының бер ярыннан икенче ярына концерт көннәрен күрсәтеп транспарант тарттыра; Пушкин урамы чатына, Дәүләт советы, Министрлар кабинеты тәрәзәсеннән күренерлек итеп биш катлы өй хәтлек фоторәсемен элеп куя; дүртәр конферансье катнашында театральләшкән концертлар сәхнәләштерә башлый; үзе турында тузга язмаган гайбәтләр тарата да пресс-конференцияләр үткәреп, шул гайбәтләргә ышанган хәбәрчеләр алдында үзе җавап тота... һәм Азамат булырга теләгән башка җырчылар Агыйделнең аръягыннан килгән егетнең бөтен яңалыгын кабатларга тотына. Инде, кыланышларын куып тоталар дигәндә генә Азамат түрәләр тарантасына утырып автораллига чыгып кача.

Мин-минлеген җиңә алган җырчылар Азаматның яңалыкларын, сәхнә артыннан түгел, билет сатып алып тамаша залында утырып карый, ә риялылар үз горурлыкларын җиңә алмыйча, коридорларда өерелә.

Сөмбелә театрның хезмәткәрләр ишеге аша үткәндә сакта торучы агайларның икесе дә баш иеп сәламләде. Алар: «Чакыру билетыгыз бармы?» дип сорарга кыймадылар. Бу хәл кызыйның кыюлыгын арттырды.

—Азамат подвалда, унөченче бункерда ял итәме?—диде ул, батыраеп.

—Әйе,—диде, сактагылар,—тик ул борчымаска кушты, бераз ял итә.

—Хатыны җиденче гримерныйдамы?

—Әйе, әйе, шунда менегез...

Грим бүлмәләрен тезеп торучы коридорның ял почмагы бар. Теләгән кеше, йомшак диванга чумып, телевизор карый, вакыты иркенерәкләре өслеге паркет идәнгә охшаган киң мәйданлы өстәлдә, балбал чаклы фигураларны күчергәләп, шахмат уйный. Бүген бу почмакта басып торырлык та буш урын юк. Сөмбелә биючеләр янында чишенеп, бик эшлекле кыяфәт белән уты сүнгән сәхнәгә ашыкты. Аяк астында сайгакларга тишеп куелган сүрән лампалар, якты сукмак булып, фойега алып чыга иде.

Театр тамашачысы алданрак йөри.

Күңел ачу сарайларында, концерт башланып яртышар сәгать үткәч тә, килеп ишек шакучылар табыла. Ике-өч җырын тыңласаң җырчының кем икәнен белеп була, бардым, күрдем, белдем өченгә шул җитә дип, яңалыктан яңалыкка йөрүчеләр бар әле. Шуңа күрә дә бикләнергә ашыкмыйлар, тамаша залы белән фойе арасына бармак калынлыгы гобеленнан ике канатлы чаршау элеп куялар.

Ә театрның кануннары кырыс. Өченче кыңгыраудан соң спектакль бикләнә, тамашачы өлешенә тигән кәнәфигә сенеп, сәхнә дигән серле дөньядан янраячак беренче авазны, артистлар теле белән әйткәндә—беренче фразаны көтә. Әнә шул беренче җөмләне ишетми калган тамашачы спектакльне тулаем аңлый алмыйча үзенә-үзе рәнҗеп кайтырга мөмкин. Менә шуңа күрә, өченче кыңгыраудан соң, хәтта драматург авторың үзе килсә дә ачылмаска тиеш ул ишек.

Концерт башланырга ярты сәгать чамасы вакыт бар. Киләсе тамашачы инде килеп беткән. Дивар тирәли тезелеп баскан сәүдә рәтендә нәзәкәтле ыгы-зыгы. Кем җыр сата, кем дини китапларны кодалый, тәм-том, халык һөнәрчеләренең бизәкле тауарлары, ике буфет, кем әйтмешли, кулга-кул тотынып баскан. Фойедагы татар дөньясы, киртә эчендә калгандай, әле бер, әле икенче сәүдә сәкесенә килеп сарыла.

Сөмбелә, кемнедер эзләгән кыяфәт чыгарып, төркем араларында тизрәк йөрергә тырышты, танып дәшкән кешеләрнең «...месез?!» дигәне генә ишетелеп калды. Һәр исәнләшкәне белән тукталып күрешә башласаң ялыгып бетәрсең.

Һәммәсенең дә сорау-йөдәтүләре бертөрле:

«Бу араларда сине никтер телевизордан күрсәтмиләр?!»

«Кызыңның җырчы буласы килми ди, ахрысы?..»

«Азамат кебек, Камал театрында да концертлар куярга вакыт инде сиңа».

Мондый сораулардан: «Әйе, әйе, әйе...»—дип кенә котыла алмыйсың, халыкка иркенләп, эчкерсез, кинаясез, төшенерлек итеп аңлатырга кирәк.

Әйе, телевизордан сатыла торган чагы үткән инде Сөмбеләнең. Продюсерлар үзәгенә барып, мескенләнә-мескенләнә контракт төзеп йөрергә әллә ул күзе ачылмаган өйрәнчекме?!

Кызының язмышына күрәзәче булыр хәле юк Сөмбеләнең. Әйе, дөресе шул—Зәйтүнәнең җырчы булуын һич теләми ул. Ләкин Сөмбелә үзе дә әти-әнисенең ай-ваена карамады, хыялына буйсынды. Табигать бүләк иткән моңны алкышлардан яшереп саклыйм димә. Сәләтле балага «юк, ярамый, кирәкми!» дигән саен ул ныграк киреләнә. Әйе, бүгенге көндә сәхнәгә ыргылу популярлык өчен буш көрәш кенә булып кала. Ул популярлык байлык белән ныгытылмаган. Иҗат төркемнәре эреле-ваклы «АО», «ОАО», «ООО»ларга ялланып кәсеп итәргә, юбилейларга, бәйрәмнәргә һәм ачылу тантаналарына чакырганнарын көтеп билгесезлектә көн күрергә тиеш. Вак-вак ханлыкларга бүленгән зур илнең бөтен байлыгы җитәкчеләр һәм җинаятьчеләр кулына күчте. Җыр яраткан, китап сөйгән, спектакльләргә ышана торган халык өлешсез калды. Бүгенге тамашачы көйсез, иркә, ялкау. Концертлар белән алгысытып өеннән чыгарыр өчен, аны рекламалар белән юмалап, газеталарда алдалап, гайбәтләр белән сокландырып, төшләренә кереп чакырырга кирәк. Сөймәгән җырчысына, билетын бушлай өләшсәләр дә, йөрми халык. Ә Азаматка дигәндә, килә...

Азамат феноменын аңлар өчен: Башкортстанда туып, Татарстанны сагынып яшәргә; җырчы булырга ашыкмыйча, әвәл үзешчән төркемнәрдә конферансье рәвешендә шомарып сүз магиясенә өйрәнергә; Чаллыдан торып Казан тамашачысын яуларга; сәхнәгә чыгасы чыраеңны кызганмыйча машиналарда янчелергә; осталык белән хулиганлыкның уртасында яши белергә кирәк. Азаматның һәр фигыле—матбугатта, һәр җыры—машинада, төркемендәге һәр артисты кеше телендә, бүләккә тигән һәр ядкәре һәм һәр уенчыгы Камал театры музеенда. Ул музейга эләгер өчен электрон сак куелган катлы-катлы ишекләрне ачасы юк. Иданнән түшәмгә чаклы калыккан тоташ тәрәзәләр диварына терәлгән пыяла музей ул. Кояш баешында, тамашачылар җыелгач, шәфәкъ нурлары кызылсу алтынга маңыла да Камал театрының икенче ягыннан чагылып—нәкъ Азамат музееның пыяла шүрлегендәге хәзинәләре аша фойега килеп керә... Бу музей гомер шушы театр сәхнәсендә эшләп-яшәп картайган халык артистларына да тәтемәгән үксез сөенеч һәм шул ук вакытта, камалчыларның үз артистына әверелгән эстрада җырчысы Азамат тудырган, кырык елсыз чишелмәслек олы сер иде.

Сөмбелә фойеда сыенып торырлык буш урын тапмады, кире китте. Сәхнә артында аңа иң беренче очраган кеше әле узган атнада гына Финляндиядән спорт костюмы киеп кайткан композитор Хәсән булды.

—Син дә катнашасың мәллә?—дип чат ябышты ул Сөмбеләгә, яналыкларга сусап килгәнен яшермичә.

—Юк,—диде Сөмбелә, юмагайланып,—Азаматның берәр җырын чәлдереп булмас микән дип йөрүем.

—Ышандым ди... Сиңа Зәлия җырларын чәлдерергә кирәк, тембрларыгыз бер...

—Ә син үзең нишләп йөрисең сәхнә артында? Автограф алырга дип килмәгәнсеңдер ич?

—Мать, ну ты сказанул! Между прочим, ул мине үзе чакырды. Партердан

ике урын бирде. Ышанмасаң, менә кара, жиденче рәттән,—дип, Хәсән спортивка кесәсеннән жырчының сурәте басылган ялтыравык билет чыгарып күрсәтте.

—Ничек жиденче рәттән?! Vip-liter[1] түгелме соң ул?!

—Ато белмисең инде. Житәкчеләр белән телевидение икенче көнгә генә чакырыла. Концертның беренче көне генераль репитиция генә бит ул. Без—авторлар өчен...

—Алайса тынларга дип килдең?

—А как же! Үзен хөрмәт иткән любой артист һәр яңа программаны карап барырга тиеш. Ну, минем особый случай, ел саен аңа ике-өч яңа жыр өлгертеп торам. Почти бөтен шлягерлары[2] да минеке...

—Ә Фирзәр белән үпкәләшкәннәрме?

—Фирзәр хәзер семейный подряд белән эшли. Шлягерлары үз гаиләсеннән артмый... Ә синең бригадаң исәнме?

—Чабата Зәлияләргә күчте. Калганнары чакырганымны көтеп тик ята.

—Да, хәзер төркем асрау не выгодно. Әллә нигә бер буласы концерт өчен аларның гаиләсен кайгыртып, исерекләрен көйләп, фатирларын иплап йөгерә торгач үзең өчен вакыт та калмый.

—«Без һәрвакыт әзер!» дип, чакырганда ялындырмыйча килә торган үзеңнең даими төркемең булуы ышанычлырак түгелме соң?

—Да ты чё, Сөмбелә! Хәзер буш жырчылар бихисап, күпме төркем таркалды. Теләсә кайсысына сызгыр гына—минут эчендә йөгереп килеп житә. Артистлар күбәйгән саен бүгенгечә концерт оештырырдай чын адмиснитраторлар азая. Чабатаны зрә ычкындыргансың, кыен жирдә жыен оештыра ала торган чи каешлы чабата иде ул.

—Миннән торамыни?! Чабата акча исен өч мең чакрымнан тоя. Зәлия белән Зөфәр кассовый жырчылар шул, халык егылып йөри үзләренә. Ә мин инде икенче сортлы жырчы, бәям төшеп бара. Сиңа рәхәт, син—автор. Жырлар язасың да иң отышлысын үзең әйләндерәсең. Әйбәт шлягер үлгән жырчыны да торгыза.

Сөмбеләнең мактаулы саламыннан соң, Хәсәннең салпы ягы хәйран турайды, үзе дә сизмәстән, әңгәмәдәшенә яхшылык эшлисе килеп китте бугай.

—Слушай, мать! Мин сине эзли идем әле...—дигән булды ул.—Син бу жомга көнне бушмы? Бер спирт магнатының түгәрәк бәйрәменә чакыру бар.

—Әйбәт түләсәләр көне буш булыр!—диде Сөмбелә, бу арада эшсез ятканын артык сиздермәскә теләп.—Акчасын шундук түлиләрме, әллә күчерү юлы беләнме?

—Шул кичне үк, «Сарман» кафесы түли. Минем анда, ачуым килмәгәе, йөз кат чыгыш ясаганым бар инде, кем әйтмешли, ул залда пропискада торабыз. Кунаклар—солидный, урыны аулак, артистлар күп... Хәзер пролетар жырчыларның өерләргә берләшә торган чагы. Так што, чакырган кеше сискәнмәслек итеп кенә бәяңне әйт тә, киттем, юкса өченче звонок булды, әнә концерт башлана. Минем әле ул жомга көн ашына синең кебек тагын ун кеше жыясым бар.

Һәм Хәсән, сул кулы белән күкрәк читлегенең йөрәк турысын угалап, сәхнә артындагы караңгылыкка кереп чумды. Сөмбелә аңа сокланып та, шикләнеп тә һәм шул ук вакытта кызганып та карап калды... Егет үзен бер дә иркәләп тормый, туктаусыз юлда, сәхнәдә, көрәштә. Кайдан шулчаклы көч табып житкерә дә, кайчан өлгерәдер. Соңгы унбиш ел эчендә татар

[1] Vip-liter—(жаргон) хөрмәтле кунаклар өчен махсус урыннар.

[2] Шлягер—халык арасында тиз тарала торган жыр.

эстрадасы өчен ин күп җыр язган кеше—ул. «Йолдызлар фабрикасы»ның Казан филиалын да ул оештырды. Төмән өлкәсенә бер вагон кунак төяп килеп татар әдәбияты һәм сәнгать көннәре үткәрүче дә Хәсән. Мәскәүнең симез борынлы оештыручылары белән уртак тел табып, авторлар хокукын саклаучы бүлекчә ачу буенча да тәки җинүгә ирешә. Концерт залларының берсендә сәнгать җитәкчесе булып эшләргә дә өлгерә... Шәһәр эчендә ике катлы коттедж салып чыкты, хатыны белән икесенә ике иномаркасы бар, ике бала үстерәләр... Самосырово чокырыннан илле чакрымдагы бер караңгы авылдан нинди якты шәхес чыкты!..

Кызгану белән соклану хисен тиз арада алыштырып Сөмбеләне шикләнү дигән җан кимергеч халәт биләп алды. Монарчы Хәсән Сөмбеләне үзенә ияртми иде. Түрәләр мәҗлесенә әйдәләве дә сәер, анда мөгаен калын кесәле агайлар җыеладыр. Үзенә даими ярдәм итә торган иганәчеләрне, меценат-спонсорларны күрәләтә башка җырчылар алдында фаш итүнең ахыры ике яклы. Артист халкының күргән нәрсәне сорый торган гадәте бар. Ярдәмчел куллы, текә холыклы, сүзе үтәрдәй абруйлы дусларының берәрсен Сөмбеләгә үз ягына авыштырып куйса Хәсәнең нишләр?! Әйтик, Төмәннең күренекле меценаты—доктор Шакиров биш ел буе аның иң якын дусты иде... «Утлар яна учакта»ны җырлап кайт әле дип, Зөһрәне Төмән филармониясенең мең урынлы концерт залына алып килгән иде... Хәзер, әнә, доктор Шакиров Зөһрәләрнең гаилә дусты... Хәсәнгә Себер якларыннан салкын сәламнәре генә килә.

Шикле шикләнер, чикмәнең бөркәнер дигәндәй, Сөмбеләнең күңелендә һаман шөһбә томаны: «Мина түлисе гонорарга ул ким дигәндә биш студент кызны җырлата алыр иде. Хәсән үз кесәсенә зыянга эшли торганнардан түгел, аның һәр уе, һәр фигыле, һәр шөгыле табышлы. Нәкъ менә мине чакыруында ниндидер, әйтелеп бетмәгән хикмәте бардыр аның. Мәгәр мин ул халтурага барам!..»

Хәсән җырчылар язмышын һәйбәт үк белә—«Сарман» кафесы Сөмбелә өчен юк-бар урын түгел.

Моннан биш ел элек тә нәкъ шушындый март ае иде... Сөмбеләне бәйрәмгә Нәүрүзбикә итеп чакырдылар. Ә гармунчы Марат Гомәргә Унышнур булып киенергә туры килде. Концерт азагында, барлык катнашучылар сәхнә түренә тезелешеп бастылар да бертавыштан: «Нәүрүз мөбарәк—бад!»—дип кычкырдылар.

Күпертмә җиңле озын яшел күлмәк, чәчәкле-чуклы такыя кигән Сөмбелә белән йолдырышлы туфрак төсендәге чем-кара кәчтүненең түш кесәсенә биш башак кадаган баянлы Марат Гомәр икесе ике яктан чыгып уртага бастылар. Нәүрүзбикәдән башка яши алмый торган Унышнур «Яз шатлыгы» көен уйный башлауга тамашачы аягүрә басып кул чабарга кереште, җыр тәмамланганчы туктаусыз алкышлап, әйтерсең лә язны каршылады...

Бу күренешне яздырып шул көнне үк «кичке яңалыклар» программасыннан күрсәттеләр. Иртәгесен «Ватаным Татарстан» газетасының беренче битенә зур сурәт итеп урнаштырдылар... Өченче көнне шунда ук некролог чыкты...

«Нәүрүз» пәрдәсе ябылып, таралышырга рөхсәт ителгәч, Марат Гомәр, баянын иңеннән алмыйча гына, Сөмбеләнең юлына аркылы төште.

—«Сарман» кафесына керик әле, ашыкмыйк әле бүген.

—Нәрсә булды сиңа? Беләсең ич, Зәйтүнә өйдә үзе генә калды. Кафега көндез, иркенләп барып килербез.

—Зур кыз инде ул, түзәр... Синең белән бик җитди итеп сөйләшәсе сүз бар.

Сөмбелә сагая төште: «Әллә дәваланырга тәвәккәллиме егетебез?»

—Ярар. Киемнәрне алыштыргач вахтер янында очрашырбыз. Баяныңны аласыңмы?

—Юк. Грим бүлмәсендә калдырам. Монда әйбергә тимиләр. Иртәгә килеп алырмын әле. Безнең бүген җырлап сөйләшә торган сүз түгел.

Марат Гомәрнең уйнаган җирендә баянын калдырып китүе—туй булган җирдә юри бүрек онытып китү ише генә: икенче көнне махмырдан эзләнеп килер өчен.

«Сарман» кафесы Мөштәри урамының аулак бер ишегалдына урнашкан. Ул Язучылар берлеге, Актерлар йорты, Рәссамнар фонды, Композиторлар союзы, филармония, радио, Драма һәм комедия театры кебек янгыравык оешмаларның үзәгендә тора. Шагыйрьләрне йә артистларны тере килеш күрәсең килсә, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында рәхим ит, кафеның йорт иясенә әверелгән шәхесләр көтеп утыра сине. Марат Гомәр монда бик хөрмәтле кунак, кайчан керсә дә аны: «О-о! Назлы-сазлы дустыбыз килде!»—дип, ихластан сөенеп каршы алалар, ярышып-ярышып сыйларга керешәләр.

Сөмбеләне култыклап килеп керүен бик өнәмәделәр, бу кафеда хатын-кыз затына ияләнелмәгән, гармунчы белән җырчыны кул изәп кенә сәламләделәр. «Йорт ияләре» быел Тукай премиясенә кемнәр лаек дигән аптыраштан шултиклем ярсып бәхәсләшәләр иде ки, хәтта зал түрендәге аерым өстәл артында кычкырып сөйләшсәң дә әңгәмәдәшеңне чак кына ишетерлек.

Өстәлгә яшел кыяр салаты килү белән, гармунчы чөлләдә җәяү кайтып әлсерәгән юлчы кебек кабаланып, бер бокалны су урынына түнтәреп куйды. Пычак калынлыгы телемнәре арасыннан кыяр төбен сайлап, тирән итеп иснәде дә киредән тәлинкә читенә куйды. Һәм бокалларны яңадан тутырды:

—Әйдә, берәрне күтәрик әле!

—Нәрсә, дустым, рюмкаларыңны санап утырыр өчен алып килдеңме мине монда? Егерме ел буе саный-саный исәбен югалттым инде.

—Вакланма әле, Сөмбелә. Телисеңме, бу графинны әнә тегеләргә илтеп бирәм.

—Һаваланма, зинһар. Ник чакырдың?

—Бер рюмка җиффәр, аннан әйтәм.

—Аек баштан сөйләшә торган сүз түгел мени?

—Оялам.

—Миннәнме? Гомердә булмаганны.

—Гомердә булмаган—Гомәрдә бар. Шуткы... Сөмбелә, әйдә мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерик.

—Нотариус аркылымы?—дигән булды Сөмбелә, гармунчының тел төбен аңламаганга сабышып.

—Загс аркылы. Өйләнешик, әйдә...

Әллә өйләнешү турында сүз башлады гармунчы, әллә һава торышын тәфсилли—Сөмбеләнең чыраенда һич дулкынлану әсәре сизелми, кеше язмышын тамырдан үзгәртердәй тәкъдимне күптәнге таныш шигырь ише генә кабул итте.

—Хатыныңны кая куясың?

—Беләсең лә. Сине очратканда мин гаиләдән киткән идем инде. Кызымны ярдәмемнән ташламам.

—Әйе. Унбиш ел буе паспортыңда тамгасын йөрттең, рәсми төстә аерылмадың. Хатының кичерер дә кире кайтырга рөхсәт итәр дип өметләнеп яшәдең... Ә мин бу сөйләшүне бик күптән үк көткән идем. Яшермим, яшьлек җүләрлегем белән кеше көлдерерлек батырлыкларга әзер идем. Соң инде, хәзер акыл керде—мин бит синең гармуныңа гына гашыйк булганмын икән.

—Гармуннан бала тумый.

—Җыр туган җирдә бала да туа ул.

—Вәт. Бер кызымны ташлап китәм, икенчесенә киләм.

—Нәрсә, Зәйтүнәне синнән дип уйлыйсыңмы әллә?

—Уйламыйм, беләм.

—Мин сиңа күпме әйттем: Зәйтүнәнең этисе Идрис исемле. Яшьләй сөйгән ярымнан. Кызым—Идрисовна! Маратовна түгел...—Ул, кайда утырганын кинәт исенә төшереп, тегеләр төркеменә карап куйды. Шөкер, ишетмиләр икән.

Гармунчы Сөмбеләнең кызып-кызып ялганлавына сүзсез, елмаеп кына җавап бирде.

Сөмбелә әлеге аңлашуны күңелсез халәттә төгәлләргә теләмәде, бергә-бергә эшлиселәр бар бит әле.

—Әгәр мөнә бу шөгыленнән котылсаң—бөтенләй ташласаң, бәлки ризалашырмын да. Юкса икәүләшеп эчәргә туры килер, сиңа азрак эләксен, дип...

—Ташлыйм. Бүген мин аракы белән бәхилләшәм, әйткән иде диярсең. Иртәгәдән баш төзәтмим—и, бетте-китте. Врачка бармыйм, үзем җиңәм. Дәваланып караучылар күп булды... берсе-бер исән түгел... Урыннары оҗмахтадыр.

—Күңеленә авыр алма, моңарчы сораганым юк иде, әйт әле зинһар, ник шулхәтле эчәсең син? Бөтен дусларыңны югалтып бетердең. Бу кафе санитарларына таянма, ышанычлы багана түгел алар.

—Алайга китсә башкаларны тикшермә, үзеңне бел. Һәр барган җиреңдә берәр житәкчене югалтып кайтасың. Спонсорлар турында әйткән дә юк. Исерек айныгач кеше була ул. Ә син аек килеш телеңне тыя алмыйсың. Җыр ярата торган лидерлар бар чагында җәелеп эшләп калырга кирәк. Сәясәт гел шушылай Мәскәүдән күчә торса, килер бер көн, татар кәнәфиләрен маңкортлар яулап алыр. Ярый да пенсиягә чыгып өлгерсәк.

—Ә яшьләр нишли?

—Яшьләр акчалылар кулында уенчык була белә. Алар өчен борчыласы юк.

—Сүзне кирегә бордың. Алайса, синең туктаусыз эчүеңә мин генә гаепле? Минем аркада «Наз»ны тараттың, мактаулы исем алалмавыңа да мин гаепле.

—Әйдә, тартып керик әле.

—Әнә бит, «йорт иясләре» өстәл артында гына пыскыта.

—Чыгып сөйләшик.

Баскыч төбенә чыккач, ул рәшәткәләп кагылган урам эскәмиясенә утырырга кушты. Тәмәкенең бөтен төтенен берьюлы сыйдырырга теләгәндәй бик тирәнгә сулыш алды. Тончыкмады, йөткермәде, тамак кырмады.

—Ышанмасаң сорый аласың, әнә Илһам абый белән Әлфия апа ялганларга ирек бирмәс, мин утыз биш яшемә чаклы бер грамм хәмер капмадым. Исерекләр күрсәм җенем котыра иде хәтта!

—Балантауга Гөлҗиһан апа белән кайткан мәлне кибет тирәсендә йөргәләдең лә, «сухой закон» дип тормадың...

—Ул чагында кырык тулган иде инде миңа...

—Биш еллык «стажың» булган алайса.

—Уенга бормыйча гына тыңла. Аңласаң—тыңларсың, тыңлыйсың килмәсә—бүлдерерсең... Безнең «Наз» төркеме оешуга ун ел тулган көннәр иде, рәхмәт, Халык ансамбле исеме бирделәр. Яшермим, состав бик көчле иде, мин кызларны җыр укытучылары, музыкаль студия педагоглары арасыннан җыйдым. Башка ансамбльләр студентлардан оеша торган иде: беренче курста укучылар килеп кушыла, диплом алганнары китеп бара, состав гел алышына, яшәрә—ләкин бишәр ел буе түгелгән хезмәт әрәм була. Безнең «Наз»ның составы егерме ел буе үзгәрмәде—егерме ел буе чарландылар, өйрәнделәр, шомардылар, кызларның башкару осталыгы әнә шуннан килә... Ул елларда унҗиде мең һәвәскәр иҗат коллективы бар иде, ил буйлап санаганда аларда

өч йөз егерме мең кеше җырлап йөргән дигән сүз! Мин моны төгәл беләм, «Агитатор блокноты»ннан укырга мәҗбүр иттеләр.

—Лекция укыргамы?

—Юк. Мәскәүдә үтәчәк «Халык иҗаты» фестивалендә катнашыр өчен. Татарстаннан ике коллективны сайлап алдылар. Берсе—Актанышның «Агыйдел» бию ансамбле иде бугай. Икенчесе—безнең «Наз»...

—Һәм син сөенечтән эчә башладың, әйеме?

—Эчәрсең, бар... Иртән Обкомның культура бүлегенә чакырталар, кичен репитициягә КГБ офицеры үзе килә. Җыр текстларын тикшерәләр, үгет-нәсихәт бирәләр, әдәпкә өйрәтәләр.

—Мәскәү чит ил түгел ич инде, ул хәтлек бәйләнмәсәләр.

—Анысы башка мәсьәлә... фестиваль лауреатлары Кремльнең съездлар сараенда йомгаклау концерты белән чыгыш ясарга тиешләр икән, СССРның IV конституциясен кабул итү уңаеннан җыелган депутатлар каршында. Әлбәттә, безнең җинәсебезгә шикләнүче юк, шуңа күрә дә зур сәхнәгә ныклап әзерләделәр. Чит илләргә чыкканда да ансамбль репертуарына шул тиклем бәйләнми торганнар иде.

—Берәр хикмәте булгандыр.

—Хикмәте шул, мең ике йөз делегат арасында Л. И. Брежнев та бар иде. «Татарстан таңнары» дигән җырны ничек башкарганыбызны хәтерләмим, ник дисәң, мин—баянлы дирижер буларак, залга кырын баскан идем, күбрәк делегатларга елмайганмындыр. Дирижерлык канунын үзгәртеп, тыңлаучыларга арка белән торырга рөхсәт итмәделәр... Берзаман, җырлап бетерүгебез булды...

—Ак баяныңның каешы шартлап өзелде...

—Сина көлке... Съездлар сарае бер мәлгә тып-тын калды... Уникe кыз миңа карап өнсез тора. Әйтәм ич, күп булса, нибарысы күке өчкә хәтлек санарлык вакыт үткәндер... куркудан хәлемне үзем генә беләм. Шулвакыт, КПССның Генераль секретаре, СССР Верховный Советы председателе, Советлар Союзы Маршалы Леонид Ильич Брежнев аягүрә басып кул чаба башлады. Әйтерсең лә держаRаның Беренче Дирижеры таякчыгын югары күтәрде—шуны гына көткәндәй, мең ике йөз музыка коралы Ана буйсынды, зал тигез ритмлы алкышларга күмелде. Бу турыда бөтен Ил буйлап сиксәнгә якын язма басылып чыкты. Ул газета-журналлар завод клубы адресына ай буе килеп торды... Йә, горурланырга, мактанырга хакым бар идеме минем моның белән? Минем «Наз» бит ул! Бөтен Казан буйлап сибелгән сәләтле кызларны эзләп тапкан, төркемгә җыйган, җырлар язган, репертуар ясаган, онытылган җырларны заманча яңгырашлы итеп партияләргә бүлгән, дүрт тавышлы вокаль ансамбль төзегән—мин бит ул! Мин барында ансамбль бар, мин юк икән—алар да юк!

—Йә, йә, кычкырып мактанма, мин ишеткәч бик җиткән. Димәк син сөенечне, җиңүләрне, унышны күтәрә алмадың?

—Нинди уныш?!. Җиңү шатлыгы сүрелгәнче дип завод клубы исеменнән Мәдәният министрлыгына хат яздык. Наградной лист тутырдылар, «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем сорап.

—Калганын беләм. Синең исемең юк ич.

—Ник булмасын, бар.

—Бер дә әйткәнең юк.

—Нәрсәсен әйтәсең инде аның... Мин хыялланган зурлау чәлпәрәмә килде. Теге, авыл клубында эшләүче китапханәчеләргә, киномеханикларга өләшә торган «Мәдәният хезмәткәре»н тоттырдылар.

—Ник алай кимсеттеләр икән? Бәлки, Мәскәү Кремленнән кайткан горурлык белән үзебезнең Кремль тирәсендәгеләргә катырак сүз әйткәнсеңдер?

—Әйтмәдем. Хәзергәчә әйтәсем юк, эчемдә яна гына... Мин дипломлы баянчы түгел бит, үзешчәннәр исемлегендә йөрим. Теләсә кайсы

профессиональ жырчы белән гастрольгә чыгарга ярыйм... Ә артист исеме алырга хакым юк. Нотага карамыйча урам көе уйный алмастай дипломлылар атказанган артист булып йөри, ә мин Партия номенклатурасының эчке циркулярына туры килмим. Коммунистлар властьтан төшкәч ничек сөенгәнемне күрсән!..

—Перестройка башлангач ул исемне янадан сорап карыйсың булган.

—Кая инде хәзер... «Наз» таралды... «Гел исерек» дигән ярлык тагылган... Ну мин төзәләм. Иртәгәдән санаторийга китәм. Бүген шешә белән бәхилләшәм, сәрхүшләр белән саубуллашам. Син бар, кайт. Мин кафега сугылып чыгам әле.

Гармунчы белән соңгы күрешү иде бу. Әгәр шушы сөйләшүнең азагы ни белән бетәсен сизенсәме—Сөмбелә аны урамнан керәсе килмәгән малай-шалай кебек итеп алдалап-юмалап уенының аерыр, өенә алып китәр. Зәйтүнә белән икәүләшеп ашказанын юдырырлар, белгән кадәре ярдәм итәрләр, кирәксә таныш врачны чакыртырлар иде. Ә инде Балантауга кайтып, әнисенә чүлмәк утырттырып коры сыра белән берәр атна дәваласаң—санаторийларың читтәрәк торсын кана...

Асыл ирләрне инсульт кыра...

## Уенчык эти

Яңа көн туды исә яңалык көтә хәзер Сөмбеләне.

Бүген аны телефон сызгысы куркытып уятты. Төнге уйларыннан тәмам изелеп, ниһаять йокыга китеп өлгергән кебек кенә иде әле. Күзен ачкач бераз аңышмыйча ятты, өйдә сызгылар күп: кызы плитәгә куйган чәйнек борынын сызгыртамы, сумка кесәсендә калган мобильникмы, домофонныкымы, әллә будильник өзгәләнәме? Шәһәр челтәре белән тоташкан радиотелефон сызгысы икән, ул әле өй эчендә яңа техника, тавышына һаман ияләшә алмыйлар. Иртүк килгән хәбәр юньлегә булмас, тизрәк җавап бирергә кирәк, дигән уй белән юрган эченнән чыгу уңаена стенадагы сәгатькә күз салса—йә, Хода, өйлә вакыты җиткән ләбаса! Көн белән төн буталган... Зәйтүнәнең укырга киткәнен дә сизми калган... Телефоннан уятучы да улдыр, берәр конспекты онытылгандыр да шуны китереп китәргә кушадыр.

Телевизор караучылар бик тиз танырлык ягымлы кыз тавышы иде телефонда.

—Сөмбелә апа, исәнмесез?

—Исәнме, сеңлем. Телефизорым кабынып калган дип торам, тавышың телефонга күчкән икән.

—Күптәннән бирле эзлим инде мин сезне, һич өегездә туры китерә алмыйм.

—Җырчылар сайрар кош кебек—күчмә халык бит инде ул. Өйдә тик ятсаң берәү дә китереп бирмәс. Акча бик тирәндә хәзер, сеңлем, еракка барып аласы.

—Сөмбелә апа, бер-ике соравыма тамашачылар өчен кызыграк итеп җавап бирә алмассыз микән?

—Кызыклы җавап ишетәсең килсә, сорауларыңны кызыграк итеп бир әле, сеңлем.

—Сез бәхетле кешеме?

—Бәхетле җырчының моңы булмый, сеңлем.

—Үзегезне кечәге җырчы дип саныйсызмы, әллә бүгенге җырчымы сез?

—Мине: җырчы халыкчан булырга тиеш, дип тәрбияләделәр. Бүген сәхнәнең беренче таләбе—сексапильность! Тән беренчел икән, җыр—икенчел, димәк.

—Кызыгыз Зәйтүнә үзегез кебек матур җырлыймы? Аны да җырчы итәргә исәбегез юкмы?

—Кошлар үз баласын сайрарга өйрәтми, очарга гына өйрәтә.

—Җырчыларны сайрар кошларга тиңләргә яратасыз икән, бүген бит без аларны эстрада йолдызлары дибез.

—Элек сандугачка тиңләү модада иде: Сарман сандугачы, Актаныш сандугачы, Арча сандугачы... Шуңа күрә дә сандугачларыбызга «Йолдыз авыруы» йокмый.

—Йолдыз дип атасаң да, сандугач дисәң дә—барыбер шул җырчы инде ул.

—Барыбер түгел. Йолдызларны фабрикада шомарталар, ә сандугач табигать баласы.

—Спонсорларыгыз күпме? Һәм сер димәсәгез, кемнәр алар?

—Сер түгел. Юк алар минем. Булмадылар да. Хәзерге яшьләр спонсорларны сөйдергеч ясатып әсир итәләр... Ә минем—тамашачым исән-сау булсын.

—Сезнең хакта никтер газеталар бик сирәк яза.

—Артистның язмышы халык телендә.

—Клипларыгыз юк. Телевизорлардан күренмисез.

—Чакырмыйсыз ич, сеңлем.

—Вәт, вәт, Сөмбелә апа, мин сезне «Адәм белән Һава» тапшыруына чакырам. Сез бик фикерле әңгәмәдәш икәнсез. Чакырам дип әйтү бик үк төгәл булмас, өегезгә килеп төшерәбез. Проектның бөтен хикмәте дә шунда: йолдызларның, ягъни сандугачларның шәхси тормышын бик якыннан күрсәтәбез.

—Абау сеңлем, төшереп күрсәтерлек әллә нәрсәм юк ич минем... Фатирым да кооператив бүлмә, җиһазларым да социализм чорыннан калган.

—Аеруча талантлы кешеләр генә гади тормышның тәмен белеп яши ала дип уйлыйм мин.

—Сеңлем, гади булып күренер өчен генә иске-москы бүлмәдә шоу ясый алмыйм инде.

—Бенефис алдыннан бушлай реклама кирәкми мени?

—Нинди бенефис?

—Мина шулай дип әйтәләр.

—Ә-ә, бенефис! Әле аның афишасы басылмаган, кайсы залда үткәрәсем дә билгеле түгел... Аннан соң, ни бит, сеңлем, сезнең ул тапшыруыгыз парлылар турында, ә минем Адәмем юк бит...

—Сез ялгыз яшисез мени?

—Япа-ялгыз түгел, зур кызым бар.

Тапшыруга кодалаучы Сөмбеләнең төгәл фикерле төзек җөмләләреннән тәмам иләсләнде. Ул инде «Адәм белән Һава»ны оригиналь ток-шоу итәргә әзер иде, шуңа күрә җырчыны кулдан ычкындырырга һич теләмәде.

—Сөмбелә апа, балаларның җилдән тумаганын беләбез. Әйдәгез, әтисен эзләп табыйк. Чакырыйк. Вәт интригалы, бик көчле тапшыру булыр иде бу!

—Сеңлем, кызымның әтисе исән түгел инде.

—Танылган кешеме, Сөмбелә апа?

—А как же...

—Сер итеп кенә әйтегез зинһар, кем ул?

—Пушкин! Гафу ит сеңлем, өметегезне акламадым. Хушыгыз. Кияүгә чыксам үзем эзләп табармын сезне.

Икенче көнне телевидениедән тагын шылтыраттылар. Бу юлысы «Кин күңел» редакциясеннән, Сөмбеләгә кунакка килеп, берәр тәмле ризык пешергәнен язып алырга телиләр икән. «Кин күңел»дән үзенең кухнясын күрсәтмичә бер Сөмбелә генә калгандыр инде, бөтен җырчы яраткан ашы белән мактанды. Ярты еллык эш планын начальство раслый, сезнең янга үз

белдегебез белән килмибез, дип ышандырырга бик тырышсалар да Сөмбелә ризалашмады. Җан тынычлыгы табардай соңгы сөенече—Зәйтүнәсенен сабыйлык авазлары сеңеп калган куышны гайбәт хөкеменә ыргытырга теләмәде.

Татарстан телевидениесе икегә бүленгәч, программалары үзара ярышка чыкты. Моңарчы күз алдына да китереп булмаган турыдан-туры элемтәләр, яшь тамашачылар өчен ток-шоулар, җыр бәйгеләре, бәйрәм трансляцияләре үтеп керде. Яңа дикторлар, яшь алып баручылар, еш алышына торган редакторлар, продюсер үзәкләре пәйда булды. Яшьләрнең Сөмбелә язмышындагы сикәлтәләрне белеп бетермәвенә гаҗәпләнәсе юк, алар эстраданы күбесенчә хит-парадлар, клиплар, шлягерлар, конкурслар, күптән ашкан шәхси газеталар аша гына белә. Бүген язылган җырлар зәңгәр экран яктылыгы белән, радиодулкыннар тизлеге белән тарала... Сөмбеләләр исә һәр тамашачыга күзгә-күз карап, тавыш таралу тизлеге белән, гармун моңында үсте.

Телефон аша сюрпризлар килә торды.

Инде тимер юл вокзалы каршындагы өч катлы ательедан шылтыраттылар һәм Сөмбеләне аяктан ега яздылар: «унмененче заказ» дигән акцияләре котелә икән, ул бәхетле кешене Зәйтүнә итеп, бушлай күлмәк тегеп, прессаны чакыртып, зурлап бүләк итәргә телиләр. Ризалыкны тиз арада хәбәр итәр өчен телефоннарының номерын әйттеләр.

Шушы хәбәрдән соң Сөмбелә бенефисны ашыктырырга булды. Билгесезлектән эзләүгә караганда, эзәрлекләүченең үзенә ау кору җайлырак. Хәлиткеч вакыйгаларны ашыктырыйм дисән, бенефис иң кулай тамаша—дус-дошманың, көткәнен-күрәлмаганын, ихласын-мәкерен бөтенесе җыела, сәхнә белән зал бергә кушыла, кичәге сөексез җырчы бүген мактаулы чәчәккә күмелә... Моның өчен күп кирәкми: залыңны эзлә, арендасын түлә, афиша бастыр, чакыру билетлары эшләт, тамашачыңны җый, телевидение килерлек программа төзе, катнашучыларны барлап исемлек тотыр, банкетлык акча җый...

Яңа гына бенефис үткәргән җырчылар аңа шәп кинәш бирделәр, матди ярдәм эзләп мескенләнеп йөрмә, иң бай спонсор—хөкүмәт үзе, диделәр.

Артист кешенең хөкүмәте Мәдәният министрлыгы булыр, әвәл аларның отказын тыңлап карыйм, диде дә кабул итү көненә чиратка язылып кайтты Сөмбелә. Көне-сәгате җиткәнче күңеленнән генә министр ханымга әйтәсе сүзләрен кабатлады, җөмләләрен шомартты, вакыт-вакыт әрләшеп тә карады хәтта...

Министр, татарча каршы алып, русчалатып озата торган кеше иде. Сөмбелә авызыннан «Бенефис» дигән сүз чыккач аның татарчасы бик тиз бетте.

«Быелгы смета әллә кайчан расланган, өстәмә чыгымнар хакында сүз була алмый. Түгәрәк дата түгел, гади иҗат кичәсе өчен зурдан кубарга кирәкми. Солидный залларда үткәрер өчен мактаулы исемең юк. Наградной лист тутырсаң да тиз генә өлгермәячәк, чират бик зур. Аннан соң нинди исем бирәләр бит әле. Юбилейлар үткәрү бумга әверелде. Җырчы шагыйрьләр анда елына икешәр-өчәр бенефис үткәрәләр, ну акчаны үзләре эзлиләр, бюджет кесәсенә кермиләр...»

Сөмбелә, парта өстенә терсәген куйган мәктәп баласы кебек, кул күтәреп сүз сорады. Министр мондый әрсезлектән аптырап янадан татарчага күчте.

—Әйе?!

—Бөтенләй үк бенефис түгел. Мин бу кичәне гармунчы Марат Гомәр истәлегенә багышларга телим. Афишада күрсәтмичә генә. Ул эшләгән завод клубына дусларын җыеп.

—Бик яхшы беләм Марат Гомәрне. Ләкин бит аның юбилее түгел.

—Арабыздан киткәненә ун ел булды.

—Ә сезгә кем соң ул Марат Гомәр?

Әйтергә ярамый торган җавап күзгә яшь булып тыгылды. Сөмбелә, мөмкин кадәр башын читкә борып, кулъяулык белән күзләрен каплады.

—Сорамыйм, сорамыйм. Әйтергә ярамый икән—әйтмәгез. Барыбызның да яшь чагы булган.

Министр, туган апага әверелеп, тавышын йомшартты, телефоннан номер җыеп ике касә чәй сорады. Бүлек кызлары кайсы-кая йомыш белән таралганмы, чәйне бер гүзәл егет кертте. Чәй йотып куйгач, баягы сорау бик ерагайганчы дигәндәй, Сөмбелә аклану рәвешендә әйтеп куйды:

—Минем гармунчым иде ул…

Үзенең эчәсе килмәсә дә чәйне ике касә итеп иптәшкә генә сораткан иде министр. Сөмбелә эчкән арада ул кара тышлы атналык көндәлеген ачып бер-ике җөмлә өстәде.

—Сез борчылмагыз. Премьер исеменә бүген үк өстәмә хат язып акча сорарбыз. Нәтиҗәсен лично үземә шалтыратып белешерсез. Бер атнадан.

Министрларның «кабинеты» дип тикмәгә генә аталмыйдыр, бу бина гаять зур кабинет рәвешендә салынган, бүлмәләрен саный китсән—исәбенә чыкмалы түгел. Инде чыгып життем, дигәндә ишек төбенә дә кабинет ясап куйганнар, кителенең җинбашына «МВД Россия»неке дигән мөһер сугылган егет саф татар телендә: «Хушыгыз!»—дип калды. Ялыныч белән килгән китек күнел киребеткән уйлардан һич арына алмас, Сөмбелә «Хушыгыз» дигән сүздән дә гаеп эзләп маташты, «бүтән килмәгез» мәгънәсендә бәхилләшеп әйтелә түгелме соң бу? «Сау булыгыз!» диярга кирәктер, дөрес өйрәтмәгәннәр үзләрен…

Мәрмәр баскычлардан йөгереп төште ул, Азатлык мәйданында аны танырдай кешеләрнең очравы бик мөмкин, бенефисына акча соранып йөри иде димәсеннәр… Ленин һәйкәле янына житкәч, никтер туктап калды. Ничәмә-ничә еллар шушы бакчада йөреп, пролетариат юлбашчысының йөзенә туры караганы юк икән әле Сөмбеләнең… Бактың исә, скульптор әлеге сынны киләчәк өчен коеп куйган—күрегез, әнә, Владимир Ильичның күзләрендә реформаторларга карата нәфрәт, йөзендә яшь буын өчен борчылу… Хәер, һәйкәлләрнең елмаеп торганын күргәнебез юк әле… Һәйкәл тирәсендә күпме мәһабәт бина: Опера һәм балет театры, Ратушалар йорты, Зур концертлар залы, Министрлар кабинеты, Дәүләт Советы, Милли Мәдәният үзәге… Ә Сөмбелә, шәһәрнең җимерек йортлары арасында кысылып калган завод клубын сагынып йөри. Яшьлек еллары исенә төшкән саен, Җинү юлларын ыграк сагынган сугыш ветераны кебегрәк…

Бенефис көне якынлашкан саен ыгы-зыгы арта барды. Соңгы унбиш ел эчендә лекцияләр, җыелышлар, кинәшмәләрдән гайре чаралар күрмәгән клубның урындыклары җимерелгән, пәрдәне ачып яба торган лебёдкалары күгәргән, люстраларын тузан баскан, лампочкалары сукырайган иде.

Шәһәр буйлап көн аралаш диярлек йөреп, кемнәрдер сыдырып ташлаган афишаларны янартырга туры килде. Өйдәге телефонны ташлап китәр хәл юк, Зәйтүнә белән чиратлашып, хәлдән килгәнчә, янында торырга тырыштылар. Туктаусыз чакыру билетлары сорыйлар, катнашырга теләүчеләр арта, телевидение сценарийны ашыктыра, рәсми оешмаларга, котлау өчен, Сөмбеләнең иҗат биографиясе кирәк. Радиолардан укыла торган белдерүләрне янартырга кушалар…

Ун көн кала тагын ательедан эзләделәр. Инде шәт, күлмәкләр турында кайгыртыр чак җиткәндер дип, кызын ияртеп, игелек эшләргә никтер атлыгып торган тегүчеләр янына йөгерде.

Осталарның Сөмбеләгә бик исләре китмәде бугай, эксклюзив үрнәкләр арасыннан классик стильгә тегелгән ике күлмәк сайлап бик тиз күндерделәр.

Ә менә Зәйтүнә янында мәш килделәр... Кызның үлчәнмәгән җире калмады... Гәүдәсен тыгыз кара челтәр белән капладылар, алтын җепләр белән күпертеп чигелгән алтын тафтага төрделәр, муенына роза чәчәкләредәй сары ефәктән эрләнгән шарф урадылар.

Алсу тасмалар белән бәйләп көзгедәй елтыр кәгазьләргә төрелгән ике күлмәкне тез өстенә куйган килеш утыра торгач, Сөмбеләнең сабырлыгы төкәнде.

—Вообще-то минем бенефис иде. Кызым кунак булып кына бара.

Үз баласыннан үзе көнләшкәндәй килеп чыкты...

—Кыз бала ахырдан әнисенә чәчәк бәйләме чыгарса, бик эффектлы күренәчәк,—диделәр осталар, әни кешегә бәхәсләшергә ирек бирмичә.

—Алай ук алтыннан коймасагыз да ярар иде. Түләргә туры килсә бюджетым җитмәс.

—Алдан сөйләшкәнчә, Зәйтүнәгез ун меңенче клиент буларак реклама акциясенә эләгә, «Золотая лихорадка» коллекциясе белән җәйге сезонны ачып җибәрәбез.

—«Алтын бизгәк» дигәч, кызымның түбәсе күккә тиде. Үзегезгә карагыз инде алайса.

Билетлар сатылып беткән, чакырулар күпләп таратылган, телевидение килгәч ишек төбендә артык урын сорап торучыларның төркемен ажиотаж итеп күрсәтер өчен татар теле бүлекләренең студентларын дәштеләр. Ә шулай да Сөмбеләнең тынычлыгын җуйган күңелен агач корты кебек итеп тымызык шик кимерә—буп-буш залга җырларга мәҗбүр иткән үчлеләр тагын берәр этлек әзерләмәсме?

Шәһәрдә кар югалды. Көздән тырмаланмыйча калган сарут камыллары шакыраеп кипкәч, тротуар читләреннән тузан исе күтәрелде. Кышкы аклыкта масаеп утырган ялангач тирәкләр, күләгәләрен югалтып, кояш баешыннан оялышып утыралар. Куе кызыл, баллы шәфәкъ нуры тамак төбенә утыра.

Кыш көне калын пәлтәләрен, мамык шәлләрен, җылы кофталарын, йон оекларын, куныччлы итекләрен салдырыр өчен хатын-кызларны күпме үгетләргә кирәк булыр иде?!. Яз чишендереп куйды үзләрен. Тамашачылар юкарып, нәфисләнеп, канатланып калды.

Артистлар тиз җыелды. Килгән берсенең ике генә соравы бар: түрәләрдән кемнәр котлый? Мин кем артыннан җырлыйм?

Кием алыштырып өлгергән артистлар ябык пәрдәле сәхнәгә ашыкты, бизәлешне күрәселәре килде. Бер читтә урындык өстендә «Rigonda» радиоласы тора, ә икенче читтә, чәчәкләр җыяр өчен, кыска тәпиле журнал өстәле. Супер-пәрдәгә, җөй тегүчеләр энәсе белән, утыздан артык төрле афишалар эленгән. Бөтен бизәлеш шушы! Гап-гади, образлы һәм иң мөһиме—арзан! Ул афишаларга Сөмбеләнең бөтен иҗади биографиясе сыйган.

Грим бүлмәсенә Рөстәм йөгереп керде. Ул «Гран-при» алган чагыннан гәүдәгә хәзер ике тапкыр чамасы артса да җиңел сөякле, өлгермәгән эше, җитешмәгән җире юк, мәҗараларга гел алдан барып эләгә.

—Җәмәгать, кем ничек киенеп өлгергән, шул килеш әйдәгез әле, пәрдә ачылганчы бер кызык күрсәтәм!

Кызык күрсәтәм, дигәндә артистларда дөнья гаме бетә, кайсы ярым киенгән, кайсы ярым чишенгән килеш ияреп китте.

Сәхнә артында тагын бер калын пәрдә бар—ул һичкайсы якка да ачылмый, түрне томалап тик тора, артист халкы аны үзенчә задник дип үртәп йөртә. «Задник»ның бу ягында уен, ә теге ягында чынбарлык хөкем сөрә. Ике хакыйкать арасына эленгән әлеге пәрдә белән тоташ стена арасында киң юл кала, концерт барышында, кирәккәндә тамашачыларга сиздермичә генә, сәхнәнең уң ягыннан сул ягына арлы-бирле йөрер өчен җайлы ул. Борыслардан

мүкләп күтәрелгән тоташ стенаны калын фанер белән тышлап акка буяганнар—нәкъ дәфтәр бите кебек кызыктырып тора... Артист халкы ручкасыз йөрми, фанер дәфтәр түзә. Мактаулы кунаклардан калган чуар язмаларда татар әдәбиятының һәм сәнгатенең соңгы илле еллык шәҗәрәсе: берсе-бер җавапсыз калмаячак адреслы үртәүләр, кинаяле теләкләр, имзалар, рәсемнәр... «Задник» сүзен татарчага турыдан-туры тәрҗемә итсәң, әлеге язмаларның бик күбесе җисеменә тәңгәл килер иде. Әйе, клублар дәүләтнең оптимизация программасына эләгеп, бөтенләй сүтелеп беткәнче, бәлкем әле дивар иҗатының фанатлары табылыр, күчермәләрен туплап аерым китаплар чыгарыр, шушы имзаларны, сурәтләрне, такмакларны бизәк итеп, иҗат кешеләренең фатирына ябыштырырга ярардай обойлар сатыла башлар...

Хәзер яз житкәнне шуннан белеп була—боз катлавы эрегәч, җир өстенә... сыра сатучы палаткалар калка, карагыз. Ә элек шәһәргә язны язучылар оештырган «Казан язы» әдәби-музыкаль кичәләре алып килә иде. Мәркәзебезнең унике клубына һәм дүрт сарайга (театр биналарында концерт кую модасы юк иде) шау-гөр килеп халык җыела, җыр белән шигырь, музыка белән юмор үрелеп бәйрәмгә әверелә иде. Филармониянең эстрада бүлеге оештырган концертлар завод клубына керми калса—бу инде хаҗга барып сәҗдә кылмыйча кайтуга тиң хафа булыр иде... Дивардагы имзаларның күплеге әнә шуннан килә.

Йөзәрләгән исем арасыннан Марат Гомәрнең автографын эзләп таптылар. Этешә-төртешә укыдылар. Телдән-телгә кабатладылар. Никтер Сөмбеләне чакырып китерделәр, ул укыганда, аңа комачауламаска тырышып, читкәрәк китеп бастылар. Язуы бик кыска булса да никтер озак укыды:

*«Күпме кызләр күреп онытылган...*

*(Имза) 1987 ел, 1 март.»*

...Балантаудан сихәтләнеп килгәч язган. Бәйрәм алдыннан кызлар репетициягә җыелгандыр дип ашыгып кайттык. Якшәмбе көн иде, ахрысы. Күчтәнәчкә дигән коры сыраны биш литрлы бидоны белән клубка күтәреп кердек. Репетиция беткәч, Хатын-кызлар көне итеп алдан ук бәйрәм үткәреп куйдык... Уйлар дәрьясына иркенләп чумарга ирек бирмәделәр, авыл мәктәпләрендәгечә электр кыңгыравы чыңлады, өченче тапкыр... Беренче имтиханына, ачык дәрескә килде Сөмбелә. Аудитория шыгрым тулы, басып торырлык урын юк, ишек каерылган килеш ачык калган—анда да халык өелгән. Бүген соңгы имтихандыр бәлки, егерме еллык иҗат мәктәбенең чыгарылыш кичәсе...

Габдулла Рәхимкулов җырлавына пәрдә ачылды. Утлары сүнгән залга сәхнә яктысы таралды. Кул чабып каршы алырга өйрәнгән тамашачыларны сискәндермәс өчен, Сөмбелә вак-вак, әкрен адымнар белән чыкты. Радиола янына килеп «Дим-дим» җырын Таһир Якуповның «Карачлы авылы көе» белән алыштырды. Граммпластинка бик иске иде, адаптерның энәсе:

Житәлмый дуслар, житәлмый
Өзелеп сөйгән ярга...

—дигән буразнаны сикереп чыга алмыйча «Сөйгән ярга... сөйгән ярга... сөйгән ярга...» сүзеннән тотлыга башлады. Сөмбелә аны бөтенләй сүндереп уртага чыкты. Миләүшә чәчәгедәй куе зәңгәр йөнтәс күлмәгенең озын итәге идәннән сөйрәлеп килгән килеш бераз тартылып калды. Чәчәк бәйләмедәй кысып алган бил путасына сул кулын куеп баш иде. Ул гәүдәсен турайтмыйча кул чабулар тынмады... Ялтыравык шыпка беркетелгән өч аяклы микрофонга якынайды. Уң кулында Рәхимкуловның җыр тәлинкәсе иде.

—Исәнмесез, сөекле тамашачыларым, туганнарым, якташларым. Моннан

егерме ел элек мин менә бу күлмәгемне киеп беренче тапкыр шушы сәхнәгә чыккан идем, җиңе дә озын, изүе ябык. Чорына күрә бик модный иде ул. Бер җире дә кысмый—биле дә, күкрәге дә...

«Фигураңны шәп саклагансың!»—дип әйтергә теләүчеләр кул чапкан иде, аларга бөтен зал кушылды.

—Рәхмәт!—дип тагын баш иде Сөмбелә.—Әвал Габдулла абый Рәхимкулов, аннан Таһир Якупов бригадасына куштылар. Соңрак Илһам абый белән Әлфия апа да иярткәли башлады... Кулымда аларның патефон тәлинкәләре генә калды... Ә бүген, әнә теге афишаларга, минем исем янына кемнәр язылган—барысы да катнашачак. Җыр индустриясе шулкадәр тиз үсте ки, бенефиска әзерләнгәндә менә шушы тәлинкәләрне уйнатырлык ни патефон, ни проигрыватель таба алмадым. Ижаудагы җизнинең дачасында менә шушы радиола сакланган. Әле егерме ел элек кенә һәр өй саен яңгыраган тәлинкәләрне магнит тасмалары, компактлы кассеталар алыштырды. Инде синтезаторларны, мини-сиди дискларны җайлы дибез. Саннар белән музыка язабыз. Ә барыбер чын гармунчыны алыштыра торган техника юк һәм булмас та. Баянчыларны каршы алыгыз!

Ике баян тавышы Сөмбеләнең җырын күтәреп алды.

Күгәрчен гөрлидер,
Баласын уятырга.
Әле дә ярый сез дуслар бар
Күңелне юатырга...

Телевидение тоташтан йөз минут кына яздыра ала икән. Ике тапкыр зурлап тәнәфес ясарга туры килде. Сөмбелә алты костюм алыштырды. Ул киенгән арада дуслары җырлады. Төркем-төркем кунаклар чыгып бүләкләр бирде, конвертлар тапшырылды, сәхнә чәчәккә күмелде. Кайчандыр банкетларда, теплоходларда, бәйрәм кичәләрендә сөйкемсез сөяккә әверелгән түрәләр исеменнән телеграммалар укылды... Якташлары залдагыларны Сөмбеләнең туган ягында кабат үткәреләчәк иҗат кичәсенә чакырдылар...

Ниһаять, бенефис үзенең финалына якынлашты.

Катнашучылар сәхнә түренә тезелде. Сөмбелә кыл уртада калды. Бергә җырланасы соңгы җырның музыкасы башлануга залда ут кабынды. Сульяктан, алтыннан коелган Зәйтүнә, ак розалар бәйләме күтәреп сәхнәгә менеп килә иде. Шулвакыт, сәхнәнең уңъяк баскычыннан тагын бер кыз күтәрелде. Ул нәкъ Зәйтүнә кебек киенгән, чәчендәге ефәк тасмасына чаклы алтынсу төстә. Артистлар турында яңалык, гайбәт һәм имеш-мимеш укыр өчен генә дә өчәр-дүртәр газетага языла торган җанатар тамашачы мондый яңалыкны көтмәгән иде. Сәхнәгә чыкканда һичкайчан күзлек кими торган Сөмбелә үзе дә бу «игезәкләрнең» кайсысы минем кызым соң әле—ак чәчәклесеме, әллә сары розалар тотканымы дигәндәй, әле уңга, әле сулга борылып каушап торды. Парадка тезелгән артистлар да, Сөмбеләнең ике кызы юклыгын белә торып, иңбашларын җыерып бер-берсенә караштылар.

Иң нык гаҗәпләнгәне Зәйтүнә булды. Ул күзгә күренмәс көзгә каршына басып, түсе, бите, авыз-борыны, каш каралыгы, чәч бөдрәлеге белән үзенең алтын күчермәсенә килеп орынырга, аның кулыннан тотып әнисе каршысына икәүләшеп барырга мәҗбүр иде.

Сөмбелә бәйләмнәрнең агын да, сарысын да кулына алмады. Ул, кызларның уртасында калып, чәчәкләре белән кочагына кысты... Әлеге сюрпризның бүләк түгеллеге, ә сәнгатьчә үч алу икәне аңлашылса да рәнҗүен йөзенә чыгармады... Пәрдәсе ачылган сәхнә—ул артистларның үзара татулык мәйданы, язмышын башкарган роленә караганда аянычрак булса да

тамашачының күз алдында син театральләшкән уен уйнарга мәҗбүрсең. Телевидениенең өч камерасы да бер ноктага төбәлеп, пардан киенгән кызларны бүгенге бенефисның азагына «стоп-кадр»[1] итте. Елмай, Сөмбелә, җинелсәң дә җинүче булып күрен...

Пәрдә ябылгач сәхнә чынбарлыкка әйләнеп кайтты... Интригага сусаган артистлар, кием алыштырырга ашыкмыйча, никтер, җанга тиеп, таралышмыйлар да. Өчәр-дүртәр кешелек төркемнәргә бүленеп мажара көтәләр. Хәзер ул, үги кызны якасыннан алып, теге автографлы фанер стенага терәр: «Кем котыртып җибәрде сине?»—дигән соравына җавап ишеткәнче өзгәләнер...

Ә Сөмбелә пәрдә ябылып беткәнне сабыр гына көтте, кызларның икесенең дә маңгаеннан үпте, рәхмәтен әйтте. Барыгыз, ял итегез дигәндәй аркаларыннан сөйде.

—Зәйтүнә, музыкантларга әйт әле, бүләкләрне грим бүлмәсенә ташысыннар. Чәчәкләр шунда торсын,—дип кычкырып калды ул алар артыннан.—Йә, сценарий шәп чыктымы? Үзем яздым, лично! Ну, кызым булышты инде бераз, финал өлешендә.—Сөмбеләнең куана-куана сөйләнүе сәхнәдәге төркемнәрне чәчте.—Ә хәзер банкет! Сәхнәдә уткәрәбез. Әгерҗенең Кодаш авылында бер шундый банкетка эләккән идек. Егетләр өстәл күчерә, кызлар урындык ташый. Тагын ун минуттан рестораннан «полевая кухня» килеп төшә! Клуб безнеке бүген, арендасы иртәнгә чаклы түләп куелган...

Уйларның таралу тизлеген исәпләрдәй галим тумаган әле. Әмма, борчулы кешенең сизгер уе гайбәттән, тавыштан, хәтта яктылыктан да тизрәк йөри... Аноним хат язармы, телефоннан шылтыратырмы, әллә Сөмбеләне урамда көтеп торачакмы ул ханым?! Ел буе эзәрлекләгән сары табышмакның ниһаять җавабы табылды. Ә шулай да көндәше белән сөйләшәсе килә, бик килә Сөмбеләнең. Ул үзенең егерме ел буе кылган бөтен хаталары өчен бары тик шушы ханым алдында гына гаепле һәм бүген җавап тотарга әзер.

Ханым коридорда көтеп тора иде. Тәрәзәгә баккан җиреннән кисәк борылды, ләкин урыныннан кузгалмады, көндәшенең килгәнен көтте. Сөмбелә каушавын сиздермәс өчен аңа таба атлады... Ниһаять ике арада үрелеп чәчләрне йолкышырлык кына бушлык калды. Ханымның нәфрәте юк. Йөзендә бөтен бәхетсезләр нужасын үзенә алган кебек хәлсезлек, алҗыганлык сизелә. Кичке Казанга курыкмыйча ничек чыккандыр—бөтен хәзинәсен элгән: колагында, муенында, бармакларында, беләгендә алтын да энже генә. Сөмбеләгә ул ерак сәфәрдән таланып кайткан хезмәткәре итеп, баш бухгалтер күзләре белән карап тора.

—Таныдыңмы?—диде ханым сүрән тавыш белән.

—Таныдым. Тик еллар буе тенкәмә тигән кешене синдер дип һич уйламадым.

—Бераз үртисем килде.

—Шактый кыйбатка төшкәнмендер: чәчәкләр, концертлар, Зәйтүнәнең көлмәге...

—Мин банкта эшлим. Зарплатам әйбәт, эшмәкәр дусларым күп. Зәйтүнә аның кызы... димәк миңа да якын кеше... Кызларыбызның яшь аермасы ике генә ел. Әгәр син Балантавында фермада гына калган булсаң, без аның белән тыныч кына парлашып яши идек әле.

—Арагызга кермәдем. Гармунчыны кар өстеннән табып алдым. Ялгышмасам, син куып чыгарган идең инде аны.

—Ирләре кайтып-китеп йөргән гаиләләр күп лә...

—Сүз виртуоз музыкант турында бара, аны гади мужиклар белән

[1] Стоп-кадр—соңгы күренештә туктап калу.

чагыштырып, урам сәрхүшләренә тинләмик. Мина үпкәләрлеген юк, гастрольләрдә сабый бала урынына көйләдем, сәхнәдән аермадым, өстен-башын карадым, хәлемнән килгәнчә әҗәлдән сакладым…

—Ярар, үпкәләшмик. Кызларыбыз аралашып яшәсеннәр иде.

—Анысын үзләре хәл итсеннәр, мин сөенермен генә. Ә син ник банкетка калмыйсың? Монда гармунчының дуслары бик күп, искә төшереп утырырбыз.

—Ул истәлекләрдә мин юктыр инде. Жан көеге булып утырганчы, китәрмен генә. Альбина кызым калсын, әгәр теләсә…

Озын өстәлнең ике генә урындык сыярлык тар ягында чөкердәшкән Зәйтүнә белән Альбина табындагыларның гел күз угында иде. Ризыкка үрелгән арадамы, рюмкаларны чәкәштергәндә дисеңме, йә күршеләренә баккан булып, һәркем жаен таба, аның саен кан-сеңелкәшләргә күз сирпеп алырга өлгерә. Кызлар бу хәлне сизмиме—бик сизә… сынаулы карашларны тоеп һәм жыеп утыра торгач, Зәйтүнә зур яшел алманы уртага ярып, берсен Альбинага тоттырды:

—Әйдә,—диде ул, пышылдап кына, жиненнән тартып,—әнигә килгән бүләкләрне күрсәтәм.

Жыелган бүләкләр—күрмәгән хәзинә түгел, кызларга серләшеп алырга бер хәйлә генә кирәк иде.

—Әтинең чын йөзен хәтерләмим. Өйгә сирәк кайтты, кайткан саен төрле-төрле кыяфәттә була иде ул,—диде Альбина.

—Минем бер уенчык өем бар, әни аны фотоательедан эшләтеп алып кайтты—пластмассадан ясалган сувенир, тәрәзәсе урынына калын линза куелган, якын килеп карасаң—өй эчендә әти утыра, нәкъ тере кебек, күзгә текәлә,—диде Зәйтүнә.

—Кызык… икебезгә бер әти.

—Ә беребезнең дә әтисе юк…

## Шамакайлар

Тамак кипкән, карын ачкан чак. Бенефиста тир түккән халык салатларга ябырылды. Ананас, алма, томат сокларының кәгазь савытлары берәм-берәм жиңеләеп, өстәлдә таба куярлык урын бушады. Борай бәлешенең күмәч бөкеле капкачын ачкач, сәхнәгә итле шулпа салып пешергән ярма боткасы исе таралды. «Симез агай» кафесыннан килгән официант кыз өлеш тәлинкәләренә бүлгәләгән арада, Сөмбелә залга төшеп, рәт арасына кереп басты.

—Бер бәлеш исе бөтен залга таралды!—диде ул бөтенесенә ишетелерлек итеп.—Эврика! Башыма яна уй килде! Ижат кичәләрен нәкъ менә шушылай үткәрергә кирәк: сәхнәдә сый-хөрмәт, бәлеш, өчпочмак, шашлык, эчемлекләр. Тамашачы мәжлесне күзәтеп утыра. Юбилярга багышлап тост әйтүләр, жырлау-сөйләүләр микрофон аркылы бөтен залга житкерелә. Чынбарлыкка бик якын, тормышчан ситуация, тамашачы үзен мәжлестә катнашкан кебек хис итәчәк.

—Һәм бөтен зал, бәлеш исенә түзәлмичә, сәхнәгә күчеп бетә! Мен тизрәк, ризык суына. Икенче бәйрәмеңне шулай оештырырсың,—диде кәефле дуслар.

—Ә минем бүтән бенифисым булмаячак!

Өстәл арты жавап көтеп тынып калды. Сөмбелә тынлыкны озакка сузмыйча дәвам итте. Сөйләнә-сөйләнә табын артына килде, урынына утырырга ашыкмады. Аягүрә тост әйтергә теләдеме?

—Бу соңгы кичәм. Саубуллашу вальсы кебек. Тамашачысы югалып беткәнне көтмичә, артист үзе сәхнәдән матур килеш югалырга тиеш. Хәвефне алданрак сизәргә кирәк. Әти-әнием янына кайтып китәм. Авылыбызда укытучы булып эшкә керәм… Бүген мине бик зурладыгыз. Гомерем буена

ишетмәгән матур сүзләрне берьюлы ишеттем. Мактасалар рәхәт икән ул! Күңеле булсын дип, юри генә әйтелгән сүзләрегезгә сөенеп утырдым. Рәхмәт. Сезнең өчен, бәлеш астына берәрне күтәрик әле...

—Рәхмәт өчен күтәрәбез. Калганнарын ишетмәдек...

Сүз иясе белән йөрми дигәндәй, алга таба куерган туры сөйләмнәрнең иясен исемнәре белән аерым-аерым атап тору кирәк түгелдер—бәхәстә барысы да катнашты.

—Мактау—әҗәт ул. Син бурычыңны түләмичә генә, зур сәхнәне ташлап, пионер сәхнәсенә күчмәкче буласыңмы? Әле безнең дә иҗат кичәләре үткәрәсебез бар, килерсең, җырларсың, мактарсың.

—Сәхнәсез яши алган егетләр күптән бизнеска күчеп бетте. Чын җырчы соңгы татар белән бергә китәр. Әнә, Әлфия апа да ун ел элек «Саубуллашу» гастрольләренә чыгып киткән иде. Әле һаман кайтып керә алганы юк. «Бәхил бул, халкым!»—дия-дия кайбер шәһәрләргә дүртәр-бишәр тапкыр килгән инде... Афишасын күбрәк бастырган, таратып бетерерлек түгел диләр. Чын җырчыга эш житәрлек... Хәзер банкет заллары да сәхнәле. Байлар күбәйгән саен мәҗлесләр арта. Шөкер, яңа татарлар җыр ярата. Яраткан кеше акча кызганмый ул, чакырсыннар гына.

—Чакырырлар... Көтеп утыр... Казанның меңьеллыгын уздырганда татар җырчылары телевизор карап утырды! Ну, меңьеллыгыбыз дөньякүләм вакыйга иде, бәйрәмебезне иярченле элемтәләр аша бөтен Җир шары күзәтеп торгандыр. Дмитрий Хворостовский, Николай Басков, София Ротару кебек федераль йолдызлар, Алманиянең «Скорпион»ы татар сәхнәсенә килеп җырлагач дәрәҗәбез үсте. «На-на» төркеме «Умырзая» җырын үзебезчә башкаргач, тамашачы бөтенләй җебеп төште.

—София Ротаруның Казанда берәр туганы бардырмы, еш килә. Әле Президентыбызның җитмеш еллыгын үткәргәндә «Пирамида»га да килгән иде, Михаил Боярскийлар белән. Татар җырчыларына чират җитмәде. Сәхнә артында дүрт сәгать буе көтеп йөрделәр. Бәширә чыккан иде, Рөстәм баянына ияреп, аны да ике генә куплет җырлаттылар.

—Аның каравы, Мәскәү президентлары килгәч мәйданда гел татар эстрадасы гына чыгыш ясады. Ельцин да, Путин да безне түбәтәй киеп тыңладылар.

—Тукта! Аркылы-торкылы сүләмик. Порядок белән, Сөмбеләгә кагылган эпизодларны гына. Әдәгез, по кругу. Да... Бу хәтлек үгетләвегезгә разве түзәргә мөмкин, үзем башлыйм... Так. Тәхеттән коелган патшаларны оныттык...

—Кара аны, монда сөйләгәннәрең репертуарың кебек билдән түбән булмасын!

—Бәйләнмә юкка! Минем мәзәкләр билдән түбән генә. Ә сезнең йолдызларыгыз анадан-тума килеш җырлый...

—Сандугачлар чишенмәс...

Значит, 2000 елның 24 июнендә Казанның алты төшендә сабантуй бара. Путин иртән сабантуй күрергә чыга диделәр. Кая икәнен төгәл әйтү юк. Алты мәйданга да приказ бирелгән: «Көтәргә!»—и всё!!! Безнең бригада Дәрвишләр урманында, көнелем сизә, нәкъ менә шында киләчәкләр. Автобустан төшкән зевакларны коридор ясап сафка тезелгән милиция коридоры аша үткәрәләр, аэропортлардагы дуганы капка итеп куйганнар. Халык әллә кичтән үк килеп урын алып калган—аланда аяк басар җай юк, сукмак өсләренә дә ашъяулык җәеп табын корганнар. Ошбу сират күперен кичеп мәйданга еттек. Тагын омон кардоны... Детектор белән сыйпыйлар, кофр эчендәге пинжәккә кидергән инсәләрне:—«Бу ниткән каты әйбер?»—дип, тотып-тотып карыйлар... Ярый, хуш, концерт башланды. Мәйдан хәттин ашкан зур—икенче ягында атракционнар—уеннар бар, уртада көрәш.

Әкренләп бәйрәмнең кызуы сүрелде: чүлмәкләр ватылды, саламлы капчыклар сытылды, арканнар тирләде, көрәш батыры тәкәне күтәрде, концерт тәмам—Сәхәби, Миндияр, Алсу—Фәридә, Ибраһимовлар белән Сөмбелә инде сәхнә күлмәкләрен салып, прогулочный чалбарларын киделәр. Китәргә рөхсәт юк, пчему—потомушто «садаканы» өләшмәделәр әле.

—Гонорар дип әйт инде…

—Гонорар тегел, садака! Мәскәү артистлары ала торганы гонорар аның—йөзәр мең, бакс белән. Ә безгә урыс акчасы белән өч мең сум садака, аны да бирми торалар әле, артистлар таралышмасын дип… Абау, апакайгынам, берзаман президент командасы килеп төшмәсенме?!! Ельцин агайны күзсез кешене йөрткән шикелле җитәкләп йөртәләр иде, ә монысы җинел сөякле—элдертә генә, командасы чак җитешеп бара артыннан. Зур Хуҗа килсә кечерәк хуҗалар Хуҗа Насретдинга әверелә бит ул… уеннарны янарттылар, ватылмаган чүлмәкләр чыкты, көрәш батырларына бил алышның финал өлешен кабатларга куштылар, артистлар киредән күлмәк-ыштан алыштырып микрофонга ябештеләр.

Бөтен җыен халкы тын да алмый, яшь патшаны күзәтә—Ельцин батырлыгын кабатлап чүлмәк ватамы, әллә дзюдоистлыгын күрсәтер өчен келәмгә чыгамы, быть может колгага үрмәлисе кели? Ул арада казус чыкты, көрәшнең ахырын кабатлаганда абсолют батырны кемдер сыртына салды. Китте бәхәс, китте этеш, китте төртеш. Әллә, Мәскәү кунаклары татарның үзара талашына күнеккән инде—шаулы шоуга исләре китмәде. Бог с ними, дигәндәй, беләкләренә юри генә кызыл тасма бәйләгән гражданский киемле спецслужба егетләре көрәшчеләрне аерды. Иң кызыгы хәзер башлана, монарчы сөләнгән өлеше увертюра гына үзе әле, кереш өлеше, так сказать… Яшь патшаның каршысына «Вамин» катыгы белән мөлдерәмә тулы агач кәнди китереп куйдылар. И папарацияне күрсән, астан-өстән, уртадан-яннан, алдан-арттан кинога төшерәләр, фотоаппарат яшеннәре ялт та йолт!.. Боларны күреп Сөмбелә миңа әтә: Мәскәү президентының катыклы битен сөртәм, тарихка керәм ди. Үзбәк кызы Мәмләкәт бармы, бала чагында Ленин бабай белән фотога төшкән өчен үскәч Социалистик хезмәт герое исемен биргәннәрие, да… И, Сөмбеләне туктатып өлгермәдек, җиң очыннан кульъяулык алды да китте. Ул Сөембикә-ханбикәгә охшатыбрак киенгән иде, Урта гасыр колориты белән, тән сакчылары туктатырга базмадылар, гәүдәсе төз—күреп торасыз, биле нечкә, күкрәге җыйнак—корал яшерерлек һич шикле җире юк. Путинны әтәм, кечкенәдән сабан туйларында уйнап үскән диярсең—йөзе белән ялт тегә кәндигә! Сөзә торгач, алтын акчаны табып алды да катыклы чыраен уңга-сулга боргалап теш арасындагы хәзинәне халыкка күрсәтте. Сабантуй аланы рәхәтләнеп көлә-көлә алкышлады… Да, мина хәзер бу халыкны көлдерүләре кыенгарак төшәчәк, минәйтәм.

—Ә Сөмбелә нишләде?

—Өлгермәде. Алдан ук билгеләнгән ике мәктәп баласы чүпләмле сөлге китереп тотырды… Ну, шулай да Сөмбеләнең кыюлыгына шаклар катканыем мин ул көнне, иртәгесе көннән курыкмыйча, йөрәге җитеп, тәки барып басты бит опасный зонага… Әйдәгез, батыр йөрәкле Сөмбелә өчен берәр чәркә кымыз күтәрик, катырагын да эчәр идем—давлениeм тиз күтәрелә шул…

—Тостың бик озынга китте. Күп сүз—ул арзан бүләкне зурлап тапшырганда гына әйбәт. Табын мулрак, кунаклар күбрәк булган саен буш сүзләр күбәя.

—Янда синең шикелле критиклар утырганда ял итүләр дә авыр эшкә әйләнә. Сүз әйт тә, сүз әйт, дидегез, әйтмәсәм дә эчәсез инде үзегез! Сөмбелә, тый әле яңа баянчыңны, исерсә гел дөресен сөйли башлый, мәлгунь! Сабантуй аланында йоклап, онытылып калганын белми…

—Тост чираты миндә.

—Чират көтү көткәндә генә була.

—Син хайван түгелдер ич?

—Хатын-кызга хайван димиләр. Хайванның имие койрык астында, ә хатын-кызларныкы менә монда—муен тирәсендә!

—Тост әйтергә теләүчеләр күп. Чиратсыз кермәгез.

—Зур бәйрәмнәргә эләксәң, андагы халык массалары хәтердә калмый, гомумән төзек гәүдәле, гадәти чырайлы, дөрес холыклы яңа танышлар тиз онытыла, хәтердә озаклап тормый. Ә менә кыек-мыек, кәкре-бөкре, кимчелекле гаепле кешеләр гел истән чыкмый. Кешеләр генә түгел, вакыйгалар да шулай...

Сөмбеләгә кагылышлы ике маҗарам бар: берсе күңелле, икенчесе—рәхәт түгел. Кайсысын сөйлим?

—Сорап торма, күнелсезе үзендә калсын.

—Ие... Килеп життек Актанышка. Чәйләп-нитеп тору юк, туп-туры Агыйдел буена төшәбез. Көймә белән зур бер утрауга алып керделәр. Күрсәгез... малай! Оҗмах!.. Табигать кочагында нәмәдән аш пешереп була—барысы да әзер тегендә. Шундук жыйнак кына сала корганнар, ә урам буйлап местный гармунчылар авыл көе уйнап йөри. Июль башында түтәлдәге җиләк пешкәнен беләм, ә монда... Кая карама—алмагачларда зур-зур өлгергән алмалар, зиреклрдә—груша, шомырт куакларында төче чияләр эленеп тора. Парлашып актан киенгән ике президент гаиләсе җәннәт бакчасында җимеш чемченеп йөри... Саф татарча гәпләшәләр, алар бик якын дуслар икән бит!..

—Булды, булды! Дүрт кеше өчен самолет куып Анталиягә китмәгәннәре өчен рәхмәт әйт...

—Алайса, тегесен сөйләргә кала... Мин әле ул вакытта Сөмбелә янында антураж булып кына җырлап йөрим. Үсәсе килә, лично үземнең бригаданы оештырасы иде дигән хыялым эчтән кимерә. Концертлардан соң, чәйләр-мәйләр эчкәндә, хуҗалар хәтерендә калыр өчен кыек-мыек җырлар, кәкре-бөкере пародияләр җырлыйм, җитәкчеләрнең тавышына охшатып үртәмешләр сөйлим. Кайбер район главаларына Президент булып шалтыраткан чакларыбыз да бар иде: күбесенең шәхси телефоннарын беләбез... Кыска-җыйнак сораулар биреп, хәлләрен сорашкандай кыланабыз да, соңыннан: «Давайте, Сөмбеләне поддержать итегез әле, пчему-потомушто, бик шәп җырчы ул, ни әйтергә теләгәнемне аңлыйсыздыр?»—дип, тизрәк саубуллашабыз. Урындагы «Первый»ларның үрә катып: «Ярый! Ярый! Әлбәттә. Һәйбәтләп чакырырбыз!»—дигәннәре телефон төребкәсеннән дә күренә иде, билләһи! Сөмбеләне чакырып гарантиягә унышар концерт оештырган районнар да булды. Ул вакытта әле элемтә техникасы бик алга китмәгән, определительләр бик сирәк кешедә генә иде...

...И-йе!.. 1990 елның мае бугай... Точно, иртәгә Җиңү бәйрәме дигән көн иде! Бер машина йолдыз төяп Пәрәү авылына киттек. Анда минем классташым Нуретдин яши. Без аның белән күрше авыл интернатында бергә укыдык, почти егерме биш ел күрешкән юк. Әйбәт яшәгәнен, нык гаилә корганын ишетеп беләм, чәйгә керергә дә исәп юк түгел. Афишада конферансьеның мин икәнен күрсә йөгереп киләчәк, соңыннан чәйгә дә алачак, урман каравылчысы ла ул—өе иркендер, бөтенебез сыярбыз, дим...

Пәрәү клубындагы кешене күрсәгез—кичке трамвай кебек өелеп төялгәннәр! Башланырга ярты сәгатьләп кенә калгач, китапханәче кыздан, Нуретдинның өе еракмы, дип сораган идем... Ужас!!! Кичә кич үтергәннәр, бүген күмгәннәр классташны... Коелып төштем, хәл китте, йөрәгем яртылаш сүнде, күзләремне чытырдатып йомдым—ачсам яшь түгеләсен беләм... Мин бит концертны юмор белән башлап җибәрергә тиеш. Юмор сөйләү түгел, сәхнәгә чыгып

бәхилләшү сүзе әйтерлек тә рәтем юк. Ярамый да… Кайгылы туганнары килмәгәндер бәлкем, ә бит зал тулы халык концерт карарга дип җыелган. Нишлисең инде, үлгән артыннан үлеп булмый, кемдер китә, кемдер килә шушы кабахәт дөньяга, тормыш дәвам итә. Сөмбелә үзе башларга булды, борынгы җырлар, халык көйләре белән. Җиде җырны рәттән җырлап бетерде дә сәхнә артына чыгып минем каршыга килеп басты: «Бар, эшеңне эшлә! Залның күзенә карама, лампочкага карап сөйлә! Безнең язмыш шушы! Егет бул!»—дип йодрык та күрсәтеп алды хәтта.

Чыктым да юмор сөйли башладым. Халык көлә… Ә мин соңгы чиккә җиткәнче еламыйча түзәм. Тыелган яшьләремнән күзләрем бүртте, яңакларым өрелде, баш түбәм шаулады. Биш минутлап түзгәнмендер… Күз яшьләре бәреп чыкты. Елый-елый көлдерәм, халык бүлдереп-бүлдереп кул чаба… Соныннан сәхнәгә менеп аркамнан сөйделәр: «күздән яшь чыкканчы көлдердең!»—диделәр… Менә шушы инде безнең язмыш, Сөмбелә. Әйдәгез, ачы да, татлы да булган артист язмышы өчен берне күтәрик әле.

—Тукта, сабыр ит! Сиңа сүз бирер алдыннан иң кыска тостка конкурс игълан итәбез. Җиңүчегә приз-сюрприз!

—Иң кыска тост—конверт! Конвертлар юк.

—Мина чират җиткәч кенә ашыктырасыз… 2000 елның февраль ахырында Рәсимгә ияреп Пензаны йөреп чыктык. Казаннан сөрелгән кырык тугыз депутатның берсе анда министр урынбасары иде—ул чакырды. Әйбәт йөрдек, шәп оештырганнар. Индирка авылында гына безне көтмәгәннәр булып чыкты. Февраль бураннары. Юл өзеге. Афиша килеп җитмәгән. Киләсебезне белмәгәннәр. Гостиница юк. Мишәрләр артист халкын фатирга бик алмый хәзер. Без анда детсадта куныдк. Хәтерлисеңме, Рәсим, балалар караватында йоклаганыңны?

—Хәтерләмәскә. Әлбәттә. Ну мин бөгәрләндем дә яттым.

—Син җиңел сөякле, чыдый беләсең. Ә администратор Рамай—йөз утыз алты килолы, ике метрлы гәүдәсе белән нишләргә тиеш? Өч бала караватын аркылы тезеп менеп ятты бахыр… Таң аткач, тәрбияче апа йөгереп кергән: «Торыгыз! Оятсызлар, һаман йоклап ятасыз, хәзер оланнар килә башлый!»—ди бу һава тревогасы күтәреп. Күрсәгез, Рамай өч бишек кабыргасында төн уздырып терсәкле валга охшап калган иде… әле бүген дә бик үк тураеп бетмәгән. Сөмбелә сынатмады, аркасына мендәрләр терәп утырып кына йоклады. Ну суты бу түгел… Килдек, зритель юк. Казаннан тикле чыгып бушка ашап ятасыңмы?.. Сөмбелә концерт күлмәген киеп… февраль аенда, ак шәлен бөркәнгән килеш кенә, урам буйлап… кибеткә барып килде. Ун минут йөреп кайтты микән… кечкә клубта битковый аншлаг иде! Генерал Карбышев батырлыгына тиң Сөмбелә өчен…

—Синең тост та озын. Кыскасын үзем сөйлим. Ноябрьск. 1996 ел. Апрель азагы, ак төннәр… Дүрт артистны Себергә озаттылар. Илһам абыйга ияредек. Зурладылар. Кар өстендә учак, шашлык пешә, сауна кызган—бик җылы каршыладылар. Концерт «Ура!» кычкыртып үтте. Крутой братлар Сургутка озатты. Казанга билетлар юк. Самолет атнага ике генә оча. 1 май аркасында билетлар сатылып беткән. Илһам абыйның поезд белән кайтасы килми. Тагын өч көн буе көтеп утырырга риза. Утырабыз. Тагын ике сәгатьтән шыплап тулган бер самолет китәчәк. Сөмбелә түзмәде. Җир шарында татар кешесе булмаган почмак юк, дип «рюмочный»га юнәлде. Алюмин банкалы адреналин алып эчте. Артык шик тудырмыйча гына буфетчы ападан сорап куйды: «Сездә татарлар эшлиме?«—янәсе.

«Күпме кирәк? Әнә—икесе йөри!»—диде, ак түткәй, зәңгәр комбинизонлыларга таба ымлап. Сөмбелә, минутларны әрәм итмичә генә тегеләрнең уртасына килеп басты.

«Егетләр, сезне Илһам Шакиров эзли иде, күрдеме әле?»

«Илһам абый?! Мондамы? Точно үземе?»—дип ышанмый маташа бит тегеләр.

«Димәк, күрешмәгәнсез әле. Әйдәгез, таныштырам»,—дип Сөмбелә егетләргә икеләнерлек хут калдырмады, икесен берьюлы култыклап, җилтерәтеп алып килде.

Илһам абый:

«Ике бизнесмен, инәләрен поп еккыры, алдалап-юмалап Сургутка илтеп ыргытты. Билетлар беткән. Шул тукмакбашлар аркасында Май бәйрәмен аэропортта каршыларга туры килә»—дип, әйтәсен әйтеп тә бетерми калды, егетләрнең берсе шундук каядыр йөгерде, икенчесе йөз меңлек купюрага автограф куйдыра торды... Кыскасы, посадкага ярты сәгать кала безне, багажга ияртеп, буш самолетка кертеп яптылар. Лётчиклары Казан авиалиниясеннән иделәр. Илһам абыйга шлем кидереп икенче пилот урынына утырттылар. Артык мавыгып, рольгә керә күрмә, кнопкаларга баскалама, юкса самолетыбыз мәтәлеп төшә дип инструкцияне бик ныгытып үткәрдек үзе белән. Рөстәм, Ельциннарны, Путиннарны биеткән гармунын кочаклап, лимонад шешәләре өстенә утырды. Сөмбеләне стюардесса иттеләр. Ә мин туалет тирәсендә йөренәм. Кыскасы, бишәр йөз мең акча төртеп, дүрт «куян» исән-имин Казанга кайтып төштек. Мин, гел аягөсте торгач, җәяү кайткан кебек булдым. Ике миллион түләдек, акчаларның өч ноле сызылмаган чак иде әле ул. Әйтәсем килгәне шул... Сөмбеләнең олы укытучылары—зур дуслары бар... Мулла кушкан исем—ул метрикәгә язып куяр өчен генә ярый, талантлы кешегә исем соңрак килә, Сөмбелә дигән матур исем өчен...

—Кайсыгызның сүзе кыска?

—Бәйлисе бар йөрәкне...

—Сөмбелә турында бер-ике кәлимә сүз белән генә булмый, ул бит сәхнәдән китәргә җыена.

—Үзем әйтәм. Иң кыска тост: «Китмә, китмә сандугач!»

***

Балантауга газ кергәнгә бишбылтыр. Яңа пәлтә кидем дип искесен тиз генә чыгарып ташларга күнекмәгән халык ипи мичләрен сүтәргә ашыкмады. Газ—ул бик сәяси ут. Җир шарына тамырланган торбалары көйсез илләр, афәтле дәүләтләр белән бәйләнгән. Ә утын—үз урманың хәзинәсе, ягылмаган килеш тә сарай читенә өелгән әрдәнәсе җылытып, сөендереп тора.

«Әни, чуен белән мичтә пешкән борчак штие ашыйсым килә, елкы ите турап...»—дигәч, Гөлчәчәк ике сорарлык итмәде, өйлә вакыты җитәрәк мичкә якты. Мич көймәсенә тигезләп тутырылган нарат ботаклары утка өерелгәч, Сөмбелә бер телем арыш ипиенә тоз сибеп, күмер кызуына терәде. Әйләндереп-әйләндереп ике ягын да кыздырды. Кайнар сохарине кулдан-кулга сикертеп урамга йөгереп чыкты, капка төбендәге бүрәнә өстенә менеп утырды. Үзе кетер-кетер кимерә, үзе авыл сәхнәсендәге язгы симфонияне тыңлый... Шушма буендагы таллыкта каргалар хоры... Капка баганасына колга белән кагылган оядагы бәхетенә сөенеп сыерчык сайрый, җырчы тавыклар тояк эзендәге кояшлы су белән тамагын чайкый... Абзар кыегындагы калай әтәч янына менеп җиткән чуаркайның «Кикри-кү»ге, сыртында мамыгы күпергән кәҗәнең тарак сорап ялварган теноры, гомерендә беренче тапкыр көтүгә чыгарга хыялланган кысыр тананың быргысы... барысы-барысы бергә яшәешнең дәвамы, язларның кабатлануы булып җиһанга хәбәр сала. Һәм Сөмбелә җырланмаган җырларын тоеп, күнеленә сеңгәннәрен чак тыеп, шушы җиһанның кыл бер уртасында яшәреп утыра. Болар туган йорт мендәренә чумган нарасыйның озын-озак саташуы кебек тоела. Таныш, бик тә таныш

авылдаш апаларның ара-тирә артистланып эндәшеп китүләре генә, әлеге халәтнең һичшиксез өндәге чынбарлык икәненә инандырып тора.

«Әләй, нәни Сөмбелә кайткан түгелме соң? Ә Идрис абыең мәктәптә физкультура укыта!»

«Сохари кимерә берәү. Казан күмәченнән үтләгән...»

«Ал әйдә чиләкләреңне. Чишмәгә ияртәм...»

«Телевизордан чыктың мәллә? Әле бик матур итеп «Кыр казын» өздерә иден».

«Үзең капка төбендә, гәүдән телевизорда. Менә сиңа, мә! Ышанып карап утыр концертларын...»

Шунда гына һушына килде Сөмбелә, бенефисның язмасын күрсәтәселәр иде ләбаса... Өйгә керсә—сервант шүрлегендә онытылып калган кесә телефоны шылтырый... Альбинаның әнисе эзли Сөмбеләне. Бер банкир өстәмә исемлек белән депутатлыкка сайланырга җыена, альтернатив кандидатлар бик күп ди, ышанычлы кешесе рәвешендә ай буе концерт куеп, яклап йөрергә кирәк икән. Ризалыгын сорыйлар.

Бик тиз генә: «Юк!»—дип өзеп әйтсә дә җавабын әллә кайчан уйлап куйган иде инде Сөмбелә. Сәхнәдән матур килеш, тамашачының сагынасын белеп, кызганыч көнгә калганны көтмичә, горур төстә җырлап китәргә кирәк! Джунгли елгаларында үрчегән бизәкле балыклар аквариумда яши алган кебек... Кискен үзгәрешләрдән курыкмаска! Садә җанны җыр житәкләп йөртер...

Ул телевизор каршындагы кәнәфидә куанып утырган әнисе янына сыенды. Экрандагы миләүшә күлмәкле Сөмбелә тамашачы Сөмбелә өчен өзгәләнеп җырлый иде...

*2004—2007.*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Әнәс
Хәсәнов

# ӘХЛАКЫЙ НУР КАЛДЫРСАҢ...

## Вакыт

Яшь егетләрне картайта,
Санламый солтаннарны,
Континентларны тетрәтә,
Санамый корбаннарны.

Хәсрәт-дәрьяга кешене
Җәлләми, тотып сала.
Теләсә, йөрәк ярасын
Дәвалап, юып ала.

Хөкем итсә, гүзәл илләр
Айкала да таркала.
Дустан дошманга әйләнә
Башкалага баш кала.

Йөзгә җыерчыклар сибә.
Диңгез кибә. Елгалар
Бормалы юлларын ташлап,
Бер аңа буйсыналар.

Бу нинди илаһи куәт,
Нинди гайрәт һәм дәрман?
...Шундый бөек көч иясе
Бакый Вакыт—каһарман...

## Җан көзгесе

Хәсрәттән дә, шатлыктан да
Күз ник яшьләнә диләр,
Күзнең җанга аерылгысыз
Береккәнен белмиләр.

## Сөенеч

Сукыр тычкан оясында сөенә,
Әле ярый кояш юк, дип, өемдә...

Әнәс ХӘСӘНОВ (1935)—*шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче; «Җырым—ал җилкән», «Минем сандугачларым», «Кояшлы яңгыр», «Табигатькә тәрәзә» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Мөһер

Миннән башка кеше кем ул?
Әйтсәм әйтим чүт кенә:
Мин булмасам бу дөньяда
Барыгыз да чүп кенә.

Мөһер! - диләр мине зурлап,
Минем сурәтсез генә
Берегез бер нишли алмый...
Кадрем белегез менә!

## Йөрәк хөкемгә хаклымы?

Юка гына китап
Укыдым да,
Бик сокландым
Кайнар хисе, олы фикеренә.
Шул китаптан күчте
Хыянәткә нәфрәт
Күкрәк читлегемә.
...Йөрәк хөкемгә хаклымы -
Шуны белмим менә.

## Игенче

Юкны бушка авыштырган—
Игенче түгел. Түгел!
Бу дөньяда шөгыльләр күп,
Игенче шөгыле - ШӨГЫЛЬ!

Сүздән ботка да пешерми,
Бурамый сүздән бура.

Сабыр гына үз эшендә
Муллыкка нигез кора.

Тыйнак юмартлыгың өчен
Рәхмәт сиңа, игенче!
Елдан-елга насыйп булсын
Игенче сөенече.

## Күләм

Җиһанның һәр инсаны—
Ком бөртеге нибары.

Әхлакый нур калдырса,
Шул ук кеше - Җир шары.

Кояшка алмашка
Болытлар куерып,
Юлымны чуалтты.
...Яшь идем, ялгыштым,
Кояшны югалттым.

Син килдең күгемә
Кояшка алмашка
Һәм балкып кул суздың,
Ялгызым калмаска.

Тормышка мәхәббәт
Кабыздың күңелдә.
Сүрелмәс дәрт белән
Яшим мин бүген дә,
Гомерем түрендә.

***

*Житмеш яшьлекләр «манифесты»!*

Әй, чибәркәй!
Чәчкә карама син,
Җитмештә дә йөрәк яшь әле:
Йөгереп киләм, дәшсәң, чәчкә тотып,
Кил, егетем, диеп дәш әле...

## Капка

Көндез капкаңа сугылдым,
Бикле идең капкаң.
Кичен килеп каккан идем,
Кат-кат бикле, баксам.

Ачык капка - ачык күңел,
Бикләп торсаң—тозак.
Үз-үзеңә рухи киртә,
Үз-үзеңә йозак.

## Кеше күңеле

Нинди иркен дөнья: диңгез, һава, дала.
Кеше күңеле барыннан да иркен—
Уйлап кына кара…

Кеше күңеле барыннан да таррак—
Күпме сабый бала,
Күпме ата-ана
Тәрбиясез кала…

## Бер абынгач…

Ачысын да, төчесен дә татып,
Яхшы беләм, имеш, дөньяны.
Уңны уңга көйләп йөри торгач,
Килеп чыга, каһәр, сул ягы.

Нык абынгач ялган абруйларга,
Таныйм хәзер алар битлеген.
Ничек күрмәгәнмен - таш баскан ич
Бик күпләрнең күкрәк читлеген.

## Меңенче кәрра

*(мәсәл)*

Асыл костюм шуңа бер мәл көрсенде:
Эчке күлмәк кәперәйде бер көнне:

«Хуҗабызга кем кадерле, кем якын.
Мин ләбаса! Мин булмасам, кем тагын?

Көне-төне ул минем кочагымда,
Күреп яшим мин ялангач чагын да!

Сиңа тими беркайчан да бу рәхәт,
Сиңамы соң мондый тормыш, бу бәхет.»

… Керләнгән дип, ничек моны күрмәдем,
Салып атты беркөн хуҗа күлмәген.

Елый-сыкрый хәзер күлмәк, бичара…
Син, укучым, моңа сабак дип кара.

***

Безнең тормыш - зур театр,
Без артистлар шавыннан
Елап-көлеп тора маска
Зур дөнья чаршавыннан.

Адым саен монда башлам,
Адым саен чишелеш…—
Кульминациягә иярә
Бик еш кына чи килеш.

Берьюлы уйнала монда
Драма, комедия…
Барыбыз да төп рольләрдә…
(Вак рольгә дә без ия!)

Режиссеры кем дисәгез,
Анысы да үзебез.
Тормыш дигән тамашада
…Клоуннар төсле без.



Рәдиф Сәгъди

# БАКЧАСАРАЙ ГӨЛЛӘРЕ

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ МЕЛОДРАМА

*Сталин әмере белән бер гаепсезгә туган җирләреннән куылып, коточкыч афәт, вәхшилекләр күргән Кырымда яшәүче туганнарыма багышлыйм*

**Катнашалар:**

Яшь Мостафа—элеккеге музыка укытучысы. Совет армиясе капитаны. Госпитальдән өенә ялга кайткан. 30 яшьләрдә.

Карт Мостафа—80 яшьләрдә.

Фазима—Мостафаның хатыны. Татар теле укытучысы. 28 яшьләрдә.

Муса—уллары. 7-8 яшьләрдә.

Шильман Израиль Моисеевич—җирле совет рәисе. 30 яшьләрдә.

Сара Абрамовна—анын сәркатибе, 23 яшьләрдә.

Дубинков—НКВД капитаны.

Ковальчук—НКВД сержанты.

Гаяз—эмиграциядәге Казан татары.

Гәүһәр—фатир хуҗасы.

Ир—47 яшьләрдә.

## I ПӘРДӘ

### II КҮРЕНЕШ

*Фазималар өе. Хуҗабикә, өстәлгә җәеп, жырлый-жырлый китель үтүкли.*

Фазима. Булды микән? *(Кительне карый. Исни дә күкрәгенә кысып, назлап тора).* Кадерлем минем! *(Элеп, киемгә орден-медальләрен тага).*

Җыр. Яз җиттеме, чәчәк ата
Бакчасарай гөлләре.
Шушы гөлләр арасында
Сөеклемнең эзләре.

Кара диңгез, дулкын-дулкын,
Кораблар йөзә микән?
Сөйгән ярың яуда булса,
Үзәкне өзә икән.

Йә Ходаем, үзең генә саклый күр инде минем Мостафамны! *(Муса йөгереп керә).*

Муса. Әни, әни, әткәй кайтмадымы әле?

---

Рәдиф СӘГЪДИ (1957)—*язучы, драматург; «Сынган беләзек», «Яз галәмәте», «Финляндиядә рәхәт ди» кебек драма әсәрләре, берничә китап авторы. Казанда яши.*

Ф а з и м а. Юк, улым, күренмәде!

М у с а. Ул сельсовет Исраиль абый белән идарәгә төшеп киткән иде.

Ф а з и м а. Ярар, улым, кайтырлар. Алар бит сугышка хәтле бергә укыдылар, сөйләшеп утыралардыр.

М у с а. Мин, алайса, әткәйне урамда көтәм.

Ф а з и м а. Сәгать җиде тулып килә.

М у с а. Булсын! Әтине көтәм.

Ф а з и м а. Син яраткан чебуреклары пешергән идем, улым. Ашыйсың да киләдер.

М у с а. Әткәй кайткач, әнием! Киттем мин *(китә).*

Ф а з и м а. Озак йөрмә, Муса! Тукта, сәгать җиде тула, бу стена кәндиен кабызып карыйм әле, ни сөйлиләр икән? (Стенадагы радионы кабыза).

Д и к т о р. Сез соңгы хәбәрләр тыңлыйсыз. Хәрби информбюро белдерүенчә, 1944 елның 3 маенда Совет гаскәрләренең Севастополь шәһәрен азат итү өчен башланган һөҗүме 17 нче немец армиясен тулысынча тар-мар итү белән тәмамланды. Дошман 100 меңләгән кешесен югалтты. 62 меңгә якыны әсир ителде. Бик күп хәрби техника һәм сугыш коралы кулга төшерелде. Дингез өстендә барган сугышларда да немец фашистлары 42 меңләп солдат һәм офицерларын югалтты.

Кырым операциясендә катнашкан Кызыл Армия һәм Кара дингез флоты гаскәрләре зур батырлыклар күрсәтте. Ләкин ... Җиңү бушка гына килмәде. Туган җиребезнең меңләгән ул-кызлары, кырым җирләре өчен башларын салды. Мәңгелек дан аларга. Батырларның исемнәре халык күнелендә мәңге сакланыр! *(Матәм көе).*

Ф а з и м а. Иа Ходаем, күпме иргетләрнең гомере өзелде. Каһәр суксын бу Гитлер дигән нәмәстәне. *(Муса йөгереп керә).*

М у с а. Әнкәй, әнкәй, әти белән Исраиль абый, Сара апа да кайтып килә. Мин каршы чыгам.

Ф а з и м а. Ярый, улым, бар!

Д и к т о р. Сез соңгы хәбәрләр тыңладыгыз. Бүген 1944 елның 17 мае, Мәскәү вакыты белән 19 сәгать 30 минут.

Фазима, барып, радионы сүндерә. Мостафа, Исраиль, Сара, Муса керәләр.

М о с т а ф а. Фазима, кунакларны каршы ал. Әйдәгез, әйдә, Израиль Моисеевич! Рәхим итегез, Сара туташ!

Ф а з и м а. Түрдән узыгыз, хөрмәтле күршеләр! Шулай зурлап килгәнегез өчен рәхмәт!

И з р а и л ь. Рәхмәт, Фазима күгәрченем! Менә бу роза чәчәкләре сиңа.

С а р а. Болары Мостафа дустыбызны фронтка озату кичәсенә америка тушенкалары.

Ф а з и м а. Рәхмәт сезгә! Мин дә сез кайтышка чебурек пешереп куйдым.

И з р а и л ь. О, боже мой, алар бит синең, Фазимакай, ашап туймаслык була. Яле, күрсәт миңа шуларны!

Ф а з и м а *(зур табак белән өстәлгә чыгарып утырта).* Тәнегезгә сихәт булсын.

И з р а и л ь. Вай-вай-вай! Исеннән үк башым әйләнә. *(Алып ашый башлый).* Искиткеч! Сара, күгәрченем, син кайчан шулай тәмле итеп пешерергә өйрәнәсең инде?

С а р а. Кайчан кияүгә аласың?

И з р а и л ь. Әгәр Фазима кебек пешерергә өйрәнсәң, бүген үк! Вай-вай-вай, чебурек җанкисәкләрем, сездән бер дә туя алмыйм бит мин!

С а р а. Кара инде, кара, тылда ятып бурсыктай симереп беттең ич.

И з р а и л ь. Алмыйлар мине, монда кирәгрәк син, диләр.

С а р а. Әнә Мостафа кебек төп-төз гәүдәле булып кайтыр идең.

М о с т а ф а. Израиль Моисеевич кебек тәҗрибәле җитәкчеләр тылда да кирәк.

И з р а и л ь. Во, ишеттеңме! Немецлар җимергәнне кем тергезер? Израиль абзагыз, әлбәттә! *(Шулчак урамда әмер тавышлары, солдатлар үткәне ишетелә).*

Ф а з и м а *(тәрәзәгә барып).* Немецлар белән сугыш барганда да Бакчасарайга моның хәтле гаскәр кертеннәре юк иде.

М о с т а ф а. Бәлкем, әсирлектән качып калган немец солдатларын эзлиләрдер.

И з р а и л ь. Вай-вай-вай! Тәмле дә соң!

С а р а. Израиль Моисеевич, син дә белмисеңме?

И з р а и л ь. Нәрсәне?

С а р а. Солдатларны әйтәм!

И з р а и л ь. Миңа докладывать итмәделәр.

Мостафа. Йә, ярар. Берәр һөҗүмгә әзерлек бара торгандыр. Баш катырмыйк әле. Генераллар беләдер.

Израиль. Әлбәттә, шулай.

Мостафа. Фазима!

Фазима. Хәзер. (Итәгенә яшереп кенә шешә алып килә дә иренә суза, үзе кабат Муса янына караватка барып утыра).

Мостафа. Хөрмәтле кунаклар! Минә госпитальдән чыгып бөтенләй терелеп бетәргә бирелгән бер атналык ялым да узды, иртәгә, Алла боерса, янадан немец-фашистларын дөмбәсләргә китәм.

Муса. Әти, мине дә ал инде үзен белән!

Мостафа. Әниенне кем саклар, мин кайтканчы бер энекәш тә табып бирсә, кем булышыр?

Муса. Ә кыз туса?!

Мостафа. Сеңлеңне тәртипсез малайлардан кем саклар?

Муса. Исраиль абый кала бит!

Израиль. Ах, шук малай!

Мостафа. Израиль абыенның эше болай да муеннан! Сез генә житмәгән ди.

Муса. Әти дим, ал инде үзең белән!

Мостафа. Юк, улым! Башта нык булып үсеп жит әле, соңыннан.

Израиль. Ул арада безнекеләр Берлинны да кулга төшерерләр.

Фазима. Каһәр генә суксын инде ул сугышны. Күпме кешенен башына житте бит.

Мостафа. Әйдәгез, дуслар, Жинү өчен башларын салган иптәшләрне искә алып шушы бокалларны күтәрик әле!

Муса. Минем дә искә аласым килә.

Израиль. Дөрес! Яле Фазима ханым, безнең булачак солдатка чәй булса да салып бир әле.

Фазима. Мә, улым.

Муса. Жину өчен!

Сара. Жину өчен, иптәшләр!

Израиль. Юк, юк, туктагыз әле, тукта! Нишләп әле Фазима эчми?

Фазима. Гомердә булмаганны!

Исраиль. Сара, яле, кыста дустыңны!

Сара. Әйдә, Фазима, тартынма!

Фазима. Юк, юк, сез нәрсә? Улым, бир әле чәеңне. Әйдәгез, туганнар, Бөек Жину өчен!

*Бар да. Жину өчен!*

Фазима. Әйдәгез инде, өстәлдә барыннан да авыз итегез. Мостафам хөрмәтенә әзерләнгән ризыклар бит алар.

Сара. Рәхмәт, Фазима. Иртәгә иртүк Мостафанын да китәсе бар. Рәхәтләнеп ял итегез.

Израиль. Анысы дөрес. Ләкин мин Мостафанын жырлаганын тынламыйча беркая да бармыйм.

Мостафа. Израиль Моисеевич, мин инде күп нәрсәләрне онытып та бетердем.

Израиль. Кыланма әйдә, кыланма! Музыка укытучысы түгелме соң син? Үзен язган берәр жырны янгырат әле.

Сара. Чыннан да, Мостафа!

Мостафа. Порох исеннән тамак та утырган.

Израиль. Хәзер рәтлибез без аны! *(Бокалын күтәрә).* Әйдәле!

Мостафа. Дуслык өчен!

Израиль. Дуслык өчен, иптәшләр! Ах, шәп вино!

Мостафа. Менә, госпитальдә ятканда Фазимага багышлап бер жыр язган идем!

Исраиль. Фазима кебек чибәр, Фазима кебек уңган хатын минеке булсамы, көн саен жырлар язар идем.

Мостафа *(жырлый).*

Язгы жилләр исә гөлбакчада,
Гөлчәчәкләр жилдә чайкала.
Фазимакай, бәгърем, гөлчәчәгем,
Иң матуры синдер арада.

Бу жырымны сиңа багышладым,
Ал чәчәгем, гүзәл Фазимам.
Үзем китәм сугыш кырларына,
Йөрәгемне монда калдырам.

Израиль. Браво, браво, Мостафа туган! Шәп жыр!

Мостафа. Рәхмәт!

Сара. Сезнең жырларыгыз үзәккә үтеп керә, тетрәндерә. Татарча белмәгәннәрне кызганам мин!

Мостафа. Син дә, Израиль туган, яхшы аңлыйсың бит.

Израиль. Татарлар арасында яшә дә телләрен дә белмә инде. Слава богу, өч тел беләм!

Мостафа. Израиль Моисеевич, инде минем дә сезгә бер үтенечем бар иде. Безнен туйда үзегезчә Сара белән биеп жырлаган идегез, хәтерлисезме?

Израиль. Хәтерләмичә! Яле,

скрипканы ал әле. Әйдә, Сара, күрсәтик әле үзебезнекеләрне!

Мостафа. Хәзер без аны! *(Скрипканы ала, сызгалый, соныннан дәртле яһүд көен сыздырып җибәрә).*

Израиль. Әйдәле, Сара, сынатмыйк. *(Икәү җырлыйлар, куплетлар арасында бииләр. Сара Фазиманы да чакыра. Муса да селкенә).* Браво, браво товарищи!

Сара. Уф, булды бу! Кешеләр кырыгынчы төшләрен күргәндә, без дүбершатыр биешеп ятабыз. Әйдә, Израиль Моисеевич, кайтыйк инде!

Израиль. Сара дөрес әйтә, оят белергә дә вакыт.

Мостафа *(бокалын күтәреп).* Сугыштан соң да бергә утырырга язсын!

Израиль. Шулай булсын! Рәхмәт сезгә! Тыныч йокы!

Сара. Тыныч йокы! Муса, сау бул, акыллым!

Муса. Сау булыгыз, Сара апа! Сау булыгыз, Исраиль абый!

Мостафа. Әйдәгез, озата барам!

Израиль. Юк, юк, юк! Никаких! Хатының белән рәхәтләнеп саубуллашыгыз.

Сара. Чыннан да шулай! Без Израиль Моисеевич белән рәхәтләнеп сөйләшеп кайтыйк әле.

Мостафа. Капка төбенә хәтле генә алайса. *(Чыгып китәләр).*

Фазима. Әйдә, улым, эчке бүлмәнә кереп ят, әнә ничек авызың ачыла.

Муса. Мин әти белән ятам.

Фазима. Ярар, син ята тор. Әтиең үзе килер синең янына.

Муса. Киттем, әнкәй! *(Фазима Мусаны эчке бүлмәгә алып кереп китә, урамда этләр өргән, әмер биргән тавышлар яңгырый, Мостафа керә).*

Мостафа. Ни галәмәт соң бу? Адым саен кораллы солдатлар. Әйтерсең, төрмә саклыйлар. *(Фазима чыга).*

Фазима. Әкренрәк, Мостафа. Муса әле генә эреп йокыга китте.

Мостафа. Көне буе чабып арыгандыр, балакаем.

Фазима. Иртәгә ничәдә уятыйм?

Мостафа. Алтыларда торсак, әйбәт булыр, матурым.

Фазима. Ничек тиз үтә дә китә икән ул бәхетле көннәр.

Мостафа. Сугыш кына бетсен, Фазимам! Без әле бик озак еллар яратышып-сөешеп яшәрбез!

Фазима. Шулай гына була күрсен инде. *(Килеп, иренә сыена. Мостафа, өреп, керосин лампасын сүндерә, Фазиманы күтәреп ала).*

Мостафа. Мин сине өзелеп-өзелеп сөям, Фазимам!

Фазима. Мин дә! Жанкисәгем!!! *(Музыка. Ут сүнә).*

## II КҮРЕНЕШ

*Урамда этләр өргән, кешеләр акырышкан, мылтыктан аткан тавышлар. Авазлар көчәя.*

Мостафа *(сикереп тора).* Нәрсә соң бу? Берәр хәл булмагандыр ич?

Фазима. Күңелем сизә, яхшыга түгел бу.

Мостафа *(кителен алып).* Тукта, урамга чыгып керим әле.

Фазима. Кирәкми, Мостафа, кирәкми.

Мостафа. Син борчылма, матурым. Мин тиз генә. *(Хәрби киемнәрен киеп, ишеккә атлый).*

Фазима. Сак бул, Мостафа. Әле аяк яраң да төзәлеп бетмәгән. Атышалар бит.

Мостафа. Яхшы, сөеклем. (Чыгып китә).

Фазима. Йә Ходаем, үзең генә саклый күр инде берүк! *(Муса да уянып чыга.)*

Муса. Әти кая китте ул?

Фазима. Машалла, син дә йокламыйсынмыни?

Муса. Тавышланасыз ич.

Фазима. Әтиең хәзер керә, бар, кереп ят, улым. Йокың да туймаган.

Муса. Мин әтине эзләп киләм.

Фазима. Беркая да бармыйсың!

Муса. Әтине генә табам да! *(Урамда мылтык аткан тавышлар ачыктан-ачык ишетелә).*

Фазима. Ишетәсеңме, мылтыктан аталар.

Муса. Әллә немецлар янадан бәреп

кергән инде? *(Караваг астыннан уенчык пистолет тартып чыгара).* Әти кебек зур гына үсим, күрсәтәм әле мин аларга!

Фазима. Шулай, улым, шулай, зур үскәч, әтиең кебек батыр булырсың. *(Үзе тәрәзәдән карый).*

Муса. Мин дә күз салыйм әле.

Фазима. Әнә әтиең үзе дә йөгереп кайтып килә. Йә Ходаем, ни, булды икән?

Мостафа. Нәрсә соң бу? Бистәбез тәмуг урынына кайный! Кыйныйлар, аталар!

Фазима. Кемнәрне?

Мостафа. Безне, безне, Фазима! Кырым татарларын!

Фазима. Ни өчен?!

Мостафа. Белгән юк инде. Аскы урамдагы Әнвәр исемле карт каршылык күрсәтеп маташкан иде, бөтен туганнары каршында...

Фазима. Нишләттеләр?

Мостафа. Атып үтерделәр.

Фазима. Атып үтерделәр?!

Мостафа. Минем белән бергә эшләгән Мәмәтләргә керсәм, аның 16 яшьлек Ләйләсен бер исерек солдат... *(күз яшьләрен сөртә)* көчләп ята...

Фазима. Көчләп?!

Мостафа. Әйе, Фазима! Сөйрәп алып башы белән диварга бәрдем. Безгә тизрәк качарга кирәк.

Фазима. Мина кая инде бу килеш.

Мостафа. Йә Ходаем, нәрсә инде бу? Әллә кызылармеецлар киеме кигән фашист солдатлары килгән микән? Җыеныгыз, улым Муса, Фазима. *(Сара белән Израиль керә).*

Сара. Мәхшәр анда. Коточкыч.

Мостафа. Израиль Моисеевич, бу хәлнең булачагын син дә белмәденме?

Израиль. Белдем! Ләкин бу дәрәҗәгә житкерерләр дип... Алар бит немецларга каршы сугышып гарип булып кайткан кешеләргә хәтле тиңләр. Бу кадәрлесен...

Сара. Качыгыз! Әйдәгез, мин юл күрсәтәм.

Мостафа. Фазима?!

Израиль. Фазима калсын, мин поссовет житәкчесе буларак яклап калырмын.

Мостафа. Әйдә, улым!

Муса. Кая барабыз соң, әти?

Мостафа. Белмим әле, улым.

Израиль. Мостафа, син туп-туры Алупкага бар. Симиезга чыккан якта, 64 йортта Гера Абрамович яши. Миннән диярсен. Тиз бул!

Мостафа. Яхшы, Израиль Моисеевич. Улым, әйдә!

Израиль. Хәлләр җайлангач, хәбәр итәрмен.

Мостафа. Фазима, бәгърем *(Кочаклашалар).*

Фазима. Мостафа, жанкисәгем! Улым!

Муса. Әнкәй!!

Израиль. Тиз булыгыз! Сара!

Сара. Әйдәгез, Мостафа! *(Эчке бүлмәгә кереп китәләр).*

Фазима. Йә, Ходаем, ни өчен?

Израиль. Тынычланыгыз, зинһар, тынычланыгыз! Сезгә борчылырга ярамый.

Фазима. Израиль Моисеевич, бу ни дигән сүз? Сез бит совет житәкчесе буларак бу мәхшәргә чик куярга тиеш идегез!

Израиль. Тынычланыгыз, Фазима Әнвәровна! Барысы да жайланыр әле. Ни генә булмасын, сезгә җил-янгыр тидермәскә тырышачакмын *(Атылып капитан Дубинков белән башы бәйләнгән Ковальчук керә).*

Капитан. Всем оставаться на месте! Сез кем?

Израиль. Мин - Израиль Моисеевич! Жирле идарә рәисе!

Капитан. Сержант, бу теге хәрби түгелме?

Ковальчук *(жентекләп карый).* Юк! Теге капитан кап-кара чәчле иде...

Капитан. Сез кем?

Фазима. Мин Фазима булам.

Капитан. Иребез, тәк... *(язуын карый).* Мустафа Джамилович кайда? Ишетүемчә, ул оптускыда булган?

Фазима. Ул кичә улым белән... нигә киткән иде.

Капитан. Кая инде ул «нигә»? Отвечайте!

Израиль. Ул Ялтага, улым Мусага диңгез буйларын күрсәтеп кайтам әле дип киткән иде.

Капитан. А вы откуда знаете?

Израиль. Без гаилә дуслары.

Капитан. Сез нишләп әле иртә таңнан өегездә түгел?

Израиль. Нинди ыгы-зыгы башланды дип ачыкларга гына кергән идем.

Капитан. Понятно! Друг семьи.

Ковальчук, сине стенага бәргән кеше кем иде?

Ковальчук. Хәрби киемнән иде, иптәш капитан.

Капитан. Сезнең ирегез дә капитан түгелме соң?

Фазима. Әйе!

Капитан. Ялтага китте, дисез инде алайса.

Фазима. Әйе!

Капитан. Ачыкларбыз! Сержант Ковальчук!

Ковальчук. Слушаюсь, товарищ капитан!

Капитан. Тикшерегез!

Ковальчук. Есть! *(Сержант карават асларын, мич артларын карый, эчке бүлмәгә кереп китә).*

Капитан. Ялтада инде алайса, шулаймы, Израиль Абрамович!

Израиль. Израиль Моисеевич!

Капитан. Мина плевать. *(Ковальчук чыга).*

Ковальчук. Бер жирдә дә юк, товарищ капитан.

Капитан. Понятно! Гражданка Фазима, жыенығыз! Ашарыгызга төйнәгез һәм иң кирәкле документларыгызны гына кесәгезгә тыгыгыз!

Израиль. Иптәш капитан, ул бит немец фашистларына каршы сугышта орден-медальләр алып кайткан офицер хатыны.

Капитан. Замолчи, Иуда! Сез, башка Кырым татарлары кебек үк, немец басып алучылары белән хезмәттәшлек иткәнгә читкә сөреләсез!

Фазима. Без яралы совет солдатларын яшердек, аякларына басарга ярдәм иттек.

Капитан. Знать не знаю! Ковальчук, алып чык урамга!

Ковальчук. Есть! Әйдәгез, стерва татарская! *(Фазиманы төрткәләп алып чыгып китә).*

Израиль. Сез, иптәш капитан, бу башбаштаклыгыгыз өчен җавап бирәчәксез әле! Ул бит чын совет укытучысы!

Капитан. Шулай дисезме? Еврей сукасы! *(Китереп эченә суга да типкәли).* Ковальчук! Ковальчук дим, ананны шулай итим, син кайда?

Ковальчук. Тынлыйм, иптәш капитан!

Капитан. Менә бу падланы кулга алынучылар арасына илтеп тык. Ялтада сорау алырбыз. *(Китә).*

Ковальчук. Есть, товарищ капитан! *(Үзе комод тартмаларын, сандыкны актара. Яхшы шәлне, бизәнү әйберләрен кесәләренә тутыра. Эчке бүлмәне таларга кереп китә).*

Сара *(керә).* Израиль Моисеевич, Израиль Моисеевич!

Израиль *(ынгырашып куя).* Сара!!!

Сара. Израиль Моисеевич, нишләттеләр Сезне, нишләттеләр?

Израиль. Сара!! *(Әйберләр төенчекләгән Ковальчук чыга).*

Сара. Кабахәтләр! Ни өчен, ни өчен кыйнадыгыз аны?

Ковальчук *(төенчеген карават астына яшерә дә).* А ну-ка встать! Кому я сказал! Встать!

Израиль *(торырга маташа, Сара булыша).* Кабахәтләр!

Ковальчук. А вот за кабахәтләр ответите! Шагай давай! *(Ут кысыла, музыка. Ковальчук, кереп, төенчеген алып чыгып китә).*

## III КҮРЕНЕШ.

*Анкара шәһәре. Хәерче генә бүлмәдә Мостафа йоклап ята, матур музыка ишетелә..*

Мостафа *(төш күрә).* Фазима! Фазима, бәгърем, син кайда?

Фазима *(пәйда була. Ул бик матур итеп бии).* Мин монда, Мостафа. Синең янда.

Мостафа. Син бигрәк матур биисен, Фазимам, туебызда шулай алдырган идең.

Фазима. Бүген дә синең өчен генә биим, Мостафам! Синең өчен генә!

Мостафа. Рәхмәт, бәхет гөлем!

Фазима. Әйдә, син дә кушыл инде!

Мостафа. Шундый сагындым үзенне, синең биегәненне генә күзәтим әле! Назлы гөлем минем! *(Гәүһәр килеп керә, Фазима юкка чыга).* Нинди сылу гәүдәле син!

Гәүһәр *(уздлдына).* Нәрсә сөйли ул?

Мостафа. Жанкисәгем, кил әле яныма, бер иркәләп назлыйм әле үзенне!

Гәүһәр. Минеме?

Мостафа. Сине, сине, гүзәлем!

Гәүһәр. Әлхәмделиллаһи, шөкер. Укыган догаларым барып житкән, күрәмсен.

Мостафа. Татлы иреннәреннән суырып-суырып үбим әле!

Гәүһәр. Хәзер, жаным, хәзер киләм. Без күптән бергә булырга тиеш идек инде. *(Халатын салып, Мостафа янына ята).*

Мостафа *(төшләнеп Гәүһәрне иркәли башлый).* Мина ничек рәхәт синен белән!

Гәүһәр. Мина да. *(Мостафаны үбәргә тотына).*

Мостафа. Әллә тазарып та киткәнсен дип әйтимме?

Гәүһәр. Бераз гына бардыр инде.

Мостафа. Юк, юк, син Фазима түгел, кем соң син?

Гәүһәр. Мин, жүләр, сөя башлаган дип уйласам, ул, төшләнеп, Фазимасын назлап ята икән.

Мостафа. Син кем?

Гәүһәр. Гәүһәр мин!

Мостафа. Гәүһәр?!

Гәүһәр. Әйе, синен фатир хужаң Гәүһәр булам мин!

Мостафа. Минем фатир хужам Гәүһәр?! *(Йокысыннан айнып, сикереп тора.)*

Гәүһәр. Әйе! Булды, житте! Ике ай фатирга да түләгәнен юк. Бүген үк, хәзер үк бушатыгыз бүлмәне!

Мостафа. Гафу итегез, зинһар! Дөрес анлагыз, Фазимамнан гайре беркемне дә сөя алмыйм мин!

Гәүһәр. Фазима да Фазима имеш! Бәлки инде ул күптән исән түгелдер!

Мостафа. Сез нишләп шундый гөнаһлы сүзләр сөйлисез?

Гәүһәр. Мин сөйләмим, Кырым татарларының 40 проценттан артыгы сөрген юлында һәлак булган диеп газите, радиосы житкереп тора.

Мостафа. Тик минем Фазимам түгел! Ул исән!

Гәүһәр. Яхшы! Тормышка ашмас хыялларын белән генә яшә! Мина үпкәли алмыйсын. Мусага да, Аллага шөкер, карангы чырай күрсәтмәдем, үзенә дә.

Мостафа. Анысы өчен дә бик зур рәхмәт сезгә! Ләкин минем Фазимам бар бит!

Гәүһәр. Әгәр ирем дингездә батып үлмәгән булсамы... *(елый).* Сынар күзем белән дә борылып карамаган булыр идем мин сина!

Мостафа. Анлыйм мин сезне дә, Гәүһәр! Ләкин...

Гәүһәр. Әйе, син көләсен миннән. Бу хатын котыра башлагандыр дип уйлыйсын...

Мостафа. Гәүһәр ханым, сез нәрсә!

Гәүһәр. Мин дә кеше. Сөясем, сөеләсем килә. Сине күргәч, яшь кызлардай гашыйк булдым, чыннан да тилерә башладым, ахры, мин *(күз яшьләрен сөртә).*

Мостафа. Сезне анлыйм, Гәүһәр. Ләкин минем йөрәгем бөтенләй бүтән жирдә.

Гәүһәр. Беләсем дә, анлыйсым да килми! Йә бүген үк фатирга түләгез, йә сау булыгыз!

Мостафа. Гәүһәр, үзегез күрәсез бит, эш таба алмыйм. Бераз гына түзегез инде, Муса хакына.

Гәүһәр. Сонгы сүземне әйттем. Бүген үк бушатыгыз бүлмәне!

Мостафа. Элек бит вак-төяк эшләрегезне эшләтә идегез, Гәүһәр ханым!

Гәүһәр. Элек бит ул. Сезгә жыенырга ике сәгать вакыт. Әгәр дә китмисез икән, полиция чакыртам. Хуш! *(Күз яшьләренә буылып чыгып китә.)*

Мостафа. Кая барып бәрелергә, нишләргә соң мина! Әгәр дә улым Муса булмаса! *(Жырлый).*

Тау-ташлардан тора дингез яры,
Гөлләр үсә, ярып ташларны.
Илсез-жирсез итеп, кара көчләр,
Ятимлеккә илтеп ташлады.

Туган жирем, сөйгән ярым белән
Сөелеп лә синдә яшәдем.
Инде хәзер сагыну, саргаюдан
Кипми күздә керсез яшьләрем.

*(Ашыгып тәрәзә янына бара.)* Улым! Улым Муса! Тиз бул! Кер әле! Килә килә, әнә йөгерә минем улым! *(Йөгереп Муса килеп керә. Өс-башы ертылып-тузып беткән.)*

Муса. Нәрсә, әткәй?

Мостафа. Улым, әниен бүген тагын төшемә керде. Сине дә бик сагындым ди. Ап-ак күлмәк-шәлдән иде.

Үзеннән нурлар бөркелә.

Муса *(елый башлый)*. Әнием, кайда соң си-ин? Әнием! Ал безне биредән. Алып кайт безне Кырымга!

Мостафа. Тынычлан, улым, тынычлан. Исән булсак, без аны эзләп табарбыз.

Муса. Табарбыз, әткәй!

Мостафа. Ходаем, нишләп шушы шатлыклы төшләремне чынлыкка әйләндермисең икән син?! Йә Ходаем! Ни өчен? *(Сыгылып төшеп үксеп елый).*

Муса. Әтием, елама инде! Миңа бик күңелсез була.

Мостафа. Кичер мине, улым! Кичер!

Муса. Әтием, әйдә, мин сиңа үзебезчә җырлыйм.

Мостафа. Җырла, балакаем!

*Муса җырлый. Гәүһәр керә.*

Гәүһәр. Хөрматлеләрем, җырлавыгыз да бик хуш, ләкин бүген үк бүлмәне бушатыгыз!

Мостафа. Гәүһәр апа, зинһар бик аз гына түзегез инде, балам хакына.

Гәүһәр. Ике ай түземләдем, җитте. Үзең хаталандың, Мостафа. Рәнҗемә!

Мостафа. Миңа эш кенә кирәк. Саулыгым бар, ни кушсалар, шуны эшләрмен. Гәүһәр апа!

Гәүһәр. Үзеңнән торды. Хуш! Җыеныгыз! *(Кисәк кенә борылып чыгып китә).*

Мостафа. И Ходаем, инде син мәрхәмәтеңнән ташлама!

Муса. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Мостафа. Әйдә, улым, әйберләрне барлыйк та...

Муса *(иске бер курчагын тоткан)*. Мин барладым инде, әткәй!

Мостафа. Булган бу, улым. *(Иске хәрби киемнәрен алып чемоданга тыга. Шулчак ишек шакыйлар.)* Әйе! *(Зыялы гына бер әфәнде керә.)*

Гаяз. Әссәләмәгаләйкүм!

Мостафа. Вәгаләйкүмәссәлам.

Гаяз *(бүлмәне куздән кичереп чыга да Мусаны күреп тукталып кала)*. Муса энем шушы буладыр инде?

Мостафа. Әйе, хөрмәтле иптәш.

Гаяз. Нихәл соң, улым, үсеп буламы?!

Муса. Була, абый!

Гаяз *(кесәсеннән зур гына катырылган татлы чыгарып суза)*. Менә, үзенә күчтәнәчем бар иде әле!

Муса. Рәхмәт, абый!

Гаяз. Сәламәт бул, улым! *(Мостафага карап)* Сезне Мостафа әфәнде дип уйлыйм.

Мостафа. Әйе, мин дөрестән дә Мостафа. *(Гәүһәр килеп керә).*

Гәүһәр. Сез бит Анкарада белгәннәрем юк, дигән идегез.

Мостафа. Дөрестән дә шулай.

Гәүһәр. Кызы-ы-к!

Гаяз. Сез кем буласыз инде, сөйкемле ханым?

Гәүһәр. Минме?!

Гаяз. Аңладым. Сез шушы бүлмәнең хуҗабикәседер. Дөрес әйттемме?

Гәүһәр. Хуп, хуп, төшендегез.

Муса. Гәүһәр апа безнең фатирдан китүебезне тели.

Гәүһәр. Теләмичә соң! Миңа да бит яшәргә кирәк! Налог түләргә! Ике ай буена бер куруш та биргәнегез юк!

Мостафа. Эш табалмыйм бит әле, Гәүһәр апа!

Гәүһәр. Әллә минем җаным юкмы? Сез дә кызганыч, миңа да яшәргә кирәк.

Гаяз. Күпме тиеш соң алар сезгә, гүзәл ханым?

Гәүһәр. Йә, бу кыланчык татарларны! Ханым да ханым, дип кенә торалар! *(Бик канәгать калып сөйли.)* Әллә ни күп тә түгел инде. Ике айга нибарысы 50 лира булыр дип торам.

Гаяз. Яхшы! Менә сезгә 52 лира. Шул хисаптан безгә өч чынаяк чәй һәм икмәк илә шикәр кертегез!

Гәүһәр. Яхши, яхши, бик яхши. Хәзер, бик тиз җиткерәм.

Гаяз. Рәхмәт, Гәүһәр ханым! *(Гәүһәр чыгып китә.)*

Мостафа. Рәхмәт сезгә, Гаяз әфәнде! Мөмкинлегем булу белән шундук бәхилләтермен.

Гаяз. Мин каршы түгел. Бәхилләтерсез.

Мостафа. Мин инде бөтенләй аптырап калдым. Аллаһы тәгаләнең бер могҗизасыдыр бу!

Гаяз. Мин Гаяз атлы булам. Үзем— Казан татары. Без оештырган «Хәйрия» оешмасында сез калдырган үтенечне укыдылар.

Мостафа. Булды андый хәл!

Гаяз. Совет Армиясе капитаны. Өч

ордены, медальләре бар. Бер баласы белән генә Төркиягә килеп эләккән. Ничектер минем үземнең язмышымны хәтерләткән кебек булды ул.

**Мостафа.** Әйе, шулайрак килеп чыкты. Көтмәгәндә... төнлә татар өйләренә бәреп кереп куып чыгара башладылар.

**Гаяз.** Сезне, совет офицерларын дамы? Сугышта кан коеп, яраланып кайткан кешене...

**Мостафа.** Кызганычка каршы, шулай.

**Гаяз.** Вәхшилек бит бу!

**Мостафа.** Мин әле дә өнемә килә алмыйм. Куркыныч төш кенә күреп ятамдыр кебек.

**Гаяз.** Хатыныгыз?

**Мостафа.** Качалмады.

**Гаяз.** Нишләп?

**Мостафа.** Алты айлык йөге бар иде...

**Гаяз.** Элемтәгә дә керә алганыгыз юкмы?

**Мостафа.** Хат артыннан хат җибәреп торам, җавап юк!

**Гаяз.** Борчылмагыз! Мин сина, туган, җәннәт төзеп бирә алмыйм. Ләкин карап торып ачтан да үтертмәм!

**Мостафа.** Рәхмәт сезгә, Гаяз абый!

**Гаяз.** Үзем дә Татарстанымны бик сагынам. Халкымны, моңлы телемне сагынам.

**Мостафа.** Мин башта сезне күргәч аптырабрак киттем. Бер карасаң, телегез аңлашыла кебек, шул ук вакытта иканчерәк тә...

**Гаяз.** Әллә ничә гасыр аера безне. Кайсы вакытта борынгы бабаларымызга рәнҗеп тә куям.

**Мостафа.** Ни өчен?!

**Гаяз.** Ызгышып, мал бүлеп ятып, нинди дәүләтне таркатканнар бит. Жиде ятларга калган бит безнең җирләр!

**Мостафа.** Шулай шул. Элеккеге хаталарның әҗерен күрәбездер инде бүген.

**Гаяз.** Нәкъ шулай! Әйдәле, Мостафа энем, җыеныгыз! Китик әле без! Мин сина үзебезнең бер татар авылында хезмәт тә табып куйган идем. Жимеш бакчасында эшләрсен. Әллә ни бай булмасаң да, тамагыгыз тук булыр!

**Мостафа.** Йә Ходай, минем ялваруларымны ишеткәнең өчен мең-мең рәхмәт яусын сина.

**Муса.** Рәхмәт сезгә, Гаяз абый!

**Мостафа.** Инде беттек дигәндә генә... Аллаһы тәгаләм, сезне җибәреп, газаплардан коткарды.

**Гаяз.** Аллага тапшырдык, Мостафа энекәш. Киттек. *(Гәүһәр поднос белән чәй, тәм-томнар күтәреп килеп керә).*

**Гәүһәр.** Кая җыендыгыз соң әле сез, бәй? Нәмә соң бу?

**Гаяз.** Чәегез, якты чыраегыз өчен бик зур рәхмәт сезгә, Гәүһәр гүзәлем. Мостафалар минем белән китә.

**Гәүһәр.** Озаккамы?

**Гаяз.** Бөтенләйгә!

**Гәүһәр.** Мостафа бәй, ни өчен?! Хакын түләдегез бит!

**Гаяз.** Мин ана эш таптым. Яшәр өчен акчасы да кирәк. Хушыгыз, Гәүһәр ханым!

**Гәүһәр.** Мостафа, зинһар кичер мине! Рәнҗеп китмә.

**Мостафа.** Нишлисен инде, тормыш бит ул. Үпкәм дә, рәнҗешем дә юк сезгә, Гәүһәр! Бәхетле бул! *(Урам яктан нинди дер тавыш килә.)*

**Гәүһәр** *(тәрәзәне ача).* Адәмнәр чабыша. Ни соң бу?

**Гаяз.** Сугыш диме? Сугыш бетте, немец гаскәрләре капитуляция ясады ди! Аллага шөкер, Мостафа туган. Нинди шатлыклы көн бүген!

**Мостафа.** Гаяз абый! *(Кочаклашалар).* Улым!

**Муса.** Әткәй, без хәзер әнкәй янына кайта алабызмы?

**Мостафа.** Белмим шул, улым...

**Гаяз.** Их, чыннан да Татарстанда үз халкың белән бергә булсаң икән ул бүгенге көннәрдә!

## II пәрдә

### I КҮРЕНЕШ

*НКВД зинданы. Ишек шакыйлар.*

**Капитан.** Керегез!

**Ковальчук.** Яһүдине китердем, иптәш капитан!

**Капитан.** Давай сюды! *(Бите-башы җимерелгән Израильне кертәләр).*

Ковальчук. Разрешите идти?

Капитан *(кул гына селти. Фляжкадан аракы салып эчә, тозлы кыяр кимерә).* Йә ничек безнең дингез буендагы курорт? Ник дәшмисең? Мин синнән сорыйм, падла! Ничек?

Израиль *(көчкә генә сүз әйтә).* Хорошо!

Капитан. Израиль Моисеевич, соңгы тапкыр әйтәм, Мостафа белән советларга каршы оешмада бергә эшләдек, дигән кәгазьгә кул куй да...

Израиль. Ялган бит ул, ялган!

Капитан. Син бер нәрсәне аңла! Кулыңны куясың икән, бер 5 ел чәпибез дә... Исән каласың!

Израиль. Ни өчен?

Капитан. Йә шушы зинданда ук юкка чыгасың!

Израиль. Ни өчен?

Капитан. Хотя бы Мостафаны 1944 елның 18 маенда качырганың өчен!

Израиль. Ул чиста кеше!

Капитан. Чиста кеше качмый ул! Аның хатыны Фазима күптән кулын куйды...

Израиль. Ышанмыйм!

Капитан. Без аның имчәк баласын тартып алуга, шундук имзасын салды!

Изариль. Кабахәтләр сез!

Капитан. Минем түземлегем бетә! Йә куясыз, йә...

Израиль. Үтерегез!

Капитан. Инде ярты ел биредә ятасың. Тагын бер ярты ел тәмугта яшәтәм әле мин сине!

*Израиль үзләренчә җыр көйли.*

Капитан. Замолчи, сволочь! *(Якасыннан тотып селки.)* Замолчи, подонок! Сержант!

Капитан. Алып кит бу еврей калдыгын!

Ковальчук. Есть!

Капитан. Ник туганыңа үкенәчәксең, падла! *(Өстәл янына килеп, тагын салып эчә.)* Ублюдок! (*Радионы кабыза.)*

Диктор. Сез соңгы хәбәрләр тыңлыйсыз. Хәрби информбюро хәбәр иткәнчә, Варшава каласы өчен каты сугышлар бара. Данлыклы совет гаскәрләренә каршы немец солдатлары котырынып каршылык күрсәтә. Шуңа да карамастан, совет гаскәрләре, Польша җирләрен азат итү өчен, үз-үзләрен аямыйча, бертуктаусыз һөҗүм итә! Дошман ягы зур югалтулар кичерә. Кичә Мәскәүдә ил эчендә корткычлык алып барган өчен Михелс кулга алынды. *(Сүндерә).*

Ковальчук. Иптәш капитан, татарваны китердем.

Капитан. Кертегез!

Ковальчук. Прошу, мадам! *(Фазима керә).*

Капитан. Ычкын! (*Ковальчук чыгып китә).* Утырыгыз, Фазима Анваровна!

Фазима. Михаил Андреевич, улым кайда?!

Капитан. Улыгыз исән-сау. Бик тере малай.

Фазима. Бирегез, үтенеп сорыйм, бирегез миңа сабыемны!

Капитан. Фазима Анваровна! Сез акыллы, чибәр хатын. Инде күпме аңлатам сезгә: шушы язуларга кул куегыз да...

Фазима. Яла бит бу!

Капитан. Яла икәнен дә беләм. Өстән кушылгач, нишлим соң? Әгәр дә улыгыз Мөхәммәт белән күрешәсегез килә икән, кулыгызны куегыз!

Фазима. Минем ирем - совет офицеры, илгә тугры булды.

Капитан. Ышанам, Фазима! Ләкин шушы протоколга кул куймыйча торып, сиңа улыңны бирмәячәкләр. Ә ана балалар йортында салкын да, исерек тәрбиячеләр арасында кеше дә чыкмаячак! Анда 70 процент яңа туган сабыйлар гүр иясе була!

Фазима. Улым, җанкисәгем!

Капитан. Балагызны кызганыгыз! Ирегез, бәлкем, исән дә түгелдер инде!

Фазима. Минем Мостафам исән! Андый ирләр үлми ул!

Капитан. Ялгышасың, Фазима Анваровна! Иң беренче шундый кыюлары башын сала.

Фазима. Михаил Андреевич, Алла хакы өчен дип сорыйм, Сез дә бит совет офицеры, коткарыгыз минем сабыемны!

Капитан. Соңгы тапкыр әйтәм, йә кулыгызыны куясыз, йә Мөхәммәтне мәңге күрмәячәксез! Мәңге!

Фазима. Китерегез улымны!

Капитан. Ковальчук!

Ковальчук. Тыңлыйм, иптәш капитан!

Капитан. Сабыйны китер!

Ковальчук. Есть, товарищ капи-

тан. *(Китә).*

Капитан. Дөрес эшлисез, Фазима Анваровна! Борчылмагыз, бу илдә бүген тегеләй, иртәгә болай ул!

Фазима. Кайда сон бу илдә кешелеклелек? Анда немецлар суя, монда үзебезнекеләр!

Капитан. Сезне кулга алмаган булсаммы, минем үземне аталар иде. Мин хәрби кеше буларак әмергә буйсынырга тиеш.

Фазима. Кешелеклелегең кайда?

Капитан. Кешелеклелекме?! Әнә анда! *(Идәнгә төртеп күрсәтә).*

Ковальчук *(имчәк баласын күтәргән).* Китердем, иптәш капитан!

Фазима. Улым!!

Капитан. Ашыкмагыз, Фазима Анваровна!

Фазима. Үтенеп сорыйм, бирегез мина жанкисәгемне!

Капитан. Кулыгызны куегыз!

Фазима. Үзең кичер, Ходаем! (Имзасын сала).

Капитан *(кәгазьләрен жыя).* Ковальчук, баланы кире илтегез!

Фазима. Улым! *(Алмакчы була).*

Капитан *(аркылы төшә).* Оставить, Фазима! Бала дәүләт тәрбиясенә бирелә. Без аннан чын славян малае ясыйбыз!

Фазима. Сез бит... кул куйсам...

Капитан. Мин өстәге житәкчеләрнең әмерен үтәмичә булдыра алмыйм. *(Ковальчук китә).*

Фазима. Улым, Мөхәммәтем! *(Баласы артыннан ташлана).*

Капитан. Менә дәүләткә каршы тагын бер фетнә ачылды. Отчетны бирергә кирәк! *(Стаканга хәмер салып, көзге каршына килә).* Сина, Михаил Андреевич, күптән майор, полковник булырга вакыт инде! Әйдә шуның өчен! *(Көзге белән чәкештереп эчә).*

Ковальчук *(керә).* Иптәш капитан, срочный, секретный хат!

Капитан. Кемнән?

Ковальчук. Симферопольдән!

Капитан. Чыгып торыгыз!

Ковальчук. Есть! *(Китә).*

Капитан *(укый).* Сезнең изоляторда Совет дәүләтенә тугрылыклы хезмәт күрсәткән Израиль Моисеевич Шильман утыра икән. Ул—чын сталинчы, социализм идеяләрен алга сөрүче шәхес. Эшләнгән хатаны төзәтергә, аны чыгарып җибәрергә боерам! Штаб начальнигы полковник Басирмань. *(Капитан югалып кала, аракыны авызына фляжкадан гына коя).* Ковальчук!

Ковальчук *(атылып керә).* Есть, товарищ капитан!

Капитан. Израильне...

Ковальчук. Нишләтергә?

Капитан. Юындырып, киендереп, бүген үк чыгарып җибәрергә!

Ковальчук. Слушаюсь, товарищ капитан! *(Китә).*

Капитан. Бар яһүд - бер яһүдне, бер яһүд - бар яһүдне! Круговая порука! Сталин гына исән булсын, сезгә дә чират житәчәк әле бер, еврей дунгызлары!

*Музыка. Ут сүнә.*

## II КҮРЕНЕШ

*Мостафаларның элекке йорты. Радио сөйли.*

Диктор. Хөрмәтле радио тынлаучылар! Бүген 1955 елның 5 ноябре. Мәскәү вакыты белән 17 сәгать 55 минут. Сез соңгы яналыклар тынлыйсыз. Иртәгә Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең генераль секретаре Никита Сергеевич Хрущев Сталинград каласына киләчәк! Ул җимерелгән шәһәрне төзекләндерү эшләренең барышы белән кызыксына. Соңыннан Симферополь шәһәренә китеп, эшчеләр белән бөек Октябрь революциясенә багышланган митингта катнашачак! Сез соңгы хәбәрләр тынладыгыз. Ә хәзер сезнең игътибарга бәйрәм концерты!

*Жыр башлана. Русланова башкаруында «Только пули свистят над головой» жыры янгырый. Ишек шакыйлар. Эчке бүлмәдән Израиль торып чыга.*

Израиль. Кем бар? Кем анда?

Сара. Мин идем, Израиль Моисеевич!

Израиль. Кер әйдә!

Сара. Израиль Моисеевич, Сезнең өйдәге ял итүчеләр китте. Расчет яса-

дым. Менә акчалары. Яңаларын кертимме?

Израиль. Кирәкми! Иртәгә генеральный килә диделәр. Бәйләнерлек сәбәп булмасын соңыннан.

Сара. Яхшы.

Израиль. Менә монысы синең өлеш!

Сара. Теге гайбәтче Оксана Федоровка бистә буйлап Израиль куылган татарлар йортын үзләштерде, диеп сөйләнеп йөри.

Израиль. Минем өйне сатарга кирәк, Сара! Син сатып алган итеп әвештәвеш китереш тә... Соңыннан күз күрер.

Сара. Яхшы, Израиль Моисеевич!

Израиль. Мә, өстенә бик матур күлмәк тектер әле, бәйрәм буләгем булыр!

Сара. Кирәкми. Бусы да җитә. Израиль... Тиздән утыз дүрт яшь тула бит инде мина, Израиль!

Израиль. Аңлыйм, күгәрченем, Сара. Сина әле егерме биштән артыгын биреп тә булмый.

Сара. Син дә ялгыз, мин дә! Гаилә корып җибәрсәк шунда! Картаеп бетәм бит инде, Израиль Моисеевич! *(Елый).*

Израиль. Аңлыйм, Сара. Ирләр бетмәгән бит! *(Чәчләреннән сыйпый).*

Сара. Исерек хохоллар белән руслармы? Эчеп сугышудан, җимерүдән башка берни белмиләр.

Израиль. Анысы дөрес, Сара туганым! Яхшы, мин уйлармын әле бу турыда!

Сара. Һаман да бер сүз. Ярый, сау бул. *(Китә).*

Израиль. Сара, күгәрченем, рәнҗемә инде. Син миңа бертуган сеңлем кебек якын! *(Уйланып утыра).* Сугыш беткәнгә дә 10 ел. Сталин да юк, Михелсны да юкка чыгардылар. Янып торган, эшчән, чиста, матур татарлар да юк. Их, Сара, күгәрченем, аңламыйсың шул син. Өзелеп-өзелеп Фазиманы сагынганымны белмисең! Мин барыбер аны эзләп табарга тиеш! Яшьләй яратып сөйгән ярым бит ул! *(Тәрәзә кагалар).* Кем икән бу?

Тавыш. Израиль Моисеевич кирәк иде.

Израиль. Мин ул. Хәзер чыгам! Йа Хода, кем булыр икән бу?

*Музыка.*

Мостафа *(керә).* Исәнме, газиз нигезем. *(Мичне сыйпый, борып тимер караватның тимерләрен тота).* Исәнме изге йортым минем!

Израиль. Мостафа, синме сон бу?!

Мостафа. Мин, Израиль Моисеевич. Нихәл, туган?

Израиль *(теләр-теләмәс кенә кочаклаша).* Нихәл, Мостафа?

Мостафа. Израиль Моисеевич, теге чакта ярдәм иткәнегез өчен бик зур рәхмәт! Сезнең кешеләр мине балык тоту шхунасында теге ярга озаттылар.

Израиль. Беләм, ишеттерделәр.

Мостафа. Рәхмәт сиңа, туган! *(Күзләрен сөртә).*

Израиль. Соң, яшьлек дуслары ич без. Син әле мине усал малайлардан саклый торган идең.

Мостафа. Синең кебек иптәшләрне гомер буе саклар идем мин, Израиль туган!

Израиль. Утыр әйдә, нишләп басып торабыз соң әле без?

Мостафа *(утыра).* Нинди кадерле йорт бит бу минем өчен! Әткәй-әнкәйдән калган нигез. Фазимам белән бәхетле мизгелләр кичергән нигез.

Израиль. Шулай-шулай, дөрес әйтәсең, Мостафа дустым!

Мостафа. Татарларга өйләренә кайтырга һаман рөхсәт юкмы?

Израиль. Рөхсәт-мөрехсәтләрен белмим, хәзер инде кайтсалар да, торыр җирләре юк. Китереп тутырдылар җыен килде-китте затларны... Исерекләр, фахишәләр...

Мостафа. Йә Аллам, нинди гөнаһларыбыз өчен?

Израиль. Инде сезнең өйгә дә шапшак гаилә кертмәсеннәр диеп үзем күчтем.

Мостафа. Рәхмәт, Израиль дустым!

Израиль. Теге яктан дисең инде алайса!

Мостафа. Әйе! Үзебезнең төрек мөселманнары арасында! Башта нык авыр, кыен иде! Яшермим, улым Муса белән бер телем ипигә дә тилмергән чакларыбыз да шактый булды.

Израиль. Вай-вай-вай! Бер гаепсезгә туган иленнән куылып! Вай-вай-вай!

Мостафа. Сонынннан, Ходайның биргәненә шөкер, Казан татарлары оештырган «Хәйрия» җыеныннан эзләп

табып, ярдәм кулы суздылар.

Израиль. Вай-вай-вай! Менә анысы әйбәт булган!

Мостафа. Аллага шөкер! Бүген бер авылда чәчәкләр үстереп сатам. Әйләнә-тирәмдә үзебезнең татарлар. Бәйрәмнәребез жыр-биюләр белән күңелле үтә!

Израиль. Жанкисәкләрем!

Мостафа. Шулай, Израиль дустым. Фазимадан берәр хәбәр килгәне юкмы? Кайларда икән ул күз нурым?

Израиль. Фазимаданмы?! Кызганычка каршы юк шул, Мостафа. Безне бит сине качырган дип бергә кулга алдылар.

Мостафа. Сине дә?!

Израиль. Әйе! Ул төрмәдә күргән вәхшилекләрне... Кайчагында төшемә кереп каравыллар кычкырып уянам.

Мостафа. Фазиманы соңгы тапкыр кайчан...

Израиль. Соңгы тапкыр шунда зинданда күрдем. Анда улыгыз Мөхәммәт туды.

Мостафа. Димәк, минем тагын бер улым—Мөхәммәтем бар!

Израиль. Әйе, бар! Үземне бер елдан соң чыгардылар. Хатыныңны, синең белән бергә немецларга хезмәттәшлектә гаепләп, 10 елга хөкем иттеләр.

Мостафа. 10 елга! Хәзер кайда икән соң ул, хәзер кайда?

Израиль. Әйтә алмыйм.

Мостафа. Израиль Моисеевич, үтенеп сорыйм, тап син аларны. Фазиманы тап, жанкисәгемне! Менә сиңа Америка долларлары. Житмәсә, тагын алып кайтам, көне-төне эшләрмен!

Израиль. Яхшы, яхшы, Мостафа. Мин аны табалсам, сиңа хәбәр итәрмен. Адресың?

Мостафа. Менә бусы адресым! Бусы Фазимама дип алган чәчәк орлыклары. Син аларны яз көне бакчабызга утырт әле. Хуш исле фазималар чәчәк атсын.

Израиль. Яхшы, яхшы, Мостафа.

Мостафа. Кайларда икән соң син, Фазимам? *(Жырлый).*

Фазимам дип кайттым туган илгә,
Фазимасыз тормыш юк миңа.

Фазимасыз яшәү - яшәү түгел
Күңел тулы хәсрәт-уй гына!

Фазимакай, бәгърем, аппагым,
Синнән татлы ярлар тапмадым.

Израиль. Мостафа дим, дустым, туктат бу эшеңне. Жырыңны ишетеп килеп житсәләр... Мине дә, үзеңне дә харап итәсең.

Мостафа. Гафу ит, Израиль Моисеевич.

Израиль. Мостафа, дустым, хәзер кит инде син! Төн караңгылыгы юлдаш булсын! Фазима белән улың табылса, шундук хәбәр итәрмен!

Мостафа. Үтенеп сорыйм, Израиль Моисеевич!

Израиль. Яхшы, яхшы! Хәзер китә күр. Тотмасыннар сине. *(Шулчак Сара килеп керә).*

Сара. Нинди татар моны яңгырый икән дисәм, Мостафа бәгърем, син икәнсең бит!

Мостафа *(кочаклашалар).* Сара!

Сара. Боже мой! Синең кебек арысландай ирләргә дә чал кунар икән! Муса кайда соң? Ул чын жегет булып киләдер инде!

Мостафа. Койган да каплаган үзем Муса.

Израиль. Сара, тоткарлама Мостафаны! Сизә күрмәсеннәр.

Сара. Яхшы! Сугышка хәтле ничек матур яшәгәнбез икән. Сау бул, Мостафа.

Мостафа. Сау булыгыз *(Чыгып китә).*

Израиль. Хуш, Мостафа.

Сара. Нинди егетләрне юкка чыгардылар бит!

Израиль. Хәбәр итәргә кирәк! Югыйсә! *(Телефонга ябыша).*

Сара. Куй хәзер үк. Ул бит сине походта кыядан очып төшәм дигәндә үлемнән алып калган?!

Израиль. Әгәр... берәрсе күргән булса?

Сара. Кабахәт син! (Израильнең яңагына суга.)

*Ут сүнә. Музыка.*

### III КҮРЕНЕШ.

*Төркиядә Мостафалар йорты.*

Диктор. Сез Истамбул хәбәрләре тыңладыгыз. Мәскәүдә, Горбачевның Кырым ярымутравында ял итеп ятуыннан файдаланып, фетнәчеләр, ГКЧП төзеп, идарәне үз кулларына алдылар, дигән хәбәрләр килеп ирешә. Башкаланың үзендә ыгы-зыгылар башланган. Шул ук вакытта Урта Азиядә яшәүче Кырым татарлары, туган җирләренә кайтаруларын таләп итеп, митинглар оештыралар. Хөрмәтле радио тыңлаучылар, без СССРдагы яңалыкларны алдагы сәгатьләрдә дә хәбәр итеп торырбыз. Хәзер ял концерты тыңлагыз.

Мостафа *(аны икенче артист уйный, нык бирешкән).* Йә Ходаем, татарларыма кире туган җирләренә кайтырга насыйп ит! *(Чәчәкләр арасындагы креслосыннан көчкә тора).* Әнә анда, диңгез артында, минем туган җирләрем. Кайчандыр Гаяз ага да, туган иленә кайтып башыңны салсаң иде дип хыялланган иде. Язмагандыр инде безгә. *(Машина килеп туктаган тавыш).* Улым Муса кайтты.

Муса *(керә, элек Мостафаны уйнаган артист).* Әткәй!

Мостафа. Улым! *(Кочаклашалар).* Улым, ишеттеңме, теге ярда ыгы-зыгылар башланган ди.

Муса. Ишеттем, әткәй! Әле Истамбулда СССРдан яңа гына качып килгән эмигрантларны күрдем. Кырым татарлары, күчеп кайтып, буш җирләргә урнаша башлады, әлегә каршылыклар сизелми ди.

Мостафа. Ходаем! Шушы көннәрне дә күрергә язган икән бит! Улым, безгә дә җыенырга кирәк.

Муса. Әткәй, куркыныч вакыт бит. Чуалышлар. Кырымга да килеп житүләре бар.

Мостафа. Миңа туган җиремә кайтырга кирәк, улым! Әниеңне эзләргә!

Муса. Әткәй! Әнкәй исән булса, Израиль Моисеевич хәбәр иткән булыр иде.

Мостафа. Каберен булса да табарга кирәк. Энең Мөхәммәтне дә эзләрбез. Җыен, улым!

Муса. Яхшы, әткәй!

*Ут сүнә.*

### IV КҮРЕНЕШ.

*Кырым-йорт. Муса керә. Кирәкле санны күреп, тәрәзә шакый.*

Израиль *(чыга).* Кем бар анда? Вай-вай-вай! Ай бу картлыкны. Вай-вай-вай. Сез кем?

Муса. Миңа Израиль Моисеевич кирәк иде.

Израиль. Тавышың таныш. Тукта, күзлегемне киим әле. *(Кия).* Вай- вай-вай! Мостафа дип әйтимме соң?

Муса. Юк, мин Муса. Мостафаның улы!

Израиль. Улы! Менә сиңа мә! Койган да каплаган Мостафа ич син!

Муса. Шулайдыр.

Израиль. Мостафа үзе кайда соң?

Муса. Әткәй, уйнап-үскән җирләрен карап, әкрен генә кайтып килә. Олыгайды инде, хәле дә юк...

Израиль. Шулайдыр, шулайдыр, Муса. Үземнән беләм.

Муса. Без, әнкәй турында берәр хәбәр ишетмәбезме, дип кайткан идек.

Израиль. Шулаймыни?!

Муса. Әйе, Израиль Моисеевич. Әнә әти үзе дә менеп житте.

Израиль. Мостафа да кайткан икән.

Мостафа. Нихәл, кордаш?

Израиль. Исәнме, годок!

Мостафа. Әйдә, улым, бер дога. *(Укыйлар).*

Израиль. Вай-вай-вай! Син дә исән икәнсең бит, Мостафа. Муса бигрәк үзенә охшаган!

Мостафа. Ул яктан бәхетем тулы минем. Ике оныгым бар, Гәрәй белән Мәмәт!

Израиль. Вай-вай-вай! Ничек әле сезнеңчә—э-э-э... сөбханалла.

Мостафа. Израиль Моисеевич, әйт әле дөресен: шул гомер Фазимадан бер хәбәр дә булмадымы?

Израиль. Вай-вай-вай! Булсамы! Шундук хәбәр юллый идем. Эзләп карадым, төрмәдән чыкач, казакъ якларына китеп югала...

Мостафа. Димәк, Фазимам табылмады... Фазимам...

Израиль. Шулай да теге Фазима дигән гөлләрен ел саен чәчәк ата әнә!

Мостафа. Фазима чәчәкләре! (*Барып чәчәкләрне сыйпый).*

Муса. Әткәй, нишлибез?

Мостафа. Бабаларыбыз каберләрен барып күрик тә дога кылырбыз. Соныннан...

Муса. Әйе, әткәй, соныннан?

Мостафа. Соныннан, улым, син кайтып китәрсең.

Муса. Син, әткәй?

Мостафа. Минем урыным биредә инде, улым.

Муса. Әткәй, мин сине калдырып китә алмыйм.

Израиль. Муса дөрес әйтә, сезгә бергә китәргә кирәк.

Мостафа. Мин китәргә дип кайтмадым. Минем урыным монда!

Муса. Әткәй!

Израиль. Чуалышлар бетсен дә янадан иркенләп кайтырсыз!

Мостафа. Теге чакта фетнә башлангач атып үтергән булсалар, бу хәсрәтләрне күрмәгән булыр идем мин. *(Сыгылып төшә).*

Муса. Әткәй, жанкисәгем! Сине Гәрәй белән Мәмәт көтә.

Мостафа. Юк, улым, үз өемдә калам мин. *(Сара кайтып керә).*

Сара. Таныш кешеләр кебек! Мостафа!

Муса. Юк, юк, мин - Муса! Мостафа әтием - менә ул.

Сара. Мостафа, нишләп бетерешкән жаным?

Мостафа. Фазимасыз картайганга, Сара!

Сара. Фазиманың үзен күрдеңме соң әле?

Израиль. Сара!

Сара. Дәшмә, мөртәт!

Израиль. Сара дим!

Сара. Фазима исән!

Муса. Исән?!

Сара. Әйе!

Мостафа. Кайда соң ул?

Сара. Көн саен, бер урам хәерчесен сыйларга дип, чыгып китә ул. Бигрәкләр дә олы жанлы хатын инде!

Мостафа. Фазимам исән?! Минем Фазимам исән икән бит!

Муса. Әткәй, бәхет бит бу!

Мостафа. Минем өчен шуннан да зурысы юк, улым!

Сара. Әнә бит үзе дә. *(Фазима белән бик начар киенгән бер ир кеше күренә).*

Ир. Фаина Моисеевна, теге яратып жырлый торган жырыгызны—тагын бер тапкыр. Прошу Вас!

Фазима. Ярый, улым. *(Әкрен генә жырлый).* И туган тел, и матур тел!

Ир. Вот смысл не понимаю, а на душе так хорошо становится!

Фазима. Шулайдыр шул, улым.

Ир. Спасибо Вам, Фаина Моисеевна!

Мостафа. Фазима!

Фазима. Тукта, кемдер эндәшә түгелме?

Ир. Вон, какой-то дядя.

Мостафа. Фазима. *(Жырлый):*

Фазимам дип кайттым туган илгә,
Фазимасыз тормыш юк миңа.
Фазимасыз яшәү – яшәү түгел,
Күңел тулы хәсрәт-уй гына.

Фазимакай, бәгърем, аппагым,
Синнән татлы ярлар тапмадым.

Мостафа. Фазима!

Фазима. Мостафа!

Муса. Әнкәй!

Ир. А что они вас Фазымой называют?

Фазима. Чөнки минем исемем шулай. Ә болар - минем иң кадерлеләрем!

*(Муса, йөгереп килеп кочаклап ала, үбә. Соныннан Мостафага юл бирә).*

Фазима. Кайттыңмыни, жаным? Нишләп шулай озакладың, тау бөркетем?.

Мостафа. Мин сине гомерем буе эзләдем, әгәр тагын бер гомерем булса, анысын да сиңа багышлар идем, Фазима!

Фазима. Мостафа, мин бит шушы мизгелләрне күрергә гомер буе хыялландым, көттем. Укыган догаларым кабул булды, күрәмсең.

Мостафа. Күрәсеңме бакча тулы чәчәкләрне, мин бит аларны Фазима исеме белән атадым. Син бит—минем Бакчасарай гөлем!

Фазима. Израиль Моисеевич!

Мостафа. Дөрес. Сине эзләп кайткач, ул орлыкларны мин калдырып киткән идем, кадерлем.

Фазима. Син?!

Израиль. Фазима, зинһар кичер мине!

Фазима. Ни өчен?

Израиль. Чөнки... чөнки мин сине гомерем буе яраттым. Әгәр шулай булмаса, сине эзләп Себер бозларына, ачы жилле казах далаларына хәтле барып житмәс идем.

Фазима. Алары өчен рәхмәт сиңа.

Израиль. Сине яратмасам, үз гомеремне куркыныч астына куеп, төрмә сакчыларына, түрәләргә зур акчалар түләп, исемеңне Фаинага үзгәрттереп йөрер идеммени? Чөнки мин сине Мостафадан да ныграк яратам.

Фазима. Син бит минем кара хәсрәт эчендә ут йотып яшәгәнемне күрә иден.

Израиль. Кичер, зинһар! Теләсәң карга, теләсәң сук, ташлап кына китмә!

Фазима. Юк, Израиль, мин үз гомеремдә бер генә кешене яраттым. Мостафаны!

Израиль. Мин синсез ничек яшим? Фазима!

Фазима. Синең янда Сара бар! Ул гомере буе сине генә олылады.

Израиль. Фазима?!

Фазима. Бәхил бул, Израиль!

Мостафа. Фазима, жанкисәгем! Безнең кече улыбыз - Мөхәммәтебез кайда соң?

Фазима. Аны минем кулымнан төрмәдә чакта ук тартып алдылар. Соныннан, Фаина Моисеевна булып йөри башлагач, көчкә эзләп таптык баланы... Ләкин....

Муса. Нәрсә, әнкәй?

Фазима. Мин эзләп тапканда, ул юлдан язган кеше иде инде.

Мостафа. Улым, Мөхәммәт! Мин бит синең йөзеңне дә күргәнем булмады.

Муса. Кайда соң ул хәзер, әнкәй?

Фазима. *(Теге ир кешегә күрсәтеп).* Әнә ул.

Ир. А что случилось-то? Все на меня уставились?

Мостафа. Улым, нишләттеләр сине, балакаем?

Ир. Я не улым, во-первых.

Израиль. Сау булыгыз! *(Әкрен генә кереп китә, Сара аның хәлен сизеп ала).*

Сара. Израиль Моисеевич, әйдәгез, мин сезне озата керәм. *(Китәләр).*

Фазима. Сынок!

Ир. Да, Фаина Моисеевна!

Фазима. Ничек аңлатырга икән аңа? *(Күзләрен сөртә).* Ничек?! Ул бит Михаил Андреевич булып йөри. Татарча бер сүз дә белми!

Мостафа. Сынок, Михаил, вот это— твоя мать! Настоящее имя ее Фазима!

Ир. Мать?

Мостафа. Әйе, улым. Мин—синең әтиең, Мостафа.

Ир. Ты мой отец?!

Мостафа. Родной брат твой— Муса!

Ир. Брат, папа, мама?!! *(Сара чыга, шәлен кулына асылындырып тоткан).*

Сара. Ул да сүнде...

Фазима. Кем ул сүнде?

Сара. Израиль Моисеевич, бөтенләйгә...

Фазима. Ходаем, шушы кыска гына гомердә ни шатлык кичердек соң без бу илдә?!

Мостафа. Авыр туфрагы жиңел, урыны жәннәттә булсын!

Фазима *(укый).* Амин, шулай булсын!

Муса. Безгә китәргә кирәк, әнкәй!

Фазима. Безнең илебез монда, улым.

Мостафа. Без биредә калабыз. Мөхәммәтне дә тәрбиялисебез бар.

Ир. Мама, папа, брат! Не слишком ли сразу!

Фазима. Улым! Мы здесь будем жить, вот наш дом, вот это наша родина.

Ир. Родина! Тюрьма моя родина! Нет у меня Родины! Где же вы раньше были! Я вас... Я вас всех ненавижу! Не-на-ви-жу!!!

Мостафа. Улым!!!

*Ут сүнә, музыка башлана. Мостафа жыры яңгырый. Пәрдә төшә.*

*Тәмам*

**Редакциядән:**
***Бу айда хезмәттәшебез Рәдиф Сәгъдигә 50 яшь тула. Аны ихластан котлыйбыз, яңа иҗат уңышлары телибез.***



Нәҗибә
Сафина

# САБЫЙ ҖАНЫҢ—ТАГЫН БИШЕГЕНДӘ

## Уй дулкыны

Мин яраткан әнә ярда ята:
Ул бит балык иде—
судагы.
Ул бит инде күптән үлгән, беләм,
Тик терелтә аны
уй тагы.

Ышанасы килми,
ышаналмыйм
Дулкын ташлавына—ярларга.
Давыллар да төшә кебек төпкә
Аны, аны гына
барларга.

Күпме дулкын, күпме суүсемнәр,
Карурманнар, киек-җанвары—
Аның җан ярсуын тыңлады да
Гайрәтләнә төште
җаннары...

Мин яраткан, әйе, мине сөйгән
Хис йомгагы
әллә сүнгәнме?
Ышаналмыйм, юк, юк,
ышаналмыйм,—
Әллә шигырь үзе...
үлгәнме?

Җил-давылга дулкын рәхмәт укый,
Үбә-үбә аның җәсаден:

Нәҗибә САФИНА—*шагыйрә; «Таң кошы», «Әгәр дә уйлаганда», «Без—шигырь, тормыш—проза» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

«Безнең кебек өйсез
ятим булдың,
Тик иректә булып
яшәдең...»

Җил-давылга мин дә җаным сонам,—
Тормыш дулкыннары рәхимсез...—
Сагышларны юып алып китми,
Калалмый, дип, җәсад
кабердсез...

Җәсаден дә дулкын суырып алды.
Кычкырамын: кирәк кабер, дим...
Дулкын шаулый диләр,
сөйли икән:
«Кирәк иде кадер! Кадер!»—ди.

Мине сөйгән, мин яраткан җанны
Дулкын тибрәтер дә тибрәтер...
«Сабый җаның тагын бишегендә—
Мәңге тибрән...»—диеп ул әйтер.

Мине сөйгән, әнә бишегендә.—
Сабый җаны өчен яраттым:
Мин бит бары аның ише генә!—
Яннарына салчы,
Йә, Раббем..

## Нидер җитми...

*Нидер җитми күңелләргә...*
(Җырдан)

Гелдәгечә—йә болытлы,
йә кояшлы көн инде.
Көндәгечә—йә кар төшә...
йә җәяүле бураны.
Менә тагы нидер эзләп,
урап чыктым урамны...
Карашларым—йә кошларга
йә тирәккә тукталды.
Менә берәү—көпә-көндез
нигә икән, ут алды?
Көндәгечә—килеп бастым
шул тәрәз каршысына.
Гелдәгечә—аны күреп,
ай гына каршы чыга.
Һәрбер кичтә моң саркыла
пыяла аша үтеп...
«Нидер җитми күңелләргә
нидер җитми...»
Тәрәз пыяласы
буйлап әллә бу,
әллә яшь төшә?—
Җил
алып китә өзеп...
Көндәгечә—
гелдәгечә—
тәрәзәгә киләм мин...

**Нидер җитми күңелләргә,**
**нидер җитми,**
**беләм мин...**

## Чалгы чыңы

Мәшһүр җырчыбыз Гөлсем
Сөләйманова истәлегенә

*Мең гасырда түгел,бер гасырда*
*Аңлыйм дисәң җанын,*
*Искә алып кара ул халыкның*
*Җырчылары барын.*

**I**

**Печән өсте. Печән—өскә чөелә—,**
**Күккә—чая сүзләр...**
**Учак уты сыман ялтырыйлар**
**Елтыр, чая күзләр.**

**Баш өстенә менеп баса кояш,**
**Аш вакыты җитә...**
**Көтмәгәндә гүя сихри набат**
**Кояш кылын чиртә:**

**Төптән күтәрелгән асыл моңнан**
**Шашып куя йөрәк...**
**Патефон да килгән... завклуб та**
**Асыл егет, димәк.**

**II**

**Аш чүмече тоткан әнкәй тынган,**
**Әткәй... Тынган чүкеч...**
**Гөлсем апа җырлый... болын тынган ,—**
**Кодрәтле бу көч.**

**Үкенечләр өскә калкып чыга—**
**Үткән, беткән, бик соң!**
**Киләчәккә дәшеп аваз килә,**
**Ачылып килә гамь, моң.**

**Әйтерсең лә, шушы моңга килеп**
**Кушыла агымсулар.**
**Бу авазга—кемнәр җиңел сулар,**
**Кемнәр авыр сулар.**

**III**

**...Печән өсте. Үткән гасыр бара—**
**Гөлсем апа чоры...**
**Машиналар чорын таптый Хәтер—**
**Кайта Чалгы чыңы.**

## Кояш бүләк сорамый

**Кояш бер дә сүнми яна.**
**Ялга да тукталмый ул.**
**Бәһа алырга эшенә**
**Һичкемнән—укталмый ул.**

**Төнлә генә күрәсез дип.**
**Үпкәләми Ае да.**
**Качмый болыт арасына,**
**Юкса чыга җае да.**

Чәчәк ата да коела
Йә өзеләләр гөлләр.
Бәхет мизгелләрен коеп,
Узып китәләр көннәр.

Һәм ...берсе дә үпкәләми.
Бәя дә сорамыйлар.
Кешеләрнең гамәлләрен
Кирегә юрамыйлар.

Шагыйрь күңеле—Кояш, Ай.
Шагыйрь күңеле—вакыт.
Вак-төякне өмет итмә,
Олы җаныңны ватып:

Кайнар Кояшны кочып ян.
Айны чакыр өеңә!
Ваклама Вакыт-хәкимне,
Торсын дисәң көеңә.

Шулай яшәгән җаннарга
Дөнья куя бәһасен.
Тарихның янмас битенә
Шагыйрь булып басасың...

## Күрмәсен... күрсен.

Әй, нишлим соң,
Бар халәтем котүдер:
Толымнарым
Бер үреп бер сүтүдер.

Ә күренсәң,
Әзер үзем качарга:
Җиңел түгел
Эч серемне ачарга.

Әй, сатлык җил,
«Уф» та»Уф»дип көрсенмә.
Зәңгәр яулык—
Тәрәздә ул күрсенгә...

Керсен, күрсен.
Мин юк диеп уфтансын.
Яулыгымны
Кулларына ул алсын...

...Яулыгымны...
Куйды йөрәк өстенә.
Күренмичә калырга ла
Бирче, Ходам, көч кенә.

Яулык кебек
Зәңгәр икән күзләре!
Нинди икән
Назлап әйтер сүзләре?!.

Яулыгымны...
Үбеп алды, оялмый.
Шул хәлгә дә түзә бит
Яулык, янмый...

Ник тотенсез
Яна минем бу йөрәк?
Күрми китә, китә бит...
Тотен кирәк!..

Китеп бара,
Күрмәде әле, шөкер!

Ә—э—э-э-й!
Яулыгымны
Бүген кичкә үк китер!

## Ә чынлыкта

*Сөю янында галәм—*
*Бары кулдагы каләм.*

Дөньяны бик зур диләр,
Ә барыбер җитмәде:
Зәррә генә бер уй җаннан
Зур дөньяга китмәде.

Галәмне бик зур диләр,
Күзләп күңел туймады.
Зәррә тылсым—күңел бары
Шушы хакта уйлады.

Дөнья... галәм... йолдызлар,—
Зәррә тылсым сыймады.
Ятсам, торсам, йөрсәм, очсам,
Күңел сине уйлады.

Кагылып китте җилләр:
Дөнья, галәм зур диләр.
Җанда сөю булса гына
Җырланмаган җыр диләр.

Галәмнең төнге серен
Иттем каләмгә сөрем:
Сөю янында галәм—
Бары кулдагы каләм...

*Хикәяләр конкурсына*



Фәрит
Яхин

# ЧИШЕЛМӘС ТӨЕН

## I

Ул инде башка һичкемне яратмады. Сәер хәл. Әгәр дә кешене мәхәббәттән аерсаң, ул беркем дә түгел. Ярый әле сөю сәгадәте бар икән диярлгә генә кала. Ә ул чыннан да шулай. Безнен гамәлләребез һәм корган хыялларыбыз, мәхәббәт булмаса, берни дә түгел. Кешене яшәтүче дә, үтерүче дә—мәхәббәт! Сүзем шул турыда. Хәер, иясенә хәбәрне кушып сөйләп бирсәм, анларсыз!

Көзнең салкын көнендә кайтып кергән Хәмиди Әзһәренең ике күзендә дә боз энҗеләре. Әнисе исән булса:

—И балам, әллә еладыңмы?—дип сорар иде.

Кырык яшьлек ирнең бу җәйдә хатынсыз калуы аның ирекка чыгуы булса да, Әзһәр үзе моны шулай дип кабул итмәде. Бәхет пәрәнҗәсен ябынып гомер уздырырга тиешле хатыны хараплар булды: уйнашчы әрмән кочагына керүдә гаепләнде.

Авыл ни сөйләгәндер дә Хәбирәсе нәрсәләр кичергәндер—аларын ук Әзһәр белергә теләмәде кебек. Үз күзләре белән генә күреп калса, шунда бетәр дә онытылыр иде. Ул Бүсер Әхәте анда каян килеп чыккан диген?

—Синең хатының әрмән белән типтерә!—дип, кеше алдында Әзһәрне мыскыллады, хайван.

Кая барасың андый вакытта? Әзһәр бирешмәде, бүселеп чыгарга теләмәде. Гомере буе җинел эштә генә йөргән, юләрләр барында—акыллылар рәхәттә яши дип лаф орган Бүсер Әхәтенең сүзенә колак салырга идемени? Күзеңнән генә түгел, бәгыреннән кайнап чыгар бу яшьләр!..

Быелтыр Бүсер Әхәте уйнашчы Фатыйма белән тавык фермасының каравыл өендә типтергәндә, өсләренә шул хатынның ире Бәдри барып кергән. Фатыймасын ду китергән, Әхәтнең бугазыннан алган, аннары ыштансыз хәлендә аны юлга чыгарып селкегән. Житмәсә өер оятына калган хатынын әрли икән Бәдри:

—Моның чикләвегенә кызыктыңмы, юләр!—дип.—Кешегә сөйләсән, адәм көләр!

—Синеке миргә житә! Бу мескенне ни кире кактым, итәгемнән төшмәде,—диярәк кан елый икән хатыны Фатыйма.

Бүсер Әхәте, тавык фермасының каравыл өе ишеген ачып:

—Киемнәремне генә бирсәнче?!. Ялгышлык белән булды, моннан ары нәселегезгә дә кагылмам, башкалардан да тидермәм!—дип, мең гафулар үтенә, бәхиллекләр сорый икән.

Каравылчы Шахтер Насыйр килеп чыкмаган булса, бу хәлләрне һичкем белеп калмас иде. Насыйбыннан узмышын юк шул.

Икенче көнне халык Фатыйманың йортыннан куылып чыгарылуы хакында телләрдән төшерми сөйләде. Әмма ире Бәдри сабыр да кеше икән!

Әзһәр алай ук булдыра алмады. Фатыйма белән Бәдри бер йортта яшәп калдылар, ә Әзһәр, шул Бүсер Әхәтенең ялганын чынга алып хатынын йортыннан сөрде, ачуын йөгәнли алмады. Бар икән күрәселәре!

## II

Ул җәйдә дә өченче ел рәттән кумхуҗ фермалары төзелешендә шабашчы әрмәннәр бил бөктеләр. Хәбирә аларга пешекче хезмәтендә иде.

—Татар эшләгәнне әрмәннәр булдыра аламы инде?—дип аптырады картлар, тау халкының кулга осталыгын инкарь итеп.

Алар хаклы да иде. Әмма кумхуҗ рәисе, шабашчы әрмәннәр белән сүз куешып, үз кесәсен калынайту белән мәшгуль булды. Авыл халкы бу хәрамчылардан ерактарак йөрде. Хәбирә дә барасы түгел иде. Әмма бригадирлары белән тәялешеп килгән кумхуҗ рәисе үзе үтенгәч, баш тартуны әдәпсезлеккә санады. Аны вакытлычага гына күндерә алдылар. Һәр эштә беренчелектә торган ире Әзһәрнең йөзенә дә кызыллык китерәсе килмәде, югыйсә. Әмма хараплар гына булды.

Хәбирә иртәдән кичкә кадәр аш пешерү белән мәшгуль иде. Төшлеккә кайткан әрмәннәрнең берсе, сабыры киселепме, аны артыннан килеп тотты. Аш бүлеп маташкан Хәбирәнең кулыннан тәлинкәсе төшеп китте. Аһ орырга өлгермәде, кайнар аш аның өстенә түгелде, аякларын-кулларын пешерде. Үтеп баручы Бүсер Әхәте, тәмле ризык исен сизеп, ачык тәрәзәгә мыштым гына килгән икән. Тәнем пешмәсен дип итәк күтәргән Хәбирәнең шәрә ботларына күзе кадалып, гаебен танудан идәнгә тезләнеп, тәлинкә ватыкларын җыючы әрмәннең мукәләвен күреп:

—Әһә, эләктегезме?!—дип аваз салырга өлгергән.

Тукранның эше тукылдау булган кебек, Бүсер Әхәтенең дә теле сөйләп торганнан гына тамагы туя, имеш. Хәбирәнең оятлы хәлен сәгате-минутында ярты авыл белеп алган. Бүсер Әхәте авызыннан халыкка китеп, аннан кире Бүсер Әхәтенә кайтып, янадан да аның хыяллары белән баетылып, Әзһәргә ирешкәндә ул хәбәр тау кадәргә әверелгән иде. Ходайның бирмешеннән кәҗәнең дә узмышы юк шул!

## III

Халыкка чыккан сүз, кучә-кучәнә йөреп, мең төрлегә тугланды. Кемнең нәрсә сөйләгәнен төшенерлек тә акыллар калмады.

—Әрмән колбасасы,—ди,—суыткычыннан чыгарган!

—И-и, исләнеп беткән булган икән ул! Шуна калганмы Хәбирә?!

—Аларныкы кешечә генә түгелдер шул.

—Хәбирәнең кызы да шунда икән. Суыткычтан колбаса урлаган, әрмәннекен!

Минем һәм иптәш малайларымның аңлавынча, кумхуҗ төзелешендә эшләүче әрмәннәрнең суыткычларында бер таяк колбаса булган да, исләнеп бетүенә карамастан, аны Хәбирә апаның кече кызы урлаган, имеш.

Авыл малайлары арасында бытбылдык үрдәкләр күп булсалар да, монын ише җитди мәсьәләдә сүзне озынга сузарга теләүчеләр алай ук табылмады.

Өлкәннәр белән балалары да кырда эштә иделәр. Халык чөгендер эшкәртте, чүп утады, бәрәнге төпләрен өйде, печән чапты, урман кисте.

Олы һәм иләмсез авылның таркау тыкрыклары, җимерек читән һәм киртәле бакча башлары, бүселеп яткан ихаталары заманның җинеллеге хакында сөйли

иделәр. Тиздән, имеш, авылларда да шәһәрчә катлы-катлы йортлар салдырта башлаячаклар. Коммунизм киләчәк. Шундый бер йортка гына да бөтен авылың белән сыеп бетәсең!

Әллә бу сүзләр дөрескә инде? Ирләр балта-чүкеч тотуны оныттылар. Машина-трактор эше белән генә мәш киләләр. Апалар-түтиләр идән юуларын да ташладылар, тузан суырткычы белән генә йөгертеп чыгалар да—беттекитте, бар да шәп, һәммә җир ялтыраган. Хактыр! Коммунизм киләдер!

## IV

Әзһәрне коммунизмга чыккан кеше итеп сөйләсәләр дә, аның хәле адәм каршында оялырлык иде. Элек җылылыгы һәм аш исе белән каршы ала торган өе дә хатынын куып чыгарган көннән бирле бушап һәм төссезләнеп калды. Җайсыз икән бу болай. Эшеңнән кайтуыңа өстәлдә кайнар самавыр да җырлап утырмагач, кызыгы юк яшәүнең.

Әзһәр чөйдәге киемнәренә карап алды. Ярата шул ул аны, юньсезне! Нигә алай эшләде икән инде? И Хәбирә, Хәбирә, болай көлкегә каласыңны белсә, Әзһәр сине ул эшкә җибәрә идеме инде?

—Аллага тапшырган, ни булса—шул!

Болай сөйләнеп куюы аның үзен дә куркытты. Күзләреннән бөселеп чыккан кайнар яшь гүяки керфекләрен эретерлек иде. Ир кешенең ялгыз яшәве дөрес хәл түгел. Ярамас болай, алып кайтыр, ахрысы. И адәм көлкесе!

Хәбирәсе, куып чыгарылган көненнән, өч баласын да итәгенә тагып, каладагы апаларына китеп барды. Ике көннән бажасы килеп:

—Киемнәрен соратты,—диде. Һәм дә аның белән килеп кергән Хәбирәнең апасы таулар иште, тавыш чыгарды.

Әзһәр сүзгә катышмады. Ни теләсәгез—шул, әнә киемнәре, дигәндәй ым какты да чыгып китте. Лапас кыегы астына кереп, көннең шыксызлыгыннан ышыкланырга теләгәндәй баганага сөялде, якасын күтәрде, куырылды. Бераздан бажасы да чыкты. Әзһәр янына килеп, тәмәке пыскытып җибәрде.

—Тартасыңмы?—дип сорады.

Белә иде: тартмый Әзһәр, тартмый, адәм тәганәсе!

—Бир әле, булмаса!

—Мә, бажа, янсын!.. Йөрәк янганчы, дим.

Әзһәрнең болай да урынын югалткан йөрәге каешыннан ычкынган тегермән ташы кебек зырылдый башлады. Тәмәке ачысы тамагына утырды. Монысында юл таба алмый җыелып торгандай иде, тагын күз яше тышка бәреп чыкты. Бармакларыннан башланган калтырану кулына һәм бөтен тәненә күчте. Кешене дөньяда хис яшәтә икән, кешене дөньяда хис үтерә икән!..

Әзһәр шуларны исенә төшереп алды. Кием элгечләре янында кадакка эленгән нәзек аркан күзенә чалынды. Моңа кадәр ул бауның барлыгын белгән юк иде. Ә хәзер—муенына үрелә, каһәр!

## V

Салкынга борылып алган җәй көне иде шул. Бажасы төянеп китеп барды. Олы йөк машинасы белән кайтмаса да яраган булыр иде, аларның бит җинеле дә бар... Ә хатыны инде, хатыны, Әзһәр аны җиңги дип кенә йөртә иде, сүзләрен күп түкте, әшәкеләнде, эчендә кайнаганын аударып калдырды. Инде һәммә әйткәннәре дә исендә түгел, шулай да берсе һаман колагында яңгырый:

—Җиләк кебек хатыныңнан колак кактың?

Эһ, җиләк кебек кенә булса иде ул! Ай гына түгел, кояш! Дөнья йөзендә андый зат тагын бармы? Фәрештәдәй иде, гөлдәй!.. Өзелде! Кешеләр ничек кенә аерылышалар да бер-берсен җиңел генә оныталар икән? Әзһәрләр дә

аерылыштылар микәнни? Нишләр инде ул хәзер? Йа Ходаl Булды микәнни бу хәлләр? Язмыш дигәннәре шушыдыр инде, шушыдыр!

Әзһәрнең күңеле кузгалып, күзләренә кабат җыела барган яшьләр мөнә тагын бүселеп төшәргә маташтылар. Ир кешенең елавы да пыскып янган учак кебек шул аның, үзәктән көя, үзәктән!

Лапас ягына ут кабызып, арканын тотып чыкты Әзһәр. Тукталып торды. Эчкә таба узды. Монда ышык иде. Кулындагы арканын чишеп җибәргәч, бер башын лапас өрлегенә аркылы салды, тартып карады. Ныклы иде. Таза. Нинди иләмсез йөкләрне таратмый буып тора алган аркан адәм муенын гына кысарлык иде.

Юк, мордарлыкның гөнаһы зур! Ярамас!

Ниятеннән кире кайтты Әзһәр. Моңа кадәр күңелен биләп изгән мескенлек хисен ышаныч һәм ныклык тойгысы алыштырды. Күзләренә тулган кайнар яшьләрен фәрештә канаты белән сөртеп алды.

## VI

Уйларның ахыры юк инде ул. Искә төшерә башласаң, адәм башы ниләр күргәнен исәпләсәң, туып та торасы килми. Шушы авыр газаплар һәм җәфалар өчен бирелә микәнни кешегә язмыш дигән кодрәт шаяртуы?

Газ плитәсенә куелган чәе кайнап чыккач, төшкелек ашыннан калган каты икмәк кисәкләре белән Әзһәр тамагын ялгап алды. Уйларыннан котылып, бераз иркенәеп киткәндәй булды. Ягып җибәргән мичennән йорт эченә җылы тарала башлады.

«Җимешле агачка һаман да кул үрелә инде ул!»—дип, ничектер җайсыз уйлап куюына кәефе килеп елмайды. Юл читендә үскән ялгыз алмагачның алмаларын яшел чагында ук коеп-чүпләп бетерәләр, ул сынган-гарипләнгән ботакларын җыя алмыйча көзгә керә. Кышны ничек үткәрәдер?

Шунда Әзһәрнең күңелен үртәп, күз алдыннан Хәбирәсенең сурәте узды. Тулы беләкләре-күкрәкләре гүяки җаныңны үртәр өчен яратылганнар, барлыгың белән юклыгыңны бергә кушып җанландыру көченә ияләр. Хәбирәнең аяк атлауларына кадәр рәхәтлек белән тулы. Хәзер кемнәр алдыннан шулай уза икән инде ул? Янындагы балалары нәрсә эшли? Җиткән кызы—Саниясе, егетләрдән ояладыр хәзер, әти-әнисенең аерылышуларын өнәмидер. Бер шулай кайтып, әтисен эт итеп ачуланып киткән иде. Аның артыннан Әзһәр:

—И кызым, бәхетләрең була күрсен, яраткан кешеңә кияүгә чыксаң иде!—дип теләкләр дә теләп калды, орылмады-бәрелмәде. Бала шул әлегә Саниясе, бала гына! Күңеленә килгәнне генә уйлый, шуның белән генә эш итә, асыл сәбәпләрне төшенеп җитми.

«Матур гөлләрне өзәләр,
Сакла үзең, җанкисәк!
Армияләргә китәмен,
Исән кайтырга исәп!..»

Әзһәр әллә җырлады, әллә елады. Сөекле Хәбирәсе белән егет чакларында шулай җырлашып аерылышкан иде ул. Мескенем, елгадагы басманың аргы башында елап баскан хәлендә торып калды Хәбирәсе, ә Әзһәр эре адымнары белән Сарман райвоенкоматына китеп барды. Аркасына эленгән биштәрендә ниләр булгандыр, анысының җинеллеге генә хәтерендә калган, әмма кесәсендә җанашы чиккән кулъяулык иде.

Алар озаклап йөрешеп мәшәкатьләнмәделәр. Әзһәрнең һаман да вакыты булмады, көне-төне эштә иде, ә Хәбирәне, гаилә агачыннан өзелеп төшәргә

торган житем кызны, күз-колактан ерак булмасын дип, әнисе һаман да үзенә ияртте, кичләрдә дә капка төпләренә сирәк чыгара иде.

—Көтәр, көтми калмас!—дип уйлады һәм өметләнде Әзһәр. Башкача булырга мөмкин дә түгел иде. Читтә, илдән аерылып, авыр муштра солдат хезмәтендә егетнең күнелендә Хәбирәсенә мәхәббәте Туган туфракны сагыну һәм ярату хисләре белән бергә тагын да үсте, ныгыды. Аның йөрәк түреннән бу ике мәхәббәтнең берсен генә дә тартып алырга ярамый иде, чөнки шунда ук икенчесенең дә тамыры корыячак...

Хәбирәсе, балаларын гына түгел, Әзһәрнең күнеленнән Туган туфрак жылысын да алып чыгып китте түгелме?

## VII

Яшәлгән дә, яшәлмәгән дә төсле иде бу тормыш дигәннәре. Мәхәббәт исереклегендә гомере үтеп тә маташкан. Инде дә айныды бугай? Бер дә дөрес яшәлмәгән түгелме? Көне-төне эшләнелгән дә эшләнелгән. Йортын да салган, абзар-курасын да, мунчасын да... Аның һәр агачы, тактасы-кадагы үз кулыннан үткән бит! Беркем дә китереп бирмәгән, эшләп, көч түгеп тапкан. Тиешен юллап алуы да жиңел булмаган.

Ә Хәбирәсе сабыр булды. Хәер, бер тапкыр ашыгулык күрсәтте, анысы. Хәрби хезмәттән кайткан елында Әзһәр үзе дә, борынны югары тотып, юри генә инде, жанашын үртәп алыйм диярәк, күршеләренә килгән кунак кызын озата барган иде. Икенче көнне Хәбирәсе кирәген бирде Әзһәренең, янагына ялтыратты.

—Ни өчен?—дип күгәреп катты егет.

—Үзең беләсең!—Хәбирәнең күз яше катыш ачуы күзләреннән бәреп чыкты, әмма йөзен яулык читенә яшерде.—Адәм тәганәсе!

—Мин нишләгән?—күнелендә булмаганлыктан, Әзһәр инде күршедәге ул кунак кызын оныткан да иде. Ә Хәбирәнең колагына аларның бергә клубка чыгулары хакында сүзләр бик хәтәр хәбәр булып килеп ирешкән. Халык телендәге гайбәт Әзһәр белән шул кунак кызының ай яктысында, оялмыйча, кочаклашып үбешүләрен, икенче көнне авылларының капкасына кадәр үк атлы арба белән егетнең озатып куюларын, юлда Мөшәррәфә чишмәсенә тукталуларын жентекләп барлады. Имеш, шомырт чәчәк аткан вакытта балыклар да уйнаклый, каз-үрдәк тә бәбкә чыгара. Әзһәр дә ул кыз белән тик йөрмәгәндер, көтүче Хисметдин, тугарылган ук булмаса да, атларының аркалыгы төшкәнлекне ашарына төшке аш китергән Чүлмәк Мөнирәгә сөйләгән.

Хәбирәнең ул сүзләрдән колаклары кызарып, йөрәге каралып бетсә дә, үзе хакында гайбәт йөри дип Әзһәрнең башына да кертеп караганы булмады. Ни генә дисәләр дә, әмма теге Мөшәррәфә чишмәсе буендагы аркалыгы төшерелгәнне—Минзәләбаш авылыннан Хәкимулла абзый жигеп йөри торган, кумхужның көндәлек эш аты иде. Ул да анда үзе генә түгел, хатыны Жәмилә белән булдылар. Чишмә буенда нишләүләре билгесез, әмма дә ләкин Әзһәр алар янынннан арбада узып киткәндә, бит-кулларын юып маташа иделәр. Мөгаен да гозер итеп, корбанлык сарык алып килгәннәрдер дә, Мөшәррәфә әүлия-бикә рухына атап, Аллаһыга багышлап, шуны чала торганнардыр... Бу йола хакында Әзһәрнең ишеткәне бар иде. Комачаулап йөрмәскә итте, атын ашыктырды. Шунда көтү куып килүче Хисметдиннең үзе кебек усал телле иләмсез чыбыркысы, таулар арасына яңгырашы белән сыеша алмыйча, ярты көнен йокыда үткәргән тәбәнәк урман агачларын да сискәндереп булыр, котелмәгәндә шартлап куйды. Әзһәргә арты белән утырган һәм тыныч кына үз авылларына кайтып килгән кунак кызы да дерт итте. Болай куркуыннан йөзенә оят кызыллыгы йөгерде. Шунда ук колакларын үрә торгызган үшән

ат, үз сырты өчен котын югалтып, таралып китәрдәй булып чаба башлады. Әзһәр артына борылып карады. Алар узганда авыл башында калган көтү, үр артыннан чыкмаган булса кирәк, күзгә-сангга чалынмады. Хисметдин дә чыбыркысын башка шартлатмады, Әзһәр дә, юл белән килеп, урман почмагыннан сулга борылдылар. Моннан Минзәләбаш авылының такта түбәләре күренә башлады. Алар, Кычытканлы сазлыгы янынннан узып, Яхъя утарына килеп чыктылар да, борынгы алпавыт һәм кулакларның ташландык ихаталарын сулда калдырып, авыл капкасынача җиттеләр.

—Абый, мин монда төшеп калыйм инде, алга таба җәяү генә кайтырмын,—диде кыз.—Күршеләр дә колак итемне ашап җәфаларлар югыйсә!

Әзһәр атын туктатты. Үзенә «абый» дип эндәшүләрен ярата иде ул. Әллә кем булып китә.

—Сеңлем, тагын кунакка килерсеңме соң?—диде Әзһәр, Хәбирәсенең барлыгын бер минутка гына онытып торып.

Әгәр дә кич клубтан озата кайтсагыз, көтәргә риза булсагыз, килермен!—дип шаяртты кызый. Имеш, егет булсаң, кунакка килүемне көтмәстән, кичен безнең капка төбенә кояш баеганда үзең үк килеп җитәр иден әле!

Әзһәр кызыллы-зәңгәрле булды. Шунда ук Хәбирәсе исенә төште, йөрәге урынынннан купты. Кызый бу галәмәтләрне үзенә багышланган дип тойды һәм егетнең бүген кичкә һичшиксез килеп җитәчәгенә хәтере ышаныч белән тулды, шунлыктан гаҗәеп тә нык жанланып, болан баласыдай урынында талпынып, кечкенә төенчеген күкрәк турына кысты да урамга таба йөгерде, күздән дә югалды. Аның артыннан Әзһәр онытылып карап калды, дөньялыкта ашау белән эшләүдән артыгын белмәгән аты, куерып үсеп килгән уҗымга таба сузыла-сузыла, басу ягына таба керде. Юл кырыенда яткан олы ташка арба күчәре килеп төртелгәч, сискәнүдән айныган Әзһәр, атын чигерде һәм, арбасын бордырып, үз авылларына ашыктырды. Бүре елгасы янынннан урманга күтәрелеп, аланнан кыркып алыр үләннең барлыгын-юклыгын карады. Печәнгә иртә иде әле, чыгып кына килә. Урман һавасының рәхәтлеге аның җанын хозурландырды.

## VIII

Чәенең янартылуы ризыгына тәм өстәмәде. Хәерсез булулары шушы идеме? Әллә ризыгың төкәнгәнгә шулай бәрәкәте дә китәме?

Гомер кыска булып тоеладыр гына ул. Ничәмә тапкырлар яшәеш үзенең кыйбласын үзгәртә торды. Бер падишаһларны икенчеләре алыштырды, күмхуҗ рәисләре дә биялэй кебек алмашына, урыннарыннан колак каккалый, кошлар кебек очып киткәли тордылар. Кешеләр ничек бер хатынны икенчесенә алмашадыр. Ходай белсен?!.

Әзһәр болай яши алмаячагын белә иде. Өендә көтеп каршылаган балаларын, аш әзерләп торган хатынын, җылы урын-җирен булмаса, ничекләр яшәмәк кирәк? Ул өйләнмичә, ялгыз башларына гомер сөргән ирләр ничекләр көн күрә икән? Харисны әйт инде! Хатын-кыз рәхәтен татып та карамыйча дөньядан үтте. Сөйгән идем дип инде, кем-кемне яратмаган? Ярый, күз атып, жан багышлап яшәгән кызың, юктан гына үпкәләшеп, башка кешегә кияүгә дә чыксын ди. Шуннан? Ә ул бәлки шулай бәхетенә ирешкәндер, язмышыдыр? Аны кабат кайтыр, иреннән-гаиләсеннән аерылыр да сина хатын булып килер дип көт инде, йә! Юньле хатын бер ирдән икенчесенә китә димени ул?!.

Күнеле тәмам арыган Әзһәрнең җанын бу уйлары кабат кузгатты. «Нәрсә җитмәде инде бу Хәбирәгә?»—дип, үзе белән үзе сөйләшеп, сүгенеп алырга иткән иде дә, теле кузгалмады. Җаны оеша алмый интекте. Гаепне үзендә дип беләсе килми иде аның. Хатынының хатасы—төндәге ай кебек, болыт

пәрдәсе белән никадәр капларга тырышсан да андый гөнаһны яшерү мөмкинме сон? Уйнаш кадәрле оятсызлык дөньяда бардырмы? Нәрсә житмәде Хәбирәсенә? Яхшы тел, дисенме, кадер-хөрмәтме? Бу мал-туар, йорт-жир— кайсы ягы житешле түгел? Кием-салым, табак-савыт, урын-жир—кая, кайсы? Хәер, болар барысы да, артыкмы-кимме, һәммә кешедә дә житәрлек. Хәзер юк нәрсә бармы сон ул? Әзһәрен, эчте, дисә, алай гына авыл мулласында да булгалый. «Жылы аш белән булганда, жанга сихәтлек бирә!»—диләр әле алар. Эчмәссен, бар, бу тормышта! Хәзер бит аракысыз коры салам да юнәтеп булмый. Имеш, «Зәмзәм суы», диләр аны. Бик алай икән, шуны эчүләренә нигә сон бәндәләр акылларын югалталар? Изге су булса, адәм баласын саташтырмас иде ул.

Әзһәр үзен ачуланырга да, акларга да тырыша иде. Барып, эч серләрен сөйләп кинәшер кешесе дә юк шул анын. Ничек инде кемгәдер килеп: «Миннән хатыным китте!»—дип әйтәсен? Ул шунда ук: «Гаебе булмаса, яныннан адым да читкә атламас иде, гаебе бардыр! Көн дә йөзенне күрүдән ояладыр!»—дияр инде. Йа Ходаем, шулай ук гаепле булды микәнни сон Хәбирә? Утсыз төтен чыкмас, жилсез йөремәс! Уты да, жиле дә бардыр инде анын, бардыр.

Әзһәрнен күз алдында гүяки бөтен нәрсәләр дә үз жаена кайтты, акылында мона кадәр урык-сурык яткан фикер төенчекләре бердәм жыйналды, күнеле утырды.

—Йа Ходай,—дип кат-кат кабатлады ул.—Жил йөгергән икән шул! И Хәбирә, ә мин—юләр, кеше сүзенә ышанмаган идем. Халыкныкы хак шул ул... Дөрес икән!..

Әзһәр тагын пыскып кына елап жибәрде.

## IX

Төнге йокы кешене сихәтләндерә, диләр. Шулайдыр, шулай булмый ни! Көн буена баш күтәрми эшләп, йончып, арып бетәсен дә кайтып авасын, йокыга жибәрмичә аяк-куллар, хәтта гәүдән таралып китмичә газаплый.

Кышкы иртә тиз генә яктырып житә алмый. Әзһәр инде чәен кайнатып өлгергән, малларын карап, утлыкларына печән салып, күмхуж фермасына эшкә чыгып китәргә тиеш иде. Ашыкмады.

И гомер дигәннәрен, кайсы тормыш юлына кереп китсә дә, сазлыкмы анда, тау-ташмы, башкасымы—тәгәрмәчләре һаман тәгәри бирә. Бара да бара. Гүяки бөтен дөнья тик кенә басып тора, артыннан карап кала сыман, ә синеке—бара... Бара, имеш.

Шундый адәмнәр була, дан-дәрәжә өчен хәтта үзләрен сату юлына керүдән дә чирканмыйлар. Кая ди ул хатын аеру гына, анысына исләре дә китми. Бияләй алыштыру ише генә аларга бу гамәл.

Ничек болай килеп чыкты сон әле? Саташты гына микәнни? Бәла бит ул аяк астында гына. Ни яхшы ат та сөрлегә. Хәбирәсе дә Әзһәрнен, ялгышып, максат итмичә саташмадымы икән? Ул бит алдан әзерләнеп, иренә көлке итеп, үзен дәрәжәгә күтәрү өчен дип кенә, хыянәткә бара алмый. Әйе, алмый, булмасны юри сөйли торганнардыр!

Бу уе Әзһәрнен күнел офыкларын кинәйтеп жибәргәндәй иде. Сагына шул ул, бик сагына Хәбирәсен. Яратып, арадан бер дип өйләнде. Хәбирәсе дә яшь чакларында һичкемгә күз салмады. Хәтта йөргән егете—шушы Әзһәре хәрби хезмәткә алынгач та, башка кызлар кебек яшь гомеренен әрәм үтүе хакында хәсрәт кичермәде. Бүтән берәүгә күз салуны уена кертеп карамады. Дөрес, капка төпләренә егетләр килмәде түгел, әмма Хәбирәнен сүзе кыска булган:

—Минем егетем бар!

һәм шул әйткәне яраган, житә торган. Капка баганасы сагына басарлык егет авылда күренми башлаган. Ә Әзһәргә жылы, йөрәк учагыннан алып язылган татлы хатлары килә тордылар. Егете хәрби хезмәттән очынып кайтты, шул көздә алар никахлаштылар, гаилә корып жибәрделәр. Алга таба тормыш мәшәкатьләре белән үз җайларына пар күгәрченнәр кебек яшисе дә яшисе иделәр.

## X

Тормышның иң авыр вакытларда туганнарыңның кадере арта, диләр. Ярый ла аркаң куярлык карендәшең, бәгыреңне ерткан хәсрәтеңне уртаклашыр туганың булса! Ул бит сине аңларга, җаныңа терәк була алырга тиеш.

Әзһәрнең андый кешесе юк иде. Аны гүяки барысы да инкарь иттеләр, яратмыйлар Хәер, кеше кешене ратса, андыйлар өйләнешеп яшиләр, хатын һәм ир булалар. Ә кемнендер, башканың сине яратуы мөмкин һәм кирәкме соң?

Ирен хатыны сөйми башласа, аңа ни кала? Нинди генә аяз һәм якты көннәр булмасын, бу ир кеше ул кояшны да, жылылыкны да тоймый башлый. Башы ялгыз кала. Ул ирләрен яратмаган хатыннарның гына түшәкләрен жылытырга әрсез ирләр атлыгып торалар. Хатыны ташлаган ир кемгә кирәк?

Әзһәр моны жаны-тәне белән аңлады. Йөрәге урынынннан кузгалып, башы әйләнеп куйды. Ул тагын бу тормышта артык кеше булуын тойды. Аңа яшьлек истәлекләре дә, күрше-күләннең күзе дә, кумхужда көнә-төнә эшләве дә бер мәгънәсез, буш һәм әһәмиятсез кебек тоелды.

Шунда балалары исенә төште. Олы кызы—чибәрләрнең чибәре, күзгә-башка күренерлек булып житеп килә. Авылның иң кәттә егетләре, аны күрүләренә, тәкатьләрен югалтып, башлары әйләнгәнен тоймый да калалар.

Ә кызлары бәхетле булырлар. Иң яхшы егетләрне сайлап алырлар, анысына да бер хәйран итми әтисе. Бу өлкәне бигрәк тә акыллы кыз, сайлана да, сайлый да белә. Әллә кайсы ерак авыллардан аны эзләп, бер күрү өчен генә дип ничәмә егетнең килеп, капка төпләрендә сайрашуларын Әзһәрнең үз колагы белән ишеткән чаклары аз булдымы? Бәхетен табар кызы, табар! Тик менә әнисенең хәлләре хакында хәбәрләрне ишеткәч, ул егетләрнең күнелләрендә шыткан кызыл мәхәббәт гөлләренә кырау төшмәсме икән? Агачыннан алмасы ерак тәгәрәми шул! Йа Ходаем, шулай ук булыр микәнни? Юк-юк, үзең сакла! Бу олы кызы үзенә охшаган Әзһәрнең! Нәкъ үзе—күнеле белән дә, холкы белән дә! Яратса, берне генә яратыр һәм... Мәңгелеккә!

—Йа Ходаем!..

Бу сүзләреннән соң Әзһәрнең йөзен ут алды. Әгәр дә шушы кызы гомере буена әтисе кебек бер генә кешегә гыйшык тотып яшәсә, аны никадәрле борчулар көтәр! Ярый да яратканына, сөйгәненә кияүгә чыга калса, ярый да анысы да шундый ук булса! Әгәр дә эшләре башкача китсә, кызы сөйгәненә чыга алмаса, яраткан кешесе: «Агачыннан алмасы ерак тәгәрәми!»—дип, әнисенең кемлеген искәртсә, баш борса?..

—Йа Ходаем!..

Анын бу уфтанулары хәерлегә түгел иде. Нигә шунда дуламады? Гайбәт ишетүгә, хатынын егып салмады, изеп ташламады? Нәрсә, ул ир түгелмени? Баш биреп торалар димени? Сөяген сындырса, төзәлер иде әле!

Хатыннан бигрәк Әзһәр олы кызын сагынуын аңлады. Аңа ничектер рәхәт булып китте. Хәбирәсен шайтан алды, ярар, алсын да ди, әмма балалары бар бит анын, балалары! Аларның әле үсәсе, башлы-күзле буласылары—алда! Кече кызы бакчага йөри. Анысы аягына басканчы ун-унбиш ел үтеп китәчәк. Ничек инде нарасыйларын, сабыйларын, балаларын кеше тупсасында ятим итеп йөртергә була?

Әзһәрнен күнеленә кергән уе, акылын савыктыргандай, күнелен-аңын биләп алды. Булмас болай, балаларын алып кайтырга кирәк ана. Хатыны үзенә карар, йә ияреп килер, яисә калыр. Әмма ялынып торасы түгел! Балалары кеше тупсасында зарлар шул, зарлар! Ярый да ашарларына булса? Шәһәргә үк китеп бармасалар ни булган? Алар анда бәрәнгене дә сатып алалар шул... И юләрләрдән икән шул анын хатыны, ахмаклар исемлегендәге кеше икән!

Кунак килсә дә, өч көннән артыгына чыдашлы түгелмени? Ә алар, Хәбирәсе дә, балалары да инде ничәнче айларын кеше өстендә яшиләр.

Алимент та җибәргәне юк аларга Әзһәренен. Анын өчен суд карары белән аерылышу кирәк, диләр. Кызы йә улы кайтып киткәләгән чакларда хәл кадәри аларга акчасын да бирә, ризыгын да төяп җибәрә ала инде, анысы... Әмма шуларга гына канәгать итеп, кеше өстендә киерелеп яшәп булмый торгандыр! Әллә соң барып алып кайтыргамы үзләрен? Балалар кызганыч, бигрәкләр дә чит-ят тупсалар төбендә үсәләр шул! Үз йортлары була торып, шулай аларны кангыраталар димени?

XII

Әлмәт юлы такыр иде. Машиналар йөреп кенә торалар. Утыртмый узучылары юк.

Юллар чатына чыгып басуына, Әзһәрне бер олы машина алып та китте. Шәһәргә килеп кергәннәрендә кышкы көн яктырып бетеп маташа, юлларнысукмакларны кардан арчып куйганнар, ашыгучы халык төркемнәре эш урыннарына сенеп бетеп килә иде. Машинадан төшеп калгач, Әзһәр ялгыз башы бераз аптырабрак басып торды. Соңгы вакытларында шушы ялгызлыгы, бәгыренәчә үтеп, җанын өшендерә башлаган иде инде. Шунлыктан үзен хәлсез калгандай тойды. Буш эш белән йөрмиме икән дигән сорау каян туарга өлгергәндер, бусы ана икенче коткы булды. Аяклары гүяки атлап китәр хәлдә түгел иделәр. Ул дөнья читенә килеп чыгып, ялгызы гына калган һәм барыр җире дә беткән кеше кебек кот чыккысыз хакыйкать каршында басып торадыр сыман хис итте үзен.

Бераздан соң ана батырлыгы янадан кайтты. Таныш урам, таныш йортлар янынннан узып, ике катлы, олы тәрәзәләре белән урамга томырылып карап торган, Чупай ташыннан салынган пулат янына житте. Анын монда беренче тапкыр гына килүе түгел. Шушында кунаклар булып, бажасында ничә кат күнелен җуйган иде ул. Әнә аларның тәрәзәсе. Утлы. Якты.

Шунда Әзһәрнең итәк чабуыннан коткысы тартып куйгандай булды. Күнеле жу итте: нишләп аптырап йөри әле ул монда, үз дәрәҗәсен бетереп?

Ана тәрәзә якынаеп килгән сыман тоелды. Пыяла бозлары эрегән, эчтәге җылылыкны сары ут яктысы тагын да хозурлый, йорт җиһазларын баерак итеп күрсәтә иде. Ә өстәл артында бер хатын утыра. Алдында кренделе, шәһәр калачы, шикәре, кәнфите, татлысы һәм баллысы, мае, кайнатмасы мул итеп өелгән һәм тезелгән. Чинаягына кайнар чәй агызып, аны тәлинкәсенә бушатып, бармак башларына гына утырткач һәм күтәргәч, суынсын өченме, әллә назланыпмы, йомшак сулыш җибәреп, ризыгына ихлас күнел салып тукланып утырган бу күмәчтәй ишелгән ханымнын үз хатыны икәнлеген танып алды. Анын бәхетле булуына хәйран итеп, Әзһәр шунда тынсыз калды. Бу тамаша ирнен йөрәген кысты, бәгырен укшытты. Берни сизенмәгән һәм бу вакытта ашау-эчү бәрәкәтенен рәхәтенә чумган хатыны, тезләрендәге ак йомшак сөлгене күтәреп, анын бер башына әледән-әле мангай һәм муен тирләрен сөрткәләп, гүяки җәннәттә тәгамь жыюда иде. Ире һаман да аптырашта карап тора бирде. Инде анын ни эчкә узарга, ни кире кайтып китәргә теләгенә килмәде. Әллә яши, әллә үле—шушымы барлыгын, адәм баласы?

## XI

Адәмдә кайгы бетә димени? Исең киткән икән, и юләр! Төн артыннан көн килми калмаган кебек, бәхет кояшы, галибанә яктырып, бөтен җиһанны үз кочагына алгандай, бөек бер падишаһ сыман, дөньялыгына гына түгел, күнел йортына да хуҗа булырга өлгерер. Үзен мәңге китмәс дип белер, бу заманада башка һичбер өстеннәр юклыктан тантана итәр. Гомергә шулай булган, башкача мөмкин дә түгел. Яшәешне Ходай Тәгалә үзе бу рәвешкә килерлек итеп яраткан. Бүтәнчә булырга һичбер мөмкинлек калдырмаган. Аның белән бәхәс итәсе дә түгел, ни барына һәм биргәненә сөенеп, килер көннәр өчен тырышып, гамәлдән калмый һәм кәсептә ашкынмый рәхәтле булудан гайре юнь бармы соң?

Әзһәр үзенең ни турында һәм нәрсә өчен болай уйлаганына хәйран итеп, ялгыз башы торып калган өенә кайтып керде. Иртән ягып җылытып киткән йортына электр уты кабызды. Күнеле иркенәеп киткәндәй тоелды. Газ плитәсенә куйган чәе кайнап чыкты. Өстәл янына килеп утырды, чәйләде һәм, абзарларга чыгып, мал-туарын карап керде дә, тагын тамагын яңартып, эшенә китәргә җыенды. Күз уңына чалынырга тиешле булган бауны хәтеренә алды. Аны кая куйганлыгы һич исенә төшмәде. «Әллә берәр кырын-ярын адәм чәлдермешме?—дип уйлап карады.—Белмәссең, чыгып киткәнне генә карап торалар!» Әмма соңыннан, үз алдына сөйләнеп, көлеп тә алды:

—И юләр, кемгә кирәге бар инде аның? Алып торган булсалар, кертерләр әле!

Аннары җырлагандай итеп шыңшып алды:

—«Арадагынай юллар ерак түгел, нигә килгәләмисең?...»

Сүзләренә кадәр җанына бик тә хуш, ятышлы иде, тирән диңгез төпләреннән дә тирәнрәк булган күңел төпләреннән ургылып чыгасы иде... Өзделәр. Кемдер ишек какты. Әллә болай гына ишетеләме дип Әзһәр колак куеп торды. Дөньялык мыштым калды, шулай да ишеге артында кемдер бар сыман, гүяки сулышына кадәр ишетелгәндәй тоелды.

—Кем йөри анда? Кем ул?—дип, бер-бер артлы кабатлады Әзһәр.

Әмма җавап бирүче булмады.

Һичшиксез анда, ишек артында, кемдер бар, керергә кыймый тора—анысы факт. Әзһәр дә барып ачарга ашыкмый: килсәләр—керерләр, кермәсәләр—китәрләр!

Тагын ишеген шакыдылар...

## XII

Хәсрәтләре гүяки һәммәсе берьюлы юылып төштеләр. Ишек төбендә керергә рөхсәт көтеп торган кеше Әзһәрнең үз хатыны—Хәбирәсе иде.

—Менә чәй эчәрмен дә эшемә китәрмен дип тора идем. Малларны карап куйдым. Кичкә башак бирербез,—диде Әзһәр, хатынынннан исәнлек-саулык та белешеп тормастан. Ул үзен Хәбирәсе белән инде бүген күрешкән кебек тотты.

—Әллә нишләп күнелем жу итеп китте. Эшләрне бераз бетереп куйгач, кереп, чәй эчәргә утырган идем, тәрәзә төбендә карап торучы шәүләнне күрдем. Әүвәле анлый алмадым. Аннары хәйран калдым. Менә шәһәр күчтәнәчен алдым да кайтып киләсе иттем әле!—диде Хәбирәсе, каушавын кая куярга белми, йөзендә балкыган итагать фәрештәсенен килбәтен үзгәртә алмыйча.

—Үз өең бит, кайчан кайтсан да ишекләр ачык, түрдә йөр!—диде Әзһәр дә, ни әйткәнен тәгаен гына колаклары белән ишетмичә.

Сүзләре шушында төкәнде. Алар бер-берсеннән ялгыз гомер хәлләрен

сорашмакчы иделәр. Әмма өзелгән сүзләре ялганып китәргә теләмәде. Аерылышу вакыйгалары—тыелган тема, ана «табу» коткысы мөһерләнгән иде. Әгәр шунда ялгышынып бер сүз ычкынса, икесенең дә күңелләре кителәчәк икәнлеген әллә акыллары, әллә күңелләре белән тоеп, чәй янына утырдылар.

Әзһәр кышкы кызыл кояш кебек елмая бирде, аңа җавабында хатыны да, әле яңа гына кайтып керүен, аерылышу газапларын кичерүләрен, адәм мәсхәрәсенә төшеп, авылдан чыгып качуларын да бер мәлгә онытып, бәхет нуры тулы йөзе белән балкыды. Әгәр дә дөньялыкта бу көнне—фәрештәләр җиргә ингән чак, дисәләр, моңа ышанмый мөмкин түгел иде. Йа Ходай Тәгалә, йа Аллаһы, син бәндәләреңне бәлаләргә дучар итеп сыныйсың да, сындырасың да, аннары кабат тормышларын бөтәйтеп, күңелләрен күтәрәсең!

Чәй янында алар сүзсез дә бер-берсен аңладылар. Хәбирәсе бүтән китмәячәк, Әзһәре дә аны һичкайчан үзеннән аермаячак иде.

—Балалар кайчан кайтырлар соң?

Бу соравын иреннән ишетермен дип хатыны уйламаган иде, алдан җавабын да үлчәп куймаган, әмма күңел кылларында ят бер тибрәнү кузгалып, бөтенләй дә каушап төште, гүяки акыл үлчәвенең тәлинкәләре як-якка кыйшаеп куйдылар. Чактан гына: «Әһә, балалар кирәкмени әле сиңа!»—дип, йөзен яктыртып нурландырган иренең күңел тәрәзәләрен ватып ташламады.

Чәйдән соң Әзһәр эшенә кузгалды. Ишекне ачып чыгуына, күзенә кичә кич чыгарып ыргыткан бау-аркан чалынды. Аны җыеп алып, кире кертеп элде. Анымоны сизенмәдеме икән дип, кырын күзен табак-савыт җыештырып маташкан хатынына ташлады. Шикләнерлек һәм уфтанырлык һични дә юк иде.

—Ничәләргә кайтырсың?

Җавап бирергә диярәк Әзһәр уйга калып торды. Кулына арканны җыйды. Мондый сорауны ул инде күптән ишетмәгән, шуңлык белән дә, хәтта шактый ягымлы ишетелгән тавышка ияртелгән хатынының сүзләре назында акылын җуярак калды. Хәбирәсе дә җавабын ашыктырмады.

—Кичке җиделәрдә өйдә булырмын! Бүген эш күп... Шулай да мунча яксак иде, арка да кычытып тора!—диде, аягындагы олы итекләре белән бер урында таптанып, бушлат төймәсен әле ычкындырып, әле яңадан элеп.— Утын да кертеп куйган идем бугай... Суы катып өлгермәгән булса... Ягып кына җибәрәсе!

—Ярар!—диде Хәбирәсе, үз мунчасын сагынуы исенә төшеп.

Йөзенә җинелчә кызыллык йөгерде. Аның бу вакытта нәрсәләр хакында уйлаганын ире күңеленә кертеп тә карый алмый иде.

—Балалар да кайтырга әйтәләрме соң?

Бу юлы да хатыны җавап бирмәде. «Ярар, анысын башка юлы сөйләшербез!» дип уена беркетте дә, Әзһәр эшенә китеп барды һәм... Җиде дигәнен, сәгать алтыда ук кайтып керде. Аны Хәбирәсе балкып каршы алырга тиеш иде, мунчаларны ягып, ашларны пешереп...

Әзһәр өнсез калды. Аш та юк, мунчасы да ягылмаган, йорт-җир кышкы салкынлык эчендә иде.

—Эһ син, хайван, «ну-ка»!—дип сүгенеп куйды ятим ир.—Талап чыгып китмәсәң ни булган?! Болай да бирми идемме бу түшәк-ястыкларны, телевизорны, самавырны...

Чөйгә үрелде, андагы бауны алмакчы иде, әмма таба алмады. Моңысыннан да җилләр искән булып чыкты. Эһ, кулында иде бит, кулында иде, бәйләп салып, ишәсе иде үзен, кузгалмаслык, арт сикертмәслек итеп!



Шәүкәт
Гаделша

# ТУГАН ЯГЫМ—СЕБЕР УЕ

***

—Туган як, мин кирәкме?—
Дип сорарга оят.
Җанмы, әллә гомерме
Монда кыйбат?

Каным, тәнем кайтып кына
Узган гомер кайтмас.
Җаным бик теләсә дә,
Урман уклар атмас...

Иң соңгы төз наратны
Авылдашмы еккан?
Яшен тигән булса, үз
Күгеннәнме суккан?

Нинди мөһерен Ходай
Бу төбәккә баскан?
...Камиллек актарылган,
Ямьнең төсе качкан.

И ботак, син бер сынып,
Шартлаган да тынган.
Ә мин бушлык күреп
Мең шартлыйм, мең сынам!

Яшел кәлтәнекедәй
Минем тән дә «дер-дер»...
Кем әйтә: туган якта
Озыная, дип, гомер?!

***

Якты ай нур койганда,
Җилләр исеп куйганда
Каенлыкта шәүләләр
Әйләнәләр буранга.

Шул буранның сулышы
Ләззәт бөрки рухыма.
Оҗмахка күтәрүче,
Төшеп, миңа орынма!

Сөт күбегедәй гөрләп,
Чистара салкын һава.
Ел мизгелгә әйләнә,
Мизгел ел булып ала.

Йомык, хәлсез җаныңның
Йокламавын тоясың;
Ярамаганны уйлап,
Гайрәтләнеп куясың.

Нәрсәләрне сыйпарга?
Нәрсәдән котылырга?
Нәрсәне хәтерләргә?
Нәрсәне онытырга?

Кая, бәхет турында
Уй, йокымсырау анда—
Ай нурлары, шау килеп,
Каенга коелганда!

Шәүкәт ГАДЕЛША (1949)—*шагыйрь; Себер табигате, анда яшәгән татарлар турында "Ярык мөгез", "Сөмән кадыйм", "Аучы җыры" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Күңелсез як, мөмкинлек аз—
Тын инеше бик саек.
Колач җитмәс агачлары
Утыралар моңаеп.

Ә чыклар—мул, ереләре
Ботакларны бөгәләр.—
Елый—агач эчләреннән
Чыга алмаган көймәләр.

***

Бик күңелле дә түгел шул
Кырга чыгып йөрүләре:
Очрап куя кыргыйланган
Бик сәер эт өерләре.

Нәрсә, ни кыланыш этне
Бай хуҗалардан качыра?
Әллә соң борынгы кеше
Тын куышка чакырып тора?

Туктап карап торышлары
Йөрәгемне телә кылга,
Каннарымны суындырып,
Аякларны бармас кыла.

...Иң яшерен уйларым минем,
Эчемнән сез чыгалсагыз,
Кыргый эт өере булып,
Урамнарда чуалмагыз.

***

Чәчәк җыеп ягам. Кипкән чәчәк.
Гади үлән исе төтендә.
Үзен ни төтене итеп сизеп,
Үрли чәчәк күзнең күгенә?

Ис алдым да, хәлләндем дә кебек—
Авылдашым, зинһар, көнләшмә!
Күләгәләребез бер чамада—
Бер юнәлешкә бит төшәлә.

## Ул җырлый иде

Таңның алсу канаты
Урманга тиде.
Наратта суер күрдем:
Ул җырлый иде.

Туфрак суер канынннан
Төтенләп көйде.
Мылтыкны төзәгәндә
Ул җырлый иде.

Кешеләр минем арттан
Ияреп килде.
Тиледәй сөйләнгәнмен:
—Ул җырлый иде.

Хатын, кошны пешергәч:
«Бик ябык»—диде...
Еладым мин кычкырып:
«Ул җырлый иде».

...Ник җырчыга төзәдем,
Рухым коргыры!..
Озак газапларымы икән
Суерның рухы?..

***

Буран булып Себеремдә
Гаделлекме тилерә?
Йолкынасы—йолкынырга?
Үләсенә—үләргә?

...Буран тынган—чык, якташым!
Күзәт: ни хәлдә урам?
Дулап уйлан! Уйланып ян!
Кызган тимердәй нурлан...

Сүз белән генә булырмы
Якташымны чүкергә?
Нинди сандалларда таптап,
Аны хәнҗәр итәргә?

## Үлем килгәч

И карт адәм! Ходай бүген
Махсус күзәтә өстән.
Миңа каты ачуланыр,
Сине күрмәдем дисәм.

Бер-ике сулыш кичегеп
Торам: кычкырып өлгер!
Аерылышу җиткәнлеген
Өнең җиленә белдер!

Рухың өчен син борчылма,
Аңа иш табар Себер.
Кайтавазың да югалмас:
Эт улавына сеңер...

Каты кычкырды бабай... Һәм
Елмаеп күзен йомды.
Җылы, назлы моң өстендә
Агып баруын тойды.



Ләйсән
Кәшфи

# АК ХИСЛӘРЕМ—ҖЫРЛАР КАНАТЫНДА

## Ир-егетләргә

**Томырылып атлар чабып килә,
Тыеп булмый ярсу атларны.
Гомер дә бит чапкын атлар кебек,
Ә юллары шундый катмарлы...**

**Ир канаты җиңә давылларны,
Ир йөрәге тауны күтәрә,
Һәр адымың изгелеккә илтсен—
Шулай кирәк гомер итәргә.**

**Шәфкать кирәк җирдә, миһербанлык,
Яхшы эшләр һәрбер адымда.
Нәфесеңне шайтан котырткканда
Намус торсын иман сагында.**

**Гаярь ирләр тарта дөнья йөген,
Гаярь ирләр—илнең кендеге.
Кылган гамәлләрнең гаме белән
Билгеләнә кемнең кемлеге.**

***

**Гомер буе мине фәрештәләр
Саклагандыр явыз-яманнан.
Юлларыма ак канатлар җилпеп
Озата бара алар һаман да.**

**Юлдаш итмәделәр затсызларны,
Азган-тузган кулын суззмады.
Минем яшьлек олы бәйрәм булды,
Минем яшьлек зая узмады.**

Ләйсән КӘШФИ—*шагыйрә, тәнкыйтьче; «Авыл кызы», «Бәхеткә юл» исемле китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Һәм бүген дә, шөкер, янәшәмдә
Сокланырлык гүзәл затлар бар—
Дөнья әкият бит ул, мин—Алиһә,
Мизгел, тукта!—дигән чаклар бар.

Ярый әле матур кешеләр бар,
Тормыш ямен тоеп яшәргә,
Күңелләрне нурга коендырып,
Телефоннан кайчак дәшәргә.

Гашыйкларның иң-иң бәхетлесе,
Иң җүләре миндер, мөгаен.
Мин дөньяга, кешеләргә гашыйк,
Миңа исә бәйрәм көн саен.

## Идеал

Мин бит сине үзем иҗат иттем,
Рәссам иҗат иткән сын кебек.
Күңелемә ничек ошый-шулай,
Җанландырдым аннан тын өреп.

Калебемнең якты бүлмәсенә
Наз иңдереп, сине мин дәштем.
Үзем уйлап тапкан идеал белән
Гел ягымлы итеп сөйләштем.

Шигырь ефәгенә чорнадым да,
Һәм кояшка куйдым чыгарып.
Минем нәфис, бәллүр хыялларны
Вата күрмә, кырыс чынбарлык!

## Кош баласы

Кош баласы оясыннан очкач,
Канат кага барлык көченә.
Очышларда килеп төшмәс өчен
Кош куәте кирәк кешегә.

Җил-давыллар белән бил алышып
Яшь канатлар ныгый, чыныга.
Тәңре үзе нурдан күпер сала
Мең газаплы кошлар юлына.

Бармак очы чаклы кош йөрәге
Сыйдыралгач шундый кыюлык,
Ерак сәфәр чыккан кешеләргә
Тәңре тарафыннан тыю юк.

## Ак сөю

Ак мәхәббәт иҗат итик әле,
Исбат итик аның барлыгын.
Инкяр итик гөнаһ-хыянәтне,
Бу тормышның әрнү, зар-моңын.

Ак хисләрне җырлар канатында
Җилләр белән илгә җибәрик.
Иксез-чиксез илһам диңгезендә
Ак дулкыннар булып тирбәлик.

Саф сөюнең, ак сөюнең көче
Ядкәр булып җирдә мең яшәр,
Әкият булып калыр гасырларга,
Йосыф-Зөләйхага янәшә.

Дания
Заһидуллина

## ЯҢА ЮЛЛАР БӘХЕТЕ

(ФАКИЛ САФИН ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ)

Дөньяда шундый кешеләр була: алар бертуктаусыз яңаны төзү, яңаны булдыру белән шөгыльләнәләр. Буш җирдә бар итеп, шәп итеп, ниндидер бер өлкәдә юкны булдырып куялар да кешеләрнең караш офыкларын киңәйтеп җибәрәләр. Әлеге күренешләр бик табигый, бик гадәти рәвештә көнитешкә кушылып китә: әйтерсең лә, шулай тиеш булган, кирәк булган, уйланылган булган. Тормышның үзен һәм кешеләрнең ана карашын, күзаллауларын да шундыйлар үзгәртә. Алар башкаларны чынбарлыктагы күп кенә күренешләргә башкача, югарыданрак димме, карарга мәҗбүр итәләр, үзләренең эш-гамәлләре белән гадәти тормыш вакыйгаларыннан өстенрәк тору мөмкинлекне, шулай яңа сукмаклар сызылуын, шулай итеп көнитешнең үзенең камилләшә, кешенең камилләшә баруын исбатлыйлар.

Факил Сафинны мин нәкъ менә шундый—яңаны төзеп, булдырып күрсәтүче— дип саныйм. Аның эшчәнлеген күз алдыннан кичергәндә, һәрчак бу кеше тотынган эш-гамәлләрнең—нәтиҗәле, кылганнарының игелекле булуы күренә. Татар мәдәнияте тарихында сәхифәләр булып язылган берничә вакыйганы гына искә төшерик. Чаллы шәһәрендә «Аргамак» журналы басыла башлады һәм тиз арада татар дөньясында мондый журналлар халыкка чыгарырлык әдәби хәзинәнең житәрлек, ул хәзинәнең укучы өчен кирәк һәм кызык булуы расланды. «Аргамак»ның әдәби багажы, мөмкинлекләре хакында Казан җәмәгатьчелеге дә сөйли, журналның һәр саны көтеп алына иде. Бу чакны журналның әдәбият бүлеген җитәкләүче, анда җаваплы сәркатип булып эшләүче Факил Сафин Чаллыдан торып республика күләмендә укылырлык журнал чыгару мөмкин икәнлекне дәлилләүгә зур өлешен кертте. Журнал аның оештыру эшчәнлегендә бер баскыч булды.

1993 елны Чаллыда балалар өчен «Көмеш кыңгырау» дигән газета оештыруда башлап йөреп, Ф.Сафин бу өлкәдә дә уңышка ирешә. Шәһәрдә мондый тип матбугат кирәклеге шик уятмый: татар укучысын кечкенәдән тәрбияләүнең мөһимлеге һәркемгә аңлашыла. Ләкин аның үз йөзен булдыру, балаларны әлеге газетаны укырга кызыксындыру һәм күнектерү җиңел түгел. Шулай да эш оештыручылар күзаллаганча килеп чыга: бүген бу басма балалар арасында иң популяр газетага әйләнде.

1996 елның көзендә «Фән һәм мәктәп» журналы басыла башлау чын мәгънәсендә педагогик журналистикадагы яңа сүз кебек тәэсир ясады. Журналның уйланышы— эшләнеше, эчтәлеге беренче саннардан ук киң җәмәгатьчелектә уңай фикер уятып, нәкъ менә укытучы өчен файдалы, кирәкле, мәгънәле матбугат чарасы мәйданга чыгуны искәртте. Баш редактор педагогик журнал чыгаруның яңа концепциясен гамәлгә куйды. Ул үзенең тиражы ягыннан «Мәгариф» журналы белән тигезләште. Ни кызганыч, Ф. Сафин киткәннән соң журнал да әлеге нигезен, яуланган биеклекне саклап кала алмады.

2001 елны Чаллы шәһәрендә «Мәйдан» журналы күренүен күпләр нәкъ менә шушы тәҗрибәнең кабатлануы дип бәяләде. Чыннан да, журнал әдәби-нәфис журналлар

чыгаруның үзгә мөмкинлекләрен барлап уйланылган. Һәр санында укучы өчен яна, кызыклы әдәби әсәрләр белән беррәттән, гаиләнең олысы—кечесе күнеленә хуш килерлек кушымталар, тәнкыйди һәм публицистик язмалар, фәнни тикшеренүләр урын ала. Татар журналистикасында беренче тапкыр буларак аерым язучыларга багышланган саннар чыгару тәҗрибәсе гамәлгә ашырылды. Һәм бик тә уңышлы. Укытучылар, тәрбиячеләр, мәдәният белгечләре өчен менә дигән чыганак булып, язучының өр-яңа әдәби әсәрләре, публицистик язмалары, аның иҗатын өйрәнеп-тикшереп язылган тәнкыйди-публицистик язмалар, библиографик белешмәләр, фоторәсемнәр һ.б. бер санга туплап тәкъдим ителә, ул язучы иҗатына багышланган китапчык кебек кабул кылына.

Гадәттә яңаны булдыручы шәхесләр генә үз артыннан башкаларны ияртергә сәләтле. Соңгысын нәсел билгесе, тамгасы, бүләге, диләр. Шулайдыр. Зыялы, укымышлы тармакның үсентеләре тирә-юньгә үрнәк булып, яңаны тергезеп яши. Фәкил Сафинның да нәсел шәҗәрәсе тирәнгә китә. Әтисе Миңлемөхәммәт ягыннан да, әнисе Нурсания ягыннан да муллалар, Минзәлә-Мөслим-Актаныш ягында мәгълүм күркәм затлар бу нәселдә.

Соңгы елларда үзенең килеп чыгышы белән кызыксынучылар, горурланучылар күбәйде. Әти-әниләренең динле-иманлы булуы, яшереп кенә дини йолаларны үтәп яшәүләре хакында язып чыгучылар да шактый. Ә менә Фәкил Сафинның әтисе Миңлемөхәммәт абзый дин тыелган, кыерсытылган елларда да Әмәкәй авылында мулла булып торды. Шунысын да искәртергә кирәк: авылда муллалык итү шомлы елларда да табигый саналды, берәү дә дини гадәт-йолалар башкаруны тыймады кебек тоела миңа. Һәрхәлдә, әти кешенең муллалыгы бу гаиләдә үскән балаларга дөньяви һөнәр сайларга да, тормышта үз урыннарын табуда да комачауламады. Күрәсең, партбилетлы авылдашларының да мәсьәләгә аек карарга акылы җиткән, рәхмәт аларга! Ә Миңлемөхәммәт абзый балаларга исем кушты, алар үсеп җиткәч, никах укыды, өлкәннәрне соңгы юлга озатты. Авылдагы ничә буын ул кушкан исемне йөртә, ул укыган никахта тату гомер кичерә, балаларына да аннан исем куштыра, никах укыта... Алай гына да түгел: аш уздырылса, авыл халкы Миңлемөхәммәт бабайның акыллы сүзен, нәсихәтен тыңлый, кайгысы булса, аның белән уртаклаша, киңәшкә килә. Хәзер инде авылда Коръән укучылар, дини йолаларны тотучылар аз түгел. Муллалар да бар. Ләкин гомер буе шушы авыл кешеләренә хәер-догада яшәгән өлкән хәзрәтнең үз урыны, аңа хөрмәт тә башка.

Менә шундый гаиләдә, 1954 елның 2 гыйнварында дөньяга килә Ф. Сафин. Әмәкәй сигезьеллык, Күбәк урта мәктәбен тәмамлый, колхозда эшләп кала, армиядә хезмәт итеп кайта. Мөслим районының «Михайловка» совхозында комсомол секретаре, Иске Карамалы мәдәният йорты директоры вазифаларын башкара. Казан дәүләт университетының филология факультетына читтән торып укырга керә.

Әлбәттә, факультет сайлау бервакытта да очраклы булмый. Фәкил яшьтән шигырьләр яза, районда сәләтле, өметле каләм иясе булып таныла. Университетка кергәч, Октябрь авылында укытучы булып эшли башлый, шушы авылда ярын таба, тыйнак һәм акыллы Ләйсирә белән гаилә корып җибәрә. Аннары туган авылы Әмәкәй мәктәбенә тел-әдәбият, тарих укытырга кайта. Мәктәптә иң беренче эш итеп әдәбият түгәрәге оештырып җибәрә, укучыларын район газетасы каршында эшләп килүче әдәби берләшмәгә тарта.

Язучының иҗаты аның холкы белән турыдан-туры бәйләнештә дип раслаучы әдәбият галимнәре бар. Алар әсәрләрне иҗатчының тормыш юлы, характеры, язмышы белән янәшә күзәтүне дөрес дип табалар, әдәбият белемендә мондый тикшерү юлы биографик метод буларак билгеле. Әлеге метод тарафдары булмасак та, холык-фигыль һәм дөньяга караш арасындагы уртаклыкны инкарь итү мөмкин түгел. Ф. Сафинның да әсәрләрендәге төп сыйфатлар, бигрәк тә: җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә усал һәм саллы тәнкыйди бәя бирелү; кешеләрнең холкын нечкә юмор белән, җылы һәм яратып тергезү; үткен, кинаяле, төртмәле сүзләр куллану; образларның бөтенлекле һәм катлаулы бирелешенә, шулар ярдәмендә мәгънә мөмкинлекләрен киңәйтүгә омтылу—авторның кешелек сыйфатларыннан үсеп чыга кебек тоела. Минем хәтеремдә яшәүче укытучы Фәкил Сафин—җинел-

житез хәрәкәтле, үткен телле, кемнен кемлегенә карамыйча, үз фикерен өзеп әйтә торган кыю, тормышны һәм кешеләрне үз идеалларына туры китереп үзгәртәчәгенә ышанган яшь кеше. Үз дигәненә ирешү юлында авторитар методлардан да баш тартмаучы, шул ук вакытта укучылар белән аралашуда күңеленең күптөрле алымнарын нәтиҗәле кулланучы укытучы коллективта башкалардан аерылыбрак тора, шул ук вакытта фикерле, әдәбиятны яратучы укучыларны «үзенеке» итә белә. Һәм иң мөһиме: сиздермичә генә үрнәк булып укучыларын да туры сүзле булырга өйрәткән, иҗат эшенә якынайткан икән. Күпләрнең сәләтен ачкан, күпләргә остаз булган. Моның өчен олы рәхмәт хисләре күңелләребездә яши.

Гадәттә, ир-егетләр авыл мәктәбендә укытучы булып озакка тоткарланмый: җитәкчелек эшенә күчә. Факил Сафин да 1981 елда Октябрь сигезьеллык мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Озак та узмый, аны районыдагы иң зур Татар Бүләре мәктәбенә директорлыкка җибәрәләр. Мәктәптә эшләгәндә дә, «Авыл утлары» исемле район газетасына бүлек мөдире булып күчкәч тә, аның үзсүзлелеге, кыюлыгы хакындагы фикер халыкта ныгый.



*Ф. Сафин китапларының берничәсе.*

Егетнең үзенә дә район киңлекләре генә житми башлый: 1984 елда ул гаиләсе белән Чаллы шәһәренә күчеп китә. Һәм аның оештыручы-җитәкче буларак та, иҗатчы буларак та танылуы Чаллы белән бәйләнгән.

Әдәбиятта Ф.Сафин шагыйрь буларак «сүз башлый»: 1980—90 еллар аралыгында татар матбугатында аның шигырьләре даими күренеп килә. 1994 елны «Аргамак» журналы китапханәсе сериясендә Ф. Сафинның (Факил Әмәк тәхәллүсе белән) беренче шигырь җыентыгы басылып чыга. «Тузганак чәчәге» дип исемләнгән бу китап шигырьләрне, пародияләрне, эпиграммаларны бер «түбә» астына туплаган. Ләкин жанрлар төрләре ягыннан гына түгел, шигырьләрнең идея-эстетик мөмкинлекләре, иҗат манерасы, кулланылган ысул-алымнар җәһәтеннән дә җыентыктагы әсәрләрнең төрле булуы күзгә ташлана. Әйтерсең, бу вакытта шагыйрь каләме сынау уза, үз сукмагын эзли.

Татар шигыре XX гасырның буеннан-буена гражданлык лирикасына өстенлек бирде. Милли күтәрелеш вакыты, туксанынчы еллар исә шагыйрьләрне яна ситуация каршына бастырды: торгынлык чорында ил, халык, милләт язмышы хакында кинаяләп, эзоп теле ярдәмендә сөйләү традициягә әйләнгән булса, сүзенне турыдан-туры әйтү мөмкинлеге туу шигърияттнең эстетик сыйфатына китереп сукты. Бездә ачыктан-ачык язу традициясе юк дәрәҗәсендә икән. Шуна күрә берара поэзиядә публицистик тенденция өстенлек итте. Фикернең эстетик калыпланмаган булуы лозунг һәм такмак тибындагы әсәрләрне вакытлы матбугат битләренә менгерде. Әнә шуның нәтиҗәсе төсендә, татар шагыйрьләре гражданлык лирикасын белдерүдә яңа юллар эзли, мәйданнан төшеп торган алымнарны янарта башладылар.

Ф. Сафинның «Тузганак чәчәге»ндә дә шушы эзләнүләр бик ачык чагыла. «Чакыру», «Безнең көннәр»—халыкка риторик эндәшләр шаукымына иярган әсәрләр. «Дөнья базарына», «Кичә», «Көн һәм төн» кебек, публицистик формага өстенлек биргән, сатира белән янәшә торган һәм фикерне үзенчәлекле эстетик формага төргән шигырьләр дә күп китапта. Менә «...Ком өстендә бәргәләнә балык...» шигыре. Парлы аллегорик образлар: ком өстендә бәргәләнүче балык, ярга аткан дулкын—шигырьнең үзәген тәшкил итә. Балык-милләт, халык, ә инде дулкын—ирек кебек укыла. Халыкны ирек кенә тормышка кайтара ала, дигән идея аңлашыла биредә.

«...«Ирек»—диеп чыктык сәфәр...» шигырендә дә сәфәр, юл, сукмак, упкын

образлары күпмәгънәлелеккә ия. Ләкин биредә образның яна төре—метабола кулланылган. «Теткәләнгән яшел байрак—безнең Хәтер» метаболасы укылыш мөмкинлекләрен киңәйтә. Хәтерне—тарихны байрак итеп күрәшкә күтәрелдек; хәтер—Ислам дине берләштергән чорларны тергезә; дин символы татарларны милләт буларак берләштерергә сәләтле; динне югалту дәүләтне югалту икәнлекне аңлау көрәшкә өнди һ.б.

Аллегорик образлылык күп кенә шигырьләрдә үзенчәлекле сурәт тудыруга, иҗтимагый фикерне фәлсәфи эчтәлекле итүгә юл ача. Мисал өчен «Кар болыты килә» шигырен алыйк. Әсәрдә аллегорик образлар тулы бер рәт хасил итә: кар болыты—афәт; кылыч—юкка чыгару сәясәте; учак—милләт өчен яшәү; каен—милләт; бөре—милләтнең киләчәге. Үзен милләтнең бер улы дип караучы лирик герой яшәү максаты дип шул милләт киләчәген кайгыртуны белдерә.

Аллегорик—символик образлылыкка корылган шигырьләр арасында «Күпер» шигыре үзенчәлекле урын тота. Бу әсәр дә беренче карашка көнитештә очрый торган бер күренешне—язгы ташу вакытында күпер китүне—сурәтли кебек. Ләкин сурәтнең чиктән тыш арттырылып бирелүе, бигрәк тә Арьяк авыл хакындагы сорау, укучыны сискәндерә, СССР таркалуы белән ассоциация уята: «Җан ачысы йөрәкләрне телә, Өмет сүнә гаҗиз калып. Куәт житми, Соңардылар нигә, Арьяк авыл, кая халык?!». Укучым, син дөрес юлда, дигән сыман, лирик герой үз үкенечен шигырьдә сурәтләнгән авыл халкы үкенеч-кайгысын китереп куша: «...Бау бәйләнгән торык калды, Әрнеп-үксеп елый авыл. Ничә язлар саклап калган, Күпер китте, Ай-һай авыр...». Нәтиҗәдә шигырь бөтенләй башка дулкында кабул ителә башлый, күпер аллегорик образга әверелә. Шул рәвешле, нәкъ менә аллегорик образлылык аша шагыйрь эчке мәгънә тудыра, укучыны янадан шигырьгә әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә.

Беренче китап эзләнүләр мәйданы кебегрәк кабул ителсә, Ф.Сафинның 2002 елны дөнья күргән «Сәфәр» җыентыгы инде бүтән. Беренче җыентыктагы күп кенә эзләнүләр бу китапта төгәлләнгән, бөтенлекле әдәби күренеш төсен алган. Шагыйрь публицистик пафостан азат: фикерне турыдан-туры түгел, бәлки сурәтлелек аша җиткерүне кулай таба. Җыентык татар шигърияте үз язу алымы булган көчле шагыйрь килүне исбатлады. Күп кенә әсәрләре белән Ф. Сафин XX йөз башы татар шигъриятендә аваз салган символизм (Дәрдмәнд) традицияләрен янарта, шуның белән бүгенге татар шигърияте өчен мөһим булган алымнарга мөрәҗәгать итә.

Китапта тормышка сокланып язылган шигырьләр аерым урын тота. Көнитештәге һәр күренешкә шатланып күз ташлаган лирик геройның күңел киңлеге гаҗәпләндерә. «Исәнме, кеше!», «Китәсе килә җырда», «Язларда яшик», «Китеп барам», «Кайту» кебек шигырьләрдә киләчәккә, матурлыкка ышану беренче урынга чыга.

Әсәрләрдәге мәхәббәт лирикасы рәслау пафосына өстенлек бирә. «Ничекләр мәхәббәт булмасын», «Сагышларым», «Мәхәббәттә яшел ут юк», «Мин сине әле яратам», «Ә шулай да» кебек шигырьләр сөю хисенең бөеклеген, матурлыгын, садәлеген, лирик геройның күңел сафлыгын югары күтәрә. «Ничекләр мәхәббәт булмасын» шигыре тормыштагы матурлыкны, бәхетне шушы хис белән бәйләп куя. Гомумән алганда, Ф. Сафинның мәхәббәт шигырьләре сөю хакында бер чиктән икенчесенә ташланып, чарасызлык чигенә җитеп җырларга яраткан татар поэзиясендә яңача яңгырый. Чөнки бу шигырьләрдә сөю хакында ихлас сөйләү өстенлек итә. Шушы ихласлык әлеге хиснең бөеклеген, сулаган һава, эчкән су кебек табигый мөһимлеген белдерә.

Мәхәббәт лирикасына караган иң гүзәл шигырьләрнең берсе—«Хатлар язма!» сөю хисенә күңелнең туктаусыз ике чик: ярату һәм югалттым дип курку арасында тирбәнүе буларак бәя бирә. Лирик герой күңелендәге каршылыклы хис аның сөйгәне җанында да шундый ук каршылык ятуны белдерү янәшәлеге ярдәмендә көчәйтелә: «Көтмә» диеп укыйм. Синең өн бу... Ә бераздан: «Сөям» сүзләре...» Шуна җавап төсендә, соңгы строфада тагын бер кат лирик геройның эчтәлектә бирелгән күңел каршылыгы калкып чыга: «Хатлар көтәм... Хәер, бернәрсә дә көтмим. Язмасын ул! Тәнрем, ялварам!».Ул күңел тирбәлешен мәхәббәтнең гомуми канунына әверелдерә.

Шагыйрь Факил Сафин татар поэзиясенә үз сулышы, үз көе, үз сурәтләр системасы белән килеп керде. Ул гражданлык лирикасы өлкәсендә кинаялелеккә, аллегорик образлар ярдәмендә эчке мәгънә, яшерен мәгънә-идея белдерүгә өстенлек биреп, ил-халык язмышына кагылган әсәрләрне фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килә. Бер үк вакытта ачы сатира, үткен ирония, аяусыз тәнкыйть алымнарын да читкә какмыйча, җәмгыятьтәге актуаль мәсьәләләрне калкытып кую, кешенең үз эчендәге каршылыкны экспрессив үстереп барып, шуның ярдәмендә тормышка бәя бирү аның шигъриятендә алгы планда тора.

Нәтиҗә ясап, Ф. Сафинның шигърияттә әзер салган юллар белән канәгатьләнмичә, үз сукмакларын эзләвен, яна алымнар табуын күрсәтергә кирәк. Аның шигъри әсәрләренә югары бәя бирүчеләр, фикер әйтүчеләр булса да, ул әле җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булып кала килә. Ни өчен? Чөнки соңгы ун еллыкта Ф. Сафин үзен җитди прозаик, романнар, хәтта трилогия тудырырга сәләтле әдип итеп танытты. Проза өлкәсендәге уңышлары шагыйрьне «күмеп» китте кебек. Бу аңлашыла да. 1992 елны аерым китап булып басылып чыккан беренче китабы—«Соңгы көз» повесте үк—бестселлерга әверелде. (Хәер, бу урында повестьның 1988-89 елларда язылып, 1990 елны «Таң йолдызы» газетасында басылуын да искәртү урынлы булыр). Әсәрнең прототипларын, язылу тарихын белгән Чаллы-Мөслим-Актаныш төбәге кешеләре китапны кулдан-кулга йөртеп, теткәләнеп беткәнче укыды. Бу китап хакында чыбыксыз телефон колактан-колакка сөйләде, халык аның язылу-басылу фактын Ф. Сафинның шәхси кыюлыгы дип бәяләде. Чыннан да, дистә еллар буе халыкны дер селкетеп торган авторитетларга кизәнү, партия исеме белән чиксез властьне кулларына туплаганнар хакында хакыйкатьне белдерү, системаның асылын ачарга омтылышы ягыннан, «Соңгы көз» әсәре М. С. Горбачев үзгәрешләренә шикләнеп-икеләнеп караган татар мәдәниятендә бомба шартлауга тиң иде. Чөнки 1992 елларда да әле безнең каләм әһелләре, аерым шәхесләрдән кала, бу мәсьәләләрне тирәннән ачарга курка, 37 еллар шаукымын хәтердә тота. Колхозлашу, шәхес культы, системаның кешелексезлеген күрсәтүгә багышланган китапларны рус әдәбиятыннан йотлыгып укысалар да, татар язучылары тормышка-җәмгыятькә яңа күзлектән карауны милли әдәбиятка алып килергә бик ашыкмый иде. Әнә шундый бер вакытта укучыга килеп ирешкән әлеге повесть официозга каршы куелган эчтәлеге белән генә түгел, ә эстетик эшләнеш җәһәтеннән дә публицистик пафостан азат, чын мәгънәсендә әдәби әсәр иде.

Төп сюжет сызыгын хасил иткән каршылык колхоз рәисе Заманов һәм аның тирәсендәгеләр конфликты кебек бирелә. Асылы ягыннан бу—хуҗа һәм кол каршылыгы. Дөрес, Заманов үз кул астындагылар белән генә түгел, югарыдарак утыручылар белән дә нәкъ шундый мөнәсәбәтләрдә тора. Бу кешенең чиксез хакимлеккә омтылуы, башкалар белән уйнап яшәве, үзен чиксез көчкә ия итеп тоюы Заманов—район җитәкчеләре каршылыгы яссылыгында ачыла.

Төп сюжет сызыгы Замановның постта утыру вакытын инли, тоенләнеш—Гөлчирә—Заманов мөнәсәбәте, ә кульминацион нокта төсендә Рәхилә—Заманов бәрелеше, кабатланучы конфликт буларак, бер-берсен көчәйтеп килә. Шулар арасында, вакыйгалар үстерелешендә, Замановның авыл кешеләре, Сабиров, Ясәви, Галимов, Гаделев һ. б. белән каршылыкка керүе күрсәтелә. Чишелеш—Рәхиләнең тормышын үз кулына алырга җөрьәт итүе, яңа мәктәп директорының фәрманны үтәмәве Замановны рухи «үтерә». Халыкны колларга әйләндереп төзелгән, кол итеп яшәтүгә корылган система, кешеләр буйсынудан баш тартуга, җимерелеп төшә, дигән объектив идея киң планда, гомумән советчыл тәртипләргә карата әйтелгән кебек аңлашыла. Уйланманың бу өлеше—әсәрнең иң уңышлы элементларыннан берсе. Ахыр чиктә физик үлем чишелешнең нәтиҗәсе булып кына кала, хуҗа булып яшәү заманы узганлыкка ишарә ясый. Гомумән, әсәрдә мондый табышлар, яңашалекләрне оста уйнату һәрдаим үзен сиздерә.

Әсәр бер геройны—Тимерхан Замановны—тулы ачарлык итеп уйланылган. Каршылыкларның бер ягында чиксез көчкә ия рәис тора, нәтиҗәдә һәр проблема аның белән бәйле һәм власть-халык мөнәсәбәтләренә кагыла. Гөлчирә—Тимерхан һәм шуның нәтиҗәсе төсендә Гөлчирә—Исрафил каршылыгы «хуҗа»ны кеше

хисләрен, бәхетен җимерүче итеп күрсәтә. Исрафил белән Гөлчирә сөйләшүе исә аңа шушы хакимиятне кешеләр үзләре, аларның колларча буйсынып, баш иеп, куркып торуы «тоттырганлыкны» ассызыклый, мәсьәләнең сәбәпләрен калкытып куя: «Ул бүкәнгә чабылган балтага омтылды. Балтаны суырып алырга да... Әмма курку хисе көчлерәк булып чыкты. Колхоз рәисен сындырырлык көч дөньяда юктыр сыман иде...». Нindидер кәнәфи биләгән кемсәгә каршы чыгу—системага каршы чыгу буларак бәяләнү, бу хакимиятнең эреле-ваклы хуҗаларны буй җитмәс биеклеккә күтәрүе шушы күренештә ачыклана.

Заманов—Камил Сабиров каршылыгы хуҗа һәм буйсынмаучы каршылыгы төсен ала. «Яшь директорның эш өчен янып йөрүен игътибарга алмаска тырышты ул, ә теләсә кем алдында үзен бәйсез, иркен тотуын, бәхәскә кереп катгый сүз әйтергә тайчынмавын исә бөтенләй өнәмәде». «Хуҗа» өчен беренче планда эш күрсәтү түгел, бәлки берсүзсез аңа буйсыну, ялагайланып тора. Конфликтның чишелеше—директорны кудыру вакыйгасы—әлеге системада буйсынмаганнарны ничек сындырып булганлыкка бер мисал кебек китерелә.

Тимерхан—Фәнис, Тимерхан—Илгиз каршылыклары рәиснең кешеләрне түбәнсетеп тәм табуын, үчле һәм явыз булуын раслый. Һәр «кол» мисалында, үзен өстен,—башкаларны үтенеч белән килүчеләр баскычына куеп, моның өчен яңадан—яңа «уеннар» уйлап табып, Заманов «чиксез властька ия хан» титулын саклый, һәр юлы яңабаштан яулый, үз «режиссурасына» соклана. Тимерхан—Ясәви каршылыгы исә оста психолог «кулы» белән башкарыла, кешеләрне сындыру, кол итү механизмын ача. Хуҗаның кешеләр язмышын җимерүдән тәм табуы абсурд чигендә тирбәлә. Бу абсурд реаль тормыштан үсеп чыга, чынбарлык кебек гадәти кабул ителә: аның фаҗигалелеге дә шунда.

Мондый мисаллар әсәрдә шактый. Колхозның баш белгечләре барысы да әлеге каршылыкны үткән. Буйсыну колхозда ниндидер тәртип-гадәтләр төсен алган. Һәр көн иртән биштә колхоз идарәсенә җыелу—шундыйларның берсе. Ачы ирония белән сурәтләнгән бу процесс бер максатка—колларның һәр көнне хуҗасына тугрылыгын исбатлауга кайтып кала. Икенче яктан, бу йола патология, акылдан язган кешенең авыру аңында туган фантазияләрне тормышка ашыру төсен ала. Аның башкалар, тирә-яктагылар тарафыннан гадәти, табигый кабул ителүе әлеге патологиянең нормага әйләнгәнлеге хакында сөйли.

Замановка бирелгән иң тискәре бәяләр баш белгечләр уйлары аша укучыга җиткерелә. «Рәис кешеләргә рәхимсез, үч тотучан. Фәйзи баштагы елларда Тимерханның үзеннән түбәннәрне нахакка рәнҗетүенә, бер дә юкка читкә кагуына эчтән генә сыза иде, әмма каршы әйтергә батырчылык итмәде, тешен кысып түзде һәм, ниһаять, тора-бара бу хәлгә тәмам ияләнде. Ул шуңа инанды: каты куллы булмасаң, сине чүпкә дә санамыйлар икән». Яки: «Сабировка яңалык түгел—«Алга»да нинди гөнаһ-гаеп эшләнмәсен, зурмы-кечкенәме, җинаять эше кузгатылмыйча калмый. Милиция юлын таптамаган кеше сирәк колхозда». Соңгы җөмлә шулай ук халыкны тулаем җинаятьче хәленә төшергән хуҗага төбәлгән. Сабиров авызыннан әйттерелгән тагын бер хакыйкать: «Шуны аңламыйм—колхоз рентабельле, тик никтер авыл кызганыч хәлдә кебек. Тыштан карасаң бар да әйбәт. Юллар әйбәт, ихаталар төзек, әмма авылга җан өрәсе бар. Һәр өч йортның берсендә—гүр иясе булуларын көтеп гомер кичерүче ялгыз карт белән карчык яши, ә берсе буш—хуҗалары киткән. Тик берсендә генә колхозда эшләүчеләр көн күрә». Күрсәткечләр ягыннан алда саналучы «Алга» кешеләрнең диктаттан качып китә баруын билгели, ил күләмендә авыллар бушавының бер сәбәбен күрсәтә. Хуҗа-кол мөнәсәбәтләре урнашкан колхозларда әлеге диктатка буйсынмадыңмы, эш сорап барырга башка хуҗа юк. Китәргә мәҗбүрсең.

Әлеге хакыйкатьне авыл халкы үз җилкәсендә татый. Колхозчыларның берсе Шәмсетдин агай сүзләре мондый яшәү тәртибен тулы ача: «Урам башындагы ерганакка да күпер салдырмыйлар хәтта. Янәсе, күпер булса, җитәкчеләргә сиздермичә генә урманга—мазарга китүебез бар. Ишек алдына кайтып керүебезне дә күрми калачаклар. ...Суарда халык өйрәнгән: яшисең килсә, күршеңне сат... Авызыңны үлчәп ачмадың, и вәт сүзең җитәкчеләргә барып ирешә дә. Аяк астына

су керде, значит. Әйтик, печән бүлгәндә, йә башка шундый чакта сине «оныталар». Инде пенсионерларга тиешле центнер ярым икмәгенне дә бирми җәфаласалар, яисә ак он тегермәненә баручылар исемлегенә керми калсаң—эшең бөтенләй харап. Үзебездә Заманов ак он тегермәне төзетмәде. Айга ике тапкыр ул раслаган исемлек белән күрше колхозга тегермәнгә барабыз» һ.б.

Әлеге ситуацияләр бер җепкә тезелеп, Замановны характер буларак кына түгел, бәлки советчыл тәртипләр тудырган хуҗа тибы кебек ача. Шушы тип ярдәмендә язучы совет идеологиясенә, системага бәя бирә, аның хуҗа-кол схемасы чикләрендә яшәвен, кешене, халыкны куркак, мескен, курчак хәленә китерүен билгели.

Заманов—заман тудырган кеше, илне тупикка китергән сәбәпләрне ачып салырга ярдәм итүче тип. Язучының героена сайлаган исем-фамилиясе символик мәгънәгә ия. Автор Замановны тарихи кеше, совет дәүләте белән бәйләнгән кеше, заманның тимердәй ханы булырга дәгъва итүче кебек сурәтли. Аны шушы система икейөзле һәм мәкерле ясаган. Хатынының иртә үлеме, малаеның юлдан язуы хуҗаның әнә шундый холык-фигыленә, гамәл-тәртибенә барып тоташа. Асылда, киләчәге булмаган бу кеше үзе дә, аның кул астында эшләүчеләр дә—бәхетсезләр, шушы илкүләм идеологик ялганның корбаннары. Повестьның исеме дә әсәрнең субъектив идеясе белән ассоциацияләшә: әйтерсең лә, язучы системаның соңгы күзен, иҗтимагый-тарихи хәрәкәтнең ахырына, соңгы ноктасына якынлашуын искәртә, аның корбаннарын берәм-берәм күз алдыннан уздырып сызлана. Әсәр кешеләрне официаль идеология тудырган иллюзияләрдән, ялгыш кануннардан арындырырга, азат итәргә омтылып язылган.

«Соңгы күз» повесте татар әдәбиятында социалистик реализм тудырган унай геройга (Тимерхан Заманов—алдынгы колхоз рәисе, эшне бар нәрсәдән өстен куючы, совет идеологиясенең төп кануннарын үзләштергән, корычтай-тимердәй нык характерлы, каты куллы кеше буларак, татар социалистик реализм әдәбияты мәйданга чыгарган уңай геройларның игезәге) башка яссылыкта күз ташлап, укучының аңа мөнәсәбәтен үзгәртү аша совет хакимиятенең асылы хакында уйланырга мәҗбүр иткән беренче әсәрләрдән булды. Көчле кеше фаҗигасен күрсәтү мотивы язучының башка эпик әсәрләрендә дә лейтмотив булып сузылып бара. Авторның көчле иҗтимагый тәнкыйте укучы мөнәсәбәтен формалаштыручы үзәккә әверелә. Полифония алымына—геройлар булып сөйләүгә, аларның уй-кичерешләрен турыдан-туры сурәтләүгә мөрәҗәгать итү—әсәрнең ышандыру көчен арттыра.

Ф. Сафин каләме укучыга тәкъдим иткән икенче эпик әсәр «Гөлҗиһан» сайлаган әдәби материалы, стиль хасиятләре ягыннан беренче повестьтан нык аерылып тора. Татар повестенең иң матур традицияләрен дәвам итеп, язучы шигъри-эмоциональ хикәяләүдә кеше җанының олылыгын, тирәнлеген күрсәтүгә омтыла, гади авыл хатыны язмышы мисалында гомумән кеше һәм кешелеклелек, җәмгыять һәм кеше мөнәсәбәтләре, бер заманда да үзгәрмәс-югалмас кыйммәтләр хакында уйлана.

Әсәр төп герой Гөлҗиһан гомерендәге 25 еллык вакытны инли, аның унсигез яшьлек кыздан кырыкның өске ягына чыккан хатынга әверелү юлын күзәтә. Автор үзе үк тормыш сынаулары, авырлыклар тулы бу язмышның гадәтилеген, бик күп язмышларның берсе булуын һәрдаим искәртеп тора. Мәсәлән, берничә тапкыр серле карчык җыры кабатлана:

*Бер кайгыга батам, бер юанам—*
*Миндәйләр күп дөнья йөзендә...*

Җыр гомумиләштерүнең бер чарасына әверелә. Әйтерсең, шуның ярдәмендә язучы, Гөлҗиһан тормышы кебек, гомумән кеше гомере кайгы-хәсрәтләргә, авырлык-сынауларга бай икәнлекне, намусына каршы килмичә, игелек кылып яшәгән кешенең җан тынычлыгы таба алуын ассызыклый. Бу яктан Гөлҗиһан образы күпмедер күләмдә беренче повестьтагы Камил Сабиров образы белән авазлаш кабул ителә.

Гөлҗиһанның язмышы күпләрнекенә охшаш. Яратмаган кешегә—Әухәткә—

кияүгә чыгу, хыянәт ачысын татып, ялгыз бала үстерү, авыру бала хәсрәте, аннары— оның тәрбияли башлау... Шушы 25 ел гомер «бүген түзәргә кирәк, иртәгә бар да яхшы булыр» дигән өмет белән узган. Әсәр тәмамланганда да Гөлһиҗан салынача к яна матур өй, Шамилнең киләчәге хакындагы өмет белән кала. Шулай итеп, төп сюжет сызыгы—Гөлҗиһанның яшь кыздан әбигә әверелүенә кадәр аралыкны колачлаган, тормыш авырлыкларын узып та, кешелеклелекне саклап калу тарихы ул. Бу тарихны хасил иткән төп каршылык та Гөлҗиһан һәм тормыш авырлыклары кебек аңлашыла.

Гөлҗиһан, үзе дә аңлап бетермәстән, яратмаган, җаны тартмаган Әүхәткә кияүгә чыга. Бу адымга аны әтисенең үзсүзлелеге дә, Әүхәтнең кыз күңелен аңламавы да, үги әнисенең рәхимсезлеге дә этәрә, әлбәттә. Ләкин төп сәбәп аларда түгел. «Гөлҗиһанны берниндиi көч тә Әүхәткә кияүгә чыгарга мәҗбүр итәр кебек түгел иде. Ул үзенең ахыргача каршы тора алуына ышана да иде кебек хәтта. Әмма Әүхәтнең күз карашы аны әллә нишләтте дә куйды, аның үҗәтләнеп каршы торырга маташуын күзгә күренмәс серле көч юып алгандай итте. Үзе бар тәне-җаны белән каршы, үзе елый, үзе өздереп «юк» дип тә әйтә алмый—арурак киемнәрен юллап, киенергә җыена башлады. Шушы кызгану хисе уянган мәл иде кызның йөрәгендә. Мәңгелек үкенечкә салыр хис...».

Повестьны аңлауга ачкыч булган шушы урында автор-хикәяләүче кызгану хисенә мөнәсәбәтле рәвештә кешеләрне икегә бүлә: «берәүләрдә була андый хискә сәләтлелек, икенчеләрдә—юк», һәм әсәрнең буеннан-буена без геройларның кызгану хисенә сәләтлеме-түгелме икәнен ачыклыйбыз, кызгану яки кызганмау нәрсәгә китергәнлекне күрәбез. Автор кешеләрне шушы хис аша бәяли. Гөлҗиһаннарның әниләрен авыру килеш эшкә чыгаручы, кызгана белмәгән Сәйдә кызның үзен дә аяп тормый. Әүхәт тә, яратмаганын белә торып, Гөлҗиһанга өйләнгәндә дә, авырлы килеш хатынын ташлап укырга киткәндә дә, хатыны өстенә Фәймәне алып кайтканда да Гөлҗиһанны кызганмый. Алай гынамы, Рәкыйп имгәткән малаена карата да аның күңелендә бер бөртек кызгану юк. Әлеге хистән мәхрүм Сәйфи Гыйльметдин күңеленә көнләшү корты салса, соңрак инде Гөлҗиһан тормышын тәмугка әйләндергәндә дә, Әхнәфне гарипләндергәч тә үзен гаепле санамый. Йә булмаса сынык күңелле Әхнәфне иләсләндергән, соңыннан баласын ташлап качкан азгын Әфүзә. Аның күңелендә дә кызгану юк: булдыра алса, үз баласы өчен өй салырга җыйган акчаны, авыздан өзеп саклаган маяны урлап китәсе... Күпме бәхетсезлек, кайгы китерә кызгана белмәүчеләр?!

Ләкин шулар белән янәшә кызгана белүчеләр бар. Сәйдәгә каршы куелган, Гөлҗиһанның әтисе үлгәндә очраган кизү санитарка белән табиб, яки Әхнәфкә операция ясаган табиб, кызгана белмәүче ире Әүхәт һәм яшьлек дусты Фәймәнең антиномик пары Бәдри абзый белән Шәмсия түти шундыйлардан. Гомумән, автор кызгана белүче һәм белмәүчеләрне охшаш ситуацияләргә куярга, авырлык-сынау алдында калдырырга ярата. Моңа кадәр гаиләсенә игелек күрсәткән Шәйхаттар авырып киткәч, хатыны һәм балалары аннан баш тарта. Гөлҗиһан исә абыйсын тәрбияләп, соңгы юлга озата. Әфүзә сау-сәламәт баласын ташлап китә. Авыру улым дип яшәүче Гөлҗиһан ул баланы бага башлый.

Әсәрдә укучыны кызыксындыруның бик үзенчәлекле алымнары табылган. Мәсәлән, әсәрнең фабуласы. Хикәяләү керештән башланып китә, ул исә—төп сюжет сызыгындагы чишелешнең ахыры. Аннан соң сюжетның гадәти тәртибе әсәрдәге вакыйгалар белән таныштыра да, чишелешнең башланган өлешендә туктап кала. Повестьны укып чыгуга, чишелешнең ахырын—өч ярдәмче сюжет төененең дә сүтелгән урынын янадан бер кат күздән кичерү теләге уяна. Бу теләк әсәрнең беренче битенә әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә.

Әсәр башында автор куйган сорау да шактый бәхәсле: «... Дөньяда иң көчле хис—мәхәббәт хисе, диләр. Әмма кызгану хисе аннан да көчлерәк түгел микән?» Повестьны укыганчы бу сорауга: «Юк, мәхәббәт көчлерәк, ул кешене канатлы итә, биеккә күтәрә, көчле ясый...» дип җавап бирәсе килсә дә, әсәрне укыганнан соң инде автор артыннан: «Кызгану—кайберәүләргә генә бирелә торган табигать бүләге. Кызгана белгән кеше игелек кыла, ярата, башкаларны бәхетле итә ала.

Кызгана белү тормыш авырлыкларын кичеп тә, олы җанлы, йомшак күнелле, кешелекле булып калыр өчен кирәк»,—диясе килә башлый. Повестьта автор кешене югары күтәрә, кеше итә торган кызгану хакында бәян итә.

Повестьның әдәби эшләнеше, поэтикасы хакында сүз алып барганда, реалистик традицияләрнең көчле икәнлеген искәртми булмый. Татар әдәбиятының бу юнәлеше кеше образларын үзәккә куя, әсәрдәге тормыш моделе нигездә характер яки типлар ярдәмендә формалаштырыла. Бу әсәрдә дә шулай.

Үзәккә куелган герой Гөлҗиһан—көчле рухлы, җаваплылыкны үз җилкәсенә алырга курыкмый торган хатын-кыз. Ул милли әдәбият өчен традицион, авторның уңай идеалы дәрәҗәсендә сурәтләнгән. Язучы аның ике сыйфатын: кызгана белү һәм гел яхшылык кына эшләү сәләтен калкытып куя.

Ф. Сафинның «Биек тауның башларында» дип аталган романы да повестьлар кузгаткан проблемаларга кагыла. Алай гына да түгел, кайбер мәсьәләләрдә инде башланган сүзне дәвам итә. Әсәр татар әдәбиятында Рәсәй-Чечня сугышын яктырткан, шушы фонда милли проблематиканы калкыткан күләмле беренче әсәр булды. Романда ике төп сюжет сызыгы бар: берсе Раушания белән Шәфкатьнең мәхәббәт тарихы, икенчесе Рәсәйнең Чечняга каршы башлаган сугышына мөнәсәбәт үзгәрү тарихы. Аларны үзәк герой Шәфкать образы бер төенгә бәйли һәм фаҗигале, иҗтимагый сюжет сызыгы да, мәхәббәт һәм гаилә хакында сөйләүче вакыйгалар да бергә чишелә.

Хәер, алар бер ноктадан башланып та китә. Нәни генә прологта кешеләр арасында тигезлек булмау хакында сүз алып барыла. Уй-гамьнәре, төс-кыяфәтләре, эш-гамәлләре ягыннан тигез булмаган кешеләр кебек үк, милләтләр арасында да тигезлек юк дип, автор шушы хәлләрне ике яссылыкта күрсәтәчәген искәртә. Алдагы әсәрдәге кебек үк, тигезлек дигән кыйммәт фәлсәфи сөйләшү объекты итеп күтәрелә.

Авылга медпункт мөдире булып Раушания килүдән башланып киткән беренче сюжет сызыгы лирик чигенеш ясап 19—20 еллар элек Хәкимәнең кияүгә чыгуы, бала табуы һәм бүгенге авылдагы тормыш турында сөйли. Хәкимә белән Раушания арасындагы характерлар каршылыгы белән янәшә, авыл яшьләренә бәйле заман проблемалары ачыла. Термос, Тарель, Фрак кебек егетләрнең язмышы—бүгенге авыл, гомумән, бүгенге җәмгыять фаҗигасе икән, ләбаса. Эшсезлектән кангырап, гаделсезлекләрдән аптырап йөрүче яшьләр явызлана, сугыш чукмарына әйләнә, эчүгә сабыша.

Ләкин бәхетсезлекне булдырмый калу юлы да бар! Раушания белән Хәкимә мөнәсәбәтләре нәкъ шуны күрсәтә. Башкаларны аңларга тырышып, ярдәмләшеп яшәргә кирәк, шул вакытта эш фаҗигагә китермәс, ди автор.

Укучыга җиткерергә теләгән фикере белән бәйле детальләрне кабатларга ярату, охшаш-игезәк ситуацияләр тудыру бу әсәр мисалында да аермачык. Мәсәлән, Раушаниянең әтисе ярдәм булмаганлыктан җан биргән. Әнисенең Раушанияне авылга җибәрү сәбәбе дә шул: бәлки, авыл җирендә кешеләр игелекле, вөҗданлы булып калгандыр, анда рухи кыйммәтләр бөтенләй үк югалып бетмәгәндер дигән өмет. Тигезсезлек, аның сәбәпләре хакындагы Тәкый агайның, Раушания әнисенең сүзләре һәм уйлары картинаны тагын да бөтенрәк итә.

Икенче сюжет сызыгында милләтләр арасындагы тигезсезлекне күрсәтү дә, асылда, җәмгыятьтәге бүгенге проблемаларга барып тоташа. Армиягә эләккәч тә, Шәфкать башыннан кичкәннәр тигезсезлекнең нинди нәтиҗәләргә китерүен ача. Авторның осталыгы хикәяләүне каршылыкка кергән якларның һәрберсе исеменнән алып барырга мөмкинлек биргән. Без Шәфкать позициясен аңлап, аның иманы, горурлыгы, намусы нык булуны эчке бер теләктәшлек белән күзәтсәк тә, автор Хасистовның яки Головастиковның ситуациягә нинди күзлектән каравын, ниләр уйлавын да укучыга җиткерә, алар булып та «сөйләшә». Шушы алым тигезсезлекнең ни өчен конфликтка илтүен аңларга ярдәм итә. Һәркем үзенчә хаклы икән бит! Кемдер үзен башкалар гомерен куркыныч астына куярга, башкалар канын коярга хокуклы саный. Мондый явызлыкка һәм ерткычлыкка каршы торыр өчен мәрхәмәтле кешеләр ярдәме кирәк. Шәфкать гомерен Головастиков белән каршылыкта Веремеев ярдәме коткарып кала.

Милләтара сугышларның төп сәбәбе—тигезсезлек. Бу явызлыкны туктатуның туры юлын язучы башка милләтләрнен ярдәмендә күрә. Шәфкать белән Раушаниянен чеченнәргә булышлык итә башлавы—шуның бер дәлиле.

Җәмгыятьтәге тискәре күренешләр хакында сөйләгәндә автор усал һәм әче телле хикәяләүчегә әверелә. Сүз сөйләүдән ары китмәгән «милли геройлар»мы ул, кеше язмышына битараф военкомат хезмәткәрләреме, авыл кешеләренә аяк чалучы авыл советы эшчеләреме—һәммәсе автор тарафыннан сатира утына алына. Мондый геройлар өч яктан бәяләнә: автор аларны ситуация эчендә күрсәтә, икенче бер герой авызыннан бәяләтә, хикәяләүче буларак үзе дә мөнәсәбәтен белдереп уза.

Гомумән, язучының һәр җөмләсе төгәл образлардан җыелган: фразеологизмнар, чагыштырулар, метафорик гыйбарәләр сүз бара торган һәр хәрәкәтне, һәр геройны, аның халәтен, торышын, холкын, хәтта аерым бер моменттагы уен-фикерен күз алдына китереп бастыра. Күптавышлылык (полифония), әсәрне берничә башлангыч белән баета. Бер яктан, бигрәк тә хикәяләүче мөнәсәбәте өстенлек алганда, юмор һәм сатира шактый калку сизелә. Юмор кешеләр арасындагы җылы һәм самими мөнәсәбәтләргә карата кулланыла. Сатира, нигездә, җәмгыять һәм кешеләрдәге тискәре якларга каршы юнәлтелә.

Романдагы тау һәм елга образлары, әсәр ахырында әйләнеп киткән карчыга символы, табигать бирелеше лирик башлангычны көчәйтеп килә. Табигать образларын тудырганда автор эпик әсәр язучыдан шагыйрьгә әверелә: «Әнә еракта боргаланып-боргаланып ятканы Дусай елгасы инде аның. Ул шукланып туймаган сабый балага охшаган. Әле тау итәгенә үк килеп сыена, әле эзләп табыгыз, мин сездән качам, дип әрәмәлеккә кереп югала, көтмәгәндә тагын ялтырап килеп чыга һәм бөтенләй башка якка—җәйләү тугаена табан юл ала. Аннан кинәт нәрсәдер исенә төшергәндәй, теләр-теләмәс кенә янә тау ягына каерып әрәмәлеккә юл тота». «Каралты-куралар артыннан тау астына табан яшел толымнар—бәрәңге бакчалары таралып төшкән. Алар иртәнге кояш астында мыштым гына йоклап яткан кебек күренәләр». «Зәңгәрсу офыкларга табан, төрле рәвешле көзгеләр ташлап калдырганнармыни—алары Ык күлләре бугай инде. Дусай суы, Усаклы авылы тирәсендә уйнап арганнан соң, кинәт кенә тураеп, тирә-ягына күз сала да, кабаланып, Ык ягына йөгерә башлый. Кин болында көмеш каеш кебек сылу гәүдәсе генә сузылып кала». Шундый сурәтләр урын һәм вакытны белдереп кенә килми, геройлар күнеленә аваздаш булып кына калмый, алар фәлсәфи фикерне ныгыта. Гаҗәеп гүзәл табигать, аның самимилеге һәм терелеге шушы табигатьнең бер кисәге булган кешене һәм җәмгыятьне дә камилләшергә чакыра кебек.

Аерым бер очракларда табигать бирелеше символик мәгънә белән өретелә. Менә Чечен җирендә таң ату күренеше. «Бер карыйсың, бөтен таулар тезмәсе ялкынга чорналган сыман. Бер таудан икенче тауга кып-кызыл ут үрмәли. Ана каршы ниндидер сихри нурлар биешеп йөгерәләр. Ул да булмый, сукмак юлчыларны түбәнгә әйди. Кояш нурлары кинәт юкка чыгалар, фәкать ике тау арасында кош оясы кадәрле яктылык талпына. Бу инде кояшның үзе түгел, ә Кояш улы сыман. Шулкадәр тере, хәрәкәтчән, берәр упкынга егылып төшеп харап булмасын дип, аны тау артында кемдер эләктереп тота кебек. Кояш малае шукланып, каптырып алган көчле куллардан ычкынырга теләп тартыша, чәбәләнә. Шул кечкенә яктылык иясе тәки үҗәтләнеп иркенгә чыга, кинәт тау өстенә менеп кунаклый, бөтен тирә-якны балкытып көлә, җирдәге һәр тереклек иясен шаярта, нурлары белән иркәли башлый». Әлеге картина чечен халкы язмышына, бүгенге һәм киләчәгенә киная итеп тудырылган, андагы тау, кояш образлары символлар дәрәҗәсендә укылалар.

Ф. Сафинның язучы буларак осталыгы традицион алымнарны камилләштерүдә. Әсәрнен төп геройлары—Шәфкать белән Раушания, алар арасындагы сокландыргыч мәхәббәт, авыл кешеләре арасындагы самими мөнәсәбәтләр сәнгатьчә югарылыкта тасвирланган. Мәхәббәт хисен тасвирлаудагы—лириклык, авыл тормышы сурәтләрен бирүдәге юмор әсәрне мавыктыргыч итә. Ф. Сафинның бу романы татар авылының үткәнен сагынучы, элеккеге матурлыкның югалуына сызланучы бер төркем әсәрләр биргән татар әдәбиятында үз булып янгырады. Ул бүгенге авылда да электән килгән матурлыкның: кеше күнеле, әхлагы, холык-фигыле, тәрбиясе

гүзәллегенең, кешеләрнең көнкүрешендәге тәртиплелекнең, үзара мөнәсәбәтләр сафлыгы-чисталыгының, традицияләр, йола-гадәтләрнең—югалмаганлыгын раслады. Әсәрдәге һәрберсе үзенчәлекле, бөтенлекле характер булып ачылган Хәкимәләр, Тәкыйләр генә түгел, яшьрәкләрдән Раушания һәм Шәфкатьләр дә милли геройлар кебек кабул ителә.

Миллилек әсәрнең уйланмасына ук салынган. Чечня вакыйгаларына карата булган автор мөнәсәбәтенең рәсәйкүләм позициягә капма-каршы бирелүе татар милләте вәкиле мөнәсәбәте буларак аңлашыла. Нәкъ менә татар яшьләренә хас тыйнаклыкны, самимилекне, эчкерсезлекне үзенә туплаган Шәфкать белән Раушаниянең кулларына корал тотып кыерсытылган милләт ягына басу тарихы шулай ук символик мәгънәгә ия. Биредә «табигый тормышта, мәхәббәт белән, туган җирне кадерләп, балалар үстереп яшәргә тиешле яшьләрне иҗтимагый гаделсезлекләр, тигезсезлекләр көрәшчегә әйләндерә» дигән субъектив идея чалымлана.

Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» трилогиясе XX гасырны тетрәткән үзгәрешләрне игътибар үзәгенә куя һәм аларга ике яклы: кешелек тарихының бер сәхифәсе буларак һәм милли тарихның бер буыны итеп күз ташлый. Романда XX гасырның беренче чирегендә булып узган тарихи вакыйгалар тергезелә. Инкыйлабтан соңгы авыр еллар, гражданнар сугышы, ачлык, колхозлашу һәм репрессияләр—егерме еллап вакыт инләнә. Үзәккә Әхмәтсафа Дәүләтъяров—татар тарихында билгеле шәхес куелган. Аның дөньяга карашы формалашу, чын күңелдән ышанып яңа тормыш төзүгә катнашуы, зур исем-дәрәҗәләргә ирешүе һәм шушы системаның канлы тегермәнендә юкка чыгарылуы бәян ителә. Автор үз героен, барыннан да элек, фаҗигале язмышка ия, яңа тормыш төзү идеясенең корбаны булган татар кешесе итеп сурәтли. Бер яктан, аның гаярь, көчле шәхес булуы ассызыклана. Икенче яктан, Октябрь инкыйлабы казанышларын милләткә хезмәт иттерергә, эш-гамәлләре белән татар халкының язмышын үзгәртергә омтылучыларның, шушы максаттан яңа хакимияттә эш башына килгән татар зыялыларының берсе икәнлеге һәрчак күз уңында тотыла. Зыялылар фаҗигасе трилогия ахырында Ш. Усманов авызыннан әйттерелә: «Гаепме? Бар аңысы. Без революциягә сукырларча ышандык. Без тарихның табигый агышына каршы гамәл кылуда турыдан-туры катнаштык, кан, үле гәүдәләр өстендә яңача тормыш төзергә маташтык. Бу иң зур ахмаклык булган. Мин моны соңрак аңладым, таш капчыкка эләккәч, уйларга вакыт бар менә. Гомернең кыйналудан калган өлеше уйланып кына үтә. Ата-бабаларыбызның йолаларына төкереп, үзебезчә әхлак әвәләдек, сәясәт укмаштырдык, денсез-имансыз кавемгә әйләндек. Шушы хәлдә үзебезне гаепсез итеп, акланып маташу зур хата, Дәүләтъяров. Болар барысы да безнең акыл, безнең йөрәк белән эшләнде. Без үстергән үсентеләр агулы җимеш бирделәр. Аларны без ашамыйча, кем ашасын!»

Бу гаять тә аяныч нәтиҗә—XX гасырның иң олы фаҗигасенә бәя дә, бары тик XXI гасыр биеклегеннән торып кына аңлау мөмкин булган хакыйкать тә, язучының Ә. Дәүләтъяров язмышы мисалында тарихи хәлләргә яңача-заманча каравы да!

Трилогиянең һәр романы мөстәкыйль. «Сакмар егете» дигән беренче кисәк Әхмәтсафаның егет чагын инли. «Өермә» 1930—37 елларны колачлый. «Ялган тәрәзәле йорт» дигән өченче китап 1937—38 еллар фаҗигасен үзәккә куя. Һәр романга эпиграф сайланган, алар кисәкләрнең исемнәре белән ассоциация тудыра һәм субъектив идеяне калкытып килә. Эпиграфтан тыш, китапларны аллегорик аңлана торган табигать сурәте башлап җибәрә. Табигать трилогиядә гел «күренеп килә», еш кына ул илдәге атмосферага авазлаш итеп бирелә. Төп сюжет җепләре әсәрнең өч китабы аша да үтә. Иҗтимагый сюжет сызыгы инкыйлаб алып килгән яңалыклар һәм яшьләр каршылыгына нигезләнә. Икенчесе—шәхси сюжет сызыгы—шуның бер тармагы кебек күзаллана: ул—Әхмәтсафаның тормышы тарихы. Каршылык Әхмәтсафаның күзаллавы, хыялы, омтылышы һәм чынбарлык бәрелеше кебек даими кабатланып, әсәрне буеннан-буена озатып бара.

Романда, аерым-аерым характер итеп эшләнгән көчле образлардан тыш, күп кенә ярдәмче образлар урын алган. Аларның бер өлеше—татар мәдәниятендә

мәгълүм шәхесләр. Муса Җәлил, Һади Такташ, Шәриф Камал, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Авзал Таһиров, Заһид Шәркый, Шамил Усманов, Максим Горький, Салих Сәйдәшев һ.б. бик күпләрнең портреты тәкъдим ителә. Язучы бүгенге укучыга татарның талантлы шәхесләренең ничек итеп яңа тормыш төзү идеясеннән очкынланып киткәнлек сәбәпләрен дә ача, әлеге талантларның характер һәм дөньяга караш үзенчәлекләрен дә күрсәтү максаты куйган, аңа ирешкән дә. Мондый максат куелу бүген, тарих дәреслекләре битләрендә 1917 ел идеологиясен кабул итүнең негатив бәяләнүе шартларында, аерым әһәмияткә ия: чор атмосферасын аермачык күзалларга да, милләт зыялыларының ни өчен инкыйлабка зур өметләр баглавын билгеләргә дә ярдәм итә ала. Бигрәк тә яшьләр: Мифтах хәлфә кебек укымышлы мөгаллимнәрдән белем һәм тәрбия алган Әхмәтсафалар, бунтарь холыклы Җамаллар, очкындай Ш.Усмановлар—талантлы, көчле-булдыклы, акыллы, саф күңелле буын соклану катыш үкенеч белән сурәтләнә. Аларның эш-гамәлләренә, уй-хыялларына артык зур игътибар бирү алмагач чәчәкләре символының нәкъ менә яшьләр кебек аңланылу вариантын калкытып куя.

Тарихи шәхесләр, аларның язмышлары тагын бер җыелма образ—заман образын тудырырга ярдәм итә. Заман—1917 елгы инкыйлабтан соңгы, яңа тормыш төзү дәвере. Ул—кешеләр күңелендә зур өметләр уяткан, аларны олы эшләргә дәртләндергән вакыт. Яңа матур тормыш төзү идеясе яшьләрне берләштерә, талантларын ачарга булыша. Ләкин шул ук заман үзе мәйданга чыгарган яшьләрнең башына җитә, аларны юкка чыгара. Аерым шәхесләр язмышына күз ташлау, сәяси материаллар аша язучы ил тарихына бәя бирә, большевиклар алып барган сәясәтнең киләчәге булмавын, аның җәмгыятьне, милләтне таркатуын ассызыклый. Автор гаменең объекты булып заманның фаҗигасе калка.

Заманга хас күп кенә сыйфатлар, кимчелекле яклар яңа тормышка аек күз белән карый алган укымышлылар авызыннан әйттерә. Мәсәлән, Гомәр абзый Әхмәтсафага болай ди: «Үзең дә аңлап бетермәстән, төрле ызгышларга юлыгып, яшьтән җегәреңне юк дауларга әрәм итмә, дим. Синең тирәдә шома кешеләр күп йөрер. Булдыклы затларны ярата алар. Җәмәгать эшлеклесе дигән булып, укуыңны онытып, башкалар эшләргә тиешле эшне син майтарып йөреп, ахыр чиктә, надан калып, кеше хуры булып бетүеңнән дә куркам. Җәмәгать эше дигән нәрсә әрсез алабайларга киләчәктә түрәлеккә юл ача. Белемле, кулыннан эш килгән асыл затлар түгел, сүз сөйләп шомарган фәхеш бәндәләр менеп атлана тәхеткә бу заманда. Синең кебек егетләрне сытып кына үтәчәк алар. Сак бул, энем, куркыныч дәвер килде сезгә...». Бу сүзләр романда тасвирланачак хәлләрне алдан күреп әйтелгән булып чыга. Мондый урыннар үз чорында ук яңа идеологиянең, аның нигезенә салына торган системаның фаҗигагә китерәчәген аңлый алган кешеләр булганлык хакындагы субъектив фикерне ассызыклый. Бу җәһәттән, татар тарихындагы күз яшьле тап булып кала килгән ТКУ белән бәйле бүлекләр, монда алып барылган бәхәсләр, Айхенвальд—Вольфович позицияләрен шактый тулы ачу, Дәүләтьяров—Сәгыйтов каршылыгы уңышлы эшләнгән. Язучы чор атмосферасын да тулы күз алдына бастыра, ни өчен ТКУда укыган зыялыларның 1937 ел тегермәнендә юк ителү сәбәбенә төшеп җитә, шуны укучыга «күрсәтә» алган. ТКУ га кагылышлы өлешләр, бухаринчыларга мөнәсәбәт белән кушылып, икенче китапны сызып бара, бер үк вакытта «социализм төзелеше тамырлана барган саен, сыйнфый көрәш тә көчәя» дигән лозунгка яхшы мисал ролен үти.

Әсәрдә ясалма образлар күп һәм алар да максатчан файдаланылган. Сталинның кызыл миләшләрне татар ирләренә охшатуы аша аңлатылган аллегория яңа заманның милли сәясәтен фаш итә: «Көчле халык, рухи тамыры сәламәт сакланган халык. Сәләтлеләрне тарих мәйданына ыргытып кына тора. Чүпләп кенә өлгер—күзне, зиһенне алдап янып торган ачы җимешләрне». Сталин алып барган вазгыять тә, кызыл миләшләрне сырып алып юк иткән кошлар кебек, татарның иң белемле, акыллы, гайрәтле, кызыл идеологияне кабул иткән шәхесләрен яшь көенчә юк итүгә, рухи һәм физик яктан имгәтүгә корылган иде, ди язучы. Әлеге аллегориянең дә икенче укылышына мөмкинлек калдырылган. «Җәмгыять үсешендә, иҗтимагый фикердә «күмәкләшү» дигән татлы җимеш күпләрнең күзен кыздыргандыр

кыздыруын...» дигән өлеш гомумән большевизм сәясәтенең аерым этапларын күздә тота. Яки тагын бер мисал. Дәүләтьяров ишегалдында нәни кызчыкның жансыз курчакны сөйрәп баруын күрә. Үзенең кәнәфидә утырган курчак, кол булуын аңлый: «Курчак язмышы... Үз язмышын оештырудан мәхрүмлек... Сискәнеп китте—чынлыкта ул үзе дә кайбер кешеләр кулында курчак бит!». Әлеге образ аерым шәхесләргә карата гына түгел, гомумән татар милләтенә, халыкка кагылышлы укылыш мөмкинлегенә ия.

Үзгәртеп корудан соңгы чор әдәбиятында кабатланып торучы йорт символы да романда үзенчәлекле уйнатыла. «Ялган тәрәзәле йорт» кебек куллану аның аңланылыш кырын киңәйтеп жибәрә. Әхмәтсафалар күчкән йорт, яна системадагы хакимият (Әхмәтсафа ирешкән дәрәжә-баскычлар), төрмә (бигрәк тә эпиграф белән бер чылбырда), милли республика идеясе һәм гомумән Рәсәй язмышы шушы символ ярдәмендә бәяләнә.

Башка әсәрләрдәге кебек үк, трилогиядә дә игезәк образларга мөрәжәгать итү күзәтелә. Бу очракта язучы шушы алым ярдәмендә зур гомумиләштерүләр ясауга ирешә. Вәлкәй—Алемасов—Сталин чылбыры бик үзенчәлекле. Алар—бер үк тип кешеләр. Вәлкәй хажи белән Мостафа (Әхмәтсафаның әтисе) арасындагы каршылык Шәмсиягә бәйле рәвештә туа. Хатыны үлгәч, Мостафа Шәмсиягә өйләнә. Вәлкәй хажи да Шәмсияне кулга төшерергә, икенче хатынлыкка алырга йөри, моның өчен ире үлгән дигән ялган хәбәр тапшырта. Шул вакыттан алып Вәлкәй Мостафага үч тота, аның үлемендә дә сәбәпче булып чыга. Балаларын дошман күрә башлый, төрле явызлыклар эшли. Урта Азиядә Әхмәтсафага һөжүм оештыра. Роман ахырында Фәтхулланың үтерелүе дә Вәлкәй намусында кала.

Үчлекле, явыз, кешеләр канын түгүне чүпкә дә санамый торган Вәлкәй нәсел язмышына кара тап сала. Шундый ук Алемасов—милләт, ә инде И. Сталин—халык, ил тормышын жимереп ташлый. Мондый янәшәлектә Сталин, Алемасов кебек кара эчле кешеләрнең власть башына килүе, хакимлеккә ирешүе, Вәлкәй кылган явызлыклар белән чагыштырганда, мең-миллион тапкыр куркыныч икәнлек ассызыклана. Игезәк образлар күпсүзлелектән, охшаш ситуацияләрне кабат-кабат сурәтләүдән коткара һәм әсәрнең эчке мәгънә мөмкинлекләрен арттыра.

Хәрәмуллин—Сәгыйтов—Михайлов чылбыры да шундый ук схеманы кабатлый. Сатлыкжаннар, кулыннан эш килмәгән, шуна күрә булдыклыларны юкка чыгару белән шөгыльләнгән адәм актыклары шулай ук характер буларак янәшә, бер-берсен тулыландырып биреләләр. Гомумән алганда, корбан-сатлык-палач амплуасындагы образлар чылбырларының әсәр буеннан-буена «җемелдәп килүе» шушы чорга хас типларның кемнәр икәнлеген тагын бер тапкыр, нәтижә төсендә искәртә. Герой—палач, герой—корбан, палач—герой кебек, бер чиктән икенчесенә ташланып статус үзгәртүне күп язмышлар мисалында эзлекле күзәтү бу процессны заманга хас типик күренеш дәрәжәсенә күтәрә.

Романда һәм фәлсәфи, һәм тәнкыйди башлангыч көчле. Фәлсәфи фикерләрне калкыту өчен язучы еш кына татар шигъри мирасына мөрәжәгать итә. Дәрдмәнд шигырьләреннән, «Идегәй»дән өзекләр табигый рәвештә әсәр тукымасына кереп урнашканнар. Алай гына да түгел, алар заманга хас сыйфатларның мәңгелек проблемалар булуын искәртергә ярдәм итә. Менә бер мисал. Әхмәтсафа белән Гомәр агай «Идегәй»дән өзекләр аша «сөйләшеп» алалар:

*«...Бозгынлыкта калган ил—*
*Аның көне кемгә охшар?*
*Кичәге киткән атамның*
*Менгәне—кеше аты икән,*
*Сауганы—кеше биясе,*
*Җиккәне—кеше дөясе.*
*Алты айлык агыр йортыңнан*
*Урын тапмый, атамның*
*Киселеп китте җөясе.*
*Аның көне кемгә охшар?...*

юллары инкыйлабтан соң төзелеп ятучы яңа заманга бик тә оста, үткән бәя булып яңгырый. Моннан тыш, текст әзерлекле укучыны «Идегәй» сюжетына алып китә һәм тарихи вакыйгаларны искә төшерергә мәҗбүр итә: аллюзиягә әверелә. Алтын Урда вакытында да, инкыйлаб чорында да кеше язмышларының хакимият, власть өчен көрәш тәгәрмәченә тапталуын искәртә. Теләсә кайсы заманда хакимият өчен сугыш бара һәм ул илләр, шәхесләр тормышын тамырдан үзгәртә, үзенә буйсындыра, дигән фикергә китерә. Мондый гомуми ассоциациядән тыш, әлеге сүзләрнең татар тарихына мөнәсәбәтле дастанда әйтелгән булуы да мәгълүм. Милли тарихны «бозгынлыкта калган ил» эпитетын ачыклаулар аша аңларга тырышу автор дискурсы кебек кабул ителә.

Гомәр һәм Мифтах образлары нәкъ менә гомумкешелек кыйммәтләре, яшәеш нигезләре хакындагы фәлсәфи материалны урнаштырырга ярдәм иткән. Еш кына иҗтимагый бәя гомумкешелек фәлсәфәсенә тәңгәл килә. «Сүзләр—пүчтәк, Идея—ялган, күзгә төтен җибәрү; яңа дигән һәрнәрсәнең төбендә искеләрнең шагыйранә ялганнары ята. Адәм баласы туганнан алып үлгәнчегә кадәр әкиятләргә ышанып, Саламторхан, Шомбайларга табынып яши... Бүген ватканны иртәгә төзәтү, бүген туздырганны иртәгә җыеп алырга азаплану иҗтиһатка саналмый, туганнар» кебек күп кенә фикерләр моңа мисал була ала.

Аерым бер фәлсәфи нәтиҗәләр геройлардан, бигрәк тә Әхмәтсафадан «әйттерелә». Болар—роман геройлары төшенгән хакыйкать, тормыш дөреслеге кебек бирелә. Менә Әхмәтсафаның Хивадан киткәндә ясаган нәтиҗәсе: «Әткәсе язмышы хакында уйлап, ул бер нәрсәгә төшенде: кешегә игелек күрсәтеп, аннан рәхмәт өмет итү, аянычка каршы, бу дөньяда иң зур тилелек бугай...». «Табигать үзе тудырганны үзе һәлак итә, кешеләр дә аннан калышмый, һаман көрәш, һаман дау дип хыялланалар. Күпме уйланса да, яшәешнең асылын аңлый алмый әле Әхмәтсафа...». Яки Әхмәтсафа малае булачагын белгәннән соң, хикәяләүче ясаган нәтиҗә: «Бәхет белән бәхетсезлек, шатлык белән хәсрәт, табу белән югалтуның гаҗәп дәрәҗәдә янәшә барулары—дөньяга адәм баласы яралган көннән барлыкка килгән һәм һичнинди үзгәреш кичермәгән хакыйкать бит ул».

Тәнкыйди башлангыч ике: юмор һәм сатира яссылыкларында янәшә бара. Яңа тормыш төзүчеләрнең чиктән тыш арттырылып сурәтләнгән аерым бер эшгамәлләре, абсурд чигенә житкерелгән «тырышлыклары», сыйнфый көрәш, колхозлашу, хәлле кешеләрне җәза тегермәненә тыгу күренешләре сатира һәм ирония арасында тирбәлә. Ә инде гади кешеләр көнкүрешен тасвирлауга күчтеме, автор жылы юморга мөрәҗәгать итә, кечкенә кешеләрнең самими фикерләвен, үткен сөйләшүен, беркатлы күзаллавын укучы күз алдына китереп бастыра. Аерым бер бүлекләрдә ике чик арасында тирбәлеш сызлану китереп чыгара. Шундыйларның берсе—Әмәкәй авылыннан гаепсез кешеләрне алдап Минзәлә төрмәсенә алып китү, өстән төшерелгән 27 санын тутыру өчен, исемлеккә Сөләйман картны язып кую, авылда калганнарны җәзалау, жирле житәкчеләрнең катылыгын һәм хөсетлеген дәлилләгән күренешләр. Яки Чалманараттагы җыелышны тасвирлау, Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе басылганнан соңгы хәлләрне сурәтләү татар авылларындагы кәеф-халәтне нәкъ менә шушы сызлану сызыгына житкереп, фаҗига буларак бәяли. Әлеге тирбәлеш кызыклы ассоциацияләр уятырга мөмкинлек бирә: Габитов үзе белән эләгешкән өчен генә кулак дип Минзәлә төрмәсенә җибәрелгән Сөләйман картның кумхужда гаризасы калган соңгы кеше булуы—шундый детальләрнең берсе.

Әсәрдә бик күп иҗтимагый проблемалар күтәрелә. Аларның күбесе яңа тормыш алып килгән үзгәрешләр белән бәйле. Бу үзгәрешләргә инкыйлаб яклыларның да, аңа каршы кешеләрнең дә мөнәсәбәте, фикер-карашы ачыктан-ачык күрсәтеп барыла. Шул ук вакытта мондый турылык ышандыру көчен киметә. Мәсәлән, романда Мифтах хәлфә губкомнан килгән вәкилгә болай ди: «Акыллы кеше беркайчан да революция ясамый! Бу эшкә, әгәр аны эш дип әйтергә яраса, йә наданнар алына, йә хөсет күңелле, явыз ниятле бәндәләр кулы белән ясала түнтәрелеш. Иң куркынычы—жанында кемнәндер ни өчендер үч алу тойгысы котырган иблисләр генә яскана инкыйлаб-фәлән дип. Акыллары томаланган

бәндәләр саташа ул революция дигән нәмәрсә белән». Фикер, Мифтах хәлфәнеке булудан бигрәк, бүгенге югарылыктан торып ясалган автор гомумиләштерүе кебек аңлашыла.

Роман үзенең фактологик нигезе нык булу ягыннан сокландыра. Татар мәдәниятендә мәгълүм кешеләр язмышы, тулы бер регион—Минзәлә, Мөслим, Әмәкәй тирәләрендә колхозлаштыру хәрәкәтенә бәйле мәгълүматлар, Татарстанда 20—30 еллар чигендә партия җитәкчелегенең кылганнары—барысы да чорга объектив бәя бирүгә, яңа тормыш тәртипләренең асылын ачуга хезмәт итә. Ләкин иң әһәмиятлесе—шушы төрле характердагы материал әсәрнең идеясе, нигезгә салынган метафора һәм әдәби чаралар ярдәмендә бербөтенгә әверелгән. Якын тарихка кагылышлы күп кенә әсәрләрдәге төп кимчелек—публицистик катламның уйдырма катламын, әдәби катламны каплап китүе күзәтелми. Дөрес, әсәр тукымасында артык әһәмиятле булмаган аерым бер вакыйгалар да шактый җентекле тасвирлана. Мәсәлән, Әхмәтсафаның Хива якларында хезмәтенә кагылышлы урыннар бик кыска гына, ретроспекция белән бирелгәндә, отышлырак булыр сыман тоела.

Шулай итеп, Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» романы—татар әдәбиятында беренчеләрдән булып 1920—30 елларда илдә барган үзгәрешләрне, аларның татар халкы язмышына тәэсирен фаҗига буларак бәяләгән, шушы чорның канлы тарихын акларга яки гаепләргә җыенмыйча, ләкин һәркем сабак алырлык итеп сурәтләгән зур әсәр, татар зыялыларының тормышын һәм омтылышларын, меңнәрчә асыл улларын югалткан милләт трагедиясен яктырткан киң бер елъязма. Әсәр нәкъ менә реализм юнәлеше үзенчәлекләренең соңгырак чорларга караган тарихи әсәрләр язганда алыштыргысыз булуын, татар әдәбияты традицияләрен дәвам итеп, бүгенге укучы өчен кызыклы һәм гыйбрәтле әсәр иҗат итү мөмкин икәнлекне дәлилләде. Тарихи үткәнгә карата хакыйкать эзләү дәверендә шул хакыйкатьне әдәби калыпта күрсәтү үрнәге бирде.

Бу трилогия хакында күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Ул Факил Сафин иҗатында иң югары нокта, алдарак иҗат ителгән әсәрләрдә сыналган алымнарның уңышлы синтезы кебек кабул ителә. Кеше образлары сурәтләү мөмкинлекләреннән оптималь файдаланучы язучы романда янәшәлекләр аша шәхес-милләт-ил язмышына караган зур гомумиләштерүләр ясауга ирешә, охшаш образлар бирелешен символик яссылыкка куя. Образларның капма-каршы сурәтләнеше исә, янадан-яңа ассоциацияләр тудырып, мәгънәви тирәнлек хасил итә. Символлар ярдәмендә объектив идеяне ассызыклау матур нәтиҗәләргә китерә. Теленең лексик байлыгы, сурәтләрнең матурлыгы, милли бизәкләрне тергезергә омтылу әсәрнең яңгырашын камилләштерә.

Бер фикер иясенең «талантлы кеше барлык өлкәләрдә дә талантлы була» дигән гыйбарәсе бар. Татар мәдәниятендә, журналистикасында игелекле эшләр башкаручы, шигърият һәм проза өлкәсендә үз исемен таныткан, үз урынын тапкан әдип Факил Сафинның көйләр язуы да, фани дөньядан бакыйга күчкән каләм ияләренең мирасын укучыга җиткерүе, иҗатка тартылучы яшьләргә ярдәм күрсәтүе, яңа талантлар ачу кебек өлкәләрдәге эш-гамәлләре дә игътибарга лаек. Бу иҗат мисалында без иҗат эшенең шәхес холык-фигыле белән тыгыз бәйләнгәненә янә бер мәртәбә ышанабыз. Тормышта төзүче, яңа киңлекләр ачучы, кешеләрнең караш офыкларын киңәйтүче булган Факил Сафин әдәбиятта да шундый мәртәбәле урын яулады.

Гөлзада
Әхтәмова

# БОРЫНГЫ АЛАБУГА

## Изге җир

Чиксез калын нарат урманнары, гүзәл җырлы чишмәләре, балыкка бай күлләре, әкрен генә аккан елгалары һәм чал Чулманы белән Алабуга элек-электән күпләрне үзенә җәлеп иткән. Татар илендә Алабуга бик борынгы шәһәрләрдән санала. Ул тугызынчы-унынчы гасырларда Болгар дәүләтенең төньяк ныгытмаларындагы шәһәр буларак барлыкка килгән. Алабуга шәһәре турындагы хәбәрне халкыбызның борынгы тарихын язып калдырган Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» китабында да очратабыз. Ул Алабуганың 1395 елда җимерелүе турында хәбәр итә. Әйе, Алабуга күпме тапкыр җимерелеп, күпме җәбер-золым күргән. Ләкин яңадан калыккан. Бүгенгә кадәр сакланып килгән «Алабуга бәете»ндә аның «Ак шәһәр» икәнлеге мәгълүм.

Әмма Алабуганың борынгы тарихын хәзер кемнәр генә белә соң? Борынгы бабаларыбызның изге җиренә «Җеннәр шәһәре», «Шайтан каласы» дип, җан чиркандыргыч исемнәр тактылар. Ә бит шәһәрчекнең калдыкларын әби-бабаларыбыз хөрмәтләп «Таш мәчет», «Изгеләр мәчете» дип йөртә иделәр! Хәзер исә аны без, татарлар, «Ак мәчет» дип йөртәбез. Татар халкында ак сүзе төсне генә аңлатмый, ә изге, кадерле, хөрмәтле дигән төшенчәләрне дә белдерә. Бабаларыбызның төсе булып калган соңгы истәлек-шәһәрчекне татар җанлы беркемнең дә кимсетеп әйтергә теле әйләнмәс, дип уйлыйм.

Урыслар яулап алганчы бу җирләрдә кемнәр яшәгән, анда нигләр булган? Бу сорауларга ачыклык кертүче чаткылар бар. Уналтынчы гасырның билгесез авторы «Казан тарихы» китабында Алабугада мәчетләр булуы, шәһәрнең сәүдәгәрләрдән ясак җыярга хокукы барлыгы турында яза. Ханлык чорында Казан кремлендә Алабуга капкасы булуы да беркемгә сер түгел.

Рус тарихчысы М. Г. Худяковның «Казан ханлыгы» тарихы хезмәтендә Алабуга турында: «Казан ханлыгында, киресенчә, шәһәр дип аталырга тиешле зур-зур торак пунктлар житәрлек санда булган, чөнки аларда авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүчеләр генә түгел, ә һөнәр ияләре, сәүдәгәрләр дә яшәгән... Су юллары буендагы Алабуга, Сенбер, Сары тау, Тәтеш, Лаеш кебек торак пунктлар, һичшиксез, шундый шәһәрләрдән исәпләнәләр» (19 бит),—дип язылган.

Борынгы Алабуганың җимерелүенә дүрт гасырдан артык гомер үтсә дә, аның хәрабәләре әле бүген дә үзләрен белгертеп торалар. Хәзерге Чапаев урамында егерменче гасыр башында зур-зур таш өемнәре булган. Алар тирәсенә урыс яшьләре кичке уенга җыелганнар. Шул ташларга утырып ял иткәннәр. Мина сиксәненче елларда бу хакта шул урам картлары сөйләгәннәр иде. Ул ташларны алтмышынчы елларда асфальт юл ясаганда ваклаганнар. Чапаев урамының көнбатыш ягында татар зираты булуы мәгълүм. Исән калган кабер ташлары янына изге җир итеп, Фәттах Әхмәтов белән татар аксакаллары җомга намазына йөргәннәр. Изгеләр рухына дога кылганнар. Бу хәл алтмышынчы елларга кадәр дәвам иткән. Шул ук урамда 1964 нче елда яңа 40 нчы йортка Гадершиннар нигез салганда гарәп имлясы белән язылган кабер ташы һәм хатын-кыз сөякләре чыга. Күрше Бәширова Фатыйма апаның сөйләве буенча (ул язуны ул үзе танып укыган), ул хатынның исеме Хатирә булган. «Үткәндә дога кылыгыз»,—дигән сүзләр дә уелган була ул ташка. Соңгы

елларда шул ук йортка урам аша су торбаларына канау казыганда бик күп каберлекләр ачыла, баш сөякләре чыга. Кызганычка каршы, алар белән кызыксынучы кеше табылмый. Татар тарихы аяк астына күмелгән. Бик аяныч хәл! Чапаев урамы, 12 йортта яшәүче Павел Разживин белән 1985 нче елда сөйләшүләрдән дә мин монда борынгы таш фундаментларның бик күп булганлыгын белдем. Ул 1950 нче елларда авылдан килеп йорт салганда, ташларны шушы тирәдән генә алуын, иске йорт фундаментларының бихисап күп булуын гаҗәпләнеп сөйләде. Кайсы заманнан калган ул ташлар? Билгесез.

Борынгы Алабуга ташлары күп кенә чиркәүләрнең, йортларның нигезе булып бүген дә хезмәт итәләр. Капитан Н. П. Рычков үзенең 1769-70 еллардагы юлъязмаларында тау башындагы борынгы шәһәр турында бик борчылып яза, чөнки монда монахларның болгар биналарын ватуларын, кирпеч өемнәренә әйләндерүләрен күрә. Шәһәрчек янында корылган ирләр монастыре исә агачтан ясалган була. Аның бүрәнәләре соңыннан Танай авылына алып кителә. Монастырь унсигезенче гасыр азагында яшәүдән туктый, ә аның каравы, шәһәрнең аскы өлешендә зур-зур чиркәүләр калкып чыга.



*Борынгы Алабуга шәһәрчегенең гомуми күренеше. 1996 елда төшерелгән фото.*

## Алабуга үз исемен югалтып бетергәнме?

Ни өчендер Алабуганы Трехсвятское урынында барлыкка килгән дип сөйлиләр. Мондый фикер белән килешү мөмкин түгел. Киресенчә, Трехсвятское авылы үзе үк Алабуга җирендә барлыкка килгән бит. Заманында Трехсвятское исемен христианнар уйлап чыгарып, Алабуга исемен оныттырырга омтылганнар. Алабуга җиренә Иван Грозный үзе килеп чиркәү салдырган, икона биргән дип сөйләүләре дә руханиларның уйдырмалары гына. Иван Грозный Казанны алгач, Кама буйлап күтәрелмәгән. Ул Казан хәрабәләре янында ун көнләп тантана иткән дә, кабат Мәскәүенә китеп барган. Бу яклар тиз генә яулап алынмаган. Әле аның икона бүләк итүе дә шикле.

Трехсвятское исемен руханилар ераkларга таратмакчы булсалар да, аны беркем дә аңламый, шуна күрә һәр документта ул «Трехсвятское, что на Елабуге» дип искәртелә. Димәк, Трехсвятское авылы Алабуга җирендә хасил була. 1780 елда Трехсвятское авылы Алабуга шәһәренә әверелә дигән сүз дә дөреслеккә туры килеп бетми.

И. Шишкинның «Алабуга шәһәре тарихы» китабында, өстәмә бит итеп, берничә документ китерелгән. Анда 48 һәм 49 битләрдә «село Трехсвятское, что на Елабуге»ны күрәбез, 50 нче биттә 1748 елда Алабуга волосте булганлыгын беләбез. Бәлки Трехсвятское авылы Подмонастырка кебек Алабуганың бер өлеше генә булгандыр.

«Татарстан тарихы материалларда һәм документларда» китабындагы 1710 елга караган язмада «Илбахтина Троицкаго Елабужского монастыря» дип укыйбыз. 389 нчы биттә П. И. Рычков 1708 елның март аенда «дошед до пригорода Алабуги» дип яза. Шул ук биттә вице-губернатор Н. Кудрявцев патшага 1708 елда башкортлар

һәм татарлар «дворцовое село Елабугу осадили» дип донос яза. Шулай итеп, без бу документлар аша 1621, 1708, 1710, 1748, 1774 елларда Алабуга сүзенең бер дә төшеп калмавын күрәбез. Борынгы Алабуга исеме яши һәм яшәвен дәвам итә.

Алабуга шәһәре борынгы кульязмаларда еш искә алына. Мәсәлән, бер кульязмада *(ул С. М. Шпилевскийның «Борынгы шәһәрләр һәм Казан губернасындагы башка болгар-татар истәлекләре» китабында китерелгән)* унынчы гасырда Айдар исемле хан хәкимлек иткәнлеге хакында әйтелә. Ул чакта Алабугада 520 йорт була. Шул вакытта Алабугада мөселман дине кабул ителгән. Алабуга турындагы кульязмаларның дөреслегенә ышанмау борынгы болгарлар яшәгән җирләрне тарайтып күрсәтүгә китерә. Нигә әле борынгы шәһәрдә Айдар исемле хан булмаска мөмкин, ди? Мөселман дине үзе дә бу якларга көнчыгыш яктан, Хәрәзем аша таралган. 922 елда гарәп илчесе Ибн-Фадлан килгәнче үк Болгар җирендә күп мәчетләр булган, мөселман дине киң таралган. Айдар хан кызы Туйбикәгә каен себеркесе шифасы гарәп илчеләре кулыннан түгел, ә Урта Азия илчеләре яисә Алабугага килгән Болгар шәһәре кешеләре тарафыннан булгандыр. Чөнки гарәп илләрендә каен үсми, каенның дәвасын алар белмәскә дә мөмкин. Гарәп кешесе Әхмәт Ибн-Фадлан болгарларда үскән каеннарны күргәч, нинди исем бирергә аптырап кала *(«Әхмәт Ибн-Фадланның Иделгә сәяхәтнамәсе», 36-37 битләр)*. Аннан соң, шуны әйтеп үтәргә кирәктер: Болгар ханнары исемлегендә Айдар исемле хан юк. Димәк, ул Алабуга ханы булган, дип фаразларга була.

Агыйдел, Чулман буйларында болгарлар килгәнче үк төрки халыклар яшәгән. Алабугадан ерак түгел генә Турай авылы янында курганнар тикмәгә генә барлыкка килмәгәндер. Болгарларның Идел, Чулман буйларына килеп, тиз генә ияләшеп китүләрен галимнәр монда электән үк төрки халыкларның яшәп килүләре белән бәйләп карыйлар. Бу тирәләр Иске Ил дип аталганга, күрәсең, халыкларын да эсегел дип атаганнар. Аның шулай ук чигел, эчкеле, эскел диган вариантлары да бар. Казан шәһәренә бәйле әмир Хәсәнне дә Эчкеле Хәсән дип йөрткәннәр. Бәлки ул атамалар Иделнең өске ягында, төрки илләрнең чигендә яшәүләр белән дә аңлатыладыр.

Хисаметдин Мөслими үзенең «Тәварихе Болгария» дигән китабында 1395 елда Алабуга шәһәрендә булган вакыйгалар турында болай дип язган: «Тимер әфәнде Сәдүм, ягъни Алабуга шәһәренә килеп житә, ул вакытта анда Уразбакты улы Илбакты ханлык итә». *(Татарстан тарихы материалларда һәм документларда», 44 бит.)* Тимер әфәнде, билгеле, монда тик ятмый. Бу кечкенә һәм горур шәһәрне ул җимереп бетерә, капкасын суга ташлый, халкын әсирлеккә ала. Туйма елгасы буендагы каберлеккә килеп, дога кыла. Каберлек, күрәсең, Тимер әфәнде игътибарын җәлеп итәрлек булгач, истәлеккә бай булгандыр. Ләкин башка тарихчылар тарафыннан Аксак Тимернең монда килүе турындагы фикерләр кире кагыла. Аның бер отряды гына килүе мөмкин дигән фаразлар бар. Бәлки бераз иртәрәк 1361 елларда Булат Тимер килгәндер дип тә фикер йөртергә була.

Әле егерменче гасыр башларында шәһәр банкы тирәсендә (Спас соборыннан ерак түгел урында) тротуарга түшәлгән мөселман кабер ташларының язуларын укырга мөмкин булган, дип сөйлиләр. Ә 1994 елда мәңгелек ут тирәсендә мөселманча күмелгән кеше сөякләре табыла. Алабуга пединститутының тарих-археология фәннәре укытучысы А. Нигамаев әйтүенчә, ул кабер Казан ханлыгы чорына карый. Шәһәрнең милиция мәктәбе ишегалдында да мона охшаш каберләр табылган иде. Димәк, Х. Мөслими Тойма елгасы буенда булган хәлләрне дөрес тасвирлый. Ә бүгенге Спас соборы зират өстендә яисә янында утыра икән. Аның нигезендә ата-бабаларыбызның кабер ташлары булуы бик ихтимал.

Х. Мөслими китабында Илбакты һәм Уразбакты ханнарның исемнәре чагыла. Уразбактының резиденциясе хәзерге Колосовка авылы урынында булгандыр дигән фикерләр бар. Колосовка авылы элек Уразбахтино исеме йөрткән. Илбакты авылы да Алабугадан ерак булмаган. Каманың аргы ягында Яр Чаллы янында Илбухтино авылы бар. Руслар бу якларны яулап алгач, ул Алабуга монастыре карамагында санала.

Димәк, Алабугада унынчы гасырда Айдар исемле хан булса, ундүртенче гасырда

Уразбакты һәм аның улы Илбакты хакимлек итә. Борынгы болгар-татар җирләрендә мөстәкыйльлек бүгенге көн белән чагыштырырлык та булмаган, һәркем үз биләмәсендә хан дип саналган. Мәсәлән, шул ук ундүртенче гасырда Ык төбәгендә Тугаш хан, Зәй төбәгендә Бәйрәш хан хакимлек иткән.

Алабуга тарихы белән кызыксынучы, тумышы белән алабугалы К. И. Невоструев татар кульязмаларын бик җентекләп өйрәнгән. Аның кулына Алабугада һәм Мамадышта табылган 1584 елга караган ике кульязма килеп керә. Алардан Алабуганың икенче исеме Сәдүм икәнен беләбез. Мамадыш кульязмасында Алабуга ханы Әндиҗан телгә алына. Аның гаскәрләре монгол яулары вакытында тар-мар ителә, ә бихисап күп байлыгын дошман килер алдыннан ул ин зур күлләрнең берсенә сала (кайсына икәнлеге әйтелми). Әндиҗан ханның кайсы елларда хакимлек итүе билгеле түгел, бәлки Уразбакты ханга кадәр үк булгандыр.



*«Ак мәчет».*

Казан белән Алабуга арасындагы туганлашу җепләре дә элек-электән килә. Илбакты кызы, ягъни Сөгүн ханның бер кыз туганы, Казан бәге Мәмәтгәрәйнең хатыны булган. Казан ханы Олуг Мөхәммәт чорында Алабугада Илбакты улы Сөгүн хакимлек итә. Үзенчә бер сәбәп табып, Олуг Мөхәммәт Сөгүнне Казанга җибәреп, Алабуганы Ислам бәккә тапшыра. Олуг Мөхәммәт 64 яшендә Алабугада вафат булып, каладан бер читтә булган тауда күмелгән. Бу хәлләрне безгә Хөсәен Әмирхан «Болгар тарихы» дигән хезмәтендә язып калдыра *(«Мирас», 1994, № 10, 110 бит)*. Болгар-кыпчак ханнары канынннан булган Сөгүн ханны алып, Ислам ханны кую, бәлки, Олуг Мөхәммәдинең үз кешеләрен арттыру, яулап алынган биләмәләргә ышанычлы кешеләр утырту максатыннан эшләнгәндер.

И. В. Шишкин «Алабуга тарихы» китабында (9 бит) тау өстенә мөселманнарның изге кеше каберенә килүләрен, ләкин аның исемен дә, кабер урынын да әйтмәүләрен, дини сәбәпләр аркасында сер итеп тотуларын яза. Бу кабер Казан ханлыгын нигезләгән Олуг Мөхәммәтнеке булырга мөмкин. Казанга караганда чагыштырмача тыныч, табигате матур бу урынны бәлки ул соңгы көннәрен үткәрергә үзе сайлап алгандыр. Ә бәлки улы Мәхмүттән качып килгәндер. Ата белән бала арасында булган хәлләр турында тарихта төрле хәбәрләр сакланган. Тәхет өчен көрәштә бер-берсен кызганмаганнар. 1445 елдан Олуг Мөхәммәт турында рус елъязмаларында бер хәбәр дә очрамый. Ә безнең татар тарихы яндырылган...

Алабугадагы иң соңгы ханның исеме—Сәүгән. Аның турында тумышы белән шушы яклардан булган, берникадәр вакыт Алабугада яшәгән, заманында Фәнни Академик үзәктә сәркятип булып эшләгән филолог Зәйнәп Максудова язып калдырган. Алабуга—Казан ханлыгының вассал кенәзлеге башкаласы була. Үз мәнфәгатьләрен яклап, Алабуга ханы Тәрбирде Чаллысы белән дә 1518, 1525 елларда сугыш алып бара. Мөстәкыйльлек алу максаты беләнме, ясак түләмәс өченме, әллә Казан ханлыгында ханнарны гел алыштырулары, аларның кайберләрен өнәп бетермәү аркасындамы, әллә безгә билгеле булмаган башка сәбәпләр беләнме—

Алабуга белән Тәрбирде Чаллысы берләшеп, Казанга һөҗүм итәләр. Шул бердәмлек булмау да халкыбызның мөстәкыйльлеген югалтуга китергәндер.

Казан университеты доценты Марсель Бакиров табып өйрәнгән материаллар арасында Зәйнәп Максудова архивыннан алынган «Алабуга бәете» дә бар *(«Мирас», 1992, № 10, 36 бит).*

### *Алабуга бәете*

*Алабуга ак шәһәр, тарихы озак яшәр,*
*Дошманга, яуга бирелмәс, юлына каршы төшәр.*

*Алабуга урыс кулына Сәүгән ханнан калгандыр,*
*Сәүгән ханның маҗарасы тарихта язылгандыр.*

*Атлар җиктем яратып, Саралыга каратып.*
*Саралы, Сәйтәк чукынган, кефер уты таратып.*

*Алабуга олылары Туйгужа белән Аккужа*
*Сөрлектеләр илендән.*
*Сарай белән Сәеттәкбәк чыктылар ислам диненнән.*

Бу бәеттә халкыбызның ачы язмышы ята. Туйгужа белән Аккужа кебек олыларның илләреннән куылулары, Саралы, Сәйтәк авылларының, читкә китүдән, үтерелүдән куркып, чукынырга риза булулары турында сөйләнә. «Алабуга ак шәһәр, тарихы озак яшәр» дигән өмет тә әйтелә.

## Шәһәрнең исеме

Алабуга шәһәренең исемен һәркем үзенчә аңлата. «Исәнме, Алабуга!» китабын ачып карасак, түбәндәгеләрне укыйбыз: «Безгә кадәр билгеле документларда, Трехсвятское авылы турында сүз барса, һәрвакыт аңа «что на Елабуге» дип кушып аңлатыла. Елабуга—рус сүзе түгел... Тойма елгасы артындагы зур күл Алабуга исемен йөрткән, татарчага тәрҗемә иткәндә алабуга балыгын аңлата» (15-16 битләр).

В. А. Никоновның «Кыскача топонимик сүзлеге» ндә (135 бит) ул болай дип аңлатыла: «Алабуга—Татарстандагы шәһәр. Алабуга дигән кеше исеменнән килеп чыгуы ихтимал, ала үгез мәгънәсен белдерә. Буга элементы кергән кеше исемнәре 14 гасырда бик еш күренә.» Шунысы әһәмиятле: В. А. Никонов А. Игнатовичның «Борынгы һәм яңа Россия» китабында шәһәр исемен шәһәр аркылы үткән Ела инеше һәм шәһәр читендәге Буга күлләреннән алынган, дип язуын тәнкыйтьләп үтә. Дөрестән дә, артык катлауландырып, урысчалаттырырга уйлаучылар хәзергә дә житәрлек. Елгаларның берсен Ела, икенчесен Буга дип, өстәл артында утырып кына исем бирүчеләр дә бар. Ләкин халык ул елгаларны Гнилушка—Черек елга гына дип йөртә.

Башка сүзлекләргә дә күз төшерик. Ф. А. Брокгауз һәм И. А. Эфрон чыгарган «Энциклопедик сүзлек»тә болай дип язылган: Алабуга—безнең кайбер елъязмачылар Үзбәк ханны шулай дип атыйлар» (345 бит). Бу фикер шулай ук В. Клюшниковның «Энциклопедик фәнни сүзлек» китабында да кабатлана (56 бит). Чыннан да, шәһәргә Алабуга исеме Үзбәк хан вакытында бирелүе мөмкин. Ул Алтын Урда ханнары арасында иң озак хакимлек итүче—1313—1342 елларда. Аның вакытында мөселман дине бөтен Чулман буена тарала һәм шулай ук күп кенә шәһәрләр торгызыла, яңалары төзелә. Вельяминов-Зернов тапкан бер татар кулъязмасында да Үзбәк хан вакытында Кама буйларында мәҗүсиләрне ислам диненә күндерүләр турында сөйләнелә һәм шулай ук борынгы Алабуга турында да искә алып үтелә *(И. Шишкин. «Алабуга шәһәре тарихы», 7 бит).*

С. В. Веселовскийның «Ономастикон. Борынгы рус исемнәре, кушаматлары, фамилияләре» китабын кулга алыйк. Анда түбәндәге юлларны күрәбез: «Олбуга

(Албуга, Алабуга), Олабугин—урда илчесе, XIV гасыр уртасы.» Димәк, Алабуга сүзе кеше исеме буларак киң таралган сүз.

Алабуга шәһәре исеменең килеп чыгуын профессорлар Ф. И. Эрдман һәм А. Халиков Кама елгасында Алабуга шәһәре каршында «усал үгез—ала буга» исемен йөрткән, судноларга үтәргә комачаулаучы зур таш булуы белән аңлаталар. Бу фикер дә шулай ук игътибарга лаек. Ул да төрки тел нигезендә аңлатыла.

Хәзер менә Гомәр Саттаровның «Ни өчен шулай аталган?» *(Татарстан топонимнары)* китабын ачып карыйк: «Алабуга районының исеме үзәге Алабуга шәһәреннән алынган. Алабуга шәһәре уналтынчы гасырның икенче яртысында борынгы болгар шәһәре урынына нигезләнгән. Төрки халыклары алабуга дип «окунь» балыгын атыйлар. Бога—буга—бука сүзе борынгы төрки телдә «үгез» дигән мәгънәдә йөргән. Тара татарлары хәзер дә үгезне «бога» диләр. Шушы мәгънәсендә бога сүзе борынгы венгр теленә кабул ителгән. Рус телендәге «бык» та «бога»—»бука» дан килеп чыккан дигән караш бар. Алабуга балыгының башы ала үгез башына охшаганга, ана шул исем кушылган.

АЛАБУГА сүзе төрки халыкларда кеше исеме буларак та кулланылган. Баланың үгез кебек көчле булуын теләү ырымына бәйләнешле рәвештә, исем составына бога-бука сүзе кергән: Букатимер, Акбуга, Айбуга, Теләбуга һ. б. кебек кушма төзелешле борынгы кеше исеменнән алынган булырга тиеш. Тамбов һәм Табул губерналарында Алабуга исемле икешәр авыл булган» (86 бит).

Ә бәлки Алабуга шәһәренең исеме Алып буга дигән сүздән килеп чыккандыр. Шәһәр кирмән буларак барлыкка килгән. Аны үгез кебек көчле сугышчы алыплар—Алып бугалар саклаганнар. Төрки халык яшәгән һәр төбәктә алыплар турында риваятьләр сакланган. Шуна күрә бүгенге Алып буга—Алабуга атамасының шуннан чыккан булуы мөмкин.

## Авылларниләр хәтерли?

Кама елгасы буендагы Бряхимов шәһәрен Андрей Боголюбский 1164 елда көлгә әйләндерә. Иван Васильевич Шишкин фараз кылуы буенча, бу шәһәр борынгы Алабуга жирендә булырга тиеш. Ләкин галимнәр Боголюбскийның бу тирәләргә үтеп кергәнлегенә ышанмыйлар, Бряхимов шәһәренең Каманың түбән агымында урнашканлыгын исбатлыйлар. Ләкин без Ибраһим хан вакытында Алабуга болгар жирләре булмагандыр дип әйтә алмыйбыз. Ибраһим—Ибраш сүзе бу якларда киң таралган исем.

Ибраһим (Ибраш) исеме Алабуга якларында берничә урында бар. Беренчесе—керәшен авылы Бөрешле. Вятка губернасының унтугызынчы гасыр архив материалларында «Ибраш авылы (Брюшли)» искә алына. Димәк, Ибраш—Брюшле—Ибраш иле дигән сүз. Бу чыганакта түбәндәгечә языла: «Ибраш (Брюшле) авылы Чикчирмә елгасының Ибраш елгасына койган урынында урнашкан. Анда бик борынгы татар зираты бар, киртәләп алынмаган, ләкин әле сөрелмәгән».

Икенчесе—Алабуга районындагы мөселман татар авылы Юраш та күпмедер чамада өйрәнелгән. Р. Сәлимов («Алабуга нуры», 1992 ел, 24 март) Юраш атамасын кеше исеменнән алынган: Ибраһим—Йобраш—Юраш дип уйлый. Рәсми кәгазьләрдә Юраш дип язылса да, авыл кешеләре, күрше-күләннәр дә Йобраш дип йөртәләр, бигрәк тә олы яшьтәге кешеләр. Бу авыл кешеләре әле үз тарихларын онытып бетермәгәннәр. Йобраш бабай кабер ташы зиратта саклана диләр иде. Ләкин соңгы елларда бу төбәктәге мөселман зиратларын махсус өйрәнгән галимнәр Р. Мәрданов һәм И. Һадиев андый ташны тапмаган *(«Мәйдан», 2006, N 8)*.

Өченчесе—Юраш авылыннан хәтсез генә ераклыкта булган Анзирка (Әнжирә) авылы халкы Вятка (Нократ) елгасы буендагы жирләрне әле бүген дә Юраш басуы (поля Юраша) дип йөртә икән. Димәк, Ибраһим бабайның нәселе бу жирдә дә яшәгән яисә бу басуда бик олы яу үткән.

Шулай итеп, Алабуга төбәгендә бер-берсеннән шактый ерак араларда Ибраш (Ибраһим) исеме белән бәйле өч урын мәгълүм. Бу очраклы гына түгелдер. Ибраһим ханның биләмәсе зур булган—бөтен Алабуга тирәли. Ә Ибраһим исеменең Ибрашка

әйләнүе гаҗәп түгел. Тугаш, Бәйрәш, Апуш кебек, исемнәрне кыскартып әйтүләр борынгы төрки-татар халкына хас булган.

Олуг Мөхәммәтнең оныгы Ибраһим хан 1460-1479 елларда, барлыгы унтугыз ел буе Казанда хан булып утыра. Аның заманында казанлылар Вятка буйлап бик ерак үтеп керәләр. Мәсәлән, 1468 елда казанлылар зур көч белән Вяткага (хәзерге Киров шәһәре) киләләр һәм вятчаннар каршы тора алмыйча, Ибраһим ханга биреләләр. (Вятканы 1468 елда гына яулап алганнар дип, Алабуганың нигезләнүен дә шул ук вакытка кертергә теләүчеләр бар. Ләкин Алабуганың Кама буенда утыруын онытмаска кирәк).

Шулай итеп, Алабуга исеме белән бәйле рәвештә ике Ибраһимны күрә алабыз. Беренчесе—уникенче гасырда яшәгән, икенчесе—унбишенче гасырда хакимлек иткән Казан ханы. Кайчан да булса галимнәр тарафыннан кирәкле мәгълүматлар җитәрлек дәрәҗәдә җыелыр, бүген без белмәгән күп мәсьәләләр ачыкланыр. Өченче Ибраһим хан булганмы? Бәлки Алабуганың үз Ибраһим ханы булгандыр. Бу сорауга да, бәлки, җавап табылыр.

Алда әйтеп үткәнебезчә, К. Невоструев телгә алган татар кулъязмаларының берсендә Алабуга ханы Әндиҗан (Андиян) турында сөйләнелә. Бүгенге көндә татарлар Әнҗирә, руслар Анзирка дип йөрткән авыл Әндиҗан җире дигәнне хәтерләтмиме соң? Анзирка авылы халкы бүген дә Ибраш хан басуларын хәтерли. Анзирка (Әнҗирә) елгасы Алабуга шәһәре тирәсендә башланып, Вятка (Нократ) елгасына коя.

Вятка губернасының 1889 ел архив материалларына караганда, күп кенә керәшен авылларында, иске татар зиратларының саклануы әйтелә: Черкас, Үтәгән, Тагай, Ибраш (Бөрешле), Шүрнәк һ. б. Ул вакытта әле бу мөселман зиратлары сөрелмәгән булса, колхозлашу чорында аларның күбесе басуларга әйләнгән, эзсез югалган. Керәшен авылларында мөселман зиратларының булуы Алабуга ягында Явыз Иван яуларына кадәр татарларның тыгыз яшәвен, аларның әле моннан 50-60 еллар гына элек мөселман зиратларына, шул исәптән борынгы ата-бабаларына ихтирамнары бетмәве хакында сөйлиләр. Чукындырылганнан соң керәшеннәргә үз авылларында үлгән кешеләрне күмәргә рөхсәт ителми, ә бәлки чиркәүле авылларга илтеп күмәргә кушыла. Иске Шүрнәк авылында кушкаен янында бик борынгы зират булган диләр. 1941 елгы сугыш елларында, язгы ташу вакытларында чиркәүле авылга илтергә хәлләре булмаган кешеләр генә мәрхүмнәрне шул зиратка күмештергәннәр. Иске Шүрнәк авылы гаять зур булгандыр. Әле егерменче гасырда да йорт нигезе казыганда мөселманча күмелгән кеше сөякләре чыккан. Хәзерге заман кешеләре инде үзләренең тарихын онытып баралар. Зиратның чикләрен хәтерләмиләр. Зиратның бер чиге авылга тоташкан, димәк, ул бик кечкенә булмаган. Авыл бик борынгы заманнардан бирле яшәп килгән, дип фаразларга була.

Алабуга якларында зур җирбиләүчеләрнең берсе Канак исемле булган. Мәсәлән, Карманково авылы марилары үз авыллары тарихын искә алганда (19 гасыр материаллары буенча), бу яклар татар кенәзе «Канак агайныкы» булуын әйтәләр. Канак үз җирләренә мариларны, ул замандагыча әйтсәк, припущенник итеп, кертқәндер. Ул алардан ясак түләттергән. Димәк, Алабуга белән рәттән генә Канак авылында аның резиденциясе булгандыр.

Кара бәк шәҗәрәсендә күренгәнчә *(М. Әхмәтҗанов, Татар халкы оешуда нугайларның катнашы // «Идел», 1992, № 3-4)*, бу якларда Җанморза уллары Котлы бәк һәм Уразай бәк яшәгәннәр. Алабугадан алтмыш чакрым чамасы ераклыкта Ямурза һәм Уразай авыллары бар. Бәлки аларның туганнары Котлы бәк Алабуга ягындагы хәзерге Котловка авылында гомер кичергәндер.

Димәк, борынгы Алабуга исеме белән бәйләнгән зур шәхесләрдән без Айдар, Ибраһим, Әндиҗан, Уразбакты, Илбакты, Сөгүн, Ислам, Сәүгән ханнарны, Кара бәк һәм Канак, Котлы бәк кебек бәкләрне санап үтәбез. Сөгүн белән Сәүгән бик охшаш исемнәр. Бәлки икесе бер үк кешедер. Ислам бәктән соң янадан Сәүгән ханның хакимлек итүе бик мөмкин. «Алабуга бәете»ндә күренгәнчә, ул Алабуганың ин соңгы ханы. Хисаметдин Мөслими Алабуганың икенче исемен Сәдүм дип атый. Бәлки бу исем дә Сәүгән ханга охшатып әйтүдәндер. Сәдүм—Сөгүн—Сәүгән—бер

үк кеше исемедер. Казан тарихы белән бәйле Сөембикәнең ачы язмышы халык күңелендә ничек озак сакланса, Алабуганың соңгы ханы Сәүгән дә халык хәтереннән чыкмый, бәетләрдә әйтелә.

## Авыл исемнәре

Алабуга якларындагы авыллар Алабуганың үзе кебек үк бик борынгылар, тикшерә башласаң, исемнәре белән бик тирән төрки катламнарга кереп китәсең. Бүгенге көндә, мәсәлән, Абалач, Тагай, Канак, Карен авыллары исемнәренең мәгънәләрен бик тиз генә әйтә дә алмыйбыз. Ә менә уйланып, эзләнеп карасаң, ачыклап була икән. Гомәр Саттаровның «Исемең матур, кемнәр куйган?» китабын ачып карыйк. АБАЛАЧ исеме «кечкенә малай», «төпчек ир бала» дигән мәгънәгә ия икән (130 бит).

ТАГАЙ—Абалач белән рәттән генә урнашкан керәшен авылы. Тагай исә борынгы төрки телдә—«өлкән ир туган, абый» дигәнне аңлата (54 бит). Тагай авылыннан Алабугага таба китсәк, элеккеге рус-керәшен авылы Канакны искә төшерәбез. Г. Саттаров китабыннан 86 биттән укыйк: «Каймак дигән мәгънә белдерә торган сүзләр, күчерелмә мәгънәдә «ләззәтле бала» төшенчәсен аңлаткан хәлдә, борынгы заманнарда ук төрки халыкларда кеше исеме итеп кулланылган. Борынгы болгар һәм аргу телләрендә «каймак», «сөт өсте» мәгънәсендә йөргән канак сүзеннән Идел-Кама болгарларында КАНАК исеме барлыкка килгән. Бу сүз М. Кашгари сүзлегендә (XI йөз) теркәлгән... Алабуга районында Канак дигән татар-рус авылы бар». Димәк, Канак яраткан бала мәгънәсендә.

Шулай итеп, Абалач—төпчек бала, Тагай—өлкән ир туган, Канак—ләззәтле баланы аңлата. Ата кеше үзенең улларын шул авылларга башка чыгарып, җир бүлеп биргән булса кирәк. Ләззәтле баласына Алабуга тирәсендәге иң матур җирләр тигән. Өлкән баласына җирне үз яныннанрак биргән, ул аңа ярдәмче, алмашчы булсын дигәндер инде. Ә ата кеше кем соң? Ул кайда яшәгән? Аның турында Карен авылында яшәгән Кара бәк булгандыр дип фикер йөртергә була. Чөнки ул авыллар барысы да Карен (руслар аны хәзер Гари диләр) авылы тирәсендә Каринка елгасы буена урнашканнар. Яулап алгач, руслар тикмәгә генә Карен авылына чиркәү куймаганнардыр. Ул иң зур авылларның берсе булгандыр. Бәлки әле чиркәү астында ата-бабаларыбызның кабер ташлары да ятадыр.

Кара бәккә килгәндә исә, бу якларда аның нәселләре бүгенге көндә дә яшәп яталар. Мәсәлән, М. Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» китабының 144 битендә Кара бәк шәҗәрәсе тасвирланган.

Абалач авылында бик борынгы изгеләр зираты бар. Тагай авылында да шулай ук борынгы зират барлыгы билгеле. Кызганычка каршы, ул урында ЕлАЗ карьер ясады, диләр. Тагай авылы кешеләре әле егерменче гасырның илленче елларында да Абалач карчыкларына җомга көннәрендә дога кылдырырга, мөселман бабаларының рухын искә алырга килә торган булганнар.

Сәйтәк авылының чын исеме—Сәетбәк. Ул исем «Алабуга бәете»ндә искә алына.

Морт авылы Алабуга ягындагы иң борынгы авыллардан санала. Ул Казан йортындагы халыкны исәпкә алу кенәгәләрендә 1603 нче елда очрый. Анда ул «Морлы-Морты» дип бирелә. Бәлки аны урыс теркәүчеләре умарталы сүзен аңламаудан ике төрле язганнардыр. Морт авылы элек зур кара урманнар эчендә утырган булган. Бәлки, аларны бәла-казалардан, көчләп чукындырулардан шул кара урман саклап калгандыр. Хәзер дә Морт урманнары зур, җиләккә, чикләвеккә бай. Г. Саттаровның «Атамалар дөньясына сәяхәт» дигән китабында (152 бит) түбәндәгеләр китерелә: «Мишәр сөйләшләрендә умартаны марта яки мурта, ә умарталыкны марталык яки мурталык диләр». Борынгы урманнарда агачка менеп бал алганнар. Шүрнәк авылы 1617 елгы ясак җыю кенәгәсендә «Шурняк—Шурма» дип теркәлә. Бу исем дә шулай ук урысларның телне аңлап бетермәүләреннәндер. Шүрнәк авылының исеме, профессор Л. Ш. Арсланов аңлатуынча, шур—елга, нюк—үзән, чокыр сүзләреннән килеп чыккан. Шулай ук Шуурмак дигән авылның Алтай якларында да барлыгы тарихта билгеле.

Үмәк авылы да бик борынгы авыллардан санала. Алар татарлар арасында иң беренчеләрдән булып христиан диненә күчәләр. Үмәк сүзе шулай ук кеше исеменнән булуы ихтимал. Татарларда Әмәк исеме булган. Ә бәлки Умай сүзе нигез булгандыр. Умай—борынгы төрки халыкларынын мәжүси аллаларынын берсе.

## Сарали-Бехтерево авылы тарихы

Дин әһеле Николай Иванович Шишкин 1901 елда Алабуга тарихына багышланган китабында 1648 нче елгы «Писцовая книга» дип аталган документларны Мәскәү архивыннан табып алуы турында яза. Анда безне бүгенге көндә кызыксындырырлык күп кенә материаллар бар.

Хәзерге вакытта Бехтерево дип йөртелгән авыл элек Сарали дип аталган. Бехтерево исеме ана егерменче гасырда гына бирелгән. 1619нчы елда монахлар жир даулый башлыйлар. Үзләренә бирелгән Анзирка авылы ерак булганлыктан, Танай авылы татарларынын Сентяк авылы ягындагы жирләренә күзләре төшә. Бәхәс куба. Тиз генә жирләрен тартып ала алмаганлыктан, законлы рәвештә бәхәсне чишәр өчен, борынгыдан монда яшәп килгән Сарали авылы татарларын: Бисяр Кагтов, Ширзаман Умеленов, Акинжя Шедейбышев, Акзат Янзитов, Байгудя Берекгузовларны чакыралар. Яндигиз житәкчелегендәге Танай авылы татарлары жиргә теше-тырнаклары белән ябышсалар да, Сарали авылы татарлары аларны, кызганычка каршы, яклап чыкмыйлар. Бу жирләр электән хөкүмәт жирләре булып санала, диләр, һәм алар кәгазьгә үзләренең тамгаларын куялар. Нәсел тамгасы ул вакытта татарлар өчен бик кадерле була, гарәп имлясын белсәләр дә, документларда тамга кую гадәткә кереп киткән була. Документларнын берсендә дә болгар дигән сүз юк. Татар атамасы бу як төрки халыкларга күптән бирелгән, күрәсен. Бу документка Яндигиз житәкчелегендәге Танай авылы татарлары кул куймыйлар.

Әйтеп үткәнебезчә, элеккеге Сарали авылы хәзер Бехтерево дип йөртелә. Андагы маллар фермасы нәкъ менә мөселман зираты өстенә салынган. Алтмышынчы елларда бирелдә колхоз фермасын төзегәндә гарәп имлясы белән язылган өч кабер ташы табыла. Бу хакта колхоз рәисе Гусев сөйләгән. Бәлки археологлар кайчан да булса, шул кабер ташлары белән кызыксынырлар. Сарали авылы кешеләре әле 1619 нче елда үз исем-фамилияләрен йөртәләр. Аларны чукындыру соңга табарак булса кирәк. Бәлки Танай авылы татарларын якламаган өчен аларга берникадәр вакыт дин ирегә бирелгәндер.

Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, Сарали кешеләренең Мөслим-Азнакай якларына барып чыгып Сарлы авылын нигезләүләре билгеле. Шулай ук алар янына Алабуга ягыннан күрше булып Сөендек (Сентяк), Стәрле (хәзерге Лекарево) авылларыннан гаиләләре белән күченүчеләр булган. Хәзерге заманда ул якларда өч татар авылы күршеләр булып яшәп киләләр. Алар, Кама аръягына Алабуга алпавыты Черкасов нәфсесен сузгач, барып чыкканнар дигән сүз дә йөрде. Ләкин тарихта бөтен авылы белән шундый ераклыкка күчеп китүләр билгеле түгел. Хәтсез генә гаиләләр үз авылларында яшәп калулары бар. Ә менә Алабуга янында ул авылларнын руслашып бетүләре көн кебек ачык. Бехтерево авылында инде бүген борынгы татар нәселеннән булган кешеләрне табуы авыр. Шул атаклы Бехтеревны Бәхтияров дип әйтсәң генә инде... Ул авылда шулай ук игътибарга лаеклы Байгуловлар фамилиясе бар. Ләкин алар үзләренең төрки тамырларын хәтерләмиләр, шулай да бу авылда бик борынгы заманнардан бирле яшәп Н. И. Шишкин үзенең китабында Петр Беренче вакытында татар авылы Саралида әсирлеккә төшкән шведлар тарафыннан жиз эретүче завод корылган, дип яза. Аннан соң Тула якларыннан килгән Красильников та озак кына вакытлар аны үз заводы итүе билгеле.

Сарали авылы исеме шулай ук «Алабуга бәете» ндә искә алына: «Саралы, Сәйтәк чукынды көфер уты таратып». Руслар килгәч, Сарали авылы бәлки анда завод булудандыр зурайган. Соныннан аннан күп кенә авыллар аерылып чыкканнар. Шулар арасында Разживино авылы да бар.

Әгәр дә Сарали авылынын исеме сарай сүзеннән алынса, ул тарих өчен бигрәк тә әһәмиятле булып чыгар иде. Чыннан да, анда Алабуга ханнарынын сарайлары

торган булса, археологик казыну вакытында күп нәрсәләр табылуы мөмкин. Югарыда әйтеп үтелгән өч кабер ташы да бәлки ханнар зиратыннандыр. Кызганычка каршы, безгә әлегә фаразлар дәрәҗәсендә генә фикер йөртергә кала.

Керәшеннәрне руслар үз авылларыннан кумаганнар. Тик Сарали авылына руслар бик күп күчеп утыру сәбәпле, руслашу артык тиз барган. Димәк, Сарали-Бехтерево авылы документларда 1619 елдан искә алына. Алар унике елдан дүрт йөз еллык бәйрәмнәрен үткәрә алалар, ә бәлки бик эзләсәләр, иртәрәк язылган документлар яисә кабер ташлары табып, үзләренең тагы да борынгылыгын расларлар.

## Рус авыллары ни өчен татар исемнәрен йөртә?

Алабуга якларында төрки халыклар бик борынгы заманнардан яшәп килгәнлектән болгар-татар атамалары бүгенге көндә торак урыннарында ачык чагыла. Руслар бу җирләрне яулап алгач, билгеле, үз исемнәрен тагарга омтылалар. Христиан диненең бу якка таралуы аларның иң беренче тәрәге икәнлеген истә тотып, дини исемнәр бирү гадәткә кереп китә. Иң беренче итеп, Алабугага Трехсвятское исемен кушарга тырышалар.

Вятка губернасының XIX гасыр архив материалларында күренгәнчә, озак еллар буе һәрбер рус авылы икешәр исем йөртә, берсе—русча, икенчесе—татарча. Руслар үзләре күчеп утырган кайбер элеккеге татар авылларына теләгән исемнәрен бирүгә ирешәләр. Мәсәлән, борынгы Уразбакты авылы хәзер Колосовка исемен йөртә. XIX гасырда әле ул авыл ике исемле була Уразбахтино-Колосовка. Сентяк (Сөендек) авылына Покровское исемен бирәләр. Әле хәзерге вакытта да халык аны Сентяк дип йөртә, ә рәсми документларда соңгы елларда аны Покровское дип язалар. Күрәш шулай ук башка авыл исемнәре өчен дә бара. Танай (Тан, Тана) авылына Архангельское исеме бирел карыйлар, әмма үтми. Хәзер аны татар тамыры сакланган килеш Танайка дип йөртәләр. Олы Елово авылына Архангельское исемен такмакчы булалар, ул эш тә барып чыкмый. Елово - борынгы татар исеме Юлай исеменнән килеп чыгуы ихтимал.

Олы Качка авылын Дмитровское белән алыштыралар, әмма ул исемнең гомере кыска була. Ул авылда кайчандыр, кайсыдыр яудан соң Танай авылыннан качып килгән кешеләр яшәгәнгә аны Качка (Качкын) дип атаганнар. Качка авылы 1619 елда җире үлчәтелгән авыл буларак «Писцовая книга»да искә алына, аның белән рәттән Тарловка авылы җире дә үлчәнелә.

Әрәмәле авылын руслар Армалы дип үзләренчә атыйлар. Хәзерге Лекарево авылы элек Стырлово була. Аның Стәр сүзеннән алынган булуы ихтимал. Татарлар яшәгән төбәкләрдә Стәрле, Стәрлетамак авыллары бар. Лекаревога чиркәү салгач, Воздвиженское исемен бирел карыйлар, әмма ул исем дә җинми. Бу авылның тагы бәлки икенче исеме Лыкыр булгандыр. Лыкыр дип элек мишәрләр Казан татарларын атап йөрткәннәр *(Халиков А. Татар халкы һәм аның борынгы бабалары, 37 бит)*.

Алабугадан 12 чакрым ераклыкта булган Чаллы авылына Рождественские Челны исеме кушыла. Әмма элек бу авылда татарлар яшәгәнен искә алып, халык телендә ул Татарские Челны булып китә һәм хәзер дә ул шул исемне йөртә. Борынгы Постабай авылы соңгы елларда, тимер юл станциясе төзелгәннән соң гына Тихоново булып китте. Алабугада Постабаев фамилиясен йөртүчеләр бар.

Свиногорье авылы Дунгыз исеме йөрткән. Руслар аны татарчадан тәрҗемә генә иткәннәр. Башта ана руханилар Христорождественское исеме бирәләр. Ләкин ул исемне халык кабул итми. Анзирка (Әнҗирә) авылына да Богородское исеме бирәләр. Ул да ныгып китми.

Шулай итеп, Трехсвятское, Рождественское, Богородское, Архангельское, Христорождественское кебек дини исемнәр, гади халыкка әйтергә авыр атамалар, нинди генә максат белән куелсалар да, җиңеп чыга алмаганнар. Кыска, матур, җиңел әйтелешле, эчкерсез татар атамалары халык тарафыннан үзеннән-үзе сайланып алынган!

Төрле язмышлар белән Алабуга төбәгенә күчеп килгән гади рус халкы татарлар

белән үзара мөгамәләдә начар яшәмәгән. Көндәлек тормышта бер-берсенә таяныч та булып киткәннәр. Чөнки аларны Мәскәү белән Петербург туендырмаган, киресенчә, гасырлар буе талап кына торган. Мәсәлән, Петербургка патша өстәленә кыйммәтле балыкларны хәтта тере килеш илтеп житкерә торган булганнар. 1850 елда Алабуга шәһәре үзәгендә булган зур янгыннан соң, күп кенә татар гаиләләре русларны үзләренә сыендырганнар. Татарларның күбесе шәһәр читендәге бистәләрдә яшәгән.

Бу якларга көчләп килгән күп кенә урысларны керәшен авылларына урнаштыралар. Керәшеннәрнең христиан диненнән кабат исламга кайту омтылышын истә тотып, һәр авылга күзәтче итеп берәр урам яисә бер-ике гаилә булса да урыс кешеләрен урнаштыралар. Ә алар исә татар телен яхшы үзләштерәләр, ике халык арасында арадашчы булып китәләр. Юкка чыгарылган татар авыллары исемнәрен керәшеннәр үз хәтерләрендә ничек сакласалар, урыслар да әлеге авылларны шулай дип атый башлыйлар. Мәсәлән, Тарловка (Тарлау), Казиле, Чыршы һ. б. Шул ук вакытта якын-тирәләрдә урманнарга посып Морт, Юраш (Йобраш), Абалач кебек борынгы мөселман авыллары яшәп киләләр.

Унжиденче гасыр исәпкә алу кенәгәләре буенча төзелгән картада Алабугадан ерак түгел хәзерге Костинеево авылы урынында Миево авылы күрсәтелгән. Миево исеме исәпкә алучылар тарафыннан бераз бозылып язылa. Моны урысларның татар телен аңлап бетермәү нәтижәсе генә дип әйтергә була. Ул Енеево дип аталгандыр. Ул авыл янында хәзер дә «Поля Енеево» сакланган. Беренчедән, борынгы татарларда янәй кабиләләре булган. Икенчедән, Кара бәк шәжәрәсендә Жәнан (Жәнәй) исемле кеше бар. Алабуга якларында аның жирләре булуы бик ихтимал. Костинеево үзе «кости енеево» дигән сүздән торадыр. Бу якларда сөякләре генә калган авыллар булган. Мәсәлән, Илмәт (Әлмөхәммәт) авылы янындагы Талбасма авылының фажигале язмышы шундыйлардан. Әле аларның сөякләре һаман да күмелмичә ята диләр, вакыт узу белән жилләр генә аларны туфрак белән каплаттырганнар. Еш кына яу килгәч, икенең берсе булган: йә биреләсең, йә үләсең.

Абалач авылы өлкәннәре мондый бер ядкәрне хәзер дә горурланып сөйлиләр. Аның халкын чукындырырга урыслар Тулбай ягыннан килгәннәр. Башта Тулбайны чукындырганнар. Авыл кечкенә булганлыктан, үзләрен якларлык көчләре житмәгән. Я безне үтереп бетерәләр, я чукынабыз, исән калабыз дигәннәр. Алар икенче юлны сайлаганнар. Ә Абалач аксакаллары дипломатларча эш йөрткәннәр. Урыслар киләсе юлга чыгып, казан асып, итләр пешереп, сыйларга әзерләнеп торганнар. «Ашагыз, эчегез, әмма авылга кермәгез, кан түкмәгез. Бу авыл бик зур, исән чыкмассыз, борылып китегез!»—дигәннәр. Чыннан да авыл бик зур (алты йөзләп йорт), сугышчан көчләре дә житәрлек булган. Балаларны, хатын-кызларны урманга качырып, ирләр сугышка әзерләнеп, бер генә мәртәбә каршы тормаганнардыр.

Шуна охшаш хәл Морт авылында да кабатлана: «Русларның татарларны көчләп чукындырып йөрүләрен ишетеп, Йөзәй һәм Бигәй бабайлар сыерларын суялар. Армалы авылы башына чыгып, зур казан асып, ит пешереп, русларны сыйлап: «Бу якта авыллар юк инде,»—дип, русларны озатып жибәрәләр, халыкны афәттән саклап калалар» *(Г.Ганиева. «Алабуга нуры», 1995 ел, 14 гыйнвар).* Элеккеге Бондюг, хәзерге Менделеев янындагы Бәзәкә авылы да үзен шул рәвешле саклап калуы тарихта билгеле.

Нократ һәм Чулман арасында яшәгән татарлар кысылуга дучар булганнар. Монда үз динеңне, телеңне саклап калу бик жиңелдән булмагандыр.

## Алабугада ничә мәчет булган?

Алабуга шәһәренә һәм өязенә ревизия ясаган Вятка губернаторы 1887 елда Алабугада бер агач һәм бер таш мәчет булуын билгеләп үтә. Агач мәчет хәзерге Тукай һәм Мәскәү урамы чатларындагы Сельхозтехника тирәсендәрәк, урам уртасында урнашкан була. Шәһәр музеенда аның фоторәсеме саклана. Мәчет 1930 нчы елларга кадәр эшли. Ябылгач, аны төрлечә файдаланалар. Алтмышынчы

елларда анда һөнәр училищесының тулай торагы иде. Шул иске мәчет бинасы 1970 нче елларда сүтеп ташланды. Бу иске агач мәчетнең төзелеше турында О. Фонарева мәкаләсеннән *(«Новая Кама», 1994, июль)* белергә була.

Алабуганың указлы мулласы Әхмәт Мәсәгутов 1866 елның 3 декабрендә Вятка губернасы идарәсенә Алабуга шәһәрендә таш фундаментлы агач мәчет төзү турында үтенеч яза. Зур мәчет салырга теләсәләр дә, күп сәбәпләр аркасында ул кечкенә итеп салына. Берничә мәртәбә үзгәртергә планлаштырыла, ләкин ул гамәлгә ашмый. Мәсәлән, мулла Әхмәтзәки Хужаханов 1914 елда Вятка губерна идарәсенең төзүчеләр бүлегенә мәчетнең яңа проектын тапшыра. Ләкин сугыш башлану сәбәпле, аннан соң инкыйлаплар аркасында мәчет үзгәрешсез кала. Еллар үтү белән башка мәчетләрнең фаҗигасе дә аны читләп үтми—беркөн манарасы киселә. Әле бик иске булмаса да, бигрәк урам уртасында утыра дип, җитмешенче елларда аны сүтеп тә ташлыйлар. Туксанынчы елларда, заман җилләре бераз уңай якка исү белән үк, мөселман кардәшебез ярдәме белән шул ук урында Әл-Кадыйр мәчете калкып чыкты. Ул шулай ук җыйнак итеп, кызыл кирпичтән салынган, халкыбызны әле озак еллар үзенә тартып торыр дип уйлыйбыз.

1887 нче елларда күрсәтелгән таш мәчет кайда булган соң? Аның Мәскәү урамы, 70 нче йортта урнашкан булуы мөмкин. Архив документлары буенча ул шулай санала. Ләкин тышкы күренеше буенча ул мәчеткә охшамаган. Ул мәчет итеп салынмаган, бәлки аның урынына файдаланылган гына булуы мөмкин. Бу фикерне миңа археолог А. Халиков бер килүендә әйткән иде. Ул бинаны ана махсус күрсәттем.

Мәчет губернатор күзенә күренгәч, кеше күп йөрерлек зур бинада урнашуы мөмкин. Бәлки әле ул Чапаев урамындагы хәзерге кибет урынында булгандыр. Егерменче гасыр башларында яткан зур-зур таш өемнәре, ихтимал, шул мәчет хәрабәләредер. Таш мәчетнең кайда булганлыгы киләчәктә ачыкланмый калмас кебек. Әнә бит, тау башындагы ялгыз корылманың кайчандыр мәчет булуын профессор А. Халиков фәнни рәвештә исбатлады. 1993 елдагы казынуларында ул аның фундаментында искиткеч төгәллек белән кәгъбәгә карап торган өчпочмаклы михрабны тапты. «Җеннәр шәһәрчеге», «Шайтан каласы» дип, тагын әллә нинди әшәке сүзләр белән хәтеребезне пычратырга тырышсалар да, борынгы бабаларыбызның «Таш мәчет», «Изгеләр мәчете» дип йөрткән, саф йөрәкләреннән чыккан атамалары үткән кара эшләрдән якты нур булып калкып чыкты.

Иван Шишкин үзенең «Алабуга тарихы»нда (9 бит) шулай ук тау өстенә мөселманнарның изге кеше каберенә килүләрен, әмма аның исемен дә, кабер урынын да әйтмәүләрен, дини сәбәпләр аркасында сер итеп тотуларын яза. Әле 1960 нчы елларда да бу калкулыкта гарәп графикасы белән язылган ташның саклануы билгеле. Бу ташны тапкан тарихчы бүгенге көндә Алабуга шәһәрендә яши. Ул әле үзенең сүзен әйтер дип көтәбез.

## Археологлар ни сөйли?

«Татарстан АССР ның археологик карталары»на караганда, Алабугада археологик казынулар унтугызынчы гасырдан башлана. Бу якларда А. А. Спицын, Ф. Д. Нефедов, М. В. Малахов, И. А. Талицкая, А. В. Збруева, В. Ф. Генинг, В. П. Мизина, С. В. Кузьминых, Р. Фәхретдинов, А. М. Ефимова, А. Халиков һ. б. галимнәр эзләнү-тикшеренүләр алып барганнар.

Алабуга шәһәрлегендә ананьино (безнең эрага кадәр 6-5 гасырлар), пьянобор (безнең эрага кадәр 3 гасыр—безнең эрада 3 гасыр), имәнкискә ( б.э. 5-7 гасырлар) культуралары һәм аннан соңгы гасырларда яшәгән болгар-татар эзләре табыла. Бу язмада менә шул болгар-татар эзләре турында гына сөйләнер.

Профессор А. Халиков җитәкчелегендә 1993 елда алып барылган зур казу эшләреннән соң Ак мәчетнең фундаментлары ачыла. Ул X—XVI гасырлар арасында мәчет тә, шул ук вакытта кальга (крепость) булып хезмәт итә.

Алабуга тирәли «Иске йорт», «Кымыз», Котловка янында «Шишка», Свиногорье янында «Донгузово поле», «Каравашек» дигән җирләр аеруча игътибарга лаек.

Свиногорье авылыннан көнчыгышкарак Отарочка (Утар) елгасы буенда 1943

елда В. М. Мизина тарафыннан борынгы шәһәрлек (городище) табыла. Андагы 30-40 см культуралы катлам һәм керамикаларыннан бигрәк, ул урынның исеме игътибарга лаек: авыл халкы ул җирне «Донгусово поле» («Дуңгыз басуы») дип йөртә икән. Борынгы заманнарда төрки халыклар ел исәбен 12 хайван циклыннан торган календарь буенча алып барганнар. Бәлки элек бу җирләрнең хуҗасы Дуңгыз исемле булгандыр. Мәҗүсилектә булган борынгы бабаларыбыз өчен бу гадәти исем. Ул безгә төрки халыкларының бу җирләрдә бик борынгы гасырлардан бирле яшәп килүләренә тагы бер өстәмә дәлил. Бу якларда әле болгарлар килгәнче үк мәҗүси төркиләр яшәгәннәр, ислам динен дә алар бер көндә генә кабул итмәгәннәр. Төрки эсегелләр, берсулалар әле унынчы гасырда да Тәңре динендә булалар. Яшәү рәвешләре белән алар болгарлардан берни белән дә аерылмаганлыгын шул заманнарда бу якларга килеп чыккан илчеләр язып калдырганнар. Алабугада Тунгусков фамилиясен йөртүче кешеләр аз түгел. Свиногорье дигән авыл исеме дә дуңгызны русчага тәрҗемә итүдән генә килеп чыккандыр.

Свиногорье авылының көнбатыш ягында тагын бер шәһәрлек бар—ул «Каравашек» дип йөртелә. Мәйданның озынлыгы 142 м, киңлеге 33 м. Бу урын шулай ук тарихта күптән билгеле Кара бәк исеме белән бәйледер, аның җиредер.

Котловка авылының төньяк-көнчыгыш ягында, авылның көнчыгышыннан башланып елгага кадәр сузылган 110 м биеклектәге калкулык «Шишка» исемен йөртә. Шишка-шеш—шулай ук татар сүзе. Бу шәһәрлек 1888 елда А. А. Спицын тарафыннан ачылган. Ул аның болгар чорына каравын әйтә. 1952 елда Т. А. Талицкая шулай ук аны болгар чорында барлыкка килгән дип билгели һәм аның X—XIII гасырларга каравын белдерә. Болгарлар өчен бу биек урынерактан күзәтү өчен хезмәт иткәндер, төньяк-көнчыгыштагы форпостларның берсе булгандыр.

Котловка авылының исемен Котлы бәк белән бәйләп әйтеп үтелде инде. Котлы сүзе кергән авыллардан тагы Балык бистәсе районында Котлы-Бөкәш авылы бар. Алабугада Котлов (керәшен татарлары), Котлыбаев фамилияле кешеләр хәтсез генә.

Алабуга районында шулай ук болгар-татар чорына караган Кумыс (Кымыз) бар. 1959 елда авыл уртасындагы каберлектән кеше сөякләре арасыннан болгар чорларына караган, коелып ясалган бакыр прәшкә табыла.

Алабугадан 4-5 км ераклыкта Луговой поселогыннан көнчыгышка таба Отарка (Утар) күле янында «Иске йорт» («Старое селище») барлыгы билгеле. Ул 1884 елда Ф. Д. Нефедов тарафыннан тикшерелгән. Бу урында ком арасыннан кеше сөякләре, чүлмәк кыйпылчыклары һәм учак калдыклары күренә. Галимнәр аларны XIV-XVI гасырларга, соңгы болгар-татар чорларына караган булырга тиеш диләр, чөнки Татарстан җирендә «Иске йорт» дип аталган торак урыннары барысы да шул чорда барлыкка килгәннәр. Шул урыннан ерак түгел бер каберлектә мөселманча күмелгән кеше сөякләре табыла.

Казан ханлыгы чоры истәлекләреннән күп очракта каберлекләр һәм алардагы ташлар гына сакланып калганнар. Чөнки ул чордагы шәһәр-авыллардан кешеләр китмәгәннәр. Татарлар китсәләр, ул урыннарны урыслар биләп алганнар. Нәтиҗәдә, культуралы катламнар җимерелгән, капланган, ташлары юкка чыккан, алардан яна корылмалар барлыкка килгән. Борынгы Алабугада да шул ук хәл булган. Татар йорт-кураларында урыслар яши башлыйлар һәм хәзер инде ул урыннарда татар катламын табу бик авыр.

Алабуганың иске өлешендә өч татар зираты билгеле иде. Беренчесе—пединститутның тулай торагы һәм К. Ф. Елизовлар йорты урынында. Икенчесе—Чапаев урамында, өченчесе—хәзерге мәңгелек ут һәм Спас чиркәве арасындагы җирләр. Алар барысы да очраклы рәвештә генә килеп чыкканнар: алмагач утыртканда, йорт нигезе казыганда һәм һәйкәлгә урын әзерләгәндә. Туксанынчы елларга кадәр фәнни рәвештә берсе дә өйрәнелмәгән иде. Бәхетебезгә, Алабуга пединститутында тарих-археология факультеты ачылып, калабызның борынгы тарихына игътибар артты. Археолог Альберт Нигамаев хәзерге вакытта зур тикшеренү эшләре алып бара. Бик күп каберлекләр ачып, казылмаларда табылган әйберләрне өйрәнеп, археологлар Алабуга шәһәре X гасыр ахырында—XI гасыр

башларында барлыкка килгән дигән фикер әйттеләр.

Алабуга тирәсендә уналтынчы гасырның уртасына кадәр бер генә славян-рус торак урыны булмаган. Трехсвятское исемен бирү шәһәрнең борынгы исемен оныттыру теләгеннән эшләнгән. Трехсвятское исеме бер генә борынгы картада юк. Ә менә 1780 елга кадәрге карталарда Алабуга атамасы чатнап ята. Мәсәлән, 1635 елгы Ю. Данкерт картасында ул «Албуга» дип, Исаак Массаның 1636, 1640, 1662 елгы карталарында ул шулай ук «Албуга» дип бирелә. Хр. Вейгельнең 1698—1712 елга караган картасында ул «Алабуга» дип теркәлгән.

Шулай булгач ничек итеп Алабуга шәһәрен Трехсвятское урынында барлыкка килгән дип әйтергә мөмкин? Алабуга шәһәренең тарихы мең елдан да ким түгел. 2007 елда ул үзенең меңьеллыгын тантаналы рәвештә бәйрәм итәчәк.

## Алабуга Болгар-татар иленең чигеме?

Болгар-татарлар Алабугадан көнчыгышта да яшәгәннәр. Г. Саттаров уналтынчы гасыр картасында *(Материалы по истории русской картографии, Киев, 1899)* Кама елгасында Алабуга шәһәреннән өстәрәк Алатур шәһәре булуын да әйтеп үтә *(Г. Саттаров. «Атамалар дөньясына сәяхәт», 107 бит)*. Ә бәлки бу атаклы Турай авылыдыр. Турай авылы үзенең дүртенче-бишенче гасырга караган 11 курганы белән күптән инде тарихта дан тота. Шулкадәр сугышчы юкка гына бу җирдә башларын салмаганнардыр. Аларда бөтен киемнәре һәм сугыш кирәк-яраклары белән бай сугышчылар күмелгән.

Галимнәр аларны һуннар диләр. Турай авылы янында шулай ук бик борынгы мөселман зираты да бар. Казан ханлыгы чорыннан ук Иж елгасы буенда Әгерже, Тирсә, Аккужа кебек борынгы татар авыллары яшәп киләләр. Явыз Иван яуларыннан соң татарлар Идел, Чулман буйларыннан еракка куылалар. Татарлар үз туган якларына, инде ничә буыннар алышынса да, бик әкренлек белән генә кайталар. Алабуга олылары Туйгужа белән Аккужаның оныкларының оныклары кайларда яшиләр икән?

А. П. Смирнов «Идел болгарлары» китабында шулай ук Сарапул шәһәре тирәсендә дә унДүртенче гасырга караган мөселман каберлекләре булуы турында яза.

Димәк, Алабуга шәһәрен әле болгар-татар иленең чиге дип әйтергә ярамыйдыр. Бары тик бу тирә-яклар житәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгәннәр генә. Ә Алабуга якларында төрки халыклар бик борынгы заманнардан бирле яшәп килгәннәр. Каберлекләр ачылган очракта да мөселманча күмелмәгәннәрен төрки халык түгел, дип әйтергә галимнәр ашыкмасыннар иде. Чөнки төрки халыклар мөселманлыкка бик озак күченгән.

Хәзерге вакытта Алабуга якларындагы урыс авылларының төркичә аталулары гына да күп нәрсәне аңлатадыр. Танай—Таң ай, Тарлау—урман кисеп ясалган иген жире, Армалы—Әрәмәле, Казили - Каз иле, Хлыстово—Ылыс тау, Качка—Качкын, Котловка—Котлы, Татарские Челны—Татар Чаллысы, Чирши—Чыршы кебек дистәләрчә урыс авыллары исемнәре борынгы болгар-татар бабаларыбызның кайтавазы булып яңгырый. Ләкин, кызганычка каршы, без аларны бик начар ишетәбез, белгәннәребезне дә оныта барабыз. Бу өлкәдә эшләүче галимнәребез дә ифрат аз. Хәтерләрне уятасы иде! Хәтерсез халыкның гомере дә кыска була диләр бит.



Адлер
Тимергалин

# ТАТАРГА НИГӘ КАГЫЙДӘ?

Латин әлифбасына кайту перспективалары турында «Казан утлары»нда язган идем инде (2006, №1). Бу—якын яки ерак киләчәк эше. Ә бүгенге көнебез?

Гамәлдәге алфавитыбыз начар да булды ди. Ләкин шул кимчелекле, гарип алфавит эчендә дә үтәлергә тиешле орфография кагыйдәләре бар, булырга тиеш, югыйсә болай да безнең психологиябездә талымсызлык һәм канунсызлык биниһая тантана итә.

Без әлеге барлы-юклы орфография кагыйдәләрен үтибезме соң? Үтәсәк, ничек үтибез?

Юк, без аларны үтәмибез һәм, еш кына, аңлы рәвештә бозып, үз белдегебез белән яна кагыйдәләр чыгарып маташабыз, соңгы вакытларда язуыбызда адәм ышанмаслык чуарлыкка, хаоска юл куябыз.

Татардагы мондый тәртипсезлек күптәннән, хәтта борынгыдан ук килә. Галимнәр язылыштагы шапшаклыкның Сәедгәрәй хан ярлыгында да күзәтелүен искәртәләр. XIX гасырда Казанда татар китаплары цензоры булган И. Н. Березин татарларның сүз язылышына игътибар бирмәүләреннән зарлана.

Моннан ун еллар элек кенә «Иман» нәшрияты Ризаэддин бине Фәхреддиннең «Җәвамигуль кәлим шәрхе» исемле китабын кириллицага күчереп бастырып чыгарган иде. Без «Иман» нәшриятына рәхмәтләр уку белән бер үк вакытта китаптагы орфографик хаталарны тавык та чүпләп бетерешле түгел икәнен әйтергә тиешбез. Мондый хаталар дөньякүләм кыйммәтле китапның дәрәҗәсенә тап төшерәләр. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китим, бу китапны рус теленә тәрҗемә иткәндә, наширләр мәгълүм күләмдә табыш та алырлар иде.

Гәзит-журналларыбыз да элементар хаталардан хали түгел. Матбугат үзәкләре арасында бу яктан иң ышанычлысы һәм пөхтәсе, ихтимал, «Мәгариф» нәшриятыдыр. Ул татарча текстка, китапка карата традицион таләпне киметмәде, корректорлары болгавыр заманыбызда да «планка»ны түбән төшермәделәр, мөхәррирләре яңалыкка талымсыз булмадылар, төрле «аурупа», «ырынбур», «үктәбер», «кәмпитер»ләр каршына тиешенчә(!) консерватив киртә кордылар.

Ярар, конкрет мәсьәләләргә, аерым сүзләргә һәм атамаларга күчсәм, файдасы күбрәк булыр төсле.

Безнең өчен тарихи һәм әхлакый әһәмияте аеруча зур булган бер сүз бар, ул да булса—гарәпчә «көнчыгыш» мәгънәсендәге *«шәрык»* сүзе.

«Шәрык» дип язаргамы, әллә «шәрекъ» дипме? «Шәрык» дип язганда «ы» сузыгы үзеннән соң килгән «к» авазының калын булачагы турында кисәтә, шуна күрә сүз ахырында русларның калынлык билгесен кую кирәк булмый. 1983 елгы орфографик сүзлегебездә «шәрык» варианты гына теркәлгән, иң соңгы орфографик һәм орфоэпик

сүзлекләрдә (2002, 2004) дә шулай. Шуна да карамастан, кайберәүләр «шәрекъ» дип язуларын дәвам итәләр. Төкерәләр алар синен сүзлегенә һәм күзлегенә! Куллары шулай язарга күнеккән, «кызыл остазлары» шулай өйрәтеп калдырган.

«Буыннар каткач, эш белү унайсыз»дыр, әлбәттә,—монысы Акбайга да анлашыла торган сакаллы хакыйкать, ләкин нигә фәнни сүзлекләргә каршы барырга? Башта фикерегезне дәлилләгез, исбат итегез, бәлки сезне анларлар да, сезнен катнашлыкта яна орфографик сүзлек төзелер?

«Шәрекъ» варианты яклылар сүзнең теге яки бу телдә дөрес язылышын асылда транскрипция дигән нәрсә белән бутыйлар. Хәер, боларнын «шәрекъ» рәвешендәге транскрипциясендә «е» хәрефе кайсы авазны белдерә—русча «е» (татарда—йе, йы) яки «ё» нымы (татарда—йо), әллә «э»нымы? Димәк, «шәрекъ» дип язу транскрипция буларак та яраксыз, чөнки рус хоруфатыннан файдаланучы башка халыклар да аны дөрес укымаячак. Өстәвенә татар күнелен калынлык билгесе дә рәнжетә, тешкә тия. Ул бит латиннан «урлап», асты өскә әйләндерелгән һәм койрык тагылган «р» хәрефеннән башка нәрсә түгел.

«Кәкре хочу, бөкре делаю»,—дигән татар, әле билингвизм дигән төшенчәне белмәгән килеш тә.

Латин графикасына күчкәннән сон мондый бәхәсләргә урын калмаячак.

Транскрипция дидек. «Гарәпчә—татарча—русча алынмалар сүзлеге»нә кергән байтак кына сүзләр транскрипциядә бирелгәннәр, шуна күрә алар орфографик сүзлеккә шул килеш теркәлми, ләкин аларны жәя эчендә анлатыбрак күрсәтсән, файдага гына булыр иде. Менә сүзлектән берничә генә мисал: *Аварә, Ашна, Имля, Истыйлях, Кәфеш, мәжлис, Никях, Фәллях, Ядкяр*. Без бу сүзләрне нигездә әвәрә, әшнә, имла, истилах, кәвеш, мәжлес, никах, фәллах, ядкәр рәвешендә кабул иткәнбез, шулардан читләшмәскә кирәк дип уйлыйм.

*«Хәлиф—Хәлифә»* мәсьәләсе.

Хәлифә—Пәйгамбәрнен урынбасары, хөкемдар; берәүнең вафатыннан сон эшен дәвам иттерүче, варис (русча—преемник). Мөхәммәд галәйһиссәламнен эшен дәвам иттерүчеләрдән беренче хәлифәләр: *Әбү Бәкер, Гомәр, Госман һәм Гали хәзрәтләр.*

«Татар исемнәре сүзлеге»ндә *Хәлиф—Хәлифә* ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре буларак теркәлгән. Ләкин гарәптә хәлифә һәм хәләф сүзләре генә бар дип беләм. Сонгысынын да мәгънәсе беренчесенекенә тәнгәл диярлек.

Татардагы «хәлфә» сүзе (ягъни мәдрәсәдә имамнын ярдәмчесе, урынбасары) «хәлифә» нигезендә барлыкка килгән.

Татарда мәшһүр Хәлфиннәр фамилиясе дә хәлфә сүзеннән. Ул рус калыбы буенча ясалган (мәсәлән, аларда Марфин фамилиясе хатын-кыз исеме Марфадан булган кебек).

Кызганычка каршы, бүген абруйлы басмаларда да «хәлифә» сүзе урынына «хәлиф» дип язуга тап буласын. Монда, күрәсен, татардагы *Хәлиф—Хәлифә* исемнәре бутый торгандыр, кайберәүләр хәлифәне хатын-кыз женесеннән дип күз алдына китерәләрдер. «Татар исемнәре сүзлеге»ндә дә анлатманын фәкать гарәптән кергән «хәлифә» сүзенә генә каравы кистереп әйтелмәгән,—бусы да саташтыра. Баштарак ир балага «хәлифә»нен «хәләф» дигән вариантын ат итеп кушу галәткә кергән дә, аннары, бик ихтимал, кыз балаларга Хәлифә исеме куша башлаганнардыр дип фараз итә алабыз. Ахырда инде «хәлифә»дән «хәлиф» ясап, аны ир-ат исеменә әйләндергән булсалар кирәк. Монда «хәлифә»нен русча «калиф» дип аталуы да рус теле йогынтысында укыган һәм тәрбия алганнарны бик жинел саташтыра.

Шушылардан чыгып, без мөселман илләрендәге элекке идарәчеләр татарча китапларда да *хәлифә* дип аталырга тиеш дибез.

Күренекле татар язучысы Атилла Расихнын исемен ничек язу да бәхәслерәк нәрсә. Әти-әниләре (әтисе мулла кеше, бабасы—ишан) ана исем кушканда мәшһүр Аттила исеменә чак кына үзгәреш кертеп, татар исемнәренең ахырында еш очрый торган «улла»га охшатыбрак, Атилла дигән ат биргәннәр.

Тарихчы Ә. Мөхәммәдиев жиһангир Аттиланы «Атилла» дип яза, Р. Әхмәтьяновта да, М. Глуховнын рус телендәге «Казанский ретро-лексикон»ында да шулай, ә «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә төп исем—Аттила һәм жәя эчендә Атилла варианты да

бирелгән. Тел белгече Г. Саттаров татарларда очрый торган Атилла исемен Иделле исеменең борынгы варианты (Атилле) дип аңлата. Бу мәсьәләдә Татарстан Фәннәр академиясе академигы М.Зәкиевнең фикерен кабатлап әйтү урынлы булыр: «Борынгы грек язмаларында сакланган бу исем һәрчак ике *т* белән язылган, шуңа күрә аның Идел (Атил) белән бәйләнеше булуы шикле».

Шулай итеп, «интернациональ» язылыш *(«Аттила»)* бердәнбер дөрес вариант булып калырга тиеш, җиһангирга кәләпүш кидермик.

Аерым-аерым *арыслан* һәм *Арслан* язылышлары ни өчен кирәк дип сорасалар, мин аңа канәгатьләнерлек җавап таба алмыйм. Берәү дә таба алмаячак.

*Тополь—тупыл.* «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»тә (1998) фәкать «тополь» язылышы гына кабул ителгән. Шулай да телебездә ике төрле язылыш йөри бирердер сыман. Рустан кергән «тополь» сүзе нәфисрәк яңгырый, әлбәттә, ләкин татар телендә боларның кайсысы беренчел? Безне *тубылгы—тубыл—тобол—тупыл сүзләренең* охшашлыгы сагайта. Рус теле этимологлары «тополь» сүзен гомумславян сүзе дип карыйлар һәм ул латин теленнән («populus» сүзеннән) алынган дип фараз итәләр. Алай булганда да беренчел чыганакта «л» калын әйтелешле була. Сүзнең русча яңгырашы нәфис дип мөкиббән китмик әле. Алайга китсә, «Казань» сүзе дә «Казан»нан нәфисрәк яңгырый.

Нашатырьмы, нишатырмы?

*Нишатыр* сүзен без русларга кадәр үк белгәнбез. Ул гарәпчә *нишадир* сүзеннән. Ак төстәге зәһәр ачы тоз, аммоний хлориды була инде. Ә «нашатырь» термины рус теле аркылы телебезгә соңрак кергән (татарча химия дәреслекләрендә шулай алына). Көнбатыш Европа фәнни терминологиясендә «нишатыр»/«нашатырь» сүзе юк, төрек телендә—*нишадир*. Борынгы чорда нишатырны Мәвараэннәһердә һәм Сицилиядә тапканнар, Көнбатыш Европада аны *татар тозы* дип тә йөрткәннәр әле. Шуңа күрә, минем иркемдә булса, татарча химия дәреслекләрендә дә *нишатыр* язылышына өстенлек бирер идем. Шулай ук халык теленә кереп урнашкан *гөлсирин* сүзенә (глицерин) дә. Хәер, монысына шигем дә юк түгел, бу очракта *нитроглицерин* кебек чыгарылма терминнар комачаулый.

Русча *«индеец»* атамасы Көнбатыш Европа телләрендә *Һиндус* сүзе белән бирелә (төгәлрәк итеп әйткәндә, киресенчә—һиндус атамасы рус теленә индеец дип тәрҗемә ителгән). Мәсәлән, Европа телләрендә күктәге *Һиндус йолдызлыгы* атамасы Һиндстанга түгел, бәлки Америка һиндиләренә—һиндианнарга мөнәсәбәтле. Руслар Һиндстан халкын Америка аборигеннарыннан аеру өчен *индиец* дип һәм икенчеләрен индеец дип язу юлына басканнар. Бик ясалма алым, әлбәттә, ләкин буталып бетмәс өчен ярап тора. (Шушындый ук әкәмәт кагыйдә рус терминологиясендә *гарем* һәм *харам*, *дехкан* һәм *дихкан* терминнарында да күзәтелә, үзләре дә буталып бетәләр, башка милләт укучысын да бутыйлар.)

Татарчада ин кулае—«һинду» (Р. Фәхреддин) яки «һинди» (патша заманында мөселман университеты төзим дип халыктан акча җыеп йөргән *Һинди Минһаж* кушаматлы татарны хәтерлисезме?) һәм «һиндиан» терминнары булыр иде (соңгысын, дөрес, «индианнар» формасында, беренче булып «эмигрант» тел белгечебез Р. Әхмәтьянов тәкъдим итте шикелле, һәрхәлдә абруйлы галим шуны яклый дип беләм).

Элегрәк, шаулатып-гөрләтеп партия съездлары үткәрелгән әкияти заманнарда, съезд үтү белән ашыгыч рәвештә аларның «*программный* документлары» төрле телләрдә бастырып чыгарыла иде. Татарча съезд материалларында «программный» мәгънәсендә «*программ*» сүзе алынганын хәтерлим. Татар теле мондый «койрыксыз», «өтек» сүзләргә каршы түгел һәм халык телендә гадәти булган бу алым әдәби телдә дә яшәргә хокуклы. Тик конкрет бу очракта ике «м» язу шикләндерә. Берсе генә булса җитмиме? Катлаулы мәсьәлә түгел инде монысы, ләкин галимнәребез үзләренең саллы фикерләрен әйтсәләр әйбәт булыр иде. Тел экономиягә омтыла—минем бар булган дәлилем шул гына.

Менә без Венера—Зөһрә, Марс, Юпитер, Церера кебек эреле-ваклы планета һәм аларның Европа, Титан, Ганимед кебек иярченнәренең исемнәрен, кагыйдә буенча, баш хәрефтән язабыз. Шулай тиеш. Әмма Җир планетасы, аның иярчене

Ай һәм хәтта Кояш турында (астрономик мәгънәдә) сүз барганда гәзит-журналларда аларны юл хәрефеннән язу бик еш күзәтелә. Күбәүләр соңгыларын йолдыз, болыт кебек гадәти төшенчәләр итеп күзаллыйлар. Бу, әйтик, Алла дәрәҗәсендәге Кояшка һәм Айга карата, ким дигәндә, гадел түгел бит. Җир-анага карата инде әйтеп тә торасы юк.

Астрономия терминнары турында сүз чыккач, бер уңайдан, русча «спутник» терминының татарчасы турында да әйтеп китмичә булмас. Әдәбиятка һәм сәнгатькә якынрак торган авторларыбыз, «иярчен» терминын ошатмыйча, «юлдаш» сүзен өстен күрделәр. Тик «юлдашлык» тигез хокуклы булуны күздә тота, ә Ай, Титан, Ганимед кебек күк җисемнәре үзәк планеталары белән «бер дәрәҗәдә» түгел, алар *сателлитлар*, ягъни иярченнәр. Әле XIX гасырда русча чыккан китапларда да астрономиядә «спутник» сүзе булмаган, аның урынына «ай» сүзе кулланылган («Фобос белән Деймос—Марсның айлары» дип сөйләгәннәр һәм язганнар, ягъни бу очракта «ай» сүзе юл хәрефе белән язылган).

Халыкара термин булган «сателлит» сүзе, мәсәлән, «сателлоид» төшенчәсен ясауда да катнаша. Бүген исә «сат» тамыры кергән сүзләр радио һәм телеэлемтә ысуллары турында сөйләгәндә әледән-әле очрый. Бусы—бер. Икенчедән исә, астрономиядә «попутчик» төшенчәсе дә бар. Мәсәлән, бер төркем күк җисемнәре (метеор җисемнәр) Юпитер планетасы орбитасы буенча ук анардан 30 градус алдан һәм 30 градус артта калып Кояш тирәли хәрәкәт итәләр. Менә боларын, вак булуларына карамастан, чыннан да Юпитерның «юлдашлары» («орбитадашлары») дип атарга мөмкин инде.

Узган гасырның җитмешенче елларында безнең малайларның күбесе космонавт булырга хыяллана иде. Хәзер Рәсәйдә космонавтның базары төште. Рәсәйдә дим, чөнки Америкада һәм, гомумән, Гаребтә һәм Шәрыктә «астронавт»ларга әүвәлгечә ихтирам белән карыйлар.

*«Космонавт»* һәм *«астронавт»*. Гадәттә сүзлекләр аларны синонимнар дип, ягъни мәгънәдәш сүзләр дип саныйлар. Бездә—«космонавт», ә көнбатыштагылар «астронавт» була дигән караш тамыр җәйгән. Ләкин егерме беренче гасырга чыкканчы ук инде бу ике терминның тәңгәл төшенчәләр түгеллеге сиздерә иде.

Проблемалы сорауны кабыргасы белән куям.

Гагарин—космонавтмы, түгелме?

Гагарин—астронавт түгел, чөнки ул башка күк җисемнәренә очмады.

Гагарин, Титов, Николаев, Терешкова, Савицкаялар һәм, әйтик, америкaн Джон Гленн Җир планетасы тирәсендә, аның тартымыннан ычкынмаган халдә, үзенә бер төрле «каботаж» очышлар гына ясадылар. Мин аларның очышын «космик» дип түгел, «субкосмик орбиталь очыш» дип атар идем, чөнки алар фактта тирән (ерак) космоска ук чыкмадылар.

Ә менә Ай тузанында беренче булып аяк эзләрен калдырган Нейл Армстронг—астронавт һәм космонавт.

Кыскасы, киләчәктә ерак планеталарга сәяхәт итүчеләрне *астронавт* дип атарлар. Ләкин терминологик тезауруста (фондта, хәзинәдә) *космонавтика* сүзе дә калыр.

Йолдызлы галәмнәрдән үзебезнең милли космосыбызга, Казан галәменә әйләнеп кайтыйк. Беләсезме, ул галәм бернинди канунга буйсынмый кебек!

Борынгы Казан турындагы әдәбиятта еш телгә алына торган Отуч мәчетенең *«Отучев мәчете»*, «Отыч мәчете», «Утыз мәчете», «Үтәч мәчете» кебек язылышлары очрый. Вариантлар күпкә китә, һәм боларны язылыш вариантлары дип кенә дә булмый, алардан төрле мәгънә чыгарырга мөмкин. Бу хакта тарихчылар белән телчеләргә уртак бер фикергә килергә күптән вакыт.

Иске Казан шәһәрендәге *«Адмиралтейская слобода»* татарча чыганакларда еш кына Адмиралтейство бистәсе дип алына, ләкин бистәнең электә «Адмиралтия» дигән исеме дә булганлыгын искә төшерсәк (немец атамалары бирү белән мавыккан Петр патша заманнарында ул исем беренче башлап кушылган булырга да мөмкин), бистәне һәркемгә аңлаешлы Адмиралтия бистәсе дип атау кулай булачак.

*Кәҗә бистәсе*. Хәлбуки еш кына татарча китапларда Иске Казандагы «Кизическая слобода»ны *Кәҗә бистәсе* дип алалар, ә ул бөтенләй башка бистәгә—

янәшәдәге «*Козья слобода*»га туры килә. Шуңа күрә «*Кизическая слобода*»ны татарча китапларда гади сөйләмдәгечә *Кижица бистәсе* дип алу кулайрак төсле, *Кизик бистәсе* дип кабул иткәндә мәгънә төгәллеге сакланыр иде («Татар энциклопедия сүзлеге» атаманың грекча Кизикос сүзеннән алынганлыгын күздә тотып, шушы язылышны кабул иткән).

*Елан—жылан*. Беренчесе кулайрак төсле-төслесен, ләкин житәрлек дәлилләү кыен. Бу сүзнең рус теленә *Зилант* (Елан тавы) рәвешендә керүе электә аның беренче авазы «ж» булгандыр дип фараз итәргә урын калдыра.

*Фибрал, април, июн, июл, үктәбер, синтәбер, дикәбер* дип язу турында. Болар, күрәсең, Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»ннән һәм 1917 елгы революциягә кадәр татар телендә чыккан календарьлардан алынгандыр. «Мәкальләр» китабына яраган транскрипцион язылыш бүгенге татарча матбугат өчен бик үк ярамый шул.

Април, июн (ийүн) һәм июл (ийүл) дип язу татар сөйләменә бик туры килә, ләкин фибрал, синтәбер, үктәбер, дикәберләргә карата фикерем башкача. Соңгылары Европа телләреннән русчага күчергәндә инде бер гарипләнгән сүзләрне татар калыбына кертеп янә имгәтү була. Ни генә әйтсән дә, без руслар һәм башка күрше халыклар белән бер информацион мәйданда яшибез һәм инде телебезгә кереп үзләшкән, тамыр жибәргән сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь кебек бик актив сүзләрнең язылышын үзгәртү кирәксез бер гамәл булыр иде. Билгеле, латин графикасына күчкәч, аларның язылышы үзгәрәчәк, һәрхәлдә татар өчен ят булган нечкәлек билгесе юкка чыгачак.

Гыйнвар ае атамасының язылышы, ихтимал, арада иң кызыклысыдыр. Бу атама латинча Januarius—Janus/Янус сүзеннән килә. Янус—Рим мифологиясендә вакыт алласы, һәр нәрсәнең башы һәм соңы, керү һәм чыгу юлы (ишеге, капкасы) мәгънәсендә. Аны ике чырайлы итеп сурәтләгәннәр һәм латин кауменең беренче бабасы дип исәпләгәннәр. Кыскасы, Европада ел башын билгеләү өчен Януар исеме аеруча кулай булган.

Петр патшаның ел башын сентябрьдән гыйнварга күчерүе, гадәтенчә, ирексезләү юлы белән эшләнсә дә, мәдәни Европа белән якынаю өчен дөрес адым булган (бу хактагы патша фәрманы 1699 елның 19 декабрендә чыга һәм 1700 елдан алып ел исәбе Көнбатыш Европадагыча башлана). Тик шунысы кызык, ул заманның рус календарьларында бу ай *генварь* дип атала. Ә бит югыйсә борынгы рус телендә (XI гасырда) һәм иске славян телендә *енуарь* сүзе теркәлгән, 1119 елдан соң *генуар* белән бергә *енуар* сүзе очрый. Соңыннан рус телендә, бигрәк тә әдәби телдә һәм канцелярия стилендә, *генварь* сүзе ныклап урнаша. Әле Александр Пушкин да үзенең журнал мәкаләләрендә һәм хатларында генварь сүзен кулланган.

Бу «г» авазы рус теленә каян килеп кергән соң дигән сорау туарга тиеш. Рус этимологлары моны үз телләре кысасында гына аңлатырга тырышалар. Ләкин «г»/«гъ» авазының Киев Русе чорында кыпчак теленнән (христианлык кабул иткән һәм Рим белән дә элемтә тоткан төркиләрдән) кергән булуы ихтималрак. Хәзер исә ул украин телендә сакланган. Без дә бит гадәттә *Али* димибез *Гали* дибез, «Мең дә бер кичә»дәге руслашкан Аладин да бездә—*Галәветдин*, исламият галиме Абло исә *Габдеһу* инде, азап—*газап*, акыл—*гакыл*, әрсез—*гарьсез*, әмәл—*гамәл*, аит—*гает*, Усман—*Госман*, Алим—*Галим*, Абдрахман—*Габдрахман*, Абдулла—*Габдулла* кебек күчеш-төрләнешләр дә татар телендә табигый.

Озын сүзнең кыскасы, «генварь» атамасы борынгы төркиләргә (кыпчакларга, команнарга) ят булмаган. Шуңа күрә бүген татар телендә *гыйнвар* дип язуда тарихи эзлеклелек бар һәм татар колагы моны сизә шикелле.

Кайбер укучылар хәтерли булыр, элегрәк сентябрьда, октябрьда, ноябрьда, декабрьда дип калын кушымчалар белән язу кагыйдәсе бар иде. Бу кагыйдә 1941 елда кертелгән: «1. Тамыры һәм нигезе белән нечкә булган сүзләргә, *ль* гә, *ия* гә һәм *ие* гә беткән сүзләргә нечкә кушымчалар ялгана: тәрәзәгә, мебельгә, типографиягә... 2. Башка барлык очракларда калын кушымчалар ялгана...» Шул рәвешле *декабрьлар, частьлар, семьялар* дип язу канунлаша. 1982—83 елларда «Татар теленең орфографик сүзлеге»н матбугатка әзерләгән вакытта без, бу сүзлекнең

редакторлары һәм редколлегия әгъзалары, сүзлекне төзегән А. Нуриева, Ф. Фасеев һәм М. Мәхмутовлар белән киңәшеп, әлеге ай исемнәренә нечкә кушымчалар ялгау кагыйдәсен кертеп җибәрдек. Моның өчен Министрлар Советының махсус карарын яки КПСС Өлкә комитетының күрсәтмәсен көтеп ятмадык, тәвәккәлләдек. Һәм дөрес эшләгәнбез. Җитлеккән социализмны тагы да ныгыту эше белән көне-төне мәшгуль булган түрәләребез мондый вак нәрсәләрне сизми дә калдылар. Сизгән булсалар, кем белә, бәлки, бу бит башбаштаклык дигән булып, чарасын да күргән булырлар иде. Дөрес, соныннан, сүзлек басылып таралгач, аптырашка калган укытучы ханымнардан хатлар да килеп төшкәләде. Тора-бара алар да табигый кагыйдәгә күнектеләр, күнделәр. Моны шуңа сөйләвем, орфографиядәге кайбер четерекле нәрсәләрне (эрерәкләрен дә!) менә шушындый бик үк кануни булмаган ысуллар белән эшләргә була (һәм булачак). Әйтик, ул «къ», «гъ» ларны әллә кайчан шома гына кертеп җибәреп була иде бит. Хәзер дә соң түгел! Латин графикасын ташлап кириллицага күчкән заманнарда сәламәт акыллы башкортлар безнең «кызыл профессор»лардан башлырак булып чыкканнар, аларда бу авазларны билгеләгән хәрефләр бар, шуңа күрә безнең язуда очрый торган байтак кыенлыклар башкорт язуында җиңел хәл ителә (бүген *кәгазь, каләм, гарәп, сәлам, шәрык* кебек сүзләрнең татарча «дөрес» язылышын без бит ятларга мәҗбүрбез, ятларга! Бүгенге графика урнашкалаганчы әле *кагәз, сагәт* дип язу да күзәтелә иде). Монда, ихтимал, *«сәләм»* сүзен аерып карау кирәктер. «Сәләм» сүзенең мәгънәсе *«сәлам»*нән үзгә, ул «киләчәктә алыначак малга алдан акча биреп кую төсендәге сәүдә»не белдерә (әйтик, җимешләрне пешмәстән элек киләсе бер яки ике еллык уңышын сату). Шуңа күрә мин әле генә мактап телгә алган башкорт сүзлекләрендәге «сәләм» сүзе урынлы түгел һәм без татар китабында мондый аваздашлыкка юл куймаска тиеш булырбыз. Дәлилебез: бу сүзнең борынгы төрки телләге язылышы да нәкъ хәзерге татарчадагы кебек (*сәлам*). «Вәссәлам» сүзен дә ике «ә» һәм ахырда бер «а» куеп язабыз, югыйсә телдән әйткән чакта «а» урынына «ә» ишетелә түгелме?

Терминологик бердәмлек хакына *гасыр* һәм *йөз* сүзләрен саграк кулланасы иде.

Әдәбиятчыларыбызның күбесе «урта йөзләр», «егерменче йөз әдәбияты» дип сөйли һәм яза. Тарих дәреслекләрендә һәм башка китапларның күпчелегендә исә, тотрыклы термин буларак, «урта гасырлар», «егерменче гасыр» сүзләрен күрәбез.

Әлбәттә, әйтик, «егерме беренче йөзне яхшый башладык» дию берәүне дә гаҗәпләндермиме, хәтта телбизәктәй яңгырарга да мөмкин әле.

Бу хакта мин «Милли казаныш» дигән мәкаләмдә сүз кузгаткан идем инде. Үземне үзем рекламалау шикеллерәк булса да, мәкаләдән бер өзек китерим: «Әлбәттә, «йөз» сүзен, исемләштереп, «гасыр» мәгънәсендә куллану татар телендә электә дә булган. Башта ул сөйләм телендә очрый башлагандыр сыман. Мәсәлән, Каюм Насыйри архивында саклаанган иске ельязмада мондый сүзләрне укыйбыз: «Мең сигез йөзнең ун икенче елында паспортның пушнәсе [ягъни пошлинасы] алты сум булды.» Тик шулай да «йөз» сүзе артык күп мәгънәле һәм фәнни текстта «гасыр» сүзен алмаштырып бетерә дә алмый. «Урта йөзләрдә казакъларда урта йөз (жүз) кабиләләр берләшмәсе булган» дип сөйләргә һәм язаргамы? Яки, фараз иттек, киләчәктәге яки хәтта милядига кадәрге туксан тугызынчы, йөзенче гасырларны телгә алырга туры килсә, ошбу әдәбиятчылар аларын ничек дип атарлар иде икән? «Туксан тугызынчы йөз»? «Йөзенче йөз»? Менә шушында Г. Тукайның яшь аралаш: «Шул гаҗәп: ник бу егерменче гасырда йөз дә юк!» дип сүз уйнатуын искә төшерсәң дә ярый. Шагыйрь күңеле егерменче гасырыбызның чырайсыз һәм кимчелекле булачагын сизенгән...»

«Гасыр» мәгънәсендә «йөз» сүзен куллану—көчләп тагылган «мәдәни жаргончылык» кына ул.

Ә казакълардагы кабилә берләшмәләрен татар терминологиясендә «жүз» дип алу кулайрак.

*Икътисади—икътисадый.* Соңгысы авыз тутырып әйтелә, тупасрак яңгырый, ләкин телетапшыруларда еш ишетәсең. Нурихан Фәттах әйтмешли, «Сезнеңчә ничек?» 1999 елда «Раннур» нәшрияты чыгарган «Русча-татарча икътисади атамалар сүзлеге», күренгәнчә, нечкә вариант яклы.

*Ривайәт—риваять.* Беренчесе дөрес язылыш булса да аны тора салып кына кертеп җибәреп булмастыр әлегә, чөнки әкият, хикәят дигән охшаш сүзләрнең орфографиясенә дә кагыласы була, эш зурга китә-китүен.

Иң өлкән һәм байтак елларга бердәнбер булып калган китап нәшриятыбызның «Татарстан дәүләт китап издательствосы» дип аталган вакытларын искә төшерик. Бер мәлне анда кабинет борынча йөреп, *«китап нәшрияты»* дипме, әллә *«китап нәшрияте»* дипме язу кулайрак булыр? дип сорашып чыкканнар иде. Төрки союз республикалары үрнәгендә, «издательство»ны кабат «нәшрият» дип атарга ниятләгәннәр икән (КПСС өлкә комитеты күрсәтмә биргәч, әлбәттә). Күпчелек калын кушымчаны яклады, ә менә башкортлар нечкә кушымчаны артык күргәннәр булып чыкты. Турысын әйткәндә, миңа башкорт варианты күбрәк ошый. «Әдәбият» сүзе дә шулай, ләкин анысына да калын кушымчалар ялгап язабыз. Гамәлдәге орфография кагыйдәләре буенча, «шигърият» сүзенә нечкә кушымча ялгана. «Әкият», «хикәят», «мәдәният» сүзләренә дә шулай. Мин бу очракта орфографиябездә эзлексезлек күрәм.

*Газета, гәзитә, гәзит, гәҗит...* Соңгысы ачыктан-ачык гади сөйләм. Кайсысын әдәби, кануни дип санарга?

Ләкин *Россия, Русия, Рәсәй* (сөйләм телендә—*Эрәсәй*, хәтта *Эрәчәй*), Русь сүзләренә килсәк, урынына карап, алар барысы да «эшкә яраклы».

*Сөнге—сөнге.* Дөресе—беренчесе, ләкин матбугатта еш кына икенче вариант язылышка да тап булабыз. Бер уңайдан шуны да әйтеп китим, хәтта бәрәңге дип язу «варианты» да очраганы бар.

*Кристалл.* Тоз *кристалы. Кристаллы*—димәк, кристалы булган нәрсә. Күплектә дә тагы бер (өченче) «л» өстәлми, кристаллар гына була.

*«Металл»* сүзе белән дә шулай. Цинк металы. Металлы катнашма. Металлар. Күрәсез, шактый буталчык.

Бу очракларда төп терминны бер «л» белән язсак, бернинди кыенлык тумый югыйсә. Төрек телендә югарыдагы сүзләрдә бер генә «л» языла. Миңа мәгълүм булган башкорт, үзбәк, каракалпак сүзлекләрендә исә бу очракта ике «л» чекрәеп тора. «Старший брат»ка ияру чире бер безгә генә кагылмаган, димәк.

Ә *«балл»* сүзе белән нишләргә? («Биш баллы система»—«татлы система» түгел). Төректә мондый алынма сүз юк, шуңа бу очракта аларның башы авыртмый. Ләкин төрекләрдә гомуми принцип—мондый куш авазлардан котылу, аларны икеләтмәү.

Русча *«съезд»* сүзе белән дә каршыга сораулар килеп баса. Әйтик, «съезд» сүзен урын-вакыт килешендә «съездда» дип түгел, «съезда» дип кенә язгалыйлар һәм русча сүзнең бер авазы янә йотылып юкка чыга. Татар моны аңлый-аңлавын ә татарча текстны башка милләт кешесе (берәр төрек әфәнде) укыганда ничек?

*«Поезд»* сүзе белән дә нәкъ шулай.

Гомумән, бу ике сүздәге «д» авазы татар сөйләмендә йотылып кала. Җанлы телебез галим-голяма чыгарган кагыйдәләрдән «гакыллырак» булган очракның берсе инде бу.

*Елау—җылау.* Бу сүзләрне латин хәрефләре белән язып карадым да, миңа «җылау» варианты күбрәк ошады. Рус алфавитын кертеп маташкан вакытларда *җыр* сүзен *ер* дип язарга тәкъдим итүчеләр дә булды шикелле, тик аны бик тиз кире кактылар дип исемдә калган.

*Мәзһәб* дип языйк. *Шәраб* дип. Ә «гарәп»—ни өчен гарәб түгел? Руста бу сүздә «б» авазы сакланып калган («араб», ләкин Пушкинда—«Арап Петра Великого» бугай).

*Мәктәп, мәктүп* язылышлары калсындыр. Китап та... Алар безнең орфографиядә тәмам калыплашкан, катып калган инде.

Татарча дәреслекләрдә *омеядлар* һәм *алидлар* кебек атамалар очраганы бар. Боларның беренчесе—*өммәвиләр*, икенчесе *галәвиләр* булырга тиеш.

Тугандаш казакъ халкының атамасын татарча язу да кыенлык тудыра (рус *казах* ди, анысы да ясалма, соңгый сүз; Брокгауз-Ефрон «Энциклопедик сүзлеге»ндә *«Казахъ»*—Кавказ аръягындагы Елизаветполе губернасында Казахъ өязенең административ үзәге («Яңа Акстафа»), ә аннан мең чакрым ераклыкта яшәүче

хәзерге казакълар иске чыганакларда «киргиз»лар һәм «киргиз-кайсак»лар дип телгә алына). Безнең бүгенге орфографиябез буенча, «казакъ» сүзендәге калынлык билгесе «казак»тан аеру өчен хезмәт итә. Мәсәлән, Казакъстан дип тә, Казагыстан дип тә язалар. Заманында, «Q-q» авазлы «яналиф» мондый кыенлыкны белми иде.

Мәгълүм булганча, *никах—никях* һәм *инкарь—инкяр* язылышлары атлаган саен очрый. Игътибар иткәнегез бармы: бу очракларда «к» хәрефе ике төрле янгырый—йә «къ» авазы, йә «к» ишетелә. Аннары беренче очракта «хъ» ишетәбез, ә икенче очракта сүзнең ахырында «х», хәтта «һ» ишетелгәндәй була. Галимнәрдән: «Кайсысы дөрес боларның?»—дип сорарга мәҗбүрбез. Кириллица белән язганда, әлбәттә. Ә латин хәрефләренә күчкәч ничек? Монда безнен имлабызнын «х» белән «һ»ны аерып житкермәве аермачык сиздерә.

Янә бер мөһим, принципиаль нәрсә «һ» хәрефе белән бәйләнгән. Ят орфографиягә, руста кабул ителгән формага иярүебез аркасында бик күп интернациональ сүзләрне без дөрес язмыйбыз һәм дөрес итеп әйтмибез.

*Һейне, Һегел (Гегель), Һамлет, Һитлер, Һамбург, һамбургер, Һейдел(ь)берг, һидроген, һидравлика, һидростатика, Һелий* (гелий), *Һиндия, Һиндонезия, Һолландия* (бусы иске татар китапларында очрый-очравын) дип язар вакыт килеп житмәдеме икән? Тикшерә башласаң, мондый рус телендә бозылган сүзләр байтак жыела торгандыр. Без бит хәтта «Париж» дип язганда да рус орфографиясенең ялгышын кабатлыйбыз. Латин графикасына күчкәнебездә болар игътибарга алынып, шәт, кайберләре яңадан каралыр. «Бәйнәлмиләл пәрәвезе»—*интернет* шуны таләп итә.

-ик суффиксына карата. Әйтик, *энциклопедик сүзлекме*, әллә *энциклопедия сүзлеге* дип әйтүме кулайрак? Бу хакта «Татар энциклопедия сүзлеге»нен баш мөхәррир урынбасары Г. С. Сабиржанов әфәнде телефоннан фикеремне сорагач, мин, мәгънә төгәллеген күздә тотып, «энциклопедия сүзлеге» вариантына каршы булуымны әйткән идем. Сөйләшүдән аңлавымча, редакция хезмәткәрләреннән татарчага тәржемә эшендә «азау ярган» Рәис Даутов та «энциклопедик сүзлек» варианты яклы булган икән. Кызганычка каршы, безнең фикер жинә алмаган һәм бу саллы белешмә мәңгегә «Татар теленең энциклопедия сүзлеге» дип аталыр инде.

Хәер, терминолог иптәшләр бик үк паникага бирелмәсеннәр, шул ук «Сүзлек»тән -ик суффиксы кулланылуга да мисаллар таба алабыз.

Бу суффикс татар теленә юкка гына алынмаган. Бик кирәкле шәй ул. Татар телен фән теле итүдә, татарча фәнни терминологияне булдыруда аның роле гаять зур. Менә бу сүзләрне генә карап карагыз: химик реакция, физик күренеш, биологик, арифметик, кинетик (энергия), математик (формула), теоретик, психологик, синтетик (матдә), грамматик (кагыйдә), стилистик (алым), реалистик, социалистик, коммунистик, хәтта большевистик... Боларның күбесен башка формада бирү кыенлык тудыра.

Кыскасы, *-ик* суффиксыннан, шулай ук *социаль, вертикаль, горизонталь, идеаль, материаль, модаль, суборбиталь, потенциаль* (энергия), *сексуаль* (революция), *тангециаль, территориаль* кебек сүзләрдә термин ясаучы -аль суффиксыннан баш тарту татар теленең фән теле буларак мөмкинлекләрен бик нык чикли. Мондый адым беренче карашка миллилек, телнең сафлыгы өчен көрәш булып тоелырга да мөмкин, ләкин төптә ул аякка басып кына килүче милли терминологиябезнең мөһим бер ботагына жәллад балтасы белән чабуга тиң.

Киләчәктә, латин хәрефләренә күчкәч, *потенциаль, тангенциаль* кебек сүзләрнең ахырында, нечкәлек билгесе урынына, әүвәлгечә, апостроф билгесе (') куярга туры килер һәм вәссәлам. Хәер, конкрет «потенциаль» һәм «тангециаль» очракларында вәссәлам үк түгел икән әле—алардагы ят «ц» хәрефе рустан килеп кергән, без анда «с» куячакбыз.

Соңгы вакытларда «*Европа*» сүзе телебездән төшми. Башта ук әйтеп куйыйм, аны «Аурупа» рәвешендә язу белән килешү кыен.

Дөнья кисәге буларак «Европа» (Көнбатыш Европа телләрендә—«Europa») атамасының татарча бирелешен тар карашларга нигезләнеп кенә хәл итәргә ярамый. Монда мәсьәләгә колачлырак, системалы якын килү зарур.

Совет чорында без житмеш ел буена *Европа* дип язарга һәм сөйләргә күнегеп беткәнбез. Менә хәзер иске әдәбиятта очрый торган вариантларны еш куллангалыйлар (*Аурупа* язылышын, ә *Яурупа, Оруфа* язылышлары онытылган бугай).

Бүгенгесе көндә «Аурупа» дип язу акланамы соң? Аның ни файдасы бар? Аның файдасы, кем әйтмешли, «кирәкле кишер яфрагыныкы кадәр» генә. Ул, әлбәттә, безне Төркиягә әз генә якынайта, ләкин фән кояшы чыга торган Европадан ераклаштыра.

Уйлап карыйк әле.

Беренчедән, Аурупа дигәндә «вау» авазы урынына «у» авазы ишетелә. Төрекләрдә исә язылыш дөресрәк—алар *Avrupa* дип язалар.

Икенчедән, картага игътибар беләнрәк карасак, Европа кыйтгасыннан башка, Һинд океанында нәни генә Европа атавы да елмаеп торыр.

Юпитер планетасының Галилей тарафыннан ук ачылган һәм соңыннан *Европа* дип аталган зур бер иярчене бар.

Химик элементлар таблицасындагы 111 нче элементны да *европий* дип атадылар. Аның химик билгесе—Eu (ә Au—аурумныкы, ягъни алтынныкы).

Мифологиядә Европа исемле хатын-кыз билгеле, телебездә *евроцентризм*, Евразия, евро (акча берәмлеге), евроремонт кебек сүзләр дә активлашып бара. Ә *«евроислам»* дигән сүзне, татарчада «ауроислам» кебек гарип (авыру) сүздән качар өчен, кыскартмыйча, «тутырып» язарга туры киләчәк, термин гади сүз тезмәсенә әйләнәчәк, ә кыскалык—терминологиянең дусты ул.

Менә шушыларның барчасын исәпкә алганда, терминологиябездә һәм орфографиябездә төрек дустларның чабуларына ябышып бару кулай эш түгел. *Аурупа* дип язу безнең өчен бер-ике адым артка чигенү булачак—бу юл белән китсәк, без татар телен фән теле итәр өчен дистә еллар дәвамында яулап алынган казанышларны югалтачакбыз.

«Аурупа»—авыру сүз. Ә инде «ауроцентристик караш» дип язу, минем карашымча, ишәк белән атны кушылдыру кебегрәк—нәтиҗәдә затсыз һәм иң мөһиме—токымсыз һәм җимешсез бер азман сүз килеп туа. Хәтта, мин әйтер идем, сонгый «ауромәркәзи» сүзе дә «ауроцентристик» сүзенә караганда эзлеклерәк, логикалырак булыр иде...

Укучыбызны тагы беркадәр ялыктыру хисабына тарихтан кыскача гына мәгълүмат китерим әле.

Европа атамасын ассирия телендә «карангылык, көнбатыш» мәгънәсендәге *эреб* сүзе белән бәйлиләр. Тора-бара ул сүз кояш баеган илне аңлата башлаган, ә *асу* (көнчыгыш) кояш чыккан төбәкне белдергән. Бу сүзләрнең беренчесе гарәпчә «гарб»—көнбатыш сүзен, икенчесе «Асия/Азия» сүзен хәтерләтә, чөнки алар канкардәшләр. Борынгы Грециядә Европа төшенчәсе Балкан ярымутравының бер өлешен—Грециянең төньягын, Албанияне, Македонияне генә колачлаган. Әле III гасырда да Европа дигәндә Дарданелл бугазы тирәсендәге кечерәк кенә төбәкне күздә тотканнар (күрәсезме, төрекләр этник яктан булмаса да, тарихи-территориаль яктан «без—европалы» дип мактана алалар икән).

«Европа» сүзенең грек телендәге мәгънәсе—«киң карашлы (күзле)», анысы, ихтимал, грек мифологиясендәге Финикия патшасы Агенорның кызы Европа исеменнән килә торгандыр. Мифологиядән билгеле булганча, Европаны үгез сурәтенә кергән Зевс алла урлый да Крит атавына алып килә. Анда Европа Зевстан өч угыл таба...

Европа кыйтгасының атамасы хәзерге мәгънәдә бик соң карарлашкан. Хәтта бүген дә Европа белән Азия арасындагы чикне (көнчыгышта һәм Кавказда) төрлечәрәк үткәрәләр. Билгеле инде, күбәүләрнең Европага эләгеп каласы килә. XVIII гасырдагы географик күзаллаулар буенча, Европа белән Азия арасындагы чик Урал буйлап түгел, Казандагы Арча кырының уртасыннан узып, хәзерге К. Маркс һәм М. Горький урамнары кушылган җирдәге ермак буйлап үткәрелгән була.

Европа кыйтгасы Азия белән бергәләп зур континент (Евразияне) тәшкил итәләр.

География күзлегеннән караганда да, тарихи яктан да без—евразиялеләр. Без—

европалылар, әмма азиатлар түгел... Без Европаның гуманистик һәм технологик казанышлары белән горурланабыз. Бүгенге фән кояшы Көнбатыш Европада чыга, ул «Рәсәй Азиясе»ндә байымасын иде дибез. Латин графикасына күчсәк, бу атама нәкъ көнбатыш телләрендәгечә язылыр иде.

Географик карта буенча сәяхәтебезне дәвам итик.

*Оренбург* атамасын бездә кем ничек тели шулай яза.

И. Рәми Оренбургны *Үрән* дип атый, чыганакларда шәһәрне *Ур Кала* дип атау да очрый. Кайбер бүгенге китапларда *Ырынбур* һәм хәтта *Ырымбур* язылышларын күрәсең. Болары «татарчалык»ны гади сөйләм белән бутаудан, ягъни талымсызлыктан башка нәрсә түгел, әлбәттә. Тирәнгәрәк китсәң, атаманың татарчасында төрки «ур» яки «ор» сүзе катнашырга тиеш иде (Оренбург шәһәренең беренче нигезе салынган урындагы елганың исеме *Орь*—төрки чыгышлы, *казылма/чокыр* яки *өем/өелмә* мәгънәсендә. Соныннан гына шәһәрне башка урынга күчерәләр, ләкин аның әүвәлге исеме үзенә ияреп килә).

«Салават бәете»ндә: «Жаек дигән жап йир-су, сай йирендә сөнге буйлайдыр, *Урунбуркайның* ягасында алтынлы тулар уйнайдыр.»

Икенче бер бәеттә бу шәһәр «Ранбур» дип телгә алына: «Яна икән саласы, *Ранбурдыр* каласы, Мәһди байның тәкъдирендә язган икән янасы.»

Иске чыганакларда *Рынбурух* язылышы да очраганы бар.

Дәрәжәле бер журналыбызның бер үк санында Оренбург атамасының өч төрле язылганын күреп тә гажәпләнгәнебез булды.

Иң дөресе—Оренбург язылышына кагылмау, тарихны ихтирам итү. Петербург һәм Екатеринбург белән бергә Оренбург та хәзергә кала бирсен.

Бервакыт үзәк гәзитләрнең берсендә «*Рәзән*» шәһәре дигән атама күзгә чалынган иде. Бусы инде гади сөйләмгә күчү дип бәяләнергә тиеш. Андый юл белән киткәндә, һәрбер рус яки башка халыктагы атаманы теләсәң ничек боргаларга, бозгаларга мөмкин бит. Мәс., борынгы рәсми кәгазьләрдә *Смоленск* шәһәре татарча *Ысмалән* дип аталган. Аңа карап Смоленск шәһәренең исемен үзгәртмәбездер бит. Ә «Рязань» атамасы, ихтимал, «иржә»/«эрзя» халкы исеме белән бәйледер, һәрхәлдә төрле-төрле гипотезалар арасында иң ышандырганы—шул.

«Рязань» атамасына да кагылмау хәерле.

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы законының 25 статьясында «Торак пунктларның исемнәрен бозып атау рөхсәт ителми» диелгән. Моны истә тотыйк!

АКШ яки Канада картасына карасаң, колакларны иркәли торган искиткеч матур, әһәнле *Миссисипи, Миссури, Аризона, Дакота, Онтарио, Чикаго, Мичиган* кебек жирле халык биргән атамаларга тап буласың. Матур булмаска ни: ирокезлар телендә «oniata rio» үзе үк *матур* дигән сүз икән ләбаса. Әһәнле булмаска ни: һиндианнар телендә Аризона—*нәни чишмә* дигән сүз бит.

СССР һәм аның варисы Россия карталарында да андый атамалар юк түгел, ләкин «мәгърифәтле» руслар яулап алынган жирләрдәге күп объектка русча яна исем кушарга яратканнар. Бештау/Биштау, әлбит, Пятигорски инде, Кырымдагы Аюдагны да Медведь-горага әйләндереп маташканнар иде, хәзер ничектер,—язмышын белмим. Бурят телендәге *Йаблени даба*/«Жәяүле үткеле» руста «Яблоновый хребет»ка, *Оката* елгасы—Охота елгасына, XIII гасырда татар тарафыннан нигезләнгән *Саричун* 1589 елда Царицынга, 1925 елда—Сталинградка, 1661 елдан Волгоградка әйләнә. *Сарытау*—Саратовка, *Агидел*—Белаяга, *Елантау*—Зилантка, *Әмитавы* Ометьевога әйләнгән, *Болгар* урынындагы авылны руслар Успенское дип атаганнар...

Әрәм булган ике гүзәл атама—тарихи һәйкәлләр—хәтергә уелып калды: *Писмән* һәм *Мәләкәс*. Боларның беренчесен Лениногорски иттек (иттеләр), ә Татарстан белән чиктәш Ульяновски өлкәсендәге Мәләкәс (ялгышмасам, татарның мәшһүр гармончысы Фәйзулла Туишевның ватаны) Димитровград булып калды. Соңгы вакытларда Мәләкәснең үзен дә, берникди нигезсез дип әйтик, Миссисипи сүзе белән ярыштыргандай, «Мелекесс» дип яза башлаганнар иде инде.

Писмән белән Мәләкәс атамаларының этимологиясе гасырлар тузаны астында күмелеп калган, кайсы халыкныкы икәнен дә анык белеп бетермибез. Ләкин ядкяр итеп саклаганбыз бит шуларны!

Коммунистлар хакимияткә килү белән, исем-атамаларны алмаштырырга тотындылар. Картада Троцкий исемле шәһәр дә, Зиновьев исемлесе дә пәйда булды (аларының гомере кыска булды булуын). «Һәрбарча дәверләр һәм халыклар даһисы» Иосиф Джугашвили-Сталин хәтта үзе үтерткән Фрунзе, Кировларның да исемен шәһәр атамаларында «мәңгеләштергән» иде. Ул Ленин исеменә нисбәтле атамаларның исәбе-хисабы юк.

Хәзер боларның күбесе әүвәлге исемнәрен йөртә, ләкин байтагы чират җиткәнен көтеп ята әле.

Болгар белән Чаллыбызның исемнәре кайтарылганга без шөкер укыйбыз инде.

1997 елның 10 декабренә кадәр Казагыстанның башкаласы булып торган Алма-Ата шәһәренең исеменә дә Мәскәүнең катнашлыгы бар. Казакълар үзләре аны хәзер Алматы дип йөртәләр, чөнки аның дөрес мәгънәсе *«Алма атасы»* түгел, бәлки *Алмалы* дигән сүз. Ул *Олы* һәм *Кече Алмалы* (Алматы) елгалары буенда урнашкан һәм, XIX гасыр урталарында барлыкка килеп, соңыннан *Верный* дип исемләнгән. Ә Алма-Ата сүзе 1921 елда Верный шәһәренең исемен үзгәрткәндә рәсми кәгазьләрдә киткән хәреф хатасы аркасында гына туган диләр. Шуңа күрә СССР таркалганнан соң, казакъларның шәһәрне кабат *Алматы* дип атый башлавы дөреслекне кайтару гына булып тора. Шунысы кызык, Мәскәү матбугаты беркадәр вакыт Алматы дип язса да, бик тиз Алма-Ата вариантына кире кайтты һәм моңа, рус галимнәреннән бигрәк, «гади» милләтчеләре сәбәп булды шикелле (хата булса булсын, руслар шуңа иярләнгән, янәсе). Хәтерегездә микән, Төркмәнстанның башкаласы *Ашхабад/Ашгабат* атамасы белән дә рус терминологиясендә нәкъ шундый ук күчеш һәм чигенеш булып алды. Шул ук вакытта бик күптәннән күнегелгән Таллин шәһәренең исемен рус матбугатында хәзер, эстоннар үзләре язганча, ахырында ике «н» белән— «Таллинн» дип язалар һәм мондый куш тартыкны җырчы-шагыйрь Владимир Высоцкийның гына «сузынкы» аваз кебек итеп көйләп әйтә алуы берәүне дә уйландырмый. «Мәскәүләр» (Мәскәү кешеләре) сүзе үрнәгендә күплек формасын ясаганда без һичшиксез «таллиннар» дип, өченче «н»сыз гына язачакбыз һәм татар кешесе барыбер төп сүз «таллин» икән дип аңлаячак. Күрәбез ки, рус галимнәре генә түгел, гади рус «обывателе» дә милләтләрне ике сортка бүлеп йөртә икән. Эстоннар, димәк, беренче класска карый, казакълар белән төркмәннәр түбәнрәк сортлы икән, аларны бик үк санга сукмасаң да ярый икән.

Владикавказ!

Төньяк Осетия—Алания республикасының башкаласы Владикавказ шәһәре 1784 елда Капкай («Тау капкасы» мәгънәсендә дип фараз ителә) авылы урынында рус крепосте буларак барлыкка килгән. «Кавказның иясе, хуҗасы» мәгънәсендәге *Владикавказ* исемен ана Екатерина II нең (Әби патшаның) чираттагы мәгъшукы Г. Потемкин биргән. 1931 елда шәһәр коммунистлар партиясе һәм совет дәүләте эшлеклесе Орджоникидзе исемен ала. 1944 елдан башлап 1954 елга кадәр ул осетинча *Дзауджикау* (кеше исеменә кау—«авыл» сүзе кушып ясалган) дип атала. Балкарларда—*Теркбашы*, чеченнәрдә—*Терк-кала* (Терек елгасы исеменнән). 1954 елдан яңадан—Орджоникидзе. 1990 елда ул русча Владикавказ исеме белән һәм шул ук вакытта осетинча Дзауджикау исеме белән йөртелә башлады (рәсми рәвештә ике исем белән атала торган бүтән башкала Россиядә юк та шикелле). Без, бичаралар, җебек булганга гына бу шәһәрне, колонизаторларга ияреп, Владикавказ дип йөртәбез, ә бит аны осетинча атасак та законда моңа каршылык (тыю) юк...

Ерак Көнчыгыштагы *Владивосток* шәһәре атамасы «Владикавказ» моделе буенча 1860 елда барлыкка килгән.

Ниһаять, без, татарлар, *Астрахань* дип түгел, *Әстерхан* дип курыкмыйча яза башладык бугай инде. Элек нидән өреккәнбездер? Үз күләгәбездән, үз күләгәбездән, милләттәшләр!

*Чуваштан* «чуаш»ка күчеп барабыз дип беләм. Берәүне дә рәнҗетмибез бит?

Ә менә *«Әзәрбайҗан»* дип язуга ияләнеп җитә алмыйбыз бугай әле (икенче «ә»

урынына «е» язгалыйлар).

Хәзерге карталарда Урал исеме йөрткән елганың элек төркиләрдә *Жаек* дип аталганын белмәгән кеше бездә сирәктер. Мәшһүр сәяхәтче Ибн Батута заманнарында аны *Олы су* дип тә атауларын беләбез.

Мәскәүләр теләсә нишләсен, телиләр икән, әби патша Жаек казакларына ачу итеп кушканча, Урал дип йөртә бирсеннәр. Себер шикелле, Жаек та тарихи үзебезнеке һәм без елга-күлләребезне ата-бабаларыбызча атап йөртә алабыз, хаккыбыз бар.

Матбугатыбызда *«Идел»* белән *«Волга»* күпме тартыштылар. Идел/Әтил җинеп чыкты.

Татар топонимиясендә *«Мәскәү»* белән *«Москва»* арасында барган ярыш та беренчесе файдасына тәмамланды.[1]

*Чечня, татарва/татарова, чуваша, мордва, хохол, немчура, самоед*—болар барысы да руслар тарафыннан башка каумнәргә кушылган атамалар, фактта кимсетүле кушаматлар.

Шәхсән минем өчен административ картада Чечня юк. *Чечен* республикасы яки *Ичкерия* генә бар. *Чеченстан* да әйбәт (нейтраль) сүз.[2]

Әйдәгез, мәскәүләргә иярмик, аларны, украиннарча, «москальләр» дип тә мыскылламыйк, авыз пычратмыйк, шул ямьсез «чечня» (Сіспә?) сүзен чүплек башына ташлыйк әле... дисәм, өндәвемнең файдасы булырмы икән? Ай-һай... «Мордва» мәсьәләсендә дә шулай. Киресенчә, әлеге «түбән өслүб» сүзләрен төкрек чәчә-чәчә яклаучылар да табылыр, халык аны үзе кабул иткән бит инде диярләр. Өстәвенә алар: «Җилгә каршы төкермә!»—дип акыл сатачаклар әле. Кая баруыңны онытып, артка борылуың белән, каршы җил дә аркан җилгә әйләнә анысы.

Агымга каршы бар, җилне җилкәнлә һәм арканла, чөнки тапталган сукмак яңа җирләргә илтми.

Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханнарының исемнәрен язуда искиткеч чуарлык яшәп килә. Мисаллар китереп тормыйм, күп алар. Чөнки бу чуарлыкка «өлеш кертмәгән» авторны яки тәрҗемәчене атап күрсәтү дә кыен.

---

[1] Төпченә башласаң, рус телендә дә беренчел форма «Москов» булып чыгарга бик мөмкин. Көнбатыш телләренә дә, һәм безгә дә аның «Moskau» һәм «Мәскәү» формаларында керүе очраклы хәл була алмый, борынгы рус язма чыганаклары да шуңа ишарәли (баштарак Мәскәү шәһәрен «город на Москве-реке» дип атаганнар, ә аңа кадәр «На Московъ» формасы өстенлек иткән). «Псков», «Волхов» атамалары да «Москов»ны искә төшерә.

[2] Соңгы елларда без «Чечня» кушаматына тәмам күнегеп беткәнбез, аның түбән стильгә карый торган сүз икәнен искәрмибез дә. Аны «Свобода» радиостанциясе дә бик «иркен» куллана. «Чечня» сүзе «Новая российская энциклопедия»нең 2004 елда басылып чыккан беренче томында да («Россия» томы) очрый инде. Соңгы вакытларда шушындыйрак «урам сүзләре», хәтта төрмә-лагерь лексикасына караган «җәүһәр кәлимәләр» рус теленә өерелеп керәп бара. Радио һәм телевизор лөгатьлеге күзгә күренеп тупасланды (рус телерадио-тапшыруларын әйтәм). Цензура булмагач, дикторлар да сүз иреген сөяксез телгә хөррият дип аңлый башладылар, ә эстрада артистларының «нәфис сүзе» еш кына солдат анекдоты дәрәҗәсеннән югары түгел. Әгәр демократлашу шушындый дорфа була икән, андый «халыклашу»ның кирәге бер тиен.

«Мордва»га килик. Бу этнонимның килеп чыгышы караңгы, хәтта бәхәсле булса да, Вл.Даль сүзлегенә теркәлгән «У мордвы две морды, а шкура одна (два языка)» әйтемен күргәннән соң, рус кешесе өчен мордва сүзендә дә кимсетү барлыгын төсмерли башлыйсың. Мордва атамасын Геродотта очрый торган «андрофаглар» (кеше ашаучылар, ялмавызлар) белән янәшә кую, ирани телдәге «мардхвар» (кеше ашаучылар) сүзеннән чыгару да без казып тапкан нәрсә түгел...

Күрәсең, руслар элек-электән үк үзләренең иң якын күршеләрен дә өнәмәгәннәр. Аларның прицибы «Күрше хакы—алла хакы» түгел, бәлки «Се—моё, а то—моё же» булган. Намуслы тарихчылар Рус иле тарихына башыннан алып бүгенге көненә кадәр «ушкуйниклык» психологиясе хас икәнен тәкрарлыйлар...

Шайтан таягы дигән тикәнле үсемлекне руслар *татарин/татарник* дип тә, *мордвинник* дип тә йөрткәннәр. Яшәүчән, усал, буен сындырмас булганга күрәме? Ләкин, дөресен әйтик, бүгенге «тикән»нәр дә «Хаҗи-Морат» әсәрендә Лев Толстой сокланып язган тикән-татарин кебек түгел инде, сыеклар, сыеграклар...

Сүз җае чыккач, шуны да әйтмичә булмый: «Хаҗи-Морат»ның татарчага тәрҗемәсендә (2004 елгы соңгы басма дип исемдә калган) оригиналдагы «татарин» атамасын татарча «убыр уты» сүзе белән алмаштырганнар иде. Ни кызганыч, тәрҗемәче даһи Толстойның бөтен әсәргә тон һәм юнәлеш биргән табышын сызган да ташлаган.

Ислам дине пәйгамбәр дип таныган затларның исемнәрен, аннары Коръән сүрәләренең исемнәрен язуда да төрлелек хөкем сөрә. Ривайәти *Хозырны* гына алып карыйк. *Хызыр, Хидр* язылышлары бар, *Хөдер (Хөзер)* варианты да яши. Хәдисләрдә—әл-Хозыр. Шапшаклык бит бу. Шуның өстәвенә халык ривайәтләрендә *Хозер* һәм *Ильяс* пәйгамбәрләр бер зат булып кушылып, *Хозыр Ильяска* әйләнә, укучыны бусы да саташтыра.

Яки менә Аллаһының күркәм исемнәрен алып карагыз. Алар йөзәү һәм шуларның күбесенең татар теленә тотрыклы тәрҗемәсе юк. Алланың үзенә мөнәсәбәтле булганга, монысына мисаллар китереп тормыйм.

Еш кына республикабыздагы татар авылларының да исемнәрен дөрес язмыйбыз. Ә чит өлкәләрдәге татар авылларын әйткән дә юк инде. Хәтта Татарстан республикасының административ бүленеше китабында да пөхтәсезлек атлаган саен очрый. Андый җаваплы басманы матбугатка югары администрациядәге бер-ике «канцелярист» кына әзерләмәскә, моңа белгечләр дә катнашырга тиеш дигән тәкъдим кертәм. Заманында д-р Искәндәр Абдуллин Татарстан топонимикасы буенча шактый материал туплаган иде. Мәрхүмнең архивында алар саклангандыр, шуларны да күтәрергә була. Шундый ук материаллар фән докторларыннан Р. Әхмәтьяновта, Г. Саттаровта, Ф. Гариповада да булмый калмас.

Хәзер инде кулланудан чыккан борынгы топонимнар—үзе бер кызыклы тема.

Ихтимал, татар торак пунктларының атамаларын дөрес язу мәсьәләсендә «Татар энциклопедия сүзлеге»без уңай роль уйный алыр. Соңгы вакытларда «Мәдәни җомга» гәзите, шушы белешмәгә таянып, Татарстандагы авыллар исемлеген бирепбарды, дөрес язылышны пропагандалау (һәм, бәлки, язылышка төгәллек кертү) өчен бу бик әһәмиятле.

Узган гасырның 80 нче елларында д-р Фирдәвес Гарипованың «Татарстан гидронимнары сүзлеге» (ике китапта) басылып чыккач, елга-күл исемнәренең язылышын тәртипкә салырга мөмкинлек туды. Минемчә, яңа орфографик сүзлекнең ахырында шушы телгә алынган тематик исемлекләр кушымта итеп бирелсә искиткеч әйбәт буласы. Шул ук вакытта галимнәребез күрше республика һәм губерналардагы татар авыллары исемлеген төзесәләр, татарның тарихи офыгы киңәер иде дип аңлыйм.

Еш кына төрле редакция хезмәткәрләре орфографиябезнең тотрыксыз булуыннан зарланалар. Ә бит алар үзләре дә бу юнәлештә шактый эш майтара алырлар иде. Нигә журналистлар берлеге кысаларында орфография буенча бер гамәли киңәшмә хәзерләмәскә? Әлбәттә, бу киңәшмәдә, журналистлардан тыш, абруйлы тел белгечләре дә, татар теле укытучылары да катнашырга тиеш. Даими үткәрелә торган киңәшмә карарларын барлык редакцияләргә һәм нәшриятларга җиткерү бик мөһим, язылышлары турында уртак фикергә киленгән аерым сүзләрнең исемлеген матбугатта игълан итү аеруча нәтиҗәле булыр иде (мәсәлән, «Мәдәни җомга»ның «И туган тел...» кушымтасында). Кыскасы, оешу һәм тиешенчә оештыру (алдан хәзерлек—мәсәлән, бәхәсле, проблемалы сүзләр исемлеген төзеп тарату) кирәк. Дөрес, мондый исемлекне бер утыруда гына төзеп ату мөмкин түгел, ул төрле өлкәләрдән хәбәрдар һәм тәҗрибәле булуны сорый. Ләкин шунысы кызык, «артык» тәҗрибәле булуның тискәре моментлары да юк түгел: *яңалыкны тотып алу* һәм *үзләштерү сәләтенә* тәҗрибә һәм теге яки бу сүзгә артык гадәтләнү аяк чалмасын—кешене кеше иткән эволюция һәм алгарыш өчен монысы бигрәк тә мөһим. Биологиядән *җәдиди* башлангычның—ирләргә (иркәкләргә), ә *кадими* нигезнең хатын-кызга (тешиләргә) хас икәнлеге күренә. Шушы ике мөһим башлангыч, бер бөтен тәшкил итеп, эволюцияне тормышка ашыралар. Җәдидидән башка кадими юк, кадимидән башка—җәдиди. Эволюция барышында җәдиди кадимигә күчә.

Сүземне шушында өзмәкче булдым.

Мәкалә өчен әзерләгән каралама язмаларымда аять—*айәт*; Башкортостан—*Башкортстан*; *бәлзәм*—бәлсән—мәлхәм; биллаһи—*билләһи, валлаһи, таллаһи;* Дәрвиш бистәсе—Дербышки (Казан бистәсе)—Дербешки (Кама буенда)—Дәрбиш; казак—*казакъ*—казах—кайсак (кыргыз-кайсак)—качак; *компьютер*—кәмпитр (көлке

сүз, минемчә, Илдус Әмирханның бер мәкаләсендә моның дөресрәк варианты да очрый-очравын: «кәмпүтер»)—санак (тарихи һәм мәгънәви яктан дөрес булмаган бу сүзнең, мәсәлән, *«санаклы җәйләү»* (?) рәвешендәгесе күзгә чалынганы бар,— «компьютерга өйрәтү өчен җәйге лагерь» икән!); крестьян—керәстиән—*крәстиән*; Кульшә—Кулҗә—Голҗа—Гөлҗә (Кытай, Синцзян-Уйгур автономияле өлкәсендәге шәһәр); Курәйшләр—*Корәешләр (Корәеш бистәсе)*—Курәйешләр—Кураешләр; *лазурит—ләҗүрд (асылташ)*; матдә—маддә; пыяла—*пийала (касә)*; садака—сәдака; *Семипалатинск—Семипулат*—Семи, Сими, Семей, Симай; стакан—тустаган; Оман—*Гомман*; *Уфа*—Өфе/Өфө; *фәллах*—фәлләх, фәллях һәм феллах (руста); Ферганә—*Ферганә*—Фәрганә—Фергана (руста); фиргавен—*фиргаун*; фирдәвес—*фирдәус*; шикаять—*шикайәт*, Якутия—*Саха* кебек сүзләрне дә төртеп куйган булганмын, ләкин алары турында хәзергә сүз озайтып тормаска туры килә, чөнки акка күчерә башлагач чыннан да озынга китә, күргәнсездер—фикерләремнен бәхәсләрәкләре дә юк түгел. Үзем ошаткан вариантлар бу «исемлек»тә курсив белән җыелган булыр.

Кузгатылган темам бик олы булып чыкты. Күрдем: аны мин генә күтәрешле түгел (бәлки башкалар дәвам итәр, чөнки мин аның берничә аспектын гына азмы-күпме яктырта алдым).

Кардәшләр, әйдәгез, фикер алышыйк. Ләкин һаман саен сүздә генә калу килешми, күмәкләшеп, оешып, әртилебез белән тотынып, бу юлы эшне «үле ноктасыннан» кузгатып җибәрик, көнчел «ут күршеләребез» дә, унай нәтиҗәсен күреп, муен артларын кашырлык булсын. Аннан, гадәттәгечә, безгә—көтү башларына—ияререләр тагы.

«Әйдәгез, милләткә хезмәткә!» дигән житди шигар бүгенге бүлгәләнү, аерымлану, «башка чыгу», низаг һәм таркалу заманында аерата актуаль янгырый.

Бу дөньяда ялгыз түгел без.

Рушан йолдызыбыз әле сүнмәгән.

*2005*

---

## Авторларыбыз игътибарына

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

# АЛЬБЕРТ ФӘТХИ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Фәнебезгә тугрылыклы хезмәт иткән китапчы галим, археограф, милләтебезнең сирәк шәхесләреннән булган Альберт Фәтхинең (1937—1992) шәхес буларак бөеклеге дә, фаҗигасе дә хакыйкатьне сөюдә, гадел һәм туры сүзле, фидаи җанлы, үтә таләпчән галим булуында, милли фәнгә эчкерсез хезмәт итүдә, халкыбыз өчен янып-көеп яшәүдә иде.

Ул калып-кысалар, катыргы исем-дәрәҗәләргә исе китмәгән, хәтта кемнәрдер өчен «җайсыз» шәхес тә иде. Менә шул сыйфатлары өчен хөкүмәт органнары да дөмбәсләде, хезмәттәшләре дә читләшергә тырышты, чордаш фән әһелләренең кайберләре аны түбәнсетеп маташты, кемнәрдер күрмәмешкә салышты... Тик аның җаны да, рухы да дөньяның мондый ваклыкларыннан өстенрәк, олуграк иде. Андыйлар кысрыкланган әшәке заманнарда да Альберт Фәтхине ихластан хөрмәт итүчеләр, искиткеч белемен олылаган кешеләр (өлкәннәр дә, яшьләр дә) аңа тартылдылар, киңәштеләр һәм аралаштылар. Аңа иярделәр һәм аңа охшарга тырыштылар, сокландылар.

Альберт Фәтхи 1937 елның 8 июлендә Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында дөньяга килгән. Әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак булган.

Альберт туган авылында җидееллык мәктәптә укыгач Актаныш урта мәктәбендә югары сыйныфларда белем алган.

1954 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә һәм алдынгы, кызыксынучан, актив студентларның берсе булып таныла, факультетның «Әдәби сүз» стенгазетасы рәссамы була. Татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча төпле белем алып, 1959 елда университетны уңышлы тәмамлый.

Шул ук елның 1 сентябреннән университетның Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәсенә Шәрык кульъязмалары секторына эшкә урнашып, гомере буенча (32 ел ярым) шул вазифасында, кечкенә генә хезмәт хакына эшләгән.

Альберт Фәтхи гарәп язулы борынгы төрки-татар, гарәп һәм фарсы кульъязма мирасын халык арасыннан җыеп туплауга зур көч куйган, аларны өйрәнеп, пропагандалаган күренекле археограф иде. Ул татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязма мирасларын тирәнтен өйрәнеп, фәнни тасвирламаларын әзерләп бастырды.

Китапханәдә эшләү белән берәттән, 1960 нчы елларда Казан университеты студентларына борынгы төрки тел тарихы буенча дәресләр биргән. Фән әһелләре, галимнәр даирәсендә ул шактый тиз танылып өлгерә. Ә «Казан утлары» журналының 1968 елгы 2 санында чыккан «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр» мәкаләсе А.Фәтхигә зур шөһрәт китерде.

Альберт Фәтхи житди сәбәпләр аркасында гаиләә корудан мәхрүм калып, тормышын ялгызлыкта үткәргән зат. Ул 1992 елның 18 гыйнварында, кинәттән дөнья куеп (гәүдәсе шактый вакыт үткәч кенә табыла), 26 февральдә Казан шәһәренең иске татар зиратында җирләнде. Аңа 54 яшь ярым иде. Үлеменә бәйле трагизмны алдан сиземләгән, күрәсең. 1981 елда «Минем бер нәрсәм дә башка кешеләрнекечә булмаячак... Алдан сизеп торам...»—дип теркәгән сүзләре шуңа дәлил.

А.Фәтхинең туган авылы милләтебезгә башка талант ияләрен дә биргән. Ленар Шәех бу турыда менә ничек ди: «Такталачык... Нинди гүзәл табигать!.. Илаһилык!.. Монда әллә нинди иҗат ияләре, тылсымчылар яшидер кебек... Татар сәхнәсен дер селкеткән, күренекле трагик артист Мохтар Мутин... Үткен сатирасы, иркә юморы,

тирән лирикасы белән татарны таң калдырган халык шагыйре Гамил Афзал... Төпле фикерле, тарих кыяларын бүгенгегә ялгап утырган галим Альберт Фәтхи...—шушы авыл балалары...

Кызганыч, Альберт абый тәпи баскан йорт исән түгел. Нигезе бар, ләкин анда башка нәсел, башка кешеләр...

Сәер, Гамил Афзал нигезе таш юл астында калган, Мохтар Мутинныкы—ярдәмче интернат-мәктәпнең алма бакчасы кочагына кереп чумган... Ә туганнары исән, алар яши. Такталачык авылы чал өянкеләре белән бергә үзенең асыл улларының якты исемен җанының иң түрендә кадерләп саклый...»

Татар язма истәлекләрен өйрәнүгә бөтен гомерен багышлаган бу серле затның 70 еллыгы һәм татар басма китабының 285 еллыгы унаеннан искә алып китү бер изге гамәл, савaплы эш булыр. Альберт Фәтхи дигән исемнең хикмәтен тулырак күзаллау өчен аның белән аралашкан галимнәр, хезмәттәшләре һәм шәкертләренең истәлекләренә мөрәҗәгать итик.

Альберт Фәтхинең басылып чыккан хезмәтләре, мәкаләләре, шулай ук матбугатта чыкмый калган язмалары һәм фикерләре тирәнтен өйрәнүчесен һәм лаеклы бәясен көтә. Шөкер, хәзер фән дөньясы кайнап тора. Ихтимал, Фәтхинең эшчәнлеген, гыйльми мирасын һәм тормышын диссертация дәрәҗәсендә өйрәнергә иҗтиһад итүчеләр, әдәби-документаль әсәр язучылар да табылыр.

**Раиф МӘРДАНОВ**

• • •

*Китапчы галимнәребез*
*Ә.Кәримуллинга, А.Фәтхигә*

**Хәзинәнең сакчысы да,**
**хуҗасы да сез аның.**
**Сезгә, мөгаен, ачыграктыр**
**кая баруы дөньяның!**

**Чор-заманнарны үтәли**
**күрәлгән зирәк ирләр,**
**сезнең үлчәү, берәмлекләр—**
**гасырлар да дәверләр!**

**Кемнәре юк бу дөньяның!**
**тиңсезе, ятимнәре...**
**Рухи мирас бакчасының**
**сез—хуҗа, хакимнәре!**

**Еллар аша ничек күренә**
**безнең эшләр, янулар?**
**Бәләкәйме? Әйтәсезме:**
**«Бичаралар, фанилар...»**

**Әйе, кылганнар аз, мыскал...**
**Шулай да бер сүз—бездән:**
**«Без фанидыр, фаньерак—**
**максатсызлар, йөзсезләр!»**

**Хаклыкка якын торучы**
**әй, халык галимнәре!**
**Ил-йортның эшчән уллары,**
**милләтнең хадимнәре!**

**Дөнья бәһасе язу да,**
**мәкале, әйтеме дә,**
**мирасы—мәшһүр бинең дә,**
**бер дәрвиш хәкимнең дә—**
**язмышы сезнең хөкемдә!**

**Сезнең үлчәү берәмлекләр—**
**гасырлар да дәверләр!**
**Сезгәме соң тыңлашә ала**
**өч көн көчле Дәү ирләр!**

**Хәзинәнең сакчысы да,**
**хуҗасы да сез аның!**
**Сезгә, мөгаен, ачыграктыр**
**кая баруы дөньяның!**

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*1970 ел, ноябрь. Әлмәт.*

* * *



*Альберт Фәтхи. Казан, 1972 ел. Фото Әнвәр Шәриповның шәхси архивыннан.*

Без Альберт белән бер урамда уйнап, тауда бергәләп чаналар шуып үстек. Балачак елларында ул башкалардан аерылмый иде, бүтәннәр кебек үк бик шаян, шук малай булып үсте. 1944 елда Тактачалык авылы җидееллык мәктәбенең беренче классына укырга кердек. Ябык, кечкенә гәүдә, агарып торган йөз, монсу зур күзләр. Ул китап укырга яратты. Мәктәптә мин аның еш кына китап укып утырганын күрә идем.

Альберт кешеләрне үтәли күрә һәм искиткеч төгәл тасвирлама-характеристика бирә иде. Ихтирам иткән, яраткан дуслары өчен сөенә дә, кайгыра да белде. Авылдашларыбыз Альбертны бик ихтирам иттеләр.

Ул үзе өчен тегендә-монда йөгерүләрдән, үзен күрсәтергә тырышулардан, карьера ясарга омтылудан, дөньяның ыгы-зыгысыннан өстен булды.

Аның кадәр китапка табынган, татар тарихына кагылышлы шулкадәр зур, бай шәхси китапханә туплаган бүтән кешене мин белмим. Аныкы кебек тарихи китаплар Әбрар ага Кәримуллинның бай китапханәсендә дә юк иде.

80 нче еллар ахыры—90 нчы еллар башындагы милли хәрәкәтне Альберт күрде, сөенде, катнашты, зур өмет белән яши башлаган иде. Милләт язмышында соңыннан килгән чигенү-югалтуларны, күңел кайту, үкенү-әрнүләрне, бәхетенәдер, ахрысы, күрмичә вафат булды.

**Нәзаһәт НУРУЛЛИНА,**
*библиограф. 2007 ел.*

* * *

Беренче курста укыганда, бер-беребезгә теләкләр әйтү дәфтәре ачып җибәргән идек. Альберт дустыбыз турында да анда язма фикерләр бар. Шуларны укыйм да хәйран калам—аның фән юлыннан китәсен тоемлаганбыз бит! Бераз шаяртыбрак та, аның күңелен үстерү нияте белән дә әйтелгәндер бәлки ул теләкләр:

Фәсыйх Хисмәтуллин (Фаяз Дунай): «Альберт, син тырыш, күп нәрсәне белергә омтылучан егет. Алга, биеккә, фән баскычларына эре адымнар белән атлап бар. Дустың Фәсыйх».

Резедә Хөсәенова: «... тирән фикерләвең сизелә. Минем сина Яңа ел теләгем: үз фикереңне курыкмыйча әйтергә өйрән һәм житди бул!»

Марсель Васильев: «Сократлык эшенне дәвам ит!»

Хәмзә Зарипов: «Әдәбият Коперникы булырга омтыл!»

Дусларының теләкләре кабул булды. Альберт Фәтхи кыю фикерле, эзләнүчән, бөтен барлыгын, яшь гомереңең һәр сәгатен фәнгә багышлады.

**Минвәгыйз ЗӘЙНЕТДИНОВ,**
*журналист. 2007 ел.*

* * *

«Аяклы энциклопедия» дип йөртсәк тә, аның гыйльми дәрәҗәләре дә, мактаулы исемнәре дә юк иде. Ләкин, хикмәти хода, чал чәчле профессорлар да, фәндә беренче адымнарын атларга жыенган аспирантлар һәм студентлар да аның белән аралашуны зур мәртәбәгә саныйлар, гаять четерекле сораулары белән аңа мөрәҗәгать итәләр иде.

—Альберт Фәтхи белән кинәш син...—Белсә, Альберт кына белә торгандыр,— дип әйтүләр ул чакларда бик гадәти иде. Аның рәсми дәрәҗәләргә тиң «Альберт Фәтхи» дигән зур исеме бар иде.

**Әхмәт РӘШИТ,**
*шагыйрь.1998 ел.*

* * *

Альберт Фәтхине кульязмалар укырга һәм борынгы төрки телгә Хатыйп абый Госман өйрәтте. Хатыйп ага бик көчле галим иде. Шәкерте Альберт та борынгы язмалар һәм иске татар теленең зур белгече булып өлгерде.

Исән булса, ул әдәбият тарихын һәм татар кульязма китабын өйрәнүнең теориясен, методологиясен эшләгән булыр иде дип уйлыйм. Һәрхәлдә, шуны башкарырлык мәгълүматы һәм белеме, әзерлеге һәм тәҗрибәсе бар иде. Альберт шул юнәлешне башлап җибәрүче булды. Альберт яхшы мәгънәсендә фанатик, фәннең фанатигы иде.

**Альберт ЯХИН,**
*галим. 2006 ел.*

* * *

Гадәти тарихчылары, филологлары, йөзәрләп-йөзәрләп, хәтта меңәрләп исәпләнә торган халыкларның да чын археографлары бармак белән генә санарлык аз була.

Фән өлкәсенә беренче адым атлаган студентлардан алып, иҗатларына йомгак ясаучы олы галимнәргә кадәр Альбертның киңәшенә, ярдәменә мохтаҗ вә бурычлы иделәр. Тарихчы белән телчесе дә, әдәбият белгече белән фольклорчысы да. Ә аның уникаль хәтере, колачлы белеме беркемне дә битараф калдырмый иде. Чит шәһәрләрдән, башка республикалардан килүчеләрне аның тюркология өлкәсендәге күпкырлы эрудициясе гаҗәпләндерә иде.

Мәрхүмнән калган хезмәтләрнең иң әһәмиятлесе сыйфатында татар әдипләренең вә галимнәренең кульязма мирасларын өйрәнүгә багышланган тасвирламасының дүрт чыгарылышын күрсәтергә кирәк (1960, 1962, 1968, 1986).

Альберт Фәтхи исемен киң җәмәгатьчелеккә таныткан, аның үзенә сөенеч белән бергә көенеч тә, рухи җәбер-золым да китергән хезмәтләренең берсе «Казан утлары»нда чыккан «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бағланышлар» дигән зур китапларга да торырлык күләмле мәкаләсе иде (1968). Сталинизмнан соң хөкем сөргән торгынлык елларында чыккан бу чын фәнни объектив хезмәт фәндә ялганлауны кәсеп кылган рәсми идеология ялчылары тарафыннан эзәрлекләнүгә дучар булды.

Һәрхәлдә, әлеге мәкалә чыкканнан соң болай да язмыш тарафыннан яшьли кыерсытылган А.Фәтхи тәмам сындырылган иде. Йомык, шикләнүчән табигатьле Альберт тагын да йомыла, янә дә кырыслана төште, шикләнүчәнлеге бермә-бер артты. Ә ул замана, белгәнебезчә, илдә диссидентлык хәрәкәте колач җәя башлаган, шуңа күрә шымчылык—жасуслык хөкем сөргән, һәр җирдә диярлек, бигрәк тә миллиятлеккә караган өлкәләрдә сатлык җаннар өскә чыккан замана иде.

Вакытында өйләнә алмыйча калган Альбертның кешеләр белән якын аралашудан качуы артканнан-арта барды. Тормыш тәмен ул бары китаплардан гына эзләде, өс-башына, көнкүреш шартларына да игътибар итмәде. Формаль дәрәҗәләргә төкереп карап, ачлы-туклы хәлдә китап җыю гадәте аның шул елларда аерата көчәя башлаган иде. Гомеренең иң җегәрле, иҗатка иң кулай өлешен китап шкафлары белән шыгрым тулган, «Әбүгалисина мәгарәсе» дип кушамат алган кысан, таш идәнле салкын бүлмәдә кульязмалар өстенә иелгән килеш, ялгызлыкта уздырды ул. Автор буларак та бу елларда аның мөмкинлекләре бик нык чикләнгән иде.

Альберт рухи мәдәниятебез тарихына караган зур күләмле китап язу нияте белән яшәде, ул хезмәтен тагын да тәплерәк, янә дә нигезлерәк итү хыялы белән мавыкты. Ләкин мәңге яши торган кеше кебек ул эшне гел киләчәккә чигереп килде...

Бүген ул җыйган, ул туплаган белемнәрнең зур өлеше—язылусы китаплар нигезенә ятасы фактлар, янача янгырарга тиешле фикерләр чикләнгән фани дөньядан китеп, очсыз-кырыйсыз бакыйлык томанына чумдылар.

Үҗәтлеккә дә бер мисал. Конференция вакытында аның өс-башының бик чамалы булуын күргән Туфан Миңнуллин, костюм-чалбар алсын дип, Язучылар берлегеннән матди ярдәм оештырырга булды. Ләкин, кат-кат искәртеп торуга карамастан, Альберт үз исеменә язылган акчаны барып алмыйча, Берлек бухгалтерларын ярты елдан артык җәфалаган иде. Дөресрәге, монда сәер горурлык белән үҗәтлек бергә кушылган иде.

Шул ук вакытта фәннилеккә, тарихи гаделлеккә тугрылыгын ул бервакытта да үзгәртмәде. Туган халкына булган ихлас, мәгәр кырыс мәхәббәте дә нык килеш калды.

**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
*галим. 1994 ел.*

* * *

Альберт үзен кызганучыларны яратмады, ул горур иде. Кайсы ел икәнлеге хәтеремдә калмаган. Бер вакыт бүлек мөдиребез В.В.Аристовка Литфондтан шалтыраталар: «Фәтхиевкә акча билгеләнгән иде, хәбәр иттек, нишләп килеп алмый? Ведомостьны ябасы бар, тиз килсен!»—диләр. Альберт аңа: «Мин бармыйм, минем беркемнән дә алачагым юк!»—дип җавап бирде. Аристов әйтә: «Диләрә, син бар инде, аңлат аларга»,—ди. Мин баргач, кул куйдырып, ул акчаны биреп җибәрделәр. Альберт: «Кирәкмәс иде барырга»,—дип бераз ачуланып та алды.

Еллар үтте... Альбертның вафатыннан соң бер папкада акчалар килеп чыкты. Болар, һичшиксез, шул акчалар иде, Альберт аларга орынып та карамаган! Ул акчага без Альбертның төсе булсын дип, үзе эшләгән бүлектәге хезмәттәшләренә файдалану өчен чәй эчү кирәк-яраклары алдык.

**Диләрә АБДУЛЛИНА,**
*библиограф. 2003 ел.*

* * *

«Казан утлары» өчен дип, университетның татар әдәбияты кафедрасында эшләүче ике профессор бер-бер артлы мәкалә язып карадылар. Редколлегиянен кинәйтелгән утырышында укып тикшерелгәннән соң, аларның икесе дә сыек дип табылды. Күпмедер вакыт инде нишләргә дип аптырап йөргәч, Альберт Фәтхигә мөрәҗәгать итеп карарга булдык. Альберт ул чагында танылып килгән яшь галим иде.

Ни гаҗәптер, Альберт озак ялындырып тормады. «Ярар, язармын,—диде,—тик өч-дүрт айсыз булмас»,—диде. Күрәсең, «Башкорт халкының әдәби мирасы» аның да канын катырган булгандыр.

Ул сүзендә торды: әйтелгән вакытка редакциягә 2,5 табаклар чамасындагы зур мәкалә күтәреп килде. Мәкалә шәп иде, без теләгән, без көткән төпле һәм фәнни мәкалә иде. Ә.Харисов китабының барлык кимчелекләрен, шулай ук аның унай якларын да ышандырырлык итеп ачып биргән мәкалә иде. Ул, автор ничек китергән булса, шул хәлендә, «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр» дигән исем белән «Казан утлары» журналының 1968 елгы 2 санында басылып та чыкты.

Шул хәлләрдән соң группадашым А.Фәтхине очраткан саен күнелдә соклану һәм горурлану хисләре уяна иде. Профессор булып профессорлар булдыра алмады, ә ябык, чандыр гәүдәле, фәкыйрь киемле шушы егет әнә нинди мәкалә язып ташлады бит!.. (Житмәсә, теге профессорларның берсе, өс-башы фәкыйрь дигән сылтау белән, аны студентларга дәрес бирүдән читләштереп йөргән булды бит әле).

Тора торгач анладым, Ә.Харисов китабына төпле рецензия язу өчен бер үк вакытта әдәбият һәм тел галиме дә, тарихчы да булу соралган, А.Фәтхи исә шундый кеше, шундый галим булган икән...

**Фәрваз МИҢНУЛЛИН,**
*тәнкыйтьче. 1994 ел.*

* * *

*...Журналда ул елларда яналыкны яратучы Рафаэль Мостафин редактор иде һәм аның тәнкыйть бүлегендә Фәрваз Миннуллин инициативасы белән кыю-кыю мәкаләләр басыла иде. Берсен хәтерлим, хәтерлим генә түгел, архивымда саклыйм, ул—Альберт Фәтхинең «Мәгърифәт төбәкләре...» дигән искиткеч сенсацион мәкаләсе иде. Бу мәкаләсе өчен ана, һичшиксез, тарих яки филология фәннәре кандидаты дигән дәрәҗә бирелергә тиеш иде, ләкин «бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?» Бу мәкалә без ул елларда яклаган бер дистә кандидатлык диссертациясен бәреп ега иде!..*

**Мөхәммәт МӘҺДИЕВ,**
*язучы. 1993 ел.*

* * *

...Тулай торакка кайтсам, студентларның телендә тагы шул Альберт Фәтхи. Бүлмәдән бүлмәгә күчерә-күчерә «Казан утлары»нда чыккан мәкаләсен укыйлар... Чират миңа җитте. Язманы укый башлауга исләрем китте. Әстагъфирулла! Безнең Башкортстан турында ич бу!

Альберт абый! Синең шушы язмаңнан соң Башкортстандагы татарлар мәсьәләсендә башка фундаменталь хезмәт чыкмаса да, Айдар Хәлимнең тарихи хөкем карары булырдай елъязмасы, Татарстаннан читтә булса да, дөньяга чыкты, шөкер. Мин дә дистә еллар инде үз төбәгем халкы мәнфәгатен яклап татар матбугатында сүз әйтә алмый интегәм. Синең карьерана гына түгел, Башкортстандагы татарлар язмышы хакында сүз кузгаткан һәр кешегә каныгалар икән... Йә Ходаем! Хакыйкатьне таптап үтереп буламы да, хакыйкатьне тыеп яки аңа рөхсәт биреп буламы?

**Нәҗибә САФИНА,**
*шагыйрә. 2004 ел.*

* * *

Ул—университет китапханәсенең дымлы подвалларыннан чыкмыйча, татарның сирәк кулъязмаларын саклап кына түгел, йөрәк җылысы белән җылытып яшәгән Гыйльмияр...

1968 елның май ае. Химкорпусның бер зур аудиториясендә Әбрар Кәримуллинның татар китабы (мәгърифәте) тарихына багышланган кандидатлык диссертациясен яклау утырышы. Диссертацияне яклау уңышлы чыкса да, залда ниндидер киеренкелек сизелә иде. Шушы киеренкелекне диссертантның якын дусты, фикердәше Альберт Фәтхи йөзендә күрә идем. Йөзе аязлы-болытлы күк кебек үзгәрә иде: мөнбәргә яклаучы үзе күтәрелгәндә бер төрле, гыйльми җитәкче күтәрелгәндә икенче, оппонентлар күтәрелгәндә өченче төрле яктырып томанлана, томанланып карангылана, аннан тагын яктыра төшә иде ул. Гүя диссертацияне Әбрар ага түгел, Альберт Фәтхи үзе яклый иде. Мин моның нинди тирән мәгънәгә ия булганын



*Шигырь бәйрәмендә. Казан, 1981 ел.*
*Сулдан-уңга: Альберт Фәтхи, Вахит Хаков, Хәләф Гарданов.*
*Фото Әнвәр Шәриповның шәхси архивыннан.*

соңыннан, еллар аша гына аңладым. Бу, чынлап та, ул чакта Казандагы ике яшерен татар диссидентының үзләре генә белгән уртак диссертация яклаулары булган икән...

Берничә генә ай элек барча татар дөньясын кузгаткан «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби багланышлар» дигән мәкаләсе уңаеннан ул:

—Уфадан, башкорт «галимдары» Обкомга һәм университетка минем мәкалә өстеннән жалулар язганнар. Мине эшемнән алырга кушканнар. Алар фәнни бәхәс алып баруга караганда жалу язарга осталар икән...

—Кайгырма, Альберт абзый!..—дигән булдым мин татар-башкорт «әдәби багланышларының» никадәр тирәнгә кереп барганын һәм нәкъ егерме елдан үземнең дә шушы «багланышларның» корбаны булачагымны күз алдына да китерә алмыйча.—Ул бер ялгышлык кынадыр!.. Аңларлар, Уфада барысы да тиле түгел!..

—Шулай дисеңме?—диде ул,—анда бит үзебезнекеләр, үзебезне талап, докторлыклар яклыйлар!..

Татар китабының, татар кульязма китабының бөек белгече—Мәрҗание, әгәр телибез икән, татар кульязма китабының Тукае, суга төшкән балта сыман, югалды. Ул—безнең барыбызның битарафлыгы нәтиҗәсендә милләтебезнең җәһаләт упкынына биргән чираттагы корбаны иде. Ул фән кандидаты да, докторы да, академияләрнең мөхбир-әгъзасы да булмады. Ул мондый шартлы атамалар белән зарарланмыйча, белгеч кенә булып калды.

Альберт Фәтхинең фәнни мәкаләләрен җентекләп өйрәнергә вакыт. Аның татар мәгърифәтенең классикасына әйләнгән «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби багланышлар» дигән хезмәте татар мәктәпләре һәм югары уку йортлары программасына кертелергә тиеш.

**Айдар ХӘЛИМ,**
*язучы. 2007 ел.*

* * *

Альберт Фәтхи аек карашлы, нык әзерлекле һәм һич арттырып әйтмим: энциклопедик белемгә ия белгеч иде. Шуңа күрә аның күпләр өчен, хәтта зур хөрмәт казанган галимнәр өчен дә аерым мәсьәләләрдә консультант ролен үтәве бер дә гаҗәп түгел. Тупланган һәм өзлексез тулыландырып торган белемен башкалар белән уртаклашудан ул ямь-тәм таба торган иде һәм үзенең күп белүе, кинәшкә килүчеләрне (бигрәк тә башка шәһәрләр яки республикалардан килүчеләрне) шаккатыра иде.

Соңгы елларда Альберт нык үзгәрде, ашау-эчүгә дә, кием-салымына да игътибар бирми башлады, дибез. Баксаң, моның беребез дә белмәгән, маңгай күзебез дә, күңел күзебез дә күрмәгән башка сәбәбе дә булган икән. Мин моны үзара сөйләшеп торганда, көтмәгәндә һәм очраклы рәвештә белдем. Сәләмә өс-башын күреп кызганыпмы, мин аена күпме эш хакы алып эшләве белән кызыксындым һәм очны-очка ялгарлык та акча түләмәүләрен ишетеп, егылып китә яздым. Бу төпкә җигелеп тарта һәм ир уртасын узып бара торган хезмәткәрне күрәләтә мыскыл итү, җан асрарлык кына «ач паек»та тоту дигән сүз иде. Мин, билгеле, Язучылар берлеге кебек, үзенә костюм-чалбар алып ки дип матди ярдәм бирдертү, горурлыгына тию юлыннан китмәдем, ә китапханә директоры Ж.В.Щелывановага университет галимнәре, педагоглары исеменнән Альбертның кемлеген-дәрәҗәсен аңлатып һәм эш хакын арттыруны сорап хат яздым. Дөресрәге, коллектив исеменнән язган әлеге хатыма китапханәгә йөрүче бөтен татар профессор-доцентларыннан, зур-зур белгечләр һәм күренекле укытучылардан кул куйдырдым. Җәмгысе утыздан артык имза җыелды. Һәм мин шушы хатны: «Нишләп шундый көчле һәм талантлы белгечне, хәтта консультант хезмәтен үтәүче кадрны мәсхәрәле хәлдә тотасыз, бер дә уңайсызланмыйсыз мени?»—дип, директорның алдына китереп салдым.

(Әгәр шул чакта белгән булсам, мин болай да суык бүлмәдә утырып эчен салкын алган Альбертны УНИКС концерт-спорт комплексы төзелешенә җибәрелеп, цемент-кирпеч һәм комлы-ташлы төзелеш чүбе ташу кебек авыр эшләрдә аның

тәмам чиргә сабышуы өчен дә администрациянен җаваплы икәне турында әйткән булыр идем.) Киләсе айда ук Альбертның эш хакын арттырдылар, һәм бу аның өчен сюрприз булды. Менә аның ничек куанганын үзем генә беләм. Менә шушыннан соң инде ул төшке ашка көн дә диярлек Кремль ашханәсенә йөри башлады. Электән үк үзе яраткан музыкаль кичәләрдә, концерт заллары һәм театрларда еш кына пөхтә киемнән күренә торган булды...

**Марсель БАКИРОВ,**
*галим. 2007 ел.*

• • •

1965 елда мин Казан университеты аспирантурасына читтән торып укырга кердем. Гыйльми совет утырышларына йөрим. Татар (тел, әдәбият, тарих) аспирантлары яклавына, берсен дә калдырмастан, Нәкый ага Исәнбәт тә йөри. Чыгышлар башлангач, әлбәттә, ул да трибунага күтәрелә. Чын артист кеше: матур сөйли, чын оратор. Әмма ул трибунага осталыгын күрсәтергә дип түгел, сискәндергеч яна фикерләр әйтер өчен чыга. Мәсәлән, бер яклауда ул: «Боз кузгалды. Әмма бездә юан-юан баганалар аларны кузгатырга, агызып җибәрергә комачау тудыра. Шул баганаларны аудармасак, бозлык дәвере үтәсе түгел»,—дигән мәгънәдә чыгыш ясаган иде. Аның һәр чыгышы шул характерда була. Җәмәгатьчелек ягыннан мондый гайрәтне, хөр фикерлелекне күрмәгән безнең кебек куркытылганнарны ул сискәндерә, уйландыра, күнелләрдәге ирекле фикер чаткыларына җан керткәндәй була. Шул чакларда мин Альбертка игътибар иттем. Аның өчен Нәкый ага гүя мөселман энтузиастларына яңа вәхи китергән пәйгамбәр. Ул сүз әйтә алмас хәлгә килгәндәй: йөзе киеренке тартышкан, күзләре чаткыланган, тирә-ягындагыларга күз сала, күз кыса, авызын очландырып «во!» дигәндәй, баш бармагын күтәрә.

«Боз кымшану» (кузгалу ихтималы) сизелгәнеп киткән ул елларда, Кулъязмалар залында студентлар күбрәк күренә башлаган иде кебек. Бу деталь нәкъ шул елларда халыкның «сиземләү аппараты»—зур шигърияткә юкка гына килеп кермәгән. Мөдәррис Әгъләмовның «Баралмасам әгәр» (1970) шигырендә:

*Вәгъдә бирел, вакыт җитеп,*
*Баралмасам сиңа:*
*«Мәгарәдә ята,—диген,—*
*Әбүгалисина».*

Кулъязмалар бүлеген «Мәгарә» дип атаулар да, ихтимал, нәкъ шул чакларда тугандыр.

Альберт Фәтхи гомуми стандартлаштыру заманында һәр эшчәнлегендә шулай калыплашуга сыймас, стандартны тоташ боза торган «кире малай» иде. Сер түгел, «Татар халкы файдасы» дигән нәрсәне совет чоры «милләтчелек» дип тамгалады...

**Мәсгут ГАЙНЕТДИН,**
*галим, 2006 ел.*

• • •

Дустым Альберт Фәтхи күнелемдә бөек фикер иясе һәм ару-талуны, алны-ялны белмичә туган халкына, фәнгә хезмәт итүне үзенә төп максат итеп куйган көчле рухлы шәхес булып калды.

Альберт Фәтхинең «Татар әдипләре һәм галимнәре кулъязмалары» исеме белән басылган хезмәтләре, чын мәгънәсендә татар мәдәниятенең бер энциклопедиясе иде. Альберт Фәтхинең бу китаплары татар мәдәниятенә бирелгән паспортлар булдылар.

Альберт Фәтхи китапханәдә эшләп алган кечкенә генә эш хакына күп санлы матбугатка язылып, авыр хәлдә яшәде. Мәгълүмат аңа һава кебек кирәк иде. Ул ярым ач яшәсә дә, хәбәрдар булып гомер итүне артык күрде. Шул сәбәпле, ул елларда илдә барган, күпләр төшенеп житә алмаган сәяси вәзгыятькә түбәннән

торып объектив бәя бирерлек шәхес булып житеште. Әңгәмәләребезнең берсендә аның: «Жегетләр, бу реакциянең пигы узды инде, алда өмет яктысы күренә»,— дигән фикере хәтеремдә калган. Галим киләчәккә якты өмет белән яшәде.

Табышларына ул сөенеп йөрде. Ул үзе: «Әүвәлге Минзәлә өязен комплекслы өйрәнәм»,—дип сөйли, аның йөргән авылларына яңадан керүне өнәмәде. Чаллы шәһәре төзелүнең татар авылларын әхлакый яктан түбәнәйтүе хакында ачынып сөйләгәне хәтеремдә. Альберт археографик экспедицияләргә очраклы транспортларга утырып һәм җәяү йөрде. Аңа экспедицияләр өчен транспорт биргәннәрен хәтерләмим. Аның экспедицияләре уңышлы, табышлары күп булды.

Альберт Фәтхи үзенең иң зур археографик табышы итеп Алтын Урда дәвере татар шагыйре Хәйдәр Хәрәзминең СССР территориясендә бердәнбер данәдә табылган «Мәхзанел-әсрар» (Серләр хәзинәсе) кульязма әсәрен саный иде. Әсәрнең икенче бер кульязмасы фәкать Англиядә сакланганлыгы мәгълүм. Альбертның Актаныш төбәгендә ачкан бу табышы татар халкында Алтын Урда әдәбиятының башка җәүһәрләре саклануга да өмет уята торган вакыйга иде.

Аның янына татарның аңлы егетләре күп йөри, бу аның халык тарафыннан танылуы билгесе иде. Күренекле язучы Тәүфикъ Әйдине, библиофил Марат Вәлишинны, әдәбият галиме Мәсгут Гайнетдиновны һ.б. Альберт бүлмәсендә еш очраттым.

Бу елларда университетта археографик экспедицияләргә чыгып, күп табышлар кайта, ләкин алып кайткан табышларны, ягъни кульязмаларны эшкәртүчеләр юк, эш бары аның үзенә генә төшә, моны ул авыр кичерә иде.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында уздырылган һәртөрле конференцияләргә Альберт Фәтхи килми калмады. Ул еш кына экспромт чыгышлар ясап, теге яки бу тема хакында өстәмә мәгълүматлар бирә торды. Гомумән, Альберт Фәтхи тирән әзерлекле энциклопедик галим булып күптән өлгергән иде.

1990 елларда Альберт Фәтхинең сәламәтлеге нык какшады, ябыкты, кәефе дә начар булды. Ләкин ул халык арасына чыга, митингларда катнаша һәм хәлсез генә тавыш, ләкин канәгатьлек белән: «А-зат-лык!»—дип аваз бирә иде.

Аның вафаты көнелләрне тетрәндерде, мин аны, Габдулла Тукай язмышына дучар булган икенче бер бөек татар баласы, дигән фикердә калдым.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
*галим. 2005 ел.*

* * *

1964 елда «Наука» исемле кооператив йортның бер подъездында яши башлагач, Альберт энекәш белән якыннан таныштык, бер-беребезне хөрмәт итешеп яшәдек.

Галим-голәма, иҗат интеллигенциясе арасында «Аяклы энциклопедия» дип исем алган Альбертның, 50 яше тулу унае белән Казан дәүләт университеты ректоры биргән мактау грамотасыннан тыш, гыйльми дәрәҗәләре дә, мактаулы исемнәре дә юк иде.

Альберт китапка аеруча маһир зат булды шул. Китап кибетләренә ике-өч көнгә бер тапкыр эштән соң экскурсия ясады. Еш кына сатучылар аның намуслы булуын яхшы белгәнгә, акчасы житмәгән очракта, яраткан китабын әҗәткә дә биреп торалар иде. Ул китапка, газета-журналларга фанатик рәвештә табынган гаҗәеп үзгә табигатьле шәхес иде.

Университетны тәмамлагач запас офицер буларак хәрби лагерьда шактый вакыт хәрби өйрәнүләр үтүе, хезмәт итүе дә аның ябык гәүдәсендә, сәламәтлегендә эзсез калмагандыр...

**Фәнис ИСЛАМОВ,**
*галим. 2007 ел.*

* * *

Альбертны белгән барлык кешеләр дә аңа хөрмәт белән карыйлар иде. Бер генә мисал китерим. А.Фәтхи Кулъязмалар бүлегенең рус секторы мөдире В.В.Аристов белән бергә эшләде. Алар арасында чын мәгънәсендә дустанә мөнәсәбәт, бер-берсен ихтирам итү яшәде. Ул елларда «өлкән агайларның» татар милләтеннән булган кешеләргә бераз өстәнрәк, үзләрен хужа итебрәк караулары да очраштыра иде. Ә бу ике галимнең үзара мөнәсәбәтендә бу нәрсә, минемчә, бер дә чагылмады. Бу, бердән, В.В.Аристовның чын мәгънәсендә зыялы шәхес булуыннан килсә, икенчедән, А.Фәтхинең Казан галимнәре арасында зур авторитетка ия булуыннан, башка милләт галимнәре алдында да үзен куя белүеннән килә иде...



*Алгы рәттә (сулдан-уңга): Лена Закирова, Рәисә Яхина, Фәрит Хатыйпов (укытучы), Резедә Хәсәенова.*
*Арткы рәттә: Фәсыйх Хисматуллин, Альберт Фәтхиев, Флорид Әгъзамов, Мидхәт Миншин, Марсель Васильев, Әхмәт Рәшитов, Хәмзә Зарипов. 1954 ел.*
*Фото Минвәгыйз Зәйнетдиновның шәхси архивыннан.*

Шулай бервакыт ул миңа: «Мин күпне күргән татар әбиләрен бик яратам. Аларда никадәр акыл, никадәр наз, никадәр тормыш тәҗрибәсе бар»,—дип сокланып сөйләде, каяндыр алып, битләре җыерчыкланып беткән үз әбисенең фотосын күрсәтте. Мин моңа бераз гаҗәпсенебрәк карадым, чөнки моңа кадәр бары тик Наполеон, Петр I, Лев Толстой, Бетховеннарга, яисә Тукай, Такташ, Муса Җәлилләргә табынган кешеләрне генә очратканым бар иде, ә гап-гади, халык арасында кайчакта «ашын ашаган, яшен яшәгән» дип йөртелә торган, картаеп беткән татар әбиләренә табынган, аларны пьедесталга бастырып, дан җырлаган кешеләрне очратканым юк иде...

Ул үзенең «Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары» сериясендә 1960, 1962, 1968 һәм 1986 елларда чыгарган тасвирламалар җыентыкларына гомуми караш ташлап, тулы бер хезмәт язарга ниятләнеп, шуны уйлап, әзерләнеп йөргән иде. Әмма бу омтылышы, кызганычка каршы, тормышка ашмыйча калды.

Альберт Фәтхи чын мәгънәсендә зур, олуг галим иде. Ул галимнәрнең үзләрен өйрәтә торган, аларга юнәлеш бирә торган галим иде. Без аның олуглыгын (инде бу безнең халыкта гадәткә кереп китте диярлек) бары вафат булгач кына бәяли башладык. Вакыт үткән саен аның зурлыгы, олуглыгы, ул язган хезмәтләрнең әһәмияте тагын да ачыграк күренәчәк әле.

Альберт Фәтхи исемен мәңгеләштерү юнәлешендә күп нәрсәләр эшлисе бар әле. Мәсәлән, КДУның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Көнчыгыш кулъязмалары бүлегенә Альберт Фәтхи исемен бирергә кирәк. Бу мәсьәлә бер тапкыр күтәрелгән иде инде, әмма хәзергә хәтле хәл ителмичә калды шикелле. Шулай ук аның исемен туган авылы Такталачыктагы, район үзәге Актаныштагы берәр урамга һәм Такталачык авыл мәктәбенә бирү бик мәслихәт эш булыр иде.

**Әнвәр ШӘРИПОВ,**
*галим. 2007 ел.*

* * *

Альберт Фәтхинең тормыш-язмыш юлында, аның архивариус, текстолог, археограф булып өлгерүендә Хатыйп ага Госманның өлеше зур булган. Университетның кулъязмалар бүлегенә дә ул остазының фатихасы белән килгән.

Альберт абый асылы белән гамьле кеше иде. Гел борчылып, хәтта хәсрәтләнеп яшәде ул. Үзе өчен түгел. Әдәбият, тарих, мирас язмышы өчен, үзебезнең изге шәхесләребез, рухи терәк-баганаларыбыз өчен, аларның саф исемнәре өчен жанын, гомерен бирергә әзер иде ул. Гомерем буе әдәбият казанында кайнап, милли мирасны күтәрүгә фанатикларча гомерен багышлаган бүтән мондый кешене очратмадым мин. Ул Һ.Атласи, Г.Исхакый кебек шәхесләребезнең милли мирастан читләштерелүләренә жан ачуы белән үртәлеп, әрнеп яшәде.

Еллар үтә тора, ләкин күңелдәге бер сораудан һич кенә дә котылып житә алмыйм: кем соң ул Альберт Фәтхи? Ул башкарган хезмәтнең исеме ничек? Аңа лаек гыйльми дәрәжә бармы? Ул безнең күңелләрдә калды, әмма әдәбият, мирас тарихында аңа лаек урын һаман табылмаган...

**Галимжан ГЫЙЛЬМАНОВ,**
*язучы. 2006 ел.*

* * *

Альберт абый күрешкән саен студент яшьләрнең тормышын сораша иде. Кем балалары укый, татарлар күпме, алар туган телләрен беләме, үзара татарча сөйләшәләрме, кемнәр туган телләреннән кача, китап ярataлармы, милли тарих белән кызыксыналармы, укытучыларга сораулар бирәләрме, илдәге хәлгә ничек карыйлар, сәясәткә тартылалармы, киләчәкне ничек күзаллыйлар, комсомолниләр бетереп ята (нәкъ шулай ди), ниһаять, аракыны нык эчәләрме? Ул шулкадәр бирелеп, ихлас игътибар белән тыңлый, кирәк жирендә рәхәтләнеп көлеп тә жибәрә һәм, һәрчак диярлек, сөйләгәннәрдән аксиома дәрәжәсенә күтәреп, өзеп әйтеп нәтижә ясап куя.

Ул бигрәк тә чит ил укучылары турында яратып тыңлый иде. Ничектер мин аңа фәнни коммунизм бүлегендә укучы (анда идеологик кадрлар әзерләнде) Лаос студентларының өчәр-дүртәр ел Союзда яшәп, рус телендә ипилек-тозлык сөйләшә алмасалар да, курстан-курска күчеп килүләрен әйттем. «Бу бит, Фәрит туган, менә дигән факт!—Альберт абыйның күзләре усал ялтырап алды,—империягә гыйлемлеләр кирәкми. Ул авызына карап тора торган ангыра марионеткаларны махсус әзерли!»

Бервакыт Альберт абый белән сөйләшә-сөйләшә фойега төшеп киләбез. Китапханә ишегеннән шактый гына салган хәлдәге бер галимебез кереп бара. Фәтхи баскычтан йөгереп төшеп, ачуланып-сүгеп, этә-төртә бичараны китапханәдән куып та чыгарды. Ярсуы йөзенә чыккан, үзе тынычлана алмый, һаман шул кешене әрли. «Альберт абый,—дим,—бетеренмәгез алай. Ул бит менә дигән галимебез, чарасызлыктан эчәдер...» Утка май салдыммени.

—Фәрит туган, теләсә кем булса төкерер идем мин аңа. Халкыбызга үрнәк булырга тиешле зыялыларыбыз шәп сылтау таптылар: милләт бетә, милләт өчен йөрәк әрни диялəр дә, эчәргә тотыналар. Бик жинел котылалар. Кара көчләр алдында горур басып көрәшәсе урынга, тамаша ясап, исереп, аунап йөриләр. Татарның дошманына шул гына кирәк, ул шатлана, кул чаба. Әллә миңа жинел идеме, әллә минем йөрәгем әрнемиме? Минем хәлне кайсыгыз белә? Алар мантыйгыннан карасаң, миңа ятып эчәсе генә калган хәзер. Ә мин аек, мин сынмыйм,—Альберт абый кинәт туктады һәм, ачулы атлап, китапханәдән чыгып китте...

**Фәрит ШӘКҮРОВ,**
*галим. 2007 ел.*

* * *

Альберт абый гыйлемгә һәм фәнгә бик зур хөрмәт белән, хәтта изгеләштереп карады. Ул галимнәргә дә, фәнгә тартылучы яшьләргә дә бик таләпчән иде. Өметлерәк студентларны үз итте, яхшы мөгамәләдә булды. Фән хадимнәрен дандәрәҗәләренә, түрә булу-булмауларына карап катлауларга бүлмичә, фәнгә керткән өлешенә, гаделлегенә күрә аера иде. А.Фәтхи фән өлкәсендәге «монополиячелек», «кода-кодагыйлык», көнчелек, тар күңеллелеккә ихластан борчылды. Ул татар фәненең гаделлеге, сафлыгы һәм әхлакый төзеклеге турында хыялланды. Фән тирәсендә очраклы буталучы узгынчыларга, исем алуны максат иткән ертлач бушкуыкларга Фәтхи бик тискәре мөнәсәбәттә булды. Ул ФӘН дип аталган гөлбакчаның булдыксызлар белән чүпләнүенә әрнеде. Аның фикеренчә, галим дигән сүз фән кандидаты яки докторы кебек формаль исемнәр белән генә тәңгәл түгел, болар кешенең гыйлем дәрәҗәсен билгеләми. Чын галим булу өчен коры исемнәр генә җитми, гыйлем мәртәбәсе өстенрәк дип исәпли һәм камиллеккә омтыла иде. Исемнәр, дан-шөһрәт артыннан кумады да. Андый ясалма дәрәҗәләрнең ниндидер калып-кысаларга керүне таләп итүен, шәхси хөрриятнең чикләнүен бик яхшы белде. Дәүләт тарафыннан фән әһелләрен, галимнәрне исем-дәрәҗәле тартма һәм киштәләргә бүлеп карауны үз итә алмады Альберт абый.



*Шигырь бәйрәмендә. Сулдан-уңга: Тәуфикъ Әйди, Эрнест Зәйни, Альберт Фәтхи. Казан, 1966 ел, 25 апрель.*

Үзе теркәп калдырган аерым кәгазьләрдән Фәтхинең сәламәтлеге бик четерекле булганлыгы күренә. Мәсәлән, 1964 елда эчке органнарына бәйле җитди авыруга дучар булуы, 1966–1979 елларда даими сызланулары, өстәвенә 1978 елның җәендә химикат белән агулануы һ.б. катлаулы хәлләре аңлашыла. Көчле авыруы сәбәпле 1964 елның язында һәм 1979 елның декабрендә дөнья белән хушлаша язып калуларын да теркәгән. Ә аннан соң берничә операция кичергән. Шул хәленә карамастан, сыкрануларын сиздермәскә тырышып эшләп йөргән һәм милләткә тугры хезмәт иткән ул.

Альберт Фәтхи ихласлы, гадел, кыю фикерле, туры сүзле, тирән белемле һәм әхлаклы, татар милләте өчен янып-әрнеп яшәгән шәхес иде. Аныкыдай тирән эчке әхлаклылык кебек күркәм сыйфат нәкъ менә кайбер фән әһелләребезгә җитеп бетмәде һәм җитми дә. Фән кыяларын яулап иң югарыга менсәләр дә, кызганычка каршы, Альберт абый дәрәҗәсендәге әхлакый һәм тәрбияви биеклеккә ирешүчеләре сирәк. Халкыбызның садә күңелле, тыйнак, милләткә хезмәт итүне шәхси мәнфәгатьләреннән өстен күргән сирәк шәхесләре турында берәүләрнең таш кыялар биеклегеннән торып хөкем йөртүләре, максатчан түбәнсетүләре—үзләренең әхлак микъдарын күрсәтә торган бер дәлил. Ә холык-фигыль мәсьәләсенә килгәндә, талантлы фән һәм иҗат әһелләренең гади күпчелеккә, хәтта якыннарына да аңлашылып бетми торган хикмәтләре—дөньялыкта була торган хәл. Ләкин милләтнең йөзек кашыдай шәхесләре хикмәтле яклары белән түгел, кылган гамәлләре, иҗади мираслары җәһәтеннән кыйммәтле. Тагын шунысы бар: Фәтхинең холкыннан беркемгә инә очы кадәрле дә зарар-зыян килмәде. Ул Ходайның киң дөньясын тарайтырга тырышып, бүтәннәрне кояш яктысыннан мәхрүм итәргә омтылып мәгънәсезләнмәде. Киресенчә, гыйлемлекнең якты үрнәге булды.

Фәтхине Тукай белән тиңләүчеләребез, һичшиксез, хаклы. Шундый ук мәгърурлек, садәлек, хакыйкатькә һәм милләткә тугрылык.

**Раиф МӘРДАНОВ,**
*галим. 2005 ел.*

## Альберт Фәтхи

Йөрәгемне, татар китабыдай,
Ачам уртасыннан—
Укыйм, дисәм, аннан Альберт Фәтхи
Атлап чыгар сыман.

Төнлә ачтым. Ачтым йөрәгемне,—
Һәрбер битен беләм.
Йөрәк китабына Альберт Фәтхи
Каян килеп кергән?

Ап-ак ыштан. Ап-ак күлмәк белән
Кара кәзәкидән—
Әйтерсең лә, татар китабын ул
Кием итеп кигән.

Аккош күле. Ут юк. Йөреп торам
Китап ера-ера:
«Шәмең яндыр!»—диеп, Альберт Фәтхи
Шырпы суза миңа.

Өй яктыра. Ике кулын сузган
Ике катлы шәмдәл;
Альберт Фәтхи булып өскә килә
Ышанмаслык хәлләр...

Котым чыга,
Аягүрә басам,
Ялгышамдыр, бәлки:
Саф һавага чыгып карга чумам,
Карда—Альберт Фәтхи.

Мунча ягып, пар эченә керәм,
Кысам да йөрәкне,—
Пар эченнән көлеп карап тора
Миңа Альберт Фәтхи.

Шунда миңа, пәйгамбәре аша,
Сүз иңдерә Ходай:
—Юк, ул синнән хәзер калмас инде
Татар китабыдай.

Гаҗиз булып тәмам, арып-талып
Өйгә кайтып авам;
Татар китабын япкандай
Йөрәгемне ябам.

Юкка гына затлы кием киеп
Йөрмәс Альберт Фәтхи;
Татар китабының авыр хәле
Җиңеләер, бәлки...

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ,**
*1991 ел.*

# ФӘТХИ

Галимебез Альберт Фәтхиевне без—житмешенче еллардагы яшь язучылар—«Фәтхи» дип кенә йөртә идек; ул үзе мона бер дә каршы килми, хәтта болай эндәшү ана ошый да иде. Фәтхи турында аның сабакташлары, әдәбият, тарих, фән-гыйльмият тирәсендәгеләр ара-тирә сөйләштергәлиләр иде. Фәрваз Миннуллин (тәнкыйтьче), Кояш Тимбикова (язучы), Зоммер Гыйләжев (журналист) Фәтхинең студент чагыннан ук тырыш, үҗәт, эзләнүчән холыклы булуы һәм дә яшәү рәвеше белән башка сыйныфташларына бер дә охшамаганлыгы турында гелән искә төшереп торалар иде. Бу хатирәләр сөйләүчеләрнең үзләренә кызык булса да, без, яшьләр, сөйләнгәннәрне шундук онытa да идек, чөнки без әле ул вакытта Фәтхине якыннан танып белмибез. Ул безгә абстракт шәхес иде. Ләкин бер вакыйга өлкән буын язучылары, сәнгатьчеләре өчен генә түгел, яшьләр өчен дә гадәттән тыш хәлгә әверелде һәм Фәтхине безнең каршыда ун башка югары күтәрде.

«Казан утлары» журналында «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр» исемле мәкалә басылып чыкты. Язучысы Альберт Фәтхи иде. Мәкаләдә тарих, тел, әдәби мирас турында сөйләнә. Әдәбият-тарих тәнкыйтендә монарчы яшәп килгән штамплар, хакыйкатьне бозып күрсәтергә тырышучылар Фәтхинең әче тәнкыйтенә дучар булды. Мәкалә, асылда, Башкортстан галиме Әхнәф Харисовның гыйльми хезмәтләре турындагы тәнкыйть иде. Авторның ялгышларын, тарихи фактларны үз кирәгенә боргалап, фәнни булмаган ысул белән эш итүен Фәтхи кире кага алмаслык дәлилләр белән ачык итеп күрсәтте.

Фәтхи әдәбият, сәнгать кичәләренә, яна спектакльләргә еш йөри, музыка, рәсем сәнгате корылтайларыннан калмый. Уртача буйлы, какча чырайлы, бик гади киенгән, аның өстендә гел бер пинжәк, гомере үтүк чырае күрмәгән чалбар, кер күтәрә торган көрән төстәге, гадәттә, шакмаклы күлмәк булыр. Мин аның муенына галстук тагканын беркайчан да күрмәдем. Кара чәчле, туры борынлы, бераз Тукайга охшаган чибәр кеше иде ул. Өс-башын рәтләп, кырынып җибәрсә, кызлар күзе төшәрдәй егет иде. Ләкин ул көяз булмады. Тарих, әдәбият-сәнгать, сәясәт турында сүз чыкса, аның күзләре очкыннар чәчә башлый, очынып-ачынып милләт турында сәгатьләр буе сөйли ала иде. Аны һич ялыкмыйча тыңлап була иде. Ул юмарт галим, белгәнен башкаларга тапшырырга әзер торучы киң күңелле шәхес.

Тарих гыйлеме өчен галимнең намуслы, вөҗдан иясе булуы шарт. Галим үзе өчен, үз милләтенең файдасына энә очы кадәр дә ялганларга тиеш түгел. Альберт Фәтхи әнә шундый саф вөҗданлы галим иде.

Гадәттә галим кешеләрне сәер итеп сурәтлиләр, имеш, көнкүрештә алар таркау; имеш, алар көлке аңламый торган, үз фәненә кереп чумган төксе һәм аралашмаучан адәмнәр. Минемчә, бу сурәт төгәл түгел. Галимнәр арасында гаять кызык, тормыш тәмен белеп яши торганнар да аз түгел.

Фәтхигә карата әлеге сурәтне кулланcак, өлешчә генә файдалана алыр идек. Фәтхи таркау түгел, көлкене яхшы аңлый торган, башкаларның әсәрләрен күп укый торган, тере зиһенле, күңел ачу кичәләренең берсен дә калдырмый торган тулы канлы шәхес иде. Без оештырган ШТМ мәҗлесләрендә Фәтхи башыннан азагынача катнаша, сатира-юморны, кинаяле әсәрләрне аңлый торган уцлы адәм иде.

Дөрес, Фәтхи кием-салым турында кайгыртмый, ни бар—шуны кия, ни бар—шуны ашый. Ләкин буйдак булса да, ул ач утырмый, аның өендә бозылмас өчен артык тозланган җылкы, сыер ите мул әзерләнгән була иде. Фәтхи өйлә ризыгын һәрвакыт Кремльдәге ашханәдә ашый, үз кашыгын алып килә, шулпалы ашны ашап, ит ризыгына күчкәч, котлет икәү булса, берсен генә ашый, ит зур кисәкле булса, аның яртысын ашап, калганын үзе белән алып китә. Ипинең, ризыкның валчыгын да әрәм итми. Бу аның буйдаклыгыннан да, бәрәкәтле булуыннан да,

гади китапханәче буларак, аз акча алуыннан да, сугыш чоры баласы буларак, ачлыкның ни икәнен белүеннән дә килә торгандыр, мөгаен.

ШТМ кичәләреннән соң артистлар, язучылар корган мәҗлесләрдән дә ул калмый, яшьләр белән бергә була, ләкин бер грамм да хәмер эчми, шифалы су гына йотып, бәхәсләрдә катнашып утыра. Егетләр киерелеп торып тәмәке кабызгач та түзә, чыгып китми, ләкин үзе тәмәке тартмый иде.

Милләткә бирелгәнлеге, тарихи хакыйкать өчен җанын фида кылырга әзер булуы, алын-ялын кызганмыйча, һаман халыкка хезмәттә булуы аны изгеләр-әүлияләр рәтенә куя.

1990 елларда халык азатлык таләп итеп урамга ургылды. Ирек мәйданына кайчан килсән дә, Фәтхи иң алгы сафта булыр, ул да халык белән бергә көрәшкә чыкты.

Башта 200-300 кеше обком бинасын урап, Ирек мәйданына кайтабыз, һавада:

—Азатлык! А-зат-лык!—таләбе яңгырый.

Тора-бара нәмаешчылар саны арта барып, мәйданга ун меңләп кеше тупланды. Фәүзия Бәйрәмова, Зәки Зәйнуллин, Газинур Морат, Рәшит Әхмәтҗаннар ачлык тотканда утыз меңләп кеше җыйналган иде. Казан каласы—таш каланы дер селкетеп, ирек-тигезлек таләп итеп йөргәндә халык арасында Альберт Фәтхи дә бар. Бөтен халык берьюлы кычкырганда Фәтхи дә сөрән сала; ул йодрыкларын төйнәп, чандыр беләген һавага ора, аның тамагыннан:

—Азатлык! А-зат-лык!—дигән оран атылып чыга.

Фәтхинең авазын бәлки беркем дә ишетмидер, авазы халык дингезенә кереп урала, сеңә. Азатлык яулауда Фәтхинең дә өлеше бар; мин ишетәм, аның иҗат хезмәте дә азатлыкка үз өлешен кертә.

Аның чандыр гәүдәсе, ябык йөзе сәяси көрәш дәрте белән тулы, аның зәңгәр күзләре очкын чәчә иде.

Шундый нәмаешларның берсендә шатлыгын яшерә алмыйча:

—Батулла, ниһаять, бу көннәрне дә күрәсем бар икән!—дип әйткәне истә.

Суверенитет игълан ителгән көнне аның күзләре дымлы иде. Бу аның куаныч яшьләре иде.

Туксанынчы еллар башында мин Лобачевский исемендәге китапханәгә йөри башладым. Максатым—Сөембикә турында тарихи чыганакларны уку иде. Ләкин ханбикә турында кириллица белән язылган әсәрләр юк, гарәп хәрефләре белән язылганнар «ябылуда» иде әле. Фәтхи шундагы «мәгарә»дә эшли иде. Тимер ишекләр артындагы сирәк кульязмалар бүлеген ул шулай атый иде. Гарәп имлялы язмаларны миңа Фәтхи таба. Мин, эшкә йөргәндәй, көн саен мәгарәгә киләм. Гарәп имлясын акрын укыйм, кайчакларда сүзнең дөрес укылышын белмим яки мәгънәсен аңламыйм. Шул чакта мин Фәтхигә мөрәҗәгать итәм: бөтен эшен ташлап, ул миңа ярдәмгә атыла, аңлата, сөйли. Ул очрашулар миңа күп белем бирде, тел буенча, халык авыз иҗаты, тарих буенча мин аннан төпле, җитди мәгълүмат алдым. Фәтхи минем Сөембикә турында әсәр язарга алынуымны бик хуплый һәм әсәрнең уңышлы чыгуын бик тели иде. Аңа чиксез рәхмәтләрем.

—Сөембикә турында син китап язарсың, шигем юк, ләкин бер китап белән генә Сөембикә кебек затлы шәхесне тулысынча күтәреп булмас. Аның турында китаплар күп булырга тиеш, операсы да, балеты да, киносы да, документаль ленталары да, киң полотнолы рәсемнәр дә иҗат ителергә тиеш. Без Сөембикә белән Тукайдан башка миллә̆т була алмыйбыз!

Шундый очрашуларның берсендә Тукай турында сүз чыккач, Фәтхи болай дигән иде:

—«Тукай» дигән фән булырга тиеш. Тукайның өйрәнелмәгән бер генә көне дә булмаска, бер генә үзенчәлеге дә игътибардан читтә калмаска тиеш. Фән икән, шәхеснең бар ягы да өйрәнелергә тиеш, Тукай ни ашаган, ни эчкән, кая барган, кайдан кайткан, бу әсәре ничек язылган—барысы да тәфсилләп язылырга, тарихта калырга тиеш.

Ни гаҗәп, Нурихан Фәттахның тарихка, Ана телебезгә кагылышлы мәкаләләрен Фәтхи өнәп бетерми иде.

—Тарих хыялга корыла алмый, Батулла туган. Тарих дәлил-исбат сорый!

Фаразлар, гөманнар булырга мөмкин, ләкин исбатланмаган шикле фараз ул—утопия, һәм фән өчен, һәм халык өчен зыян эшли.

Бервакыт шул мәгарәдә берничә галим белән әңгәмә булып алган иде. Фәтхи сөйләүчеләрне игътибар белән тыңлый, сүзгә катнашмый. Галимнәрнең берсе нидер әйтте, Фәтхи сикереп торды да академикка каршы төште, галим фикеренең киресен сөйләп китте. Башкалар да олы галимнең фикере дөрес түгеллеген, Фәтхинең хаклы икәнен икърар иттеләр. Әйе, олы-олы исемнәр, дәрәҗәләр яулаган галимнәр дә Фәтхидән бераз шүрләбрәк торалар иде.

Баш булмаса койрык аза ди. Туксанынчы елларда коммунистлар партиясенең казыгы какшый башлагач, төрле оешмалар, төрле фиркаләр үсеп чыкты, «болгарчылар», «тәнречеләр» пәйда булды. Иң абруйлы галимнәребезнең берсе әнә шул «болгарчылык»ны күтәреп чыкты да инде. Бу хәрәкәтне Фәтхи җаны-тәне белән кабул итмәде.

—Зур галим, ләкин бу мәсьәләдә ялгыша ул,—диде Фәтхи «болгарчылык»ны башлап йөрүче әлеге галим турында.—Исеме ошамаса, кеше алыштырсын, тик шәһәр исемнәрен, милләт исемен алыштыру ул тамырга балта чабу дигән сүз. Болгарлыгыбыздан баш тартмастан, без—татар! Шундый яңгыравыклы матур исемне алыштыралармыни? Ул кеше: мине армиядә урыслар «татар» дип мыскыл иттеләр, без болгар булып языйк, дип аргумент тапкан. Урыс бит аны татар булганы өчен түгел, урыс булмаганы өчен тукмаган. Болгарга алмаштыргач урыс мине тукмаудан туктар дип ялгыша ул. Болгар булып язылгач та урыска син барыбер нацмен булып калачаксың...

«Сөембикә» язылып бетте, басылып та чыкты. Миннән битәр Фәтхи куанды.

—Булдырдың, дустым,—диде Фәтхи китапның тышлыгын назлап сыпыра-сыпыра.—Инде алга таба ни кылачаксың?

—Алга таба христиан диненең какшау урыннарын, очы-очка ялганмаган җирләрен тәнкыйть итеп бер памфлет шикелле нәрсә башламакчы булам!—дидем.

Мин остазым тарафыннан хуплау көткән идем, ләкин нәкъ киресе килеп чыкты. Юаш-тыныч холыклы күренгән Фәтхием кинәт ярсыды:

—Ташла, Батулла! Беткәнме сиңа башка темалар!—дип кычкырды.—Башкаларның иманына кагылма! Бу хата юл! Әгәр шуны язсаң, син үзеңә каһәр алачаксың!

Еллар буе әзерләнеп йөргәннәремне, дәртем-теләгемне шушы өч җөмлә җимерде дә ташлады, чөнки Фәтхи бу сүзләрне үткәзерлек итеп, ышандырырлык итеп әйтте. Ул мине бер мизгелдә тәрбияләде дә куйды. Фәтхи юаш күренсә дә, усал була белә иде.

Шул вакыйгадан соң мин әлеге уемнан ваз кичеп, Коръәнне өйрәнә башладым. Шулай итеп, без якынаеп киттек. Икебезнең уртак фикерләр безне тагын да якынайткандыр.

Фәтхи үз фатирына беркемне дә кертми иде. Ул фото сорап килгән сабакташы Кояш Тимбикованы гына керткән һәм анда да ханымны ишек катыннан уздырмаган.

—Альберт мине чәй эчәргә дә кыстамады,—дип искә ала иде Кояш ханым.—Утырып торырга урын да күрсәтмәде, кирәкле фотоны алгач:—Гафу ит, Кояш, эшем тыгыз, сау бул!—дип озатып та җибәрде.

Үз йортына читләрне генә түгел, якын танышларын да кертмәгәне турында мин дә белә идем, шулай да Яңа ел бәйрәмендә—1969 елның 31 декабреннән 1970 елның 1 гыйнварына чыккан төндә—кайнар өчпочмаклар, гөбәдия алып, Фәтхине Яңа ел белән котларга киттем, без якын тора идек. Бөтен дөнья «от зари до зари о любви говори» дип тамак киереп җырлый, урам тулы исерек, халык бәйрәм итә. Фәтхи ни эшли икән бу мизгелдә? Фатирының тәрәзәсендә ут бар, димәк, ул да кем беләндер бәйрәм ясый булыр, дип уйладым.

—Бу мин әле—Батулла,—дигәч, Фәтхи ишекне ачты.

Бүлмәгә уздым. Бөтен дөнья бәйрәм иткәндә Фәтхи ялгызы эшләп утыра икән.

Йә, Ходам! Өй эче тулы китап, кульязмалар, кәгазьләр. Ишек катында таптанып торам. Күчтәнәчләрне алды Фәтхи.

—Утыр дип әйтер идем, урын юк!—диде.

Өйдә кульъязмалар арасында ике генә сукмак бар, сукмакның берсе аш почмагына илтә, икенчесе—ятак урынга. Калган урыннарда авыллардан җыйган кульъязма китаплар, түшәмнән идәнгә чаклы башлыйнә белән тегелгән кәгазь битләре. Бары тик түшәмгә генә бер кәгазь дә ябыштырылмаган иде.

Фәтхи мине аш почмагына дәште. Бераз сөйләшеп утырганнан соң, залга чыгып, ул үз байлыгын күрсәтә башлады.

—Бусы бер томлык материал, менә монысы икенче томлык,—дип ул бер системага салынган кәгазьләрне күрсәтә.

Анда кимендә ун томлык материал бар иде.

—Фәтхи, син боларны кайчан китап итеп чыгарасың инде?! Ашыгырга кирәк бит,—дидем.

—Пенсиягә чыккач, башка эш белән шөгыльләнмичә, мин шушы кульъязмаларны рәткә салып, күптомлык итеп әзерләргә уйлыйм!—диде галим.

Ләкин көннәрнең берендә аның мәетен үз фатирының аш бүлмәсендә таптылар. Фәтхинең вафат булганын бер ай дәвамында берәү дә белмәгән. Ишекне пүнәтәйләр белән ватып кергәннәр. Йөрәге тоткан булган.

Томнар чыкмыйча калды, ләкин аның гомере буе туплаган кыйммәтле материаллары ышанычлы кулларга эләккәндер дип өметләнәм.

Авыр туфрагы җиңел булсын, урыны җәннәттә булсын! Амин!

**Рабит Батулла, язучы.**
*1 май, 2007.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклаңган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ӘДИП. ГАЛИМ. МӨХӘРРИР.

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, педагог һәм журналист Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәти (Нигъмәтуллин) 1897 елның 26 июлендә хәзерге Башкортстанның Чишмә районына кергән Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында игенче гаиләсендә дөньяга килгән. Галимҗанга ике яшь чагында, аның әтисе гаиләсен ияртеп Уфа шәһәренә күчә. Төрле төзелешләрдә гади эшче булып көн күргән Әмирҗан агай, тормыш авырлыгына карамастан, улын укытырга тырыша: Уфаның алдынгы «Галия» мәдрәсәсенә урнаштыра. Галимҗан анда бик тырышып укый, соңгы сыйныфларда чагында үзе дә шәкертләргә әдәбият дәресләре бирә башлый.



Илдәге 1917 елгы революцион үзгәрешләрне Галимҗан Нигъмәти укытучы буларак каршылаган, ул чагында мәдрәсәдәге укучылар комитетында эшләгән.

Г.Нигъмәти 1918 ел ахырында Көнчыгыш фронтның Бишенче Кызыл Армия политбүлеге органы «Кызыл яу» исемле газетада эшли башлый. 1919 елның язында, Уфа шәһәре Колчак гаскәрләре кулына төшү куркынычы тугач, Г.Нигъмәти Бәләбәй шәһәренә күчә һәм редакциядәге хезмәтен дәвам иттерә. Шунда вакытта, 1919 елда Коммунистлар партиясенә алына. 1919 елның декабрендә Бишенче Армиянең Реввоенсоветы карары белән, газета хезмәткәрләре, шул җөмләдән Г.Нигъмәти дә, партия Үзәк Комитетының Себер бюросы карамагына күчерелә. Анда Г.Нигъмәти Омскида (соңыннан Новосибирскида) чыккан «Азат Себер» газетасында башта җаваплы секретарь, аннары редактор булып эшли.

1921 елда Г.Нигъмәти Мәскәүдәге Көнчыгыш коммунистик институтның бер еллык курсларында укый һәм шунда ук татар курсантларына татар әдәбияты буенча дәресләр алып бара. 1922-23 елларда Дәүләт журналистика институтында белем ала. ВКП(б) Үзәк Комитетының милли матбугат бүлегенә инструктор итеп билгеләнүе сәбәпле, институтны тәмамламыйча кала.

Мәскәү чорында (1921—1926) Г.Нигъмәтинең журналистика, әдәби тәнкыйть һәм иҗтимагый фәннәр өлкәсендәге актив иҗат эшчәнлеге башлана. Ул яшь совет матбугатының һәм әдәбиятының төрле мәсьәләләренә багышланган күп санлы мәкаләләр һәм марксизм-ленинизм тәгълиматы, социализм нигезләре турында популяр характердагы фәнни хезмәтләр язып бастыра. «Октябрь һәм әдәбият» (1922), «Карл Маркс безгә нәрсәләр калдырды?» (1922), «Адәмнәр ничек яратылган?» (1924), «Ленин һәм пролетариат революциясе» (1924) кебек мәкаләләре һәм «Коммунизм турында» (1924), «Әдәбият мәйданында» (1925) исемле китаплары аның шул еллардагы иҗади активлыгына дәлил.

1926 елның ахырында Г.Нигъмәти Казанга килә һәм «Кызыл Татарстан» газетасына баш редактор итеп билгеләнә. 1928—1930 елларда Татар дәүләт нәшриятының баш редакторы булып эшли. Редакторлык хезмәте белән берртән, 1929 елдан башлап Көнчыгыш педагогия институтында әдәбият укыта. 1933 елда ул институтның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, ә 1934 елдан профессор һәм кафедра мөдире вазифаларын башкара. 1930-32 елларда, төп эшеннән аерылмыйча, «Яңалиф» журналының җаваплы секретаре, редакторы булып та тора.

Бу елларда Г.Нигъмәтинең әдәби-тәнкыйть эшчәнлеге тагын да киңәя. 1927—1932 еллар арасында гына да ул дүрт китап, иллегә якын әдәби-тәнкыйть мәкаләсе язып бастыра. Аның бу хезмәтләрендә татар язучыларыннан М.Гафури, Г.Коләхмәтов, Дәрдмәнд, Г.Ибраһимов, Ш.Бабич, К.Нәҗми, Һ.Такташ, А.Шамов, И.Гази, Г.Толымбай һәм башкаларның иҗатлары тикшерелә. Ул шулай ук Л.Толстой, А.Чехов, М.Горький кебек рус әдәбияты классикларының иҗатлары турында да мәкаләләр яза. Ул бигрәк тә Г.Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә игътибарын юнәлтә һәм аңа күләмле берничә мәкаләсен багышлый («Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?», 1929; «Г.Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы турында», 1932; «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә революция мотивлары», 1928 һ.б.).

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турында»гы 1932 елгы карары һәм совет язучыларының I Бөтенроссия съездыннан (1934) соң Г.Нигъмәти, үзенең әдәби-эстетик карашларындагы һәм методологиясендәге элеккеге пролеткультчылык һәм вульгар социологизм элементларыннан арына барып, татар әдәбиятының үсеш процессларын тагын да тирәнрәк һәм нигезлерәк итеп анализлый башлый. «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933), «Социалистик реконструкция чорында совет татар матур әдәбияты» (1934), «Татар совет әдәбияты күтәрелештә» (1934), «Шәриф Камал—драматург» (1934), «Татар совет драматургиясенең үсеше» (1935), «Һади Такташ» (1936) һәм, ниһаять, Г.Тукай иҗатына багышланган «Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы» (1936) исемле хезмәтләр Г.Нигъмәтине марксистик-ленинчыл тарихилык концепцияләренә нигезләнгән әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче буларак раслый.

Педагог буларак, Г.Нигъмәти татар әдәбияты фәне буенча югары квалификацияле белгечләр хәзерләү эшенә күп көч сала. Соңыннан исемнәре киң танылган филология фәннәре докторлары Мөхәммәт Гайнуллин, Хәмит Ярми, Гали Халит, филология фәннәре кандидатлары Җамал Вәзиева, Мөхәммәт Мамин, Якуб Агишев, Гази Кашшаф, язучылардан С.Хәким, А.Алиш, А.Әхмәт, И.Туктаров һ.б.—Г.Нигъмәтинең шәкертләре.

Г.Нигъмәтинең бай әдәби мирасы хәзерге көндә дә кыйммәтен югалтмаган. Татар әдәбияты тәнкыйтен һәм әдәби хәрәкәте тарихын өйрәнүдә бу мирас әлегәчә үзенең файдалы эшен башкара.

Татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур һәм кыйммәтле өлеш керткән, татар совет әдәбиятын үстерү өчен күп көч һәм талантын биргән күренекле тәнкыйтьче, әдәбиятчы галим һәм тәҗрибәле педагог Галимҗан Нигъмәти нахакка гаепләнеп 1937 елда кулга алынган, 1941 елның 4 ноябрендә һәлак булган. Үлеменнән соң акланган.

Галимҗан Нигъмәтинең әдәбият мәйданындагы игелекле эшен балалары—кызы Йолдыз һәм улы Энгель—әдәбият галимнәре буларак дәвам иттеләр.

*(Бу биобиблиографик язмада Г.Нигъмәтинең «Сайланма әсәрләр» (төзүчеләре Җ.Нигъмәтуллина һәм Ә.Мәүлиханов, 1958) китабындагы, Р.Даутов һәм Н.Нуруллинаның «Совет Татарстаны язучылары» (1986) хезмәтендәге материаллар файдаланылды).*

❋



# Зәки Зәйнуллин

## Шахматтагы ике ат һәм һәйкәл Салават

1948 елның октябрь ае. Район үзәгендәге китапханәдә гәзит-журналлар актарып, укыштырып утырам. Минем янга китапханәче, Мөеш Хәйбрахман бабай кызы Фәридә апа килде (бүгенге көндә Казанда яши).

—Зәки! Син туганым шахмат уйный беләсенме?

—Беләм.

—Бер абзыйның бик тә шахмат уйныйсы килә. Тик уйный белүче юк. Уйнале шуның белән!

—Кайда ул?

—Әнә, иң кырдагы өстәл артында утыра.

Мин инде тугызынчы сыйныфта укыйм, җаен унбиш яшем тулды. Тик минем буй-сын 12–13 яшьлек малайларныкы хәтлек кенә. Һич кенә дә үсеп булмый бит. Ашау житмәгәннәндер дип уйлыйм үзем. Һәм мин кечкенә гәүдәле булып калырмын дип бик тә куркам. Кешеләр белән, бигрәк тә олы гәүдәлеләр белән аралашмаска тырышам.

Кырдагы өстәл артында безнең урамдагы Ташкергән Сәхиулласына охшаган, иллене узган бер абзый утыра иде. Безгә, авыл малайларына авылда яшәп кырыкны узган һәркем бабай инде. Минем өчен бу кеше дә бабай!

Шушы Сәхи бабайга охшаган кеше өстенә сорырак пальто кигән (китапханә эче суыграк), өстәл кырында шундый ук төстәге эшләпә дә ята. Матурлап кырган сарырак мыегы да нәкъ Сәхи бабайныкы шикелле. Урыныннан азрак кузгала биреп, абзый исәнләшергә ике кулын суза һәм урысчалап сорый:

—Исемең ничек?

—Зәки.

—Ә тулы исемең ничек?

—Әхмәтзәки.

—Минем исемем Сосланбек. Кавказдан мин. Шахмат уйный беләсеңме?

—Беләм. Азрак.

—Шулаймы? Азракмы!

Елмая абзый.

—Әййе.

Өстәл астыннан тартмасы белән шахмат тартып чыгарды да бу, кулына кара һәм ак пешкалар алып, аларны өстәл астында ике учына яшерде.

—Сайлап ал!

Миңа кара пешка эләкте.

Тотындык минсинәйтим уйнарга! Үземчә мин ару гына уйнаган кебек

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН (1933)—*язучы, галим; «Полковникны озату», «Ник ямансу бу күзләр?», «Агыйделнең аръягында...» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

идем инде. Мәктәптә мине җинә алган бер генә укучы да юк. Математик Мәгъсум абый Зәйнуллин мине пыр туздырып җинә иде дә, минем «бәхеткә» ул Свердловск каласына күченеп китеп барды. Үземә үзем бик ышанып уйный башладым—җинәм лә мин бу Кавказдан килгән картны!

Ләкин!

Абзый кеше баштан ук үзенең ике филен дә миңа биреп, минем атларны алды. Ат белән фил көч ягыннан бер чама, шунлыктан мин бу хәлгә әлләни әһәмият бирмәдем. Атларны алу белән, бу Кавказ кешесе сигез пешкасы белән дә һөҗүмгә күчте. Пешкалар алдан, алар артыннан ике ат, ике ладья бара, алар пешкаларны тылдан саклап, ныгытып килә. Ә минем аның тылына чыгарга атлар юк. Ә филләргә юлны пешкалар тоташ ябып, мине кысрыклап киләләр. Мин үземнең пешкаларны алмашка биреп карыйм да бит, алышмый, каһәр! Инде миңа йөрергә дә җай калмады. Менә ул пешкалар аша сикертеп, ике атын минем якка кертеп җибәрде дә, мине тар-мар итеп ташлап, мат биреп тә куйды. Моңарчы беркайчан да болай тиз һәм көчле тар-мар ителгәнем юк иде әле.

Ул көнне рәттән дүрт мат алып, кәеф тәмам төшеп, кикрик шиңеп кайтып киттем район китапханәсеннән...

Төнлә әллә нинди тынгысыз төшләр күреп саташып чыктым. Теге абзый мине шахмат тактасы өстендә корыч дагалы, ярсу, гайрәтле ике атыннан таптата икән. Атларга ияреп бер көтү пешкалар йөгерә икән. Барсы да миңа «мат!», «мат!» дип кычкыралар икән!..

Икенче, өченче... бишенче, алтынчы көннәрдә дә бу Сосланбәк миңа мат арты мат куя бит!

Ә яшисе килә! Отыласы килми! Ничек инде мин, Лотфулла Писер малае, эшләпә кигән бер Капказ кешесеннән мат арты мат алып торырга тиеш ди әле! Үзебезнең Эстәрлебаш авылында, үзебезнең китапханәдә!

Уйлый торгач, таптым бит әй. Тар-мар ителүдән котылу юлы әлләни катлаулы да түгел икән. Абзыйның филләренә үземнең атларны бирмәскә! Һәм мин, уйный башлау белән ике филне алга китереп чыгарам да, тегенең һөҗүм итә башлаган филләренә каршы юнәлтәм, филгә—фил! Тегеңәрдә дә атлар бар, миндә дә атлар кала. Абзый пешкаларын минем якка куа, мин үземнекеләрне аның ягына куам. Арттан атлар, ладьялар бара. Өйрәндем бит Сосланбәк абзыйдан аның тактикасына. Китә сугыш, китә алдаш, китә урап үтүләр һәм кырылыш! Дөньялар, тыштагы карлы буран-суыклар, ярым буш, ач корсак—бар да онытыла.

Безнең бу алышларга ике ай тулып узган чакта биш партиянең икесе минеке була иде инде. Кавказлы абзый яңа тактика уйлап чыгарып мине отты исә, икенче партиядә үк аның тактикасын мин үзенә каршы кулланам. Хәле мөшкелләнсә, абзыйның күзлеге тирли башлый. Күзлеген сөртергә дип чуар яулыгын чыгара икән, минем эчкә җылы йөгерә. Тагын да тырышыбрак, дәртләнебрәк ябырылам үзенә. Көннәр үтә-үтә без уйнаган өстәл янына халык җыйнала башлады. Тавышланмыйча, пышылдап сөйләшеп кенә фикер алышалар һәм минем өчен җан аталар. Үзебезнең авыл малае алыша ләбаса Кавказ кешесе белән!..

Шулай март азакларына кадәр «сугыштык» без шахмат тактасы өстендә. Тигез алыша идек инде...

Бер көнне килсәм, Сосланбәк абзый юк. Фәридә апа миңа «Овод» исемле урыс телендәге китап бирә. Кичә Сосланбәк абыйны Уфадан килеп «Победа» дигән машинада алып киткәннәр икән.

—Менә, сиңа истәлеккә китап калдырды. Язуы да бар. Укы!—диде Фәридә апа.

Укыйм: *«Заки, дорогой! Будь таким же упрямым, каким ты играл в шахматы. Постарайся учиться и получить хорошее образование.*

*Сосланбек ТАВАСЕЕВ.*
*Март, 1949 год».*

1969 елда, Рига каласында хәрби аспирантурада укып йөргән чакта, хәрби китап кибетеннән бер буклет сатып алдым. Шунда Уфа каласында Салават Юлаевка куелган һәйкәлнең фотосы бирелгән. Анда һәйкәл авторының да фотосы бар. Ул фотодан мина... бик тә таныш йөз карап тора иде! Йөрәк урыныннан купкандай дөп-дөп тибә башлады. Бу кеше мин 1948-49 елларда Эстәрлебаш китапханәсендә шахмат уйнаган Сосланбәк абзый иде... Ул Салават батырны атландырган ат та төштә мине куган-таптаган шахмат атлары кебек ярсу, гайрәтле иде.

Скульптор Сосланбәк Тавасеев безнең Эстәрлебаш авылына 1941 елның июль аенда Мәскәүдән эвакуация белән килгән була. Һәм Эстәрлебашта, ир-егетләрне сугышка озаткан чакта, бер башкорт картыннан беренче мәртәбә Салават Юлаев дигән батыр турында ишетә.

Салават Юлаевка һәйкәл кую уе аңа 1941 елның июль-август айларында, безнең Эстәрлебаш исемле татар авылында килгән...

Эстәрлегә кайтышлый һәрчак мин Уфага кереп чыгарга тырышам. Салават Юлаев һәйкәле янында, Агыйделнең биек ярында озак-озак басып торам. Салават батыр рухына һәм бөек осетин скульпторы Сосланбәк Тавасеев рухына белгән догаларымны кат-кат укыйм. Догалар укыган саен күңел жылына бара, күзгә яшь килә. Гомер үтеп бетеп бара! Ә үләсе килми!

## Җиде юл чатында

1989 елның 17 май киче. Вакыт 18 сәгать 15 минут. Ригадан Мәскәүгә бара торган «Юрмала» (латыш телендә «Диңгез») поездының 7 нче вагонында юлга чыктым. Риганы, Латвияне, хатынны ташлап чыгып киттем.

Төн «Юрмала» вагонында үтте. Иртәнге сигездә поезд Мәскәүгә килеп җитте. Сул кулда—урта зурлыктагы чемодан, уңында—гомерем буена җыйган, тарихка караган архив документлары тутырылган дүрткелле парашют капчыгы. Илле алты яшен тутырып барган отставкадагы полковникның бөтен байлыгы шушы инде.

Чемодан белән капчыкны Мәскәүнең Рига вокзалындагы саклау камерасына тапшырам да, вокзал алдына чыгып басам. Башта бер генә уй: «Кая барырга хәзер? Ничек итеп яшәп алып китәргә!» Чөнки мин япа-ялгыз урамда калган кеше. Туганнар да, гаилә дә, яшәргә урын да—юк. Һәм мин бүгенге көнне беркемгә дә кирәк түгелмен!

Җанны тынычландырырга тырышып шулай бик озак басып торгач, ике тапкыр Советлар Союзы батыры, Кырым татары Әмәтхан Солтан кабере янына барырга булдым. Ул батыр егет—урысларның атаклы Новодевичье зиратына күмелгән бердәнбер мөселман. 1971 елның 31 гыйнварында самолет катастрофасында һәлак булды 50 яшендә.

Мәскәүгә килгән саен мин аның каберенә барам. Барып басам, чәчәкләр салам һәм озак-озак итеп, үземнең уйларга күмелеп басып торам. Әмәтхан сугыш вакытында немецларның 72 самолетын бәреп төшергән очучы ас. Татар булганлыктан, өченче Алтын Йолдызны бирмәделәр аңа.

Мин зиратка кереп, Әмәтхан кабере янына барып җиткәндә, анда олы яшьтәге бер мөләем генә хатын кабернең гранит ташларын юа иде.

—Әссәламегаләйкем, апа!

Апа тураеп баса да, татарчалап җавап бирә:

—Хуш киләсең, акыллым! Вәгаләйкем әссәлам!

Минем кулдагы чәчәкләргә күз сирпеп алды.

—Минем юып бетергәнне көт инде. Мин хәз-зер!

Сорыйм:

—Сез Әмәтханның берәр туганымы әллә?

Апа матур итеп елмая:

—Әйе! Туганы мин Әмәтханның. Кырым татары мин. Ә без, Кырым татарлары, барыбыз да туганнары Әмәтханның. Якын туганнар! Син дә Кырым татарымы?

—Юк, апа! Мин Уфа ягы татары. Шулай булса да, мин дә Әмәтхан Солтанны үземнең бертуган абыем дип саныйм.

—Дөрес, туганым! Дөрес! Менә мин һәр атнаны килеп, Әмәтханның кабер ташын юам. Үзем юам, үзем елыйм бертуктаусыз. Безнең асыл Әмәтханыбыз урыс тәреләре арасында япа-ялгызы ята бит, дип елыйм. Ул монда ятарга тиеш түгел.

—Ә кайда ятарга тиеш?

—Бөтен Кырым жиренә күренеп тора торган биеклектә—Ай-Петри тау башында безнең батырыбызның урыны. Кырымны карап яткан кебек ятсын. Кабере өстенә һәйкәл итеп лачын куярга кирәк. Гранит-таштан. Әмәтхан бит ул без татарның йөрәге имгәтелгән лачын кошы... Андый егет Жир йөзендә бүтән юк!..

Хатын эшен төгәлләде.

—Куй, туганым, чәчәкләреңне! Бик тә олы йөрәкле, нечкә күңелле егетсеңдер син! Исемең кем?

—Әхмәтзәки булам мин.

—Чын татар икәнсең. Рәхмәт сиңа бу кабер янына килгәнең өчен. Зур рәхмәт.

Кычкырып «Әлхәм»не укыйм. Апа, кулларын «догага куеп», минем артымда басып тора. Дога тәмамлангач, жылы итеп хушлашып китеп бара...

Ә минем барыр урыным юк. Сәгатьтән артык сүзсез генә, онытылып Әмәтхан янында басып торам. Уйланам. Тик уйларымның очына чыгарлык та түгел, һәм аларны бергә жыйнап, нәтижә дә ясарлык түгел.

Әмәтхан кабере яныннан киткәч, зират эчендә бик озак йөредем мин. Заманында бик атаклы булган шәхесләрнең каберләрен карап йөри-йөри йөрәк азрак басыла төшкән кебек булды...

Бер кабер янында тукталдым. Тимер чардуганы нык тутыккан, кабер өстен чүп баскан, ташландыкка әйләнгән. Бу—революциягә кадәр үк атаклы журналист-репортер Владимир Алексеевич Гиляровский кабере. Аны бөтен Мәскәү белгән, «Дядя Гиляй» дип кенә атап йөреткән.

Костюмны салып, чардуганга элеп куйдым да, эшкә тотындым. Чүп үләннәрен йолкып, кабер өстен тигезләдем. Бер агач кисәге табып алып, чардуганны тутыктан тазарттым. Бик зур эш башкарган сыман, чардуганның кечкенә капкасын ябып, тимер чыбык белән уратып, бикләп куйдым. Зират капкасы янындагы киосктан зәңгәр, сары төстәге чәчәкләр сатып алып килеп, кабер өстенә үрелеп куйдым. Якындагы колонкада кул-битне юып, кульяулык белән сөрттем дә, кабер янындагы кечкенә эскәмиягә утырдым. Эш бетте, көлтә жыясы гына калды!..

Кая барырга? Нәрсә эшләргә?

Шул ике сорауга жавап таба алмыйча бик озак утырдым мин «Дядя Гиляй» кабере янындагы эскәмиядә. Утыра торгач, күз бер хәрәкәтне искәрде. Мин утырган жирдән берничә кабер аша өлкән яшьтәге бер ханым эшли—кабер ташлары юа. Берсен юып бетергәч, икенчесен юа башлады. Ә ташлар бик матурлар. Минем эш юк—теге хатынның эшләгәнен күзәтеп тыныч кына утыра бирәм. Хатын миннән 5-6 яшькә өлкәнрәк күренә. Менә ул икенче ташны да юып бетерде, өченчесен юа башлады. Таштагы язулардан күренә—беренче ике кабердә полковник дәрәжәсендәге чик сакчылары күмелгән. Өченче кабердә Советлар Союзы Герое булган подполковник жәсәде ята. 46 яшендә вафат булган. Ә полковникларның яшь аралары байтак—32 ел. Өченче ташны юа башлар алдыннан хатын чиләктәге суын каядыр барып түгеп килде дә, колонкадан саф су агызып алды. Минем күзәтеп утырганны сизенде, ахрысы—карап-карап алгалый башлады...

Хатын жыйнак кына гәүдәле, чалбар, сорырак төстәге жиңелчә генә

куртка кигән. Башына артка тарттырып сорырак яулык бәйләгән.

Байтак кына эшләгәч, бу тырыш хатын өченче кабернең гранит-мәрмәрләрен дә юып бетерде. Өч кабер арасындагы сукмакларны себерде, җыелган чүпне каядыр илтте. Аннан соң чиләк, кечкенә себерке, чүпрәк, пумалаларын, соскысын каядыр алып барып яшереп килде бугай. Бер кабер ташы янындагы кара төстәге сумкасыннан сабын, сөлге чыгарып, колонкадан литрлы пыяла банка белән су алып, үләнлерәк җиргә басты да, битен-кулларын юды. Сөлге-сабынын, банкасын кире кара сумкасына салып, аннан кечкенә көзге алды, чәчен төзәтте. Баш яулыгын сумкасына салды да, миңа табан борылды. Күзләре нур чәчеп тора иде хатынның. Менә ул яныма килеп туктады да, елмайды.

—Сезнең янда эскәмиядә урын бар. Миңа утырырга рөхсәт итегезче, зинһар!—диде ул.

Мин эскәмия читенәрәк шудым:

—Утырыгыз! Урын җитәрлек.

Хатын утырды. Елмаюы юк булды җылылык бөркелеп торган ягымлы һәм матур тавыш белән дәште:

—Гафу итегез! Минем сезгә бер соравым бар.

—Рәхим итегез!

—Сезнең бик зур кайгыгыз бар, ахрысы. Шулаймы?

—Юк. Кайгы юк миндә.

—Ә нәрсә, алайса? Күзегез газап белән мөлдерәмә тулы бит.

—Кайгы түгел ул. Минем тормышта катастрофа булды.

Күнелсез генә елмаям үзем.

—Ката-астро-оф-фа-а?!

Хатын аз гына уйлангандай булды да, акрын гына сөйли башлады:

—Мин сезнең өчен чит-ят кеше. Яшькә сездән олырак. Миңа сездән берни дә кирәкми. Берни дә. Мин бик акыллы еврейка. Мәскәүнең бик күп еврейләре миңа киңәшкә киләләр. Рәхмәтләре бик зурдан була мин биргән киңәшләр өчен. Әгәр миңа ышансагыз, сөйләгез миңа... катастрофагызны.

Мин дәшмичә уйланам. Ничек инде зиратта яныңа килеп утырган таныш булмаган бер еврей хатынына үзеннең эчке халәтеңне ачып саласың ди?

Хатын исә ышану теләге тудыра торган җылы сүзләр әйтте:

—Сез—урыс түгел. Мин—еврейка. Сөйләгез миңа, тартынмагыз да, яшермәгез дә. Юкса мондый киеренкелектән йөрәгегез шартларга мөмкин.

Үзем дә көтмәстән, мин «чишелә» башладым:

—Полковник мин. Запастагы. Гаиләмне ташлап чыгып киттем.

—Башка хатынгамы?

—Юк минем башка хатын дигән нәстәм. Утырам менә... зиратта. Кая барырга белмичә.

—Белемегез, һөнәрегез бармы?

—Бар, Техник фәннәр докторы мин. Прочнист.

—Пенсиягез күпме?

—Полковник пенсиясе инде. Ике йөз илле сум.

—Сер булмаса, әйтегез әле, нигә ташладыгыз хатыныгызны.

—Без гомер буе начар яшәдек. Соңгы елларда төннәрен өйгә кайтмаулары ешайды.

—Берәр җирдә урнашырга дигән уегыз бармы?

—Мәскәүдә түгел. Алма-Атага барырга дигән уем бар... азрак... Хезмәттәшем димли, анда синең кебек галимнәр кирәк, ди.

—Алма-Атада бит казакълар яши. Ә сез—татар.

Миңа кызык булып китте.

—Минем татар икәнне сез каян белдегез инде?

—Сугыш елларында мин Алабуга каласында яшәдем. Кырык дүрткә кадәр. Сез татарларны әйбәт беләм мин. Сез дөньяда иң яхшы күнелле, кин җанлы милләтсез. Татарлар кебек башка асыл халык юк дөньяда. Тик сезнең бер

зур кимчелегегез бар...

—Нинди?

—Бик тә мәрхәмәтле милләт сез!

—Бу кимчелек түгел бит, өстенлек.

—Әйе, өстенлек булыр иде. Әгәр сезнең тирәдә үзегез кебек мәрхәмәтле күршеләрегез яшәсә. Урыс милләтен генә алып карагыз—күпме башка милләтләрне юк итте, күпмесеннән үзләре кебек урыс ясады...

Ханым бераз күзгә текәлеп торды.

—Читкәрәк кереп киттек. Әйдә, сезнең проблемага якынрак килик. Сез Татарстаннанмы?

—Юк. Уралдан.

—Кай тирәсеннән?

—Башкортстаннан.

—Минем уем-исәбемчә, сезгә Казанга кайтырга кирәк.

—Фатир...

—Мине тынлап бетерегез. Сез ир буларак та көчлегә ошагансыз. Хатыныгыз сезне тыныч калдырмас. Ничек кенә булса да кире кайтарырга тырышачак. Балаларыгызга, оныкларыгызга булган мәхәббәтегезне, сагынуларыгызны нык файдаланачак. Белемегез бар, һөнәрегез дә шәп—сопромат бит?

—Әйе.

—Башкортстанга кайтмагыз. Анда урыс шовинистлары надан башкорт милләтчеләрен татарга каршы котырталар, татарларны бик каты кысалар. Сез татарга анда урын булмаячак. Фәндә дә, эштә дә, яшәргә дә...

Үзегезнең татарлар янына, Казанга кайтыгыз. Белемегез зур, һөнәрегез бик кирәкле. Татар халкы сезнең кебек улына юкка чыгарга юл куймас. Тынлагыз мине!

Көлеп җибәрде.

—Мин чыннан да бик акыллы еврейка. Тынлагыз!

Мин каберләргә ымладым:

—Кем каберләре бу?

—Пограничник полковникларнын берсе—әтием, икенчесе—ирем. Ә Герой очучы—бертуган энем.

—Рәхмәт. Мин китим инде.

Тора башладым. Хатын да урыныннан торды, хушлашырга кулын сузды.

—Кунарга урыныгыз булмаса, әйдәгез, дачама алып китәм. Курыкмагыз, күршеләр бар анда.

Мин сакланып кына сузылган кулны кыстым.

—Рәхмәт сезгә! Мин бүген поезд белән Казанга китәм. Шунда урнашам. Алма-Атага үземнең дә бик барасым килеп тормый иде. Аннан соң, мин бит әле татар язучысы да. Берлек әгъзасы түгел түгелен, ләкин күп язам.

—Ниләр язасыз?

—Әлегә кыска гына юмор хикәяләре.

—Дөрес бу, юморда сирәк язучы гына эшли ала. Күбрәк языгыз... Кирәксә, телефонымны да бирә алам.

—Яхшы киңәшегез өчен зур рәхмәт. Хәзергә шул житте. Кирәк булса, мин сезне үзем эзләп табармын.

Кызыксынып карый:

—Ничек итеп?

—Шушы урынга килермен.

Шатланып елмая:

—Ярар, алайса. Хушыгыз!

—Исән булыгыз!..

Кич житкәндә мин инде, йоклап китәргә исәп тотып, «Татарстан» поездының аскы сәкесендә ята идем...

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# Г

**ГАЛИЕВ** Әнәс Касыйм улы (3.4.1920, Арча р-ны Кушлавыч а. -26.7.1996, Казан), язучы. Казан финанс-икътисад техникумын тәмамлаганнан соң (1939) башта Юдино һәм Дөбъяз р-ннарында, соңрак Казанда налог инспекторы булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942 елның сентябрендә Майкоп шәһәре тирәсендә барган бәрелешләрдә каты яраланып, әсирлеккә эләгә. Фашист концлагерьларындагы (Польша, Германия) авырлыкларны үз җилкәсендә кичерә. 1945 елда Америка гаскәрләре тоткынлыктан азат иткәннән соң, совет эвакогоспиталенә озатыла. 1945 нең октябрендә Казанга әйләнеп кайта. 1946-70 тә (өзеклек белән) ТАССР Финанс министрлыгы оешмаларында эшли. Беренче шигырьләре 1937 дә басыла. Г. - «Сөю» (1940), «Кыен юл» (1958), «Тормыш бакчасында» (1960) исемле шигъри җыентыклар авторы. 1960 еллардан нигездә проза өлкәсендә иҗат итә. Фашист тоткынлыгының бөтен газапларын чагылдырган автобиографик характердагы «Йолдызлар шаһит» (1968), «Һәр солдатның үз язмышы» (1991) повестьларын яза. Финанс оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә багышланган «Намус кушканча» (1982) , «Җәза озак көттермәде» (1994) повестьлары да әдипнең тормыш тәҗрибәсеннән алынган. «Авылдашлар» (1995) романында фәлсәфи-психологик анализ аша кешенең эчке дөньясын ачып бирә.

Әд.: Расих А. Язучы турында берничә сүз // Социалистик Татарстан. 1970. 5 апр.; Гыйләҗев А. Борма юллар аша // Социалистик Татарстан. 1990. 1 апр.; Галимуллин Ф. Авылдашлар кемнәр алар? // Шәһри Казан. 1993. 3 апр.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГАЛИЕВ** Әсрар Әбрар улы (16.10.1938, Әлки р-ны Түбән Биктимер а. - 13.8.1998, Лениногорск ш.), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1971). Укытучы, шахтёр булып эшли, республика һәм район газета-журнал редакцияләре б-н хезмәттәшлек итә. «Төнге җыр» (1980) дип аталган хикәяләр җыентыгында туган илгә мәхәббәт, татар халкының милли гореф-гадәтләре турында сүз бара. «Асыл кошым минем» (1987) повесты, «Көн яктысы» (1993) романы шахтёрлар тормышыннан алып язылган. 1996-97 дә аның «Гали батыр» (1-2 кит., 1-4 томнар) исемле автобиографик повесты дөнья күрә. Г. әсәрләренең геройлары - тормыш кадерен белгән, гадел, максатларына ирешүчән шәхесләр.

Әд.: Маннапов Ш. Гали батыр оныгы // Казан утлары. 1998. N11.

**ГАЛИЕВ** Гариф Закир улы (10.5.1903, Самара губ., Бөгелмә өязе Урманай а. - 22.3.1985, Казан), язучы. 1918 елга кадәр «Галия» мәдрәсәсендә белем ала, соңыннан Бөгелмәдә укытучылар семинариясендә укый. 1928-41 дә «Сабанчы», «Колхоз газеты» г-талары, «Советлар канаты», «Колхоз бригадиры» ж-ллары редакцияләрендә җаваплы сәркәтип булып эшли. 1941-46 да - «Кызыл сугышчы», «Кызыл Армия» фронт г-таларында хәрби хәбәрче, җаваплы сәркәтип. Сугыштан соңгы елларда - «Кызыл Татарстан» г-тасы, «Сельское хозяйство Татарстана» ж-лы редакциясендә. «Вәли ничек кызылармеец булды» дигән беренче хикәясе 1925 елда «Эшче» г-тасында басыла. 1927 дә «Кызыл Армия хикәяләре» җыентыгы дөнья күрә. Иҗатында чагылыш тапкан төп тема - татар авылының үткәне һәм бүгенгесе («Еллар һәм кешеләр», 1951; «Мин авылны яратам», 1960; рус теленә тәрҗемәдә «Старый дуб», 1976; «Җир турында җыр», 1980; «Без авылныкылар», 1982; «Истә, һаман истә», 1986). Балаларга багышланган «Борчаклар сөенәләр» (1962), «Чәчәкле малайлары» (1965), «Хикәяләр» (1970) җыентыклары, авыл театрлары өчен язылган бер пәрдәлек пьесалар авторы. Г. бигрәк тә 1949 да Мәскәүдә рус телендә, 1956 да немец телендә Дрезденда басылган «Хаттан башланды» комедиясе б-н таныла. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1961.

Әд.: Хәйри Х. Яңа авыл җырчысы // Казан утлары. 1983. N5.

**ГАЛИЕВ** Марсель Баян улы (8.10.1946, Азнакай р-ны Балтач а.), шагыйрь, прозаик, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Казан ун-тын (1974) һәм

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар (Мәскәү, 1985) тәмамлый. «Беренче карлыгачлар» (1972) исемле күмәк җыентыкта беренче шигырьләре басыла. 1979 да «Еллар чалымы», 1980 дә «Су буеннан әнкәй кайтып килә» дигән шигырь җыентыклары дөнья күрә. Шигырьләренә нечкә психологизм, үзенчәлекле стиль хас. Лирикасы көчле гражданлык хисе белән сугарылган, заманча яңгырашлы. Г.нең 1980 дә «Ул чакта» дип исемләнгән беренче проза китабы басыла. Дөньяның бөтен катлаулылыгын, төрлелеген аңлап, тормыш вагыйгаларын үзенчә сурәтләргә омтылу, һәрдаим яңалыкны, үзгәлекне табу Г. әсәрләренең нигезен тәшкил итә. «Ерак урман авазы» (1981) романында, «Нигез» (1984), «Алтын тотка» (1988) повестьларында һәм күпләгән хикәяләрендә Г. «торгынлык еллары»ның катлаулы сынауларын узган шәхес образларын тудыра. Очерклар, юльязмалар, татар язучыларының әдәби портретларын үз эченә алган, үзенә бертөрле вакыт елъязмасын хәтерләткән «Догалы еллар» (1998), чор, заман, тарихыбыз турында фәлсәфи уйлануларын туплаган «Рух» (2005) китаплары укучыларга яхшы билгеле. Г. шулай ук юмористик хикәяләр иҗат итә, балалар әдәбиятында уңышлы эшли, публицистик мәкаләләр б-н матбугатта еш чыгыш ясый. Аның әсәрләре рус, украин, үзбәк, казакъ, чуаш һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. Кайбер шигырьләре көйгә салынган һәм популяр җырларга әверелгән. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (2006). ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1996).

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 1998-99.

Әд.: Фәйзуллин Р. Марсель Галиев // Казан утлары. 1980. N8.

*Р.Х.Сверигин.*

**ГАЛИЕВ** Фәнил Ислам улы (27.7.1939, Үзбәкстан АССРның Бохара өлкәсе Каракүл ш.), язучы, ТРның атказ. юристы (1992). Рус телендә иҗат итә. Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1963-66 елларда Башкортстан АССРның Хәйбуллин р-ны прокуратурасында тикшерүче булып эшли. 1966-75 тә Азнакай р-нында тикшерүче һәм прокурор ярдәмчесе, 1975-81 дә Кукмара р-ны, ә 1981-85 тә Казан шәһәре Идел буе районы прокуроры, 1985-92 дә ТР прокуратурасының тикшерү идарәсендә, ә 1992-94 дә Теләче р-нында өлкән прокурор вазифаларын башкара. 1994 тән Саба р-ны юридик консультациясе адвокаты. Г.ның әсәрләре детектив жанрда язылган, аларның нигезендә авторның профессиональ эшчәнлегенә бәйле вакыйгалар ята. «Следы остаются» дип исемләнгән беренче җыентыгы 1983 тә басылып чыга. «По следам призрака» (1986), «Тайна лесного дома» (1989), «Рассказы следователя Сомова» (1991), «Утерүче якында гына» (1994), «Искать убийцу» (1994) җыентыкларына тупланган хикәя һәм повестьларында катлаулы психологик һәм этик проблемаларны күтәрә.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГАЛИЕВ** (Һидиятуллин) Шәүкәт Гали улы (20.11.1928, Кайбыч р-ны Олы Бакырчы а.), шагыйрь, ТРның халык шагыйре (1995). Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар тәмамлый (Мәскәү, 1961). 1949-53 елларда «Колхоз бригадасы» исемле Кайбыч район г-тасы редакциясендә җаваплы сәркәтип, җаваплы редактор, 1953-59 да «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли. 1971-84 тә Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире. Аның шигырьләре республика газета-журналларында 1948 дә басыла башлый. 1954 тә «Яңа көйләр» исемле беренче җыентыгы, 1956 да - «Кечке утлар» китабы дөнья күрә. Г.ның поэзиясенә нечкә лиризм хас. «Сөенечләрем, көенечләрем» (1961), «Күңел күзе» (1963), «Чынлык» (1972), «Тамчылар тамар чаклар» (1975), «Баллада о колоколе» (М., 1976) шигъри цикллары лирик моң белән сугарылган. Шагыйрь замандашларының уй-фикерләрен эчкерсез бер җылылык белән чагылдыра. Аның шигырьләрендә авыл тормышы, халыкның гореф-гадәтләре, яшьлекләре сугыш чорына туры килгән буын вәкилләренең кичерешләре, туган як табигате урын ала. Г.нең табигать һәм мәхәббәт турындагы шигырьләренең образлы яңгырашы, композицион камиллеге татар композиторлары игътибарыннан да читтә калмый. Аның шигырьләренә язылган «Раушаниям, бәгърем» (В.Хәбисламов муз.), «Утыр әле яннарыма» (И.Хисамов муз.) һ.б.лар популяр җырлар булып китә. Г. тормыштагы һәртөрле кимчелекләрне, кире типларны сатирик рәвештә тасвирлаган яки кешеләрдәге аерым җитешсезлекләрдән көлгән күп санлы юмор һәм сатира әсәрләре авторы буларак та билгеле («Уены-чыны бергә», 1966; «Фикердәшкә», 1969; «Шалт, Мөхәммәтҗан!», 1970 һ.б. җыентыклар). «Шәвәли» (1965), «Котбетдин мәргән» (1971), «Заяц на зарядке» (1980; Г.-Х.Андерсен исем. Почётлы Диплом, 1982), «Исәнме, дус!»(1985), «Кто играет на курае?» (М., 1985) җыентыкларына тупланган шаян шигырьләре балаларга хас тапкырлык, шуклык, фанта-

зия белән тулы; жор, йөгерек телдә язылган. «Минем беренче гомерем» (1997) автобиографик повесты «Илһамым — мәхәббәтем» исемле лирик язмалары дөнья күрде. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (1972). «Почёт Билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Шигырьләр, поэмалар: Лирика, юмор, балаларга. К., 1978; Сайланма әсәрләр. Балалар өчен шигырьләр. К., 1987; Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2002.

Әд.: Галиуллин Т. «Коль сын земли - будь добр к её судьбе...» // Здравствуй, поэзия! М., 1987; Хәким С. Юмор — шагыйрьнең табигатендә // Үз тавышың белән. К., 1969; Туфан Х. Киләчәккә барырлык ижат // Социалистик Татарстан. 1972. 19 апр.; Юзиев Н. Әйтер сүзе бар // Шигърият дөньясы. К., 1981; Ахунов Г. Шагыйрь ачкан дөнья // Казан утлары. 1998. N11.

**ГАЛИЕВА** Эльмира Рәкыйп кызы (3.2.1954, Биектау р-ны Каракүл а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2003), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1979 елдан Казан. пед. ин-тында укыта, 1991 дән татар әдәбияты каф. мөдире, 1995 тән татар филология ф-ты деканы. Хезмәтләре татар әдәбияты, әдәби тәнкыйть һәм әдәби-эстетик фикер тарихына, 1920-30 елларда татар әдәбият белеменең барлыкка килүенә һәм аның кысаларында культура-тарих мәктәбенең формалашуы һәм үсешенә карый.

Хезм.: Татар әдәбияты тарихы К., 1989. Т. 4 (автордаш); Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. К., 2002.

**ГАЛИМОВ** Әкрам Миңнегали улы (14.11.1892, хәзерге Казахстан Респ-касы, Тургай өлкәсе Кустанай ш., башка мәгълүматлар буенча, Акмулла өлкәсе Акмулла ш. - 7.8.1913, Оренбург губ. Троицк ш.), шагыйрь, журналист. Татар һәм казах телләрендә язган. «Рәсүлия» мәдрәсәсендә (Троицк) белем ала. 1911-13 елларда беренче казакъ ж-лы «Айкап»-та (1911-16 да Троицк шәһәрендә нәшер ителә) җаваплы сәркәтиб, төрле оештыру эшләрен алып баручы. «Шура», «Айкап», «Кармак» ж-лларында, «Идел» г-тасында «Чала татары», «Кара туры егет» псевдонимнары б-н чыгышлар ясый. Мәкалә һәм фельетоннарында казах халкының артта калганлыгы турында яза, аны укыту-агарту зарурлыгын яклап чыга. Казакъ телендә чыккан «Яшьлек жимешләре» («Жасты жимістері», 1912) исемле шигъри жыентык авторы. Руханиләргә каршы юнәлтелгән, татар телендә язылган «Май мәсьәләсе, яхуд Аңгыра мулла» (Троицк, 1913) пьесасы башта Кустанай шәһәренең һәвәскәр театры сәхнәсендә, соңыннан һәвәскәр труппалар тарафыннан Уфа, Троицк шәһәрләрендә уйнала. Г.Тукай, Абай шигырьләренә нәзыйрә яза. Татар, рус һәм Европа язучылары әсәрләрен (мәс., Тукайның «Сөткә төшкән тычкан»ын, Байронның «Шильон мәхбүсе» поэмасын) казакъ теленә тәрҗемә итә.

Әд.: Исмаилов Е.К. К вопросу казахско-татарских литературных связей // В поисках нового. А.-А., 1967; Искаков Б. Этапы развития казахско-татарских литературных связей // Казахская литература и её интернациональные связи. А.-А., 1973; Гафифи С. Шагыйрь Әкрәм Галимевнең вафаты // Шура. 1913. N17; Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи рәҗигун // Акмулла. 1913. N28; Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001.

*А.М.Ахунов.*

**ГАЛИМУЛЛИН** Фоат Галимулла улы (21.3.1941, Кукмара р-ны Арпаяз а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТР, РФ ның атказ. фән эшлеклесе (1995, 2006). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1974). 1957-60 елларда Арпаяз авыл клубы мөдире, 1960-62 дә Кукмара р-ны мәдәният сарае каршындагы татар театры җитәкчесе, 1965-67 дә КПССның Кукмара райкомы инструкторы, 1967-74 тә ТАССР МС каршындагы телевидение һәм радио комитеты дикторы. 1974 тән Казан пед. ун-тында: татар әдәбияты каф. укытучысы, тарих-филол. ф-ты деканы (1986-91), татар әдәбияты каф. мөдире (1995-2000, 2005тән). Берүк вакытта 1975 тән респ-ка радиосында «Тел күрке - сүз» тапшыруын алып бара. 1999 дан ТР Язучылар берлеге идарә рәисе. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбияты үсешенең закончалыкларына, 1920-30 нче еллар татар әдәбиятын өйрәнүдә эстетик һәм социологик категорияләренең үзара мөнәсәбәтләренә, татар әдәбиятын урта һәм югары мәктәптә укыту методикасына карый. Мәктәптә сәнгатьле укуның теория һәм практикасына багышланган, урта мәктәп өчен татар әдәбияты дәреслекләре авторы. РТ Дәүләт Советы депутаты (1999 дан).

Хезм.: Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. К., 1988; Эстетика һәм социологизм. К., 1998; Әле без туганчы. К., 2001.

Әд.: Шәрәфиев Р. Үткәннәр аша бүгенгә // Мирас. 1999. N 1. Хисамов Н. Отзыв на докторскую диссертацию Ф. Галимуллина // Хәтер сатында. К., 2004.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Бакырчы авыллары

Бакырчы авылы Яшел үзән районында урнашкан. Рәсми рәвештә Бакырчы дип аталса да, халык телендә ул Әрә Бакырчысы дип йөртелә. Авыл район үзәге Зеленодол шәһәреннән 46, тимер юл станциясе Урмардан—14, Козловка пристаненнән 3 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бу авыл тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә искә алына.

Казан ханлыгы чоры авыллары теркәлгән исемлектә дә авыл бар, Һарун Йосыпов Бакырчы авылы зиратында XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы булуын яза.

Д. А. Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) авылда 107 йомышлы татар, 50 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә.

А. Артемьев Бакырчы авылын искә ала, андагы 526 хуҗалыкта мөселман дине тоткан 526 ир-ат һәм 568 хатын-кыз исәпләнгән. Авылда мәчет һәм гыйбадәт кыла торган бер йорт булган. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә күрсәтелгәнчә, Бакырчы авылында татарлар яшәгән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә Әрә Бакырчысы авылы халкы күршедәге Җуйынчы, Акъегет авыллары белән бергәләшеп июнь башында Симек/Чимек җыены бәйрәм иткән.

Каюм Насыйри Бакырчы авылын болай сурәтли:

«Бакырчы авылы—Чуел өязендә бик кадимге иске авылдыр. Җиде-сигез йөз елдан бирле Бакырчы авылы бардыр. Кадим заманада Бакырчы авылы бик караңгы урман эчендә Эрә суы буена утыргандыр, шуның өчен Эрә Бакырчысы дип аталадыр. Әмма Бакырчы авылы төп Болгардан килгән халык түгелдер. Бәлки, соңыннан җыелган халыклар булса булыр. Иң әүвәл башта Бакырчы мукшы авылы булгандыр. Үзләре мукшы булсалар да, ислам дине тотканнар. Алар бакырчылык һөнәре белән тереклек кылганнар; шул сәбәпле бу авылны Бакырчы авылы дип атаганнардыр. Эрә суы белән йомычкалар, адәм кулыннан чыккан нәрсәләр агып килгәнен күрсәләр, әйтәләр икән, анда да торучылар бар икән, дип. Иске заманда урманның аргы ягында авыл бар икәнен дә белмәгәннәр, шулкадәр калын урман эчендә яшәгәннәр. Хәзер дә Бакырчы байтак зур авылдыр. Соңыннан төрле җирдән җыелып зурайганнар. Тәтеш өязендәге Бакырчының асылы бу Бакырчыдан чыккандыр. Хәзер дә Бакырчы зиратында кадимге бер бик иске таш бардыр, хәзер ул уалып беткән. 1855 елда Шырдан авылы мулласы Габденнасыйр аның тарихын язып алган. Ул вакытта ташның язулары укырлык икән...».

Бакырчы авылы олылары сөйләвенә караганда, авылда элек иске зират була. Бу зиратка тирә-юньдәге 12 авыл мәет күмгән. Авылның иске урыны хәзергесеннән 2800 метрлар читтә, «йорт өсте» дигән урында була. Заманында Мәскәүгә бара торган олы юлны авыл халкы Топалан җулы дип йөрткән икән. Бакырчы авылы башта менә шул юл буена урнашкан була. Олы юл буена утырган халык бик күп җәбер күргән. Явыз Иван гаскәрләре дә Казанга яу белән барганда шул юлдан үткәннәр.

---

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Заманасында авыл чукындырылган. Бу вакыйга белән бәйләнешле истәлекләр дә сакланган. Чукындыручылар авыл халкын бик каты кыйныйлар. Кайбер кешеләр кыйнауга чыдый алмыйча чукынырга да риза булалар. Чукындырылган халыкны керәшен дип йөртә башлыйлар. Авылда керәшен зираты да бар. Бар халык та инде күптән исламга кайткан.

Бакырчы авылында яшәүче Борһан Низамиевтән (1901 елда туган) И. Надиров 1955 елда «Бакырчы бәете» исемле бәет язып ала. 1978 елда аны М. Әхмәтжанов кабат язып кайта.

Бу бәет 1897 елның 28 гыйнварында үткәрелгән җан исәбе алу вакыйгалары белән бәйле рәвештә чыгарылган. Билгеле булганча, Идел-Урал буендагы төрки халыклар патша хөкүмәтенең бу эшен көчләп христиан диненә күчерү өчен башкарыла торган бер эш дип кабул итәләр һәм төрле юллар белән ана каршы торырга тырышалар. Авылларга җәза отрядлары («обжор командалары») килеп, патша әмерен үтәргә керешә. Крәстиәннәрне камчы белән суктыру, мал-мөлкәтләрен талау, хатын-кызларны мәсхәрәләү һ. б. моңа хәтле дә өзелеп тормаган башбаштаклыклар дәвамы булып, халыкның көчле нәфрәтен уята. Әле 1870 нче елларда гына «Мир җыемнары һәм повинностьлар турындагы яна инструкция» унае белән күтәрелгән крестьян хәрәкәтләре (Татарстан АССР тарихы, 1970, 226 б.) яна протест дулкыннарына килеп тоташа. Татар авылларындагы бу елларга караган вакыйгалар һәм халык тормышы М. Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» һәм Х. Кәримнең «Ертылган приказ» дигән китапларында сурәтләнә.

Халык үзе исә «Перепись», «Бакырчы» кебек әсәрләрдә әлеге вакыйгаларны бәет жанры рухында фаҗига итеп тасвирлый, үзенең протестын шул юл белән мәңгеләштерә. Типик хәлләрне тасвирлаганга, ул әсәр төрле төбәкләргә таралган.

Бәетнең эчтәлеге болай:

*Бу вакыйга булды үзе мең сигез йөз туксан җидедә,*
*Көз көнендә декабрьнең егерме дүртенче көнендә.*
*Губернатор шашып килгән, җиз барабан кактырып,*
*Зур команда алып килгән, Бакырчыларны куркытып.*
*Бакырчыларның капкасын җил күтәреп атмасын,*
*Бакырчыга команда килде—Бакырчылар качмасын.*
*Бакырчы авылы зур авыл, икмәк—тозга бай авыл,*
*Бакырчылар шаккаттылар: тирә-якта каравыл.*
*Бакырчының капкасы шыгырашмыйча ачылмый,*
*Бакырчының халыклары каравыллы—качалмый.*
*Иртә торсак, ни күрик, солдатлар ташый талчыбык,*
*Өч-дүрт солдат бергә сукты, Бакырчы халкын яткырып.*
*Бакырчыда уртада су, язын ага ыргылып.*
*Бакырчы халкын суктылар, «Гаепле сез»,— дип куркытып.*
*Бакырчы авылы зур авыл, ике ягы таулы икән,*
*Сугылганнар бик кызганыч, аркалары канлы икән.*
*Бакырчы халкы җәфалана, йөриләр янып-көеп;*
*Сугылганнар дәваланды чи тиреләр ябынып.*
*Бакырчының капкасына тимер кадак какканнар,*
*Бакырчының кешеләрен казаматка япканнар.*
*Зур команда солдатлар ике атна торганнар,*
*Бакырчының халыклары хәйран булып калганнар.*
*Бакырчының халыклары кое казучы—һөнәрле,*
*Узып киткән зур вакыйга истән чыккан юк әле.*

Төбәкнең топонимиясенә килгәндә, Укша елгасы, Корканаш чокыры, Таллы күл, Килен күле, Фәсәхәт күле, Фәхри бабай коесы, Сәгъди кизләве, Эчкәре каенсаз, Каенсаз чирәме, Алып чабата каккан җир исеме, Пута бияләе кыры, Кирәмәт тавы, Куян атавы, Сәлам аланы, Чимук аланы, Әмир аланы һ. б. кебек аһәнле атамаларга тап булабыз.

Авылда урта мәктәп, балалар бакчасы, китапханә, кибет, медпункт эшли. Мәктәптә авыл тарихына багышланган музей бар. Яңа Мәчет 1993 елның көз аенда ачылган.

Татар дәүләт академия театрының әдәби бүлек мөдире Юныс Габдулла улы Сафиуллин Бакырчы авылында туып үскән.

***

Бакырчы исеме алган авыл Тәтеш районында да бар. Ул Тәтеш шәһәреннән—42, тимер юл станциясе Борындыктан 18 чакрым ераклыкта урнашкан.

Югары әйтелеп кителгәнчә, авыл Яшел Үзән районындагы Бакырчы авылы белән бәйләнешле.

Бакырчы авылы утырган урын тарихилыгы белән аерылып тора. Археолог-галимнәр Бакырчы авылы тирәләреннән борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәсе һәм Алтын Урда чорына нисбәтле зират булуын билгеләгәннәр. Элек бу зиратта гарәп хәрефләре белән язылган кабер ташлары да булган. 1859 ел мәгълүматларына караганда, Бакырчының 83 йортында 464 ир-ат һәм 470 хатын-кыз күрсәтелгән. Мәчет берәү булган.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Бакырчы халкы Олы Тархан, Татар Бидәнгесе, Сөендек авыллары белән бергә июнь ахырында Кыйат ярминкәсе бәйрәме үткәргән. Бабайлар һәм әбиләр сөйләве буенча, Бакырчы дип аталачак авыл урынына бер кеше килеп төпләнгән. Ул үзе утырган урында бакыр таба. Менә шушы бабай һөнәренә мөнәсәбәтле рәвештә, бу урында барлыкка килгән авылны Бакырчы дип атыйлар. Бу авыл урман арасында утырган булган, тирә-юньдәге кешеләр анын барлыгын да белмәгәннәр.

Авыл яныннан елга аккан. Халык елгада балык та тоткан. Судан агып килгән әйберләрне күргәннән соң гына халык күршедә авыл оешканлыгын абайлап ала.

Хәзер авыл тау башына урнашкан. Таунын йортлар салынмаган өлеше Мискә тавы дип атала. Нәкъ мичкә кебек түгәрәкләнеп эчкә батып торганга аны шулай атаганнар.

Бакырчы авылы Бидәнге суы ярына утырган. Бу суны авыл халкы икенче төрле Инеш дип атый. Тирә-юньдәге топонимнардан: Бидәнге суына яки Инешкә коя торган Каенлык чокыры, Олы чокыр, Батка елгаларын, Мант башын (кызганыч, ул хәзер Идел суы астында калган), Баткак чишмәсен, Изге кизләүне әйтеп китик.

Тау астында ямь-яшел Кизләү урманы бар. Элекке вакытларда өйләрдә су булмаганда, кызлар чиләкләрен биетеп кизләүгә һәм коега су алырга төшкәннәр. Тау астындагы урман эчендә кизләү ясаганнар. Йортларда су бетеп торган вакытларда халык Кизләү урманындагы чишмәгә суга килә.

Авыл уртасында кечкенә генә күл җәелеп ята. Аны Таракан күле дип йөртәләр. Авылнын бер башында Зур күл яисә Әдһәм күле, Кече күл бар; урман янындагы Тай күле әлегә исән.

Авылдан 3 чакрым чамасы читтә Чагылдым урманы үсә. Урман эчендә, анын Бурчау урыны дигән өлешендә Изгеләр чишмәсе ага. Илһам чишмәсе янына утыргыч куелган, ул бура эченә алынган.

1986 елда авылнын икенче ягына зур күл ясаганнар. Күл белән Инешне бүлеп тора торган арага ике яклап каен агачлары утыртылган. Бу эш Г. Тукай туган көнне эшләнгәнгә күрә, аны Тукай аллеясы дип атаганнар. Күлнең уртасында утраучык бар. Ул утрауга көймә белән кереп таллар утыртканнар. Утрауны Кызыл тал утравы дип йөртәләр.

Авылда хәзер 215 хуҗалык исәпләнә, аларда 987 кеше яши. Шуларнын 560—хатын-кыз, 327—ир-ат. Хәзер авылда урта мәктәп, медпункт, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, элемтә бүлеге эшли. Китапханәнең бер бүлеге музей хезмәтен үти. Мәдәният йорты каршында Ватан сугышыннан кайтмаган авылдашлар истәлегенә бик матур һәйкәл куелган. Урамда су колонкалары койма белән уратып алынган һәм тирәләренә агачлар утыртылган. Авылда элек дүрт мәчет һәм мәдрәсәләр булган. Мәчет манаралары 1930 елларда киселгән. 1991 елда авылда яна мәчет ачылган.

## Бөек җырчы турында шәп китап

Бер дустым миңа китап бүләк итте. «Рәшит Ваһапов. Заман, иҗат, шәхес» дигән бу китапны нәшер итүчеләр—«Татарстан» журналы нәшрияты, Татарстан китап нәшрияты һәм «Якташлар» җәмгыяте, авторы исә бөек җырчыбызның авылдашы Рифат Фәттахов икән.

Китапны кулга алу ук күнелле булды, чөнки сыйфатлы итеп эшләнгән, шәп бизәлгән ул. 300ләп фоторәсем файдаланылган икән. Эчтәлеге исә шундук мавыктырып-бөтереп ала.

Атаклы җырчы чын авыл малае булган икән, авылда нинди эш бар, бөтенесен дә белгән, эшләгән. Үзенә генә хас һөнәре дә булган: камыштан кисеп курай ясаган һәм сабан туйларында аны уйный-уйный саткан.

Шунысы да күнелгә хуш килде: мәктәптә дә, педагогик техникумда да яратып үзләштергән фәне татар теле һәм әдәбияты булган, һәм ул соңгы көненә кадәр милли җанлы кеше булып калган. Артистлык вазифасына исә үтә җитди караган ул. Девизы мондый булган: «Җырчы халык артыннан барырга тиеш түгел, халык җырчы артыннан барырга тиеш». Һәм ул моңа ирешкән дә: ул җырлаган һәр җырны халык шундук күтәреп алган, яше дә, карты да бердәй яратып җырлаган...

Р. Фәттахов зур эш, игелекле эш башкарган, рәхмәт аңа. Шәхси китапханәмдә шундый китап булу зур сөенеч.

**Фәнис ШӘФЫЙКОВ.**
*Чирмешән районы.*

---

## Мең-енче сан дәресе үткәрдек



Хөрмәтле Равил әфәнде!

Сезгә Башкортстаннан Бәләбәй педагогия көллияте укытучысы Илгизәр Солтан улы Гыйззәтуллин яза. Бу уку йортында гына да 45 ел эшләдем. Заманында училищега ел саен 4әр татар төркеме алына иде. «Шигрин көн» кысыла бара. Бүген 15 укучы алына.

2000 елда Казанда «Канатлы сүзләр» китабын (320 битле, 317 сүз), 8 нче сыйныф өчен Татар теле дәреслеге (синтаксис) чыгардым. Дәреслекне оригиналь диделәр. Быел Уфада «Китап» нәшриятында «Канатлы сүзләр»нең 2нче китабы чыгачак (Алла боерса).

Узган уку елында «Казан утлары»ның 1000нче санына багышланган дәресләр үткәрдек (һәр класста). Дәресләрдән бер күренеш җибәрәм.

Хушыгыз.

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!



*Ак җилкән*



## Алия Габделхакова

# ТАРТУ КӨЧЕ

ХИКӘЯ

Балалар кайтып беткәч, Камилә апа бакчаны тагын бер урап килергә булды. Койма буенда үсүче куаклар төбендә җиргә ботак белән рәсем ясап утыручы Әлфияне күреп аптырап китте:

—Бәрәч, Әлфия! Нишләп утырасың монда, бөтенесе дә кайтып беттеләр бит инде. Ранил белән Зөлфәт тә кайтып киттеләр бугай.

—Әйе, Камилә апа, мин аларга кайта торырга куштым. Үземә генә уйланырга кирәк иде, ә безнең мәктәп бакчасыннан да тынычрак җир юк.

—Анысы дөрес. Кишер урлаучылар да булмагач, хәзер бөтенләй тынычлап калды, Ходайның рәхмәте. Йә, ярар, син утыр алайса, мин чия куакларын карап киләм әле.

Камилә апа үзе буе куаклар арасына кереп югалгач, Әлфия яңадан үз уйларына чумды. Уй йомгагы мондый фикер белән очланды:

«Минем янга киләчәк әле ул».

Авылда эш эңгер-меңгер төшә башлагач кына тәмамлана. Көтү кайткан, сыерлар савылган, түтәлләргә су сибелгән. Игенчеләр генә һаман басуда. Калган авыл кешеләренең кайсылары өйләрендә, кайсылыры капка төбендә. Соңгылары йә авыл яңалыклары ишетергә чыккан әбиләр (хәер, алар иртән дә капка төбендә), йә таңсыз йокларга ятмаган, кызык эзләп йөрүче яшьләр. Капка төбенә урта яшьләрдәге апалар һәм абыйлар да чыкмый түгел, чыга. Ләкин алҗу үзенекен итә шул, алар бик тиз йокларга кереп китәләр.

Ул арада күктә беренче йолдызлар кабына, балкып ай чыга. Су буендагы бакаларның тавышлары тагын да көчлерәк ишетелә башлый. Кайдадыр өздереп сандугач сайрый.

Кичке һава саф, тәмле. Аны сулыйсы да сулыйсы, һәр сулыш алганда үпкәгә күбрәк кертәсе килә. «Үз гомереңдә бер тапкыр да авыл кичен күрмәгән кеше бәхетсездер», дип уйлады Ранил, абзар түбәләренә менгәч. Ул күкрәген тутырып кичке һаваны сулады да, тирә-ягында ачылган манзарага күз салды. Нинди матур икән бит аның туган ягы! Йөрәген кинәт биләп алган шатлыктан бар җиһанны

*Ахыры. Башы 5 нче санда.*

тутырып, «Мин яратам сине, дөнья!»—дип кычкырасы килде. Мондый минутларда малайда бер генә теләк туа. Тизрәк Әлфияне күреп, аның белән шатлыгын уртаклашу теләге. Ранил Әлфияләр капка төбендә пәйда булганын сизми дә калды. Хәтта үзенә якынлашып килүче Зөлфәтне дә күрмичә, капка келәсенә үрелде. Дустының: «Өйдә микән соң ул?»—дип соравы аны сискәндереп җибәрде.

—Белмим,—дип иңбашын сикертте Ранил.

Ул арада койма өстендә Наилә апаның башы күренде.

—Әссәламәгаләйкем, егетләр!—диде ул малайларга, энҗедәй тешләрен күрсәтеп. Бу сылу апа да кызы кебек үк көнчыгыш шаһиналәрен хәтерләтә: шундый ук калын кара толымнар, яшел зөбәрҗәт күзләр.

—Әллә Әлфияне эзли идегезме? Ул су коеныргa төшеп киткән иде бит әле.

—Кай тирәдә су кергәнен әйтмәдеме ул, Наилә апа?

—Егетләр, китегезче! Ул бит иптәш кызлары белән. Әллә кызлар су керган җиргә барырсызмы?

—Әйе шул. Булмас. Рәхмәт, Наилә апа.

—Ни өчен «рәхмәт», күгәрченкәйләрем? (Бу сүз дә Әлфиягә әнисеннән күчкән иде). Үзегезгә рәхмәт, Әлфиябезне онытмаган өчен.

Ранил үзен бик нык рәнҗетелгән итеп хис итте. Бернинди сәбәп булмаса да, нәрсәгәдер нығытып үпкәләде ул.

Зөлфәт Әлфияләрнең яшел коймаларына терәлеп торган утыргычка аяклары белән үк менеп утырды.

—Нәрсә булган соң бу Әлфиягә? Әле безгә ышанмый ул, әле бездән башка су буена төшеп китә.

—Үзе әйтмешли, бардыр сәбәпләре.—Ранил дә иптәше янына менеп кунаклады.

—Ничек итеп Әлфиядән теге йөзекне сорап алырга икән? Бер карасаң, бүләк иттем инде, икенче карасаң—кеше әйберсе.

—Ал да бир, Әлфия аңлар әле,—Зөлфәт, кечкенә брелок-фонарчыгын бер яндырып, бер сүндереп уйнавын дәвам итте.

—Мин дә шулай уйлый идем. Хәзерге Әлфия үзен ничек тотачагын кем белгән. Үпкәләсә?

—Авыр хәл.

—Минем абый мондый чакта: «Бер нәрсә дә эшләмичә ни буласын көт»,—дияр иде. Их, абый тизрәк армиядән кайтсын иде!

—Дүрт кенә ае калды бугай бит.

—Өч ай да ике атна. Көннәрне саный башладым инде.

—Их, минем дә абыем булса, мин дә көннәрен санап аны армиядән көтәр идем.

—Апаң булу да начар түгел лә.

—Кайсы яктан карыйсың бит. Кызлар эше кушып интектермиләр, ансы әйбәт. Ну шуның өчен көне-төне апаның акыл сатуын тыңларга кирәк. Тегеләй итмә, болай ярамый. Бала-чага түгел лә мин!

—Аның сине яхшырак итәсе килә.

—Үзеңнең апаң булса, син ничегрәк сайрар идең икән?

—Апам булса иде әле.

—Әйдә, алмашабыз. Син миңа абыеңны бир, мин сиңа апамны бирәм.

—Юк-юк инде. Рәхмәт. Миңа болай да әйбәт.

—Күрдеңме? Үзеңнең алмашасың килми,—Зөлфәт йөзенә үпкәләгән кыяфәт чыгарды.

—Булмый бу болай, киттек су буена,—диде Ранил, бераз тын утыргач.

—Кызлар янынамы?

—Ниткән кызлар ди? Су керергә. Кичен елга буенда тынычрак та, рәхәтрәк тә. Әйдә.

—Әйдә сәнә, миңа ни.

Малайлар өйләре каршындагы тыкрык буйлап Күлсу елгасы буена төшеп киттеләр. Көне буе кояшның нурларын үзенә җыеп ярыйсы гына җылынган елга суына чумып, берара йөзеп алгач, ике дус ярга чыкты. Әлфиядән башка аларга су буенда да күңелсез иде. Юеш тәннәренә ашык-пошык футболка һәм шортикларын киделәр дә кайтыр юлга чыктылар. Ранил, чылатасы килмичә, кроссовкаларын кимәде. Аннан күрмәкче Зөлфәт тә шлепкаларын кулына тотты. Тыкрык үләне өстеннән янәшә яланаяк атлады дуслар. Үлән келәме салкынча яфраклары белән табан асларын кытыклап ала... Тыкрыкның яртысына җитәрәк, малайлар Әлфияләр капка төбендә кемнәрнеңдер басып торуын шәйләделәр.

—Берсе Әлфия түгелме?

—Әлфиягә ошаган. Ә тегесе кем тагын?

Якынлашкан саен дусларның йөрәкләре кысыла барды. Әлфиянең ниндидер бер егет белән капка төбендә торуы аларның икесендә дә көнчелек уты кабызды. Тыкрык башына җиткәч, малайлар туктап калдылар. Әлфиянең күзенә чагыласы да, теге егет белән очрашасы да килми иде аларның. Койма буенда үскән карт өянкенең кара шәүләсенә посып, малайлар капка төбендәге «яшь пар»ны күзәтә башладылар. Кичке тынлыкта аларның сөйләшкәннәре дә аермачык ишетелә иде. Болар яңа гына очрашканнар, ахрысы, егетнең:

—Көттеңме?—дигән соравына Әлфиянең:

—Мин синең киләчәгеңне белә идем. Син килми булдыра алмый идең,—дигән җавабы ишетелде.

—Бик җиңел эләктердең әле син мине.

—Алай ук җиңел микән?

—Нәрсә бирдең соң син? Нәрсәңне корбан иттең? Хәер, син үзең дә беләсең, әлегә мин синеке түгел.

—Түгел дә, тик озакламый—булачаксың.

—Гадилә мине...—егет тиеш түгелне ычкындыруын аңлап туктап калды.

—Аһ, Гадилә мени әле ул? Минем эшне җиңеләйттең бит әле син.

—Ул барыбер мине сиңа бирмәячәк. Үз теләге белән бирүе кирәк, үзең дә беләсең!

Малайлар бу сөйләшүдән берни дә аңламадылар. Бары Зөлфәт кенә: «Ул егет белән серьёзно сөйләшәсе булыр әле. Нишләп йөри ул безнең авылда, безнең кызлар тирәсендә?»—дип пышылдады. Ранилнең исә тамагына төер, күзләренә яшь тыгылды.

Ул арада капка ябылган тавыш ишетелде. Әлфиянең кереп китүен аңлап, Зөлфәт алга ыргылды. Аның бик тә теге ят егетнең юлына каршы төшәсе килә иде. Тик егеттән генә җилләр искән, шәүләсе дә күзгә чалынмый хәтта.

—Качкан, шайтан!—дип Зөлфәт теш арасыннан гына җиргә төкерде. Аннары һаман да тамагына тыгылган төерне йота алмый басып торган дустыннан:

—Карале, син аларның сөйләшүләреннән берәр нәрсә аңладыңмы?—дип сорап куйды. Ранил «юк» дип баш какты.

—Ә мин шуны аңладым. Бу егет Гадиләнеке булган башта. Хәзер аны Әлфия үзенә каратмакчы. Менә ни өчен Гадилә Әлфияне күралмый икән! Аңладыңмы инде?

—Аңладым ла. Тик Әлфия... Әлфия алай эшләр дип башка да килмәде.

—Барысына да шул егет гаепле. Дөресен генә әйткәндә, Әлфия классташының егетен урлар дип уйламаган идем мин.

—Без аны башка егетләр белән йөрер дип тә уйламаган идек соң. Дөнья без уйлаганча гына бармый икән шул.—Ранил күк йөзенә күтәрелеп карады. Энҗедәй сибелеп җемелдәшкән йолдызлар аңа үз гомерендә беренче тапкыр күкнең күз яшьләре булып тоелды.

—Ни генә булмасын, безгә ул егет белән сөйләшергә кирәк. Әйдә, бүген бездә кунабыз.—Әти-әниләре малайларның бер-берсеннән аерыласылары

килмичә әле Зөлфәтләр, әле Ранилләр печәнлегендә йоклауларына күнегеп беткәннәр иде инде. Шуңа күрә көн саен Наилә апаларның икесе дә печәнлекләрендәге хуш исле печән өстенә палас җәеп, ябынып ятарга юрган әзерләп куялар иде. Малайлар Зөлфәтләр печәнлегендә әзер урынга чумып, күзләрен генә йомганнар иде, колакларына ямьсез улау тавышы ишетелде. Бу улау шул кадәр дә шыксыз иде ки, малайлар сикереп торып утырганнарын сизми дә калдылар.

—Әллә тоелды гынамы?—диде Зөлфәт, күпмедер вакыт колак салып торганнан соң. Авыл сәер рәвештә тын иде. Әйтерсең барлык җан ияләре дә баягы иләмсез тавыштан куркып, сагаеп калган. Чикерткәләр генә гадәттәгечә берсен-берсе уздырып черелдәшәләр... Бераздан малайлар, тоелган гына икән дип, урыннарына аудылар. Берничә минуттан алар инде йокыга талган иделәр.

Әгәр дә алар төнге авылга колак саласы урында күз салган булсалар, бер өй түбәсеннән икенчесенә сикереп ыргылып чапкан алагаем зур этне күрерләр иде...

Бүген Зөлфәтнең төшенә Гадилә керде. Имеш бер ел элеккеге кебек дус икән алар. Әллә нинди борчулы сагыш белән уянып китте малай. Әйе, дус иделәр шул. Балалыктан чыгып бетмәгән классташлары «кияү белән кәләш» дип үрти дә башлаганнар иде хәтта. Зөлфәт үзенең Гадиләгә карата булган хисләренә төшенеп кенә бетә алмады. Мәхәббәт иде микән ул? Баштарак малайның бу хакта уйлаганы да булмады. Тыныч, рәхәт иде аңа Гадилә янында. Кыш көннәрендә кызның җепкә тезелгән сәйләннәр кебек эзләренә сокланып кайтканы булды. Апасы көне-төне укыган мәхәббәт романнарының берсендә бер егетнең сөйгән кызы эзләренә сокланып йөрүе турында язылуын белгәч, Зөлфәт: «Мин дә Гадиләне яратам икән,»—дип уйлаган иде. Ләкин күршеләренә Әлфияләр күченеп килгәч, бар да үзгәрде. Кызда ниндидер көч сизде малай. Тарту көче. Гадилә икенче планга күчте.

Шуларны исенә төшерде дә Зөлфәт, кичәге таныш түгел егетне кызганып куйды. Ул егет тә Әлфиянең «гравитация кырына» эләккән, ахрысы. Шулай була калса, «Мин синеке түгел», дип сөйләнүдән файда юк.

Зөлфәт торып утырды. Тәне буйлап нәрсәнеңдер аска шуып төшкәнен сизде ул. Фотболкасы итәген күтәреп, әлеге әйберне юллый башлады, һәрвакыт муенына асып йөри торган медальоны икән. Чылбыры өзелгән булып чыкты. Аксыл металлдан эт формасында ясалган бу медальонны ике ел элек Гадилә бүләк иткән иде аңа. «Эт тугрылык билгесе,»—дигән иде кыз.

—Убыр оныгыннан бер нәрсә дә алма. Сихерләнгән булса тагы,—дип битәрли иде аны апасы. Бу медальонны да юк иткән булыр иде, Зөлфәт күрсәтмәде. Әбисе сәеррәк булганга оныгы гаепле түгел лә. Кызык, Гадилә чынлап та аны яратты микән?

***

Гадилә күзләренә тыгылган яшьләрен инде ничәнче мәртәбә кире куып кертте дә, әле җүнләп үсәргә дә, кояш нуры күрергә дә өлгермәгән кечкенә алабутаны суган кыяклары арасыннан йолкып алды. Ташламакчы иде дә, кире уйлады. Нәни чүп үләнен игътибар белән карарга кереште. Ни зыяны тигән соң аның, әле туарга да өлгермәгән килеш нигә йолкып атарга? Менә аның мәхәббәте дә шундый иде: нәни, чиста, бер зыянсыз. Ләкин аны да йолкып алдылар да кызу кояш астында кибәргә калдырдылар. Күз яшьләре аның саф хисләренә ярдәм итә алмагандай, чык тамчылары гына бу үләнчекне кире яшәртергә ошамаган. Кызның бу алабутаны кочасы, җылытасы, урап алып бар дөньядан саклыйсы килде. Алабута аңа үзе булып, яшәү чыганагы бирүче җир—Зөлфәт, ә үләнне йолкып аткан кул—аны яшәү чыганагыннан аерган Әлфия булып тоелды. Энҗедәй яшь бөртеге кызның бите буйлап тәгәрәп төшеп, сукмак тузанына тамды. Гадилә

түтәл читендә кечкенә генә чокыр ясады һәм алабутачыкны яңадан утыртып куйды. Азактан бер уч су алып килеп үлән өстенә сипте.

—Яңадан үсеп китәр дип уйлыйсыңмы?

Кыз сискәнде.

—Хәер, бу синең аңа ничаклы яшәү көче бирүеңнән тора, шулаймы?

Тыныч һәм тигез сызылып яткан кашлар астыннан кызга чем-кара ике күз төбәлгән иде. Күзләр шул дәрәҗәдә кара иделәр ки, хәтта күз уртасы да күренми. Озаграк карап торсаң, бу күзләргә батарсың кебек тоела. Очы бераз гына аска караган борын, тулырак иреннәр күзләрнең хуҗасын тагы да чибәррәк һәм затлырак күрсәтәләр иде. Бар кылучы егетнең һәр йөз сызыгын бөртекләп ясап утырган диярсең. Күпме генә эзләсә дә, Гадилә анда бер җитешсезлек тә күрмәде. Ап-ак тире, кара-кучкыл чәч, өске ирен өстендәге кечкенә генә миңе—һәммәсе матурлык өчен яратылган кебек иде.

Гадилә: «Вәт кызлар яратадыр моны!»—дип уйлап куйды. Шунда ук «Кайда күргәнем бар соң әле минем аны?»—дигән икенче уй беренчесен бүлеп үтте.

—Гадилә, әллә танымыйсың инде? Мин бит синең мондый чагыңны да хәтерлим,—дип, егет кулын җир өстеннән 30-40 сантиметрга күтәреп күрсәтте.—Сездә була идем бит. Мин—әбиеңнең танышы.

Кызның югалып калганын күреп егет яңы белән борылды:

—Ә болай. Таныйсыңмы?

Бер кояш нуры егетнең маңгаеннан иягенә таба чабып узды, аннан муенына үрмәләде. Гадилә бирелеп укыган «Грек мифлары һәм риваятьләре» китабын исенә төшерде. Сугыш алласы Арес шулай ясалган иде анда.

—Ярар. Син бик кечкенә идең шул әле.

Егет кинәт күңелсезләнеп китте:

—Әбиең үлүе кызганыч. Ярар, бүгеннән син минем дустым булырсың. Танышыйк: Хирас.

—Гадилә.

Егет кызның кулын эләктереп алып күрешә башлады:

—Шатмын. Би-и-ик шатмын!—диде ул күрешкәндә кызның кулын йолкып ала язып.

—Бәрәч,—диде егет кинәт кызның кулын дикъкать белән карый башлап. Гадиләнең икенче кулы да аның учына керде.

—Бәрәч,—дип кабатлады ул каушаган кыяфәттә.—Әбиеңнең йөзеге кая соң? Әбиең сиңа калдырам дигән иде бит.

Гадиләнең йөзеннән кан качты. Ул ишетелер-ишетелмәс кенә:

—Югалттым,—диде.

—Ничек инде—югалттың?

—Бакчада. Эшләгәндә,—диде кыз, тагы да коела төшеп. Әбисенең танышы каршында (хәзер ул аны таныды) әбисе васыять иткән йөзекне югалттым дип әйтү оят иде аңа.—Егетләр тапканнар аны. Бирербез диделәр.

—Сиңамы?—егетнең тавышында һәм кыяфәтендә кызга ышанмау сизелә иде.

—Соң, миңа инде,—Гадиләне бу сорау тәмам аптырашта калдырды.—Миңа булмый кемгә булсын тагын?

—Ә мин ул йөзекне бүген генә башка кыз кулында күрдем. Ялгышкансыңдыр дияргә ашыкма. Андый йөзекләр дөньяда унау гына, ә бу якларда әбиең йөзеге—бердәнбер. Мин ул йөзекне бик яхшы таныйм. Билгеле, аны син үзең дә бирә аласың, тик йөзекнең мөмкинлекләрен белсәң, алай эшләмәс идең дип уйлыйм.

—Нинди мөмкинлекләрен?—дип сораганын кыз үзе дә сизми калды.

—Мин барын да беләсеңдер дип уйлаган идем. Әбиең сөйләгәндер дип. Ул йөзекнең хуҗасы зур тарту көченә ия була. Кешеләр теләсәләр дә, теләмәсәләр дә аңа тартылалар. Ул теләсә кемне үзенеке итә, буйсындыра ала. Иптәш кызың йөзектән файдалана күрмәсен дим.

—Нинди иптәш кызым?—Гадиләнең башында бер генә уй иде хәзер: ничек итеп тизрәк йөзекне табасы да аның ярдәмендә Зөлфәтне кире кайтарасы.

—Әлфия синең иптәш кызың түгелмени? Мин йөзекне аның кулында күрдем.

«Әлфия» дигән исем Гадиләгә яшен суккандай тәэсир итте. Аптырау, гарьләнү, ачу, күрәлмау—барысы бергә буталды. Аңын томалады. Яңа гына гәпләшеп торган егетнең барлыгын да онытып, ул күзләре белән Әлфияне эзли башлады. Аның бакчаның икенче башында чәчәк түтәлләрендә чүп утап йөрүен күргәч, шунда ашыкты. «Ранил минем йөзекне Әлфиягә биргән! Ә үзләре алып киләбез дип алдадылар», дигән рәнҗүле уйлар бөтерелде кыз башында. «Менә хәзер очрасыннар иде алар, әйтер идем кем икәннәрен!». Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләр бит. Әллә каян гына сулы чиләкләр күтәргән Ранил белән Зөлфәт Гадиләнең каршысына ук диярлек килеп чыктылар.

—Ранил,—диде кыз килә килешкә.—Минем йөзек кая? Алып килдеңме? Әллә Әлфиягә бирдеңме?—Ачуы ташып чыккан Гадилә, малайларның аклануларын көтеп тә тормыйча, юлын дәвам итте.

Әлфия атлап түгел, очып килүче Гадиләне ерактан ук күреп алды. Кулындагы чүп үләннәрен сукмакка ташлап, торып басты. Башындагы яулыгын рәтләде. Ул арада Гадилә аның янына килеп җиткән иде инде.

—Әлфия, минем йөзек синдәме? Ранил аны сиңа бирдеме?

—Әйе. Ләкин мин аны сиңа кайтара алмыйм.

Гадиләнең шаккатудан күзләре тәгәрәп төшә язды.

—Н-и-ичек инде кайтара алмыйсың? Минеке бит ул!—кызның йөзендәге аптырауны бераздан ачулы төшенү алмаштырды:

—Син аның нинди көчкә ия икәнен беләсең, әйеме? Шуңа кирәк ул сиңа! Тик ул—минеке.

Гадиләнең ачулы күз карашына да, ярсый-ярсый сөйләвенә дә Әлфиянең исе китмәде.

—Димәк, Ул синең яныңа да килгән. Нәрсә диде инде ул сиңа? Йөзек тылсымлы көчкә ия, дидеме? Ә ул үзенең убыр икәнен әйттеме соң? Бу йөзекне кигән кешегә иярләшеп, аның ихтыярын, акылын үзенә буйсындырганын?

—Мин сиңа ышанмыйм. Йөзек тарту көченә ия, шуңа син аны үзеңнеке итмәкче.

—Йөзек белән убырдан көчлерәк зат кына идарә итә ала. Көчсезләр үзләре буйсынып, колга әйләнәләр.

—Әкият бу, бар да әкият.

—Әкиятме? Кайтып әниеңнән сорап кара, әкият булса. Рәхәт булды микән аңа убырлы әни белән? Ни өчен бу йөзектән баш тартканын да сора.

—Кем әйтте аны,—дип, Гадилә каршы килгән иде дә, күп еллар элек әбисе белән әнисе арасында булган бер сөйләшүне исенә төшерде.

Гадилә туганнан туганы Илүсә белән качышлы уйный иде. Гадилә аш бүлмәсендәге шкафка кереп качты. Ә Илүсә аны таба алмыйча ишегалдына эзләргә чыгып китте. Гадилә качкан җиреннән чыкмакчы гына иде, бүлмәгә кызып-кызып бәхәсләшүче әбисе белән әнисе килеп керде. Гадиләгә шыпырт кына алар чыгып китүен көтеп утырырга туры килде. Шкафка качып уйнавын белсәләр, эләгәчәк бит. Кыз ирексездән әбисе белән әнисе арасындагы бәхәснең шаһиты булды.

—Алмыйм да, кирәкми дә, әни. Әйтмә дә, үтенмә дә, елама да,—диде әнисе кырыс тавыш белән. Шунда ук әбисенең еламсыраган тавышы ишетелде:

—Кызган инде, кызым. Мин ия табарга тиеш бит аңа. Ул тылсымлы бит.

—Тылсымлы түгел, убырлы ул, әни. Үзең дә бик яхшы беләсең. Үземнең интегүләрем дә бик җиткән, кызымның да газаплануын теләмим. Убырлы әни белән яшәү бик рәхәтме әллә? Чыгарып атачакмын мин аны.

Менә ни өчен әбисе үлем түшәгендә ятканда, «Әниеңә күрсәтмә, мине күмгән көнне киярсең», дип, яшерә-яшерә биргән икән ул йөзекне. Бик аптыраган иде

моңа Гадилә. Әбисен җирләгән көнне әнисе гасабиланып, бөтен җирне актарып эзләгән иде аны. Гадиләдән дә әллә ничә тапкыр, «Әбиең сиңа бирмәдеме?», дип сораган иде. Гадилә, әбисенең сүзен тотып, берни дә әйтмәде. Йөзекне ул шул көнне үк иртән практикага баргач югалтып кайткан иде.

—Мин кисәм, ул миңа хуҗа буламы?—Гадиләдә үз-үзенә ышануның әсәре дә калмаган иде. Ләкин күңелендә кинәт сәер шик тә пәйда булды. Әлфия нигә убырдан көчлерәк соң? Ул үзе дә җен-фәлән түгелме? Зөлфәтне ничек сихерләде әнә.

—Әйе. Убыр синең хуҗаң булсын өчен бу йөзекне бармагыңа киюең җитә,—диде дә, Әлфия йөзекне Гадиләнең учына салды. Болай тиз генә йөзеген кире кайтаруга гаҗәпләнгән кыз:

—Бирәсең? Нигә үзеңдә калдырмадың соң?—дип сорап куйды.

—Йөзекне хуҗасы үз теләге белән бирергә тиеш. Урлап та, табып та аңа хуҗа була алмыйсың.

—Әгәр мин аны сиңа бирсәм...—Әлфия Гадиләгә башлаган җөмләсен әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде:

—Сез мине бүтән авылыгызда күрмәячәксез. Алай гына да түгел, минем кайчандыр монда яшәвемне дә онытачаксыз.

Шунда ук Гадиләнең күз алдына бер ел элек булган чаклар килеп басты. Әлфиясез мәктәп, Әлфиясез авыл... Әгәр ул булмаса... Хәтта аның турында истәлекләр дә булмаса...

Гадилә Әлфиянең кулын үз кулына алды һәм зур яшел ташлы йөзекне кызның имән бармагына кидерде:

—Бирәм. Үз теләгем белән бирәм,—диде ул.

Авыл уянып кына килә. Кояш әле чыкмаган. Аның озак көттермәячәген офыкның кызарганнан-кызара баруы һәм әтәчләрнең берөзлексез кычкыруы хәбәр итә. Автобус тукталышына бишәү атлый—дүрт үсмер һәм бер хатын-кыз.

—Бөтенләйгәмени, Наилә апа?—диде Ранил, озакка сузылган тынлыкны бозып.

—Бөтенләйгә,—дип көрсенде хатын.—Бөтенләйгә шул.

—Кунакка кайткалагыз,—диделәр яшьләр, беравыздан диярлек.

—И, күгәрченкәйләрем, бик тиз онытачаксыз сез безне. Авылыгызда безнең яшәгәнне дә онытачаксыз әле.

—Менә анысын арттырасыз, Наилә апа. Без сезне мәңге онытмаячакбыз.

—Алай димә, Ранил энем. «Мәңге» бик зур төшенчә ул,—диде Наилә апалары. Аннары Әлфиягә карап, тукталышка таба ымлады:

—Көтә.

—Көтми кая барсын. Хәзер ул минеке бит,—диде аңа каршы Әлфия.

Чыннан да, тукталышта берьялгызы басып торучы затлы, коры чибәр егет аларны көтеп торадыр сыман иде. Гадилә аны шунда ук таныса да, иптәшләренә сиздермәде. Егетнең ачулы һәм үпкәле карашын да күрмәмешкә салынды. Зөлфәте янәшәсендә чакта Гадиләгә берни дә кирәкми иде.

Өч юлчыны утыртып кузгалып киткән автобус артыннан яшьләр бик озак, күздән югалганчы карап калдылар. Аннары кояшның беренче нурлары астында балкып яткан авылларына таба юл тоттылар. Көтүгә малларын куып кайтып килүче апаларның: «Каян кайтасыз болай таң тишегеннән?»—дип сорауларына, ни гаҗәп, берсе дә төгәл генә җавап бирә алмады. Чынлап та, кая бардылар соң әле алар?

*Бетте! Йә, ошадымы, әйтеп хат языгыз әле.*
**Алия.**

## Рәйсә Ишморатованың тууына 90 ел

Рәйсә Гыйниятулла кызы Ишморатова (Чебдарова) 1917 елның 20 июлендә Чистай шәһәрендә туа. Жидеелләк мәктәпне тәмамлаганнан соң башта рабфакта, аннары Мәскәү Азык-төлек институты каршындагы курсларда укый. Бөек Ватан сугышы елларында хәрби госпитальдә шәфкать туташы була, ә сугыштан соң дәүләт куркынычсызлыгы органнарында эшли.

1952 елдан бирле Р. Ишморатова әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Иҗат эшчәнлеген ул драматургиядән башлый. «Бай кияү» исемле беренче пьесасы 1952 елда дөнья күрә. Аннары «Директор хатыны (1953), «Омтылыш» (1953), «Куркыныч авыру» (1954), «Фирая» (1956), «Өйрәнелгән гадәт буенча» (1958) кебек бер яки ике пәрдәле пьесалар яза. Әлеге пьесалар Татарстан һәм Башкортстанның һәвәскәр драма түгәрәкләрендә яратып уйнала. 1955 елда студент яшьләр тормышына багышланган дүрт пәрдәле «Тормыш юлында» драмасы язучының иҗаттагы мөмкинлекләрен тагын да ачыграк күрсәтә. Әлеге драма Татарстанның республика күчмә театры сәхнәсендә уңыш белән бара, аннары башкорт, чуаш, мари театрлары репертуарларына кертелә. 1965 елны Минзәлә театрында «Әйтер идем йөрәк серемне» исемле комедиясе куелып, берничә ел уңышлы уйналып килә. 1969 елны республика күчмә театры «Яшьлек канат җәйгәндә» исемле пьесасын сәхнәләштерә.

Р. Ишморатованы укучыларына аеруча таныткан әсәре—«Милиция лейтенанты» (1972) һәм «Язмышлар» (1978) исемле ике кисәктән торган повесте булды. Яшь укучыларга исәпләнгән бу әсәр детектив жанрга карый, ул яшьләр арасындагы җинаятьчелек күренешләренә каршы көрәшне күрсәтүгә багышланган.

Язучының шәхси тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп язылган тагын бер әсәре— «Рәйхана» повесте (1983). Әлеге әсәрдә аның сугыш елларында госпитальдә эшләгәндә күргән һәм кичергәннәре тасвирлана.

Рәисә Ишморатованың барлык әсәрләрендә дә диярлек, төп тема буларак, яшьләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр һәм аларның тормышка карашлары чагылдырыла. Язучы шулай ук хикәя һәм очерк жанрларында да актив иҗат итә.

Рәйсә Ишморатова—1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. Татар әдәбиятындагы хезмәтләре өчен 1987 елны аңа ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде.

Рәйсә ханым драматург Риза Ишморатның хатыны иде. Алар бергә иҗади матур гомер кичерделәр, тормышта да, иҗатта да бер-берсенә таяныч булдылар.

Р. Ишморатова 1997 елны Казан шәһәрендә вафат булды.



Татарстан язучыларының IX съезды президиумы күренеше. Алгы планда, сулдан уңга—Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Мансур Хәсәнов, Алия Кадыйрова, Мирсәй Әмир. 1979 ел.



Язучы Нәби Дәүли
һәм рәссам Лотфулла Фәттахов.
1978 ел.



Үткән гасырның 80 нче елларында «Казан язы» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәләр уза иде. Шул елларның бер хатирәсе. Сулдан уңга—И. Фазлуллин, Г. Садә, Г. Ахунов, Р. Кәрами, Н. Дәүли, Р. Низами, Р. Гаташ. 1986 ел.



*Сулдан: Габдулла Рәхимкулов, Рәшит Гариф һәм Заһид Хәбибуллин. 1973 ел.*



*Кырымда яшәүче фронтовик шагыйрь Фоат Мортазин.*



*Татарстан Язучылар берлеге каршындагы балалар әдәбияты секциясе утырышыннан соң төшерелгән фоторәсем. Беренче рәттә (сулдан уңга)—Гарәфи Хәсәнов, Мөнир Мазунов, Зәкия Туфайлова, Гариф Гобәй, Саимә Ибраһимова, Шамил Рәкыйпов; икенче рәттә—Нур Гайсин, Рафис Сәлимҗанов, Ләбибә Ихсанова, Венера Ихсанова, Шәүкәт Галиев, Марсель Галиев, Хәсән Сарьян, Хәкимҗан Халиков. 1974 ел.*

## ГАРӘП МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Россия Федерациясе тарихында беренче тапкыр Согыд Гарәбстаны Корольлегенең мәдәният көннәре узды.

Мәскәүдә башланган мәдәният көннәре Татарстанда дәвам итте. Шул унайдан республикабызга Согыд Гарәбстаны Корольлегенең мәдәният һәм мәгълүмат министры Айяд Әмин Мәдәни житәкчелегендәге делегация килде. Кунакларны Президент Минтимер Шәймиев кабул итте. Очрашу барышында Татарстан Республикасы белән Согыд Гарәбстаны Корольлеге министрлыклары арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

Согыд Гарәбстаны Корольлегенең мәдәният көннәрен ачу тантанасы «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә башланып китте. Анда ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Согыд Гарәбстаны Корольлегенең мәдәният һәм мәгълүмат министры Айяд Әмин Мәдәни, шулай ук күпсанлы кунаклар катнашты.

Мәккә якларыннан килгән кунаклар Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Милли сәнгать галереясендә, Казан хореография училищесында булды, Теләчедә Сабан туе бәйрәмендә катнаштылар.

## КАЗАНДА ХАЛЫКАРА ИСЛАМ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Казанда «Яшьләр диалогы: Ислам конференциясе оешмасы—Россия» дип аталган халыкара Ислам конференциясе үткәрелде. Ислам конференциясе оешмасына кергән илләрдән килгән яшь мөселман лидерлары өчен бер атналык җәйге лагерь ачылды. Әлеге чара Татарстан Президенты М. Шәймиев химаясендә үтә. Мәгълүм ки, быелның февраль аенда Президентыбыз Ислам мәдәниятенең янарышына зур өлеш керткән өчен король Фейсалның халыкара бүләгенә лаек булган иде. Конференциядә Татарстандагы яшьләр берләшмәсенең әлеге халыкара оешмага керүе турындагы мәсьәлә каралды.

Халыкара конференциягә алтмышлап кеше чакырылган иде. Аларның егермедән артыгы Әзәрбайҗан, Әфганстан, Бангладеш, Мисыр, Иордания, Иран, Казакъстан, Күвәйт, Марокко, Пакыстан, Согыд Гарәбстаны, Тунис, Төркия, АКШ кебек илләрдән килгән вәкилләр.

Яшьләр ислам конференциясе 2004 елда Баку шәһәрендә төзелгән иде. Аның составына Ислам конференциясе оешмасындагы 35 дәүләттән 40 милли һәм халыкара яшьләр оешмасы керә. Форум яшьләр мәнфәгатьләрен яклау, яшьләр арасында әхлак һәм белемне күтәрү, төрле мәдәниятләр һәм цивилизацияләр арасында элемтә урнаштыру белән шөгыльләнә.

## МАТБУГАТ БӘЙРӘМЕ

18 майда Татарстанның гаммәви мәгълүмат, матбугат чаралары хезмәткәрләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен зурлап билгеләп үтте.

Шул көнне иртәнге якта баш мөхәррирләрне, телерадиокомпания генераль директорларын һәм нәшрият директорларын парламент бинасында Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин кабул итте. Ул журналистларны Президент М. Шәймиев исеменнән кайнар котлады һәм аларга иҗади эшләрендә яна уңышлар теләде. «Соңгы елларда барлык тармакларда да Татарстан ирешкән зур уңышларда журналистларның өлеше дә бар»,—диде парламент җитәкчесе.

Ф. Мөхәммәтшин очрашу ахырында кайбер журналистларга Дәүләт Советының Рәхмәт хатларын һәм акчалата бүләкләр тапшырды.

Очрашуда Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, «Татмедиа» агентлыгы генераль директоры М. Моратов катнашты.

Шуннан соң «Идел-Пресс» газета-журналлар нәшрияты янәшәсендәге мәйданда бәйрәм башланды. Биредә һәр газета һәм журнал редакциясе коллективы үз укучылары белән очрашты. Аларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде, шунда ук алдагы яртыеллыкка матбугатка язылу оештырылды. Җыр-музыка, төрле уеннар кичкә кадәр тынып тормады.

Бәйрәмнең йомгаклау өлеше «Идел-Пресс» газета-журналлар нәшриятының конференцияләр залында булды. Биредә «Бәллүр каләм-2007» республика конкурсында җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды.

Жинүчеләрне котларга Премьер-министр Р. Миннеханов килгән иде. Ул «Фиат» автомобиле ачкычын журналистика ветераны, Татарстан журналистлар берлегенең җаваплы сәркатибе Ю. Ханжинга тапшырды.

### ПУШКИННЫ ОЛЫЛАУ

Республикабызда Пушкин көннәрен үткәрү матур традициягә әйләнде. Быел да әдәбият сөючеләрне бөек шагыйрьнең 208 еллыгы уңаеннан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева котлады.

Әлеге бай мирасны олылау йөзеннән А. Пушкинның туган көнендә шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салынды, һәйкәл янында шигъри митинг үткәрелде. Митингта Р. Харис, И. Ибраһимов, «Наш современник» журналы вәкиле А. Казенцев һ. б. чыгыш ясады.

Июнь ае буена республикабызның төрле шәһәр-районнарында әдәби-музыкаль кичәләрдә, балаларның җәйге ял лагерьларында, китапханәләрдә Пушкин иҗаты турында сөйләшүләр дәвам итте.

### ЯПОНИЯДӘ ТАТАР КӨЙЛӘРЕ

«Сәйдәш» мәдәни үзәгенең иҗат коллективы Япониядә узган гастрольләреннән кайтты.

«Сәйдәш» бию театры артистлары «Япония—Евразия илләре» (элек ул «Япония—СССР» җәмгыяте буларак билгеле иде) җәмгыятенең 50 еллыгына багышланган халыкара фестивальдә катнаштылар.

### НУРИЕВ ФЕСТИВАЛЕ

Рудольф Нуриев исемендәге XX халыкара классик балет фестивале гала-концерт белән тәмамланды. Анда Германия, Бөекбритания, Украина, Мәскәү, Санкт-Петербург театрлары балет артистлары катнашты. Кичәгә «Музыкальное обозрение» газетасы баш мөхәррире Андрей Устинов та килгән иде. Ул газета тарафыннан гамәлгә куелган махсус премиянең 2006 ел лауреатларын игълан итте. Алар—композитор София Гобәйдуллина, Татарстан премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов. Зилә Вәлиева үзенең лауреат исеменә шәхси тырышлыгы белән генә түгел, ә шактый дәрәҗәдә Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең 2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итү турындагы Указын тормышка ашыру нәтиҗәсендә лаек табылганы турында әйтте. «Әлеге Указ безгә Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Натан Рахлин, Николай Фешин һәм башка атаклы шәхесләребезне кылган хезмәтләренә тиң дәрәҗәдә искә алырга, юбилейларын истә калырлык итеп билгеләп үтәргә мөмкинлек бирде,—диде ул.—Алар бит, мәшһүр биючебез Рудольф Нуриев кебек үк, Татарстан мәдәниятен баетып, дөнья мәдәниятенә үзләреннән өлеш кертүчеләр».

Гала-концертны хәләл җефете Сәкинә ханым белән Минтимер Шәймиев тә тамаша кылды.

### ТАТАР ГАИЛӘСЕ БӘЙРӘМЕ

Казанның «УНИКС» спорт һәм тамаша комплексында Халыкара гаилә көне уңаеннан «Татар гаиләсе бәйрәме» булды. Аны «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе, Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Татар гаиләсе» фонды һәм «Таттрансгаз» ачык акционерлар җәмгыяте оештырды.

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең баш мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Пар канатлар» тапшыруының авторы Рәзин Нуруллин әйтеп үткәнчә, әлеге гаилә бәйрәме «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенә быел декабрь аенда—80 ел, «Пар канатлар» тапшыруына 20 ел тулу һәм, әлбәттә, Президент М. Шәймиев тарафыннан игълан ителгән Хәйрия елы уңаеннан оештырылган чараларның берсе иде.

«Татар гаиләсе бәйрәме»ндә катнашучылар Арча районыннан Гыйззәтуллиннар гаиләсе, Буа балалар йортында тәрбияләнүче сәләтле балалар, АКШта узган яшь рәссамнар конкурсында призлы урыннар яулаган Светлана Дмитриева, Балык Бистәсе районыннан 92 яшьлек Маһирә әби һәм аның кызы Раилә апа Яруллиналар гаиләсе, Мамадыш районыннан 80 яшьлек Вахит Галиев (үзенең 9 баласын һәм энесенең улы—танылган җырчы Мингол Галиевне үстергән Вахит ага!), Кайбыч районыннан ятим балалар тәрбияләп үстерүче Галия һәм Мөнир Салаватовлар һәм Саба районыннан 12 бала үстергән Нурия һәм Рәшит Гыйләҗиевләр гаиләсенең гыйбрәтле һәм бәхетле язмышы белән таныштты. Әлеге гаиләләрне Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Татар гаиләсе Фонды» рәисе, язучы Туфан Миннуллин тәбрикләде. Кичәдә Арча үзешчәннәре «Бәби туе» исемле бик тә матур тамаша күрсәтте. Анда танылган җырчылар һәм музыкантлар Мингол Галиев, Рәгъдә Халитова, Лилия Муллагалиева, Бәширә Насыйрова, Резидә Шәрәфиева, Рөстәм Закиров, Рөстәм Асаев, артистлар Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар, «Зөләйхә» вокал төркеме, Илһамия Гыйләҗиева җитәкчелегендәге «Сөембикә» балалар бию ансамбле чыгыш ясады. Кичәне Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар алып барды.

### КОНФУЦИЙ ИНСТИТУТЫ АЧЫЛДЫ

Хәзергә кадәр Россиядә мондый үзәкләр бишәү иде, Казанда ачылганы алтынчысы булды.

Конфуций үзәген ачу өчен Кытай хөкүмәте 50000 доллар акча бүлеп биргән.

Моннан тыш ул институтларны эшләтеп җибәрү өчен укытучылар, дәреслекләр һәм мульти-медиа материаллар белән дә ярдәм итә. Конфуций институты эшчәнлеге кытай теленә өйрәтүдән һәм аның милли мәдәнияте белән таныштырудан гыйбарәт. Бер-ике елдан исә кытайлар әлеге үзәк өчен Казанда аерым бина да төзергә вәгъдә итте.

КДУ каршындагы Конфуций институты рәисе итеп профессор Җәмил Зәйнуллин билгеләнде. Аның сүзләренә караганда, Казан университеты гомер-гомергә Көнчыгышны, шул исәптән Кытайны өйрәнү мәркәзе булып торган.

## ИЛ ЯЗМЫШЫН—ИҢНӘРДӘ

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында мөселман мөгаллимнәренең Беренче Бөтенроссия съезды узуга 90 ел тулу уңаеннан фәнни-гамәли конференция булып үтте. Анда галимнәр Ф. Солтанов, Т. Биктимирова, И. Әмирханов, Р. Ягъфәров һәм башкалар бүгенге көнне һәм киләчәкне үткәнгә карап өйрәнү хакында эшлекле чыгышлар ясады.

«Мөселман мөгаллимнәренең беренче съездына 90 ел дигән бу фәнни-гамәли конференциядә институтның өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Тәэминә Биктимированың «Ил язмышын салып иңнәргә» исемле яңа китабын да тәкъдир итү булды.

## ИЗГЕ БОЛГАРГА СӘФӘР

11 июнь көнне «Болгар» музей-тыюлыгы мәйданында борынгы бабаларыбызның Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүенә 1085 ел тулу уңаеннан Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте идарәсе һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты оештырган зур җыенда гарәп илләреннән, Төркиядән, Әстерхан, Екатеринбург, Оренбург, Пермь, Пенза, Башкортстан, Дагыстан, Мордовия, Самара, Сарытау якларыннан һәм башка төбәкләрдән, Татарстан районнарыннан бик күп вәкилләр җыелган иде.

Анда катнашучыларны Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаев, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте баш мөфтие Тәлгат Таҗетдин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров тәбрикләде. Җыенда күренекле артистларыбыз тарафыннан шигырьләр укылды, мөнәҗәтләр әйтелде. Шулай ук бай сәүдә һәм аш-су рәтләре эшләде.

Җыенда катнашучылар Изге Болгар җирендә корбан ашлары әзерләп, бер-берсен кунак итеште.

## АГЫЙДЕЛНЕҢ МӘШҺҮР УЛЫ

Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында татар әдәбияты классигы, җәмәгать эшлеклесе Мирсәй Әмирнең тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Аны Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов ачты һәм М. Әмирнең тормыш юлы, иҗатының бүгенге көндәге әһәмияте хакында сөйләде.

Аннары ул Татарстан Язучылар берлегенең әдәби премияләре быелдан башлап Мәдәният министрлыгы премияләре буларак бирелә башлаячагын белдереп, сүзне Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиевага бирде. З. Вәлиева шулай ук М. Әмирнең иҗатын балачактан ук белүен, әдипнең «Повесть—киң күңелле жанр» дип әйтүе хәтеренә сеңеп калуын, олы язмышлы бу язучының юмор хисенә бай булуына сокланып яшәвен әйтте һәм быелгы әдәби премияләрнең лауреатларына бүләкләр тапшырды. Мәдәният министрлыгының Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләге быел шагыйрь, танылган журналист Акъегеткә (Рөстәм Фәйзуллин) «Тел күрке—сүз» дигән радиотапшырулар, «Туган тел дәресләре» телетапшырулары һәм «Тукай» китабын төзеп чыгаруы өчен бирелде. Һ. Такташ исемендәге әдәби премиягә шагыйрә Лена Шагыйрьҗан—«Сагынмаклык» китабы һәм Һади Такташка багышланган әсәрләре өчен; Ф. Хөсни исемендәге әдәби премиягә язучы Марат Әмирханов «Мөкәррәмә» һәм «И, кылган догам» әсәрләре өчен; Ж. Вәлиди исемендәге әдәби премияләргә әдәбият белгечләре Азат Әхмәдуллин «Офыклар киңәйгәндә», Фәрит Хатыйпов «Мөлкәтебезне барлаганда» исемле җыентыклары өчен лаек булдылар.

Мирсәй Әмирнең тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәдә әдипне күреп-белеп калган, аның белән якыннан аралашып яшәгән һәм эшләгән язучылар, галимнәр Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Рабит Батулла, Фоат Галимуллин, Фәрит Хатыйпов һ. б. катнашты. Кичә әдип әсәрләреннән алынган аерым өзекләрне уку, театраль күренешләр белән аралашып барды.

## САРА САДЫЙКОВА—МОҢ ЧИШМӘСЕ

29 май көнне Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Сара Садыйкова» дип исемләнгән китап-альбомны тәкъдир итү кичәсе үтте. Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, композитор, җырчы Сара Садыйкованың тууына 100 ел тулуга багышланган бу затлы китап-альбомга төрле елларда язылган, матбугат битләрендә дөнья күргән истәлекләр һәм мәкаләләр тупланган, бай фотоматериал бирелгән.

Кичәдә Сара Садыйкова иҗтимагый фонды рәисе, китапны чыгаруда күп көч куйган, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әзһәр Хөсәенов чыгыш ясады. Ул китапны төзүдә катнашкан Язилә Абдулкадыйровага, мөхәррир Венера Камалиевага, ша-

гыйрь Нияз Акмалга, рәссам Рушан Шәмсетдиновка, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакировка һәм нәшриятның бөтен коллективына рәхмәтен белдерде. Дамир Шакировның сүзләренә караганда, якын киләчәктә сәнгать сөючеләр нәфис сүз остасы Айрат Арсланов һәм җырчы Әлфия Афзалова иҗатларына багышланган шундый китап-альбомнарны кулларына алачаклар.

Кичәдә Сара Садыйкова иҗат иткән җырларны танылган җырчыларыбыз Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Римма Ибраһимова, Клара Хәйретдинова һ. б. башкарды. Шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Роберт Миннуллин, Ренат Харис, Әхмәт Рәшит композитор Сара Садыйкова белән бергәлектә иҗат ителгән җырларның туу тарихын сөйләп үттеләр.

## ӘДИПКӘ БАГЫШЛАНГАН КОНФЕРЕНЦИЯ

Күренекле әдәби тәнкыйтьче, журналист, галим һәм педагог Гази Кашшафның тууына 100 ел тулу уңаеннан республикада төрле чаралар үткәрелде. Ул озак еллар эшләгән Казан дәүләт университетында ел саен үткәрелә торган «Кашшаф укулары» әчтәлеге ягыннан быел аеруча бай булды.

18 майда Татарстан Язучылар берлеге һәм КДУның журналистика һәм социология факультеты «Татар эссеистикасы: кичә, бүген, иртәгә» дигән темага төбәкара фәнни-гамәли конференция үткәрде. Гази Кашшаф—татарда эссе жанрын фәнни өйрәнүгә нигез салган галим, үзе дә чордашы һәм каләмдәше Муса Җәлил иҗатын анализлаганда эссе язу үрнәген күрсәткән публицист. Конференция барышында доклад, чыгышларда әдипнең менә шушы тәҗрибәсе ачык күрсәтелде, соңгы егерме елда татар әдәбиятында һәм журналистикасында эссе жанрының үсү барышына бәя бирелде.

Мәгълүм булганча, Гази Кашшаф озак еллар—сугыш чорында һәм аннан соңрак дәвердә «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналының баш редакторы булып эшләгән әдип. Конференциядә чыгыш ясаучылар Г. Кашшафның әдәби хәрәкәтне оештыру эшендәге хезмәтләре турында ассызыклап әйтеп уздылар.

Конференциядә галимнәр жанрның асыл сыйфатларын язу үзенчәлекләрен ачыклап, эссеистиканың үсеш перспективаларын тәгаенләделәр, язучы, журналистлар исә бу жанрда иҗади эшләү тәҗрибәсе белән уртаклаштылар.

## ТУГАН ҖИРЕНӘ БЕРЕККӘН ӘДИП

Шагыйрь һәм прозаик, Ш. Маннур һәм Ф. Хөсни исемендәге әдәби бүләкләр, Г.Х. Андерсен исемендәге халыкара диплом иясе Рафаил Газизовка 60 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсе әдипнең туган авылы Кече Кирмән авылында һәм Мамадыш районы мәдәният үзәгендә булып узды. Әлеге тантаналарда Татарстанның халык язучысы Т. Миннуллин, Татарстанның халык шагыйре Р. Миннуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе В. Имамов, ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фондының башкаручы директоры Н. Хашимова катнашты. 42 ел мәгариф системасында, шуның 34 елын туган мәктәбендә директор булып эшләгән әдипкә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиеванын котлау хаты һәм «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе тапшырылды.

## ШЕВЧЕНКО ВАТАНЫНДА

26-30 апрельдә Киевта «Халыкларның культура диалогында һәм үзара аңлашып яшәүләрендә мәгариф һәм массакүләм мәгълүмат чараларының роле» темасына багышланган халыкара форум булды. Украинаның дәүләти һәм иҗтимагый оешмалары, «Диалог Евразия» платформасы оештырган бу чарада 20ләп илнең (Россия, АКШ, Төркия, Германия, Көньяк Корея, Мисыр, Һиндстан һ. б.) галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре, әдипләре һәм журналистлары катнашты. Анда сүз, нигездә, илләр, халыклар арасында аңлашуны көчәйтү, бер-береннән әхлакый, мәдәни, инсани байлыкларын үзләштерү хакында барды. Форум эшендә журналыбызның редколлегия әгъзасы, КДУ профессоры Хатыйп Миңнегулов, шулай ук республика журналистларыннан Рәшит Минһаҗ һәм Рәсим Хөснетдинов катнаштылар. Алар, башка кунаклар белән бергә, Киевның тарихи урыннарында, шул исәптән атаклы «Майдан»да булдылар, шәһәрнең мәдәни истәлекләре белән таныштылар.

Украинада татарларның төрле иҗтимагый-мәдәни оешмалары бар. Татарстан вәкилләре бөтен Украина татарларының «Туган тел» җәмгыяте җитәкчеләре белән дә очраштылар. Мәгълүм булганча, Украинада 800 меңнән артык милләттәшебез гомер кичерә.

## ЖУРНАЛЛАР ТАРИХЫН БАРЛАУ

Казан дәүләт университетының диссертацияләр яклау советының 27 апрель утырышында Рәсимә Галиева «XX гасыр башы беренче татар сатирик журналларының («Уклар», «Карчыга» журналлары материаллары буенча) үзенчәлеге» дигән темага (фәнни җитәкчесе филология фәннәре докторы Васил Гарифуллин) кандидатлык диссертациясе яклады.

## «САНДУГАЧЛАР» ҖЫЕНЫ

Киевта «Киев сандугачы» дип исемләнгән IV халыкара төрки-татар фестивале булды. Җыр һәм бию бәйрәмендә Украинаның төрле почмакларыннан, Кырымнан һәм Мәскәүдән сәнгать коллективлары, җырчылар, нәфис сүз осталары, биючеләр катнашты.

Фестивальне оештыручылар—Бөтентатар «Туган тел» мәдәни үзәге, Украина Мәдәният министрлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы. Иганәчеләре—«Татнефть», «Укртатнафта» һ. б. «Киев сандугачы» фестивале кысаларында Р. Ваһапов исемендәге III халыкара жыр фестивале дә булды. Анда Россиянең халык артистлары Наилә Фатехова, Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов, Татарстанның атказанган артисты Роза Хәбибуллина һәм Украина жырчылары чыгыш ясады.

### «ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ—2007» КОНКУРСЫНА НИГЕЗЛӘМӘ

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе, «Казан утлары» журналы һәм «Татарстан яшьләре» газетасы драматургия өлкәсендә чираттагы «Яңа татар пьесасы—2OO7» премиясенә конкурс игълан итә.

Конкурска моңарчы сәхнәдә куелмаган, матбугатта басылмаган һәм «Яңа татар пьесасы» конкурсларында катнашмаган әсәрләр кабул ителә.

Конкурс ябык. Псевдоним белән имзаланган әсәрләр (текстларның компьютерда яки язу машинкасында басылуы шарт) 2 нөсхәдә булырга тиеш. Автор турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, адресы һәм телефоны, кыскача иҗат биографиясе) аерым конвертта тапшырыла.

Конкурс шартлары үтәлмәгән очракларда, ягъни әсәрнең авторы күрсәтелмәсә, яки автор турындагы мәгълүматлар дөреслеккә туры килмәсә, пьеса жюри тарафыннан бәяләнгәннән соң да конкурстан төшереп калдырылырга мөмкин.

Конкурска жибәрелгән пьесалар кире кайтарылмый һәм рецензияләнми, алар Камал театры китапханәсендә саклана.

Пьесалар конкурска 2007 елның 31 декабренә кадәр кабул ителә.

Текстларны почта буенча түбәндәге адреска жибәрүегез сорала: 420021, Казан, Татарстан урамы, 1 нче йорт, Камал театры «Яңа татар пьесасы—2007» конкурсына.

Жиңүче авторлар акчалата премияләр (100 мең сум, 75 мең сум, 50 мең сум) белән бүләкләнә. Моннан тыш, конкурс кысаларында махсус премияләр: Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы премиясе, шулай ук 35 яшькә кадәрге яшь авторлар өчен махсус номинация—күренекле драматург Туфан Миңнуллин премиясе билгеләнә.

Премияләр конкурсның генераль һәм рәсми спонсорлары тарафыннан бирелә.

Конкурс турында өстәмә мәгълүматларны аның координаторы Гөлнур Гыйматовадан **8(843) 293-52-50** телефоны буенча алырга мөмкин.

Конкурс 2 этапта уздырыла:.

1 нче этапта (2008 елның 1 февраленә кадәр) жюри әгъзалары конкурска килгән барлык пьесаларны укыйлар һәм 2 нче этапка узган 10-15 пьесадан торган шорт-бит төзиләр. Бу шорт-бит массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

2 нче этапта жюри жиңүче әсәрләрне билгели.

Конкурста жиңеп чыккан авторларның исемнәре 2008 елның 27 мартында игълан ителәчәк.

«Яңа татар пьесасы—2007» конкурсының жюри рәисе—Миркасыйм Госманов, жюри әгъзалары—Гали Арсланов, Фәрит Бикчәнтәев, Айгөл Габәши, Шамил Закиров, Илфак Ибраһимов Фаил Ибраһимов, Нияз Игъламов, Туфан Миңнуллин, Рамил Фазлыев, Шамил Фәрхетдинов, Илдар Хәйруллин, Исмәгыйль Шәрәфиев. Конкурста жиңеп чыккан пьесалар махсус жыентык булып дөнья күрәчәк, шулай ук, сәхнәләштерү өчен, театрларга тәкъдим ителәчәк.

* * *

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен шагыйрә, тәржемәче, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының беркетмә бүлеге баш киңәшчесе **Тарханова Флера Габдрахман кызына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгатькәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Шушы елның май аенда Чаллыда яшәп иҗат иткән публицист язучы **Хисмәтуллин Фәсих Хәбибулла** (Фаяз Дунай) 71 яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Җәйге күренеш.


*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Әнәс Хәсәнов**.

# Яңа китаплар




**Мөхәммәт Мирза.** Тере су: газәлләр, робагыйлар, гыйбарәләр, шигырьләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 2007.—351 бит. Тиражы—3000 данә.

Мөхәммәт Мирза (Ибраһимов Илфак Мирза улы) соңгы ун-унбиш ел эчендә танылып, хәзер иң актив иҗат итүче шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырьләре чын мәгънәсендәге тирән фәлсәфи эчтәлеккә ия; алар дөньяви гамьле, якты сагышлы. Китап, нигездә, кыска формалы әсәрләрдән тора. Икеюллыклар, өч-дүрт, алты-сигезюллыклар, гыйбрәтле җөмләләр... «Тулган айга карап» дигән бүлектә традицион шәкелле шигырьләр тупланган. «Тере су»—күпмедер дәрәҗәдә сайланма саналырлык, шагыйрьнең чыккан китаплары арасында иң күләмлесе. Китапка кереш сүзне Ркаил Зәйдулла язган.



**Булгакова Дилә.** Давыллар йөгәнләдем: шигырьләр, җырлар, хикәяләр, нәсерләр, парчалар.—Уфа: «Китап» нәшр., 2006.—448 б. Тиражы—2000 данә.

Бу китапта Уфада яшәүче каләмдәшебез Дилә Булгакова, шагыйрә буларак та, чәчмә сүз остасы буларак та, шактый тулы чагылыш тапкан. Беренче бүлеккә шагыйрәнең лирик шигырьләре, популяр җырлары керсә, икенче бүлектә—теләсә нинди шартларда, аяныч тәкъдир кануннары астында да кешелеклелек сыйфатларын җуймаган затларның гыйбрәтле язмышлары тасвирланган әсәрләр тупланган.



Әнәс Хәсәнов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)